www.kazanutlary.ru

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

Баш мөхәррир сүзе: Рөстәм ГАЛИУЛЛИН. Яңа елга – ак ышаныч белән! 3

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рафис КОРБАН. Ватан. *Роман*. 4
Факил САФИН. Мәңгелектән килгән көнем... *Шигырьләр*. 66
Чыңгыз АЙТМАТОВ. Чыңгызханның ак болыты. *«Бер көн – бер гомер» романына нисбәтле повесть. (Мөдәррис ВӘЛИЕВ тәрҗемәсе).* 71
Әхәт ГАФФАР. Без – Ак барс. *Поэма*. 102
Айдар ХӘЛИМ. Кара төннең карасында. *Хикәя*. 109
Булат ИБРАҺИМ. Татар булып гомер итү кирәк... *Шигырьләр*. 123
Җәһәт тәнкыйть: сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. 127
Яңа исемнәр: Гөлнур ӘХМӘДУЛЛИНА-АРХИПОВА. Ташлар телен өйрәнәм мин... *Шигырьләр*. 129

«ХӘЗИНӘ» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Гөлфәгыйзә ЮЛЫШЕВА. Бәхет. *Документаль хикәя*. 133
Зәбир ГЫЙМАЕВ. Зилзиләдән соң. *Хикәя*. 140

ӘДӘБИ ХӘЗИНӘЛӘРЕБЕЗ

Ринат ШИҺАБДИНОВ. Кереш сүз урынына. 150
Һади ТАКТАШ. Скрипкә егълайдыр. *Нәсер*. 151
Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Әсәргә караш. 152
Шигъри хәтер: Фатих КӘРИМ. Илең турында уйла... *Шигырьләр*. 156

«ТАТАРСТАН. ТАРИХ. ШӘХЕСЛӘР» ӘДӘБИ ОЧЕРКЛАР КОНКУРСЫ

Нурислам ХӘСӘНОВ. «Малайка». *Очерк*. 159

ЮБИЛЕЙЛАР

Рифат СВЕРИГИН. Богаулардан арыну *(Әхәт Гаффарга 70 яшь)*. 167
Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА. Заман сулышын тоеп... *(Ким Миңнуллинга 60 яшь)*. 173

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. «Килде-китте кеше түгел без!» 176
Котлыйбыз! Дамир Гыйсметдингә 70 яшь. 178
Безнең календарь. Галиәсгар Камалның тууына 130 ел. 180
Печән базары: Шәфкать ГАНИЕВ. Шаян парчалар. 181
«Бәләкәйләр»: Лилия ГАТАУЛЛИНА. Бәләкәй Лилия. 184
Шаян сәхифә: Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде*. 186
Музейларыбыз: сәхифәне Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН алып бара. 188
«Хәзинә» конкурсы нәтиҗәләре. 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

БАШ МӨХӘРРИР –
Рөстәм Госман улы
ГАЛИУЛЛИН

ИДАРӘ:
Ирада Әюпова
Рабит Батулла
Мөдәррис Вәлиев
Разил Вәлиев
Рәдиф Гаташ
Искәндәр Гыйләҗев
Айрат Зарипов
Дания Заһидуллина
Илфак Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Газинур Морат
Рүзәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Равил Фәйзуллин
Илсур Һадиуллин
Ленар Шәех

Баш мөхәррир урынбасары: **Рамил Ханнанов.**

Җаваплы сәркатип: **Вакыйф Нуриев.**

Бүлек мөхәррирләре: **Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

Мөхәррирләр: **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева.**

Сайт мөхәррире: **Рәзилә Хәйретдинова.**

Исәп-хисап бүлеге: **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер)**.**

Машина йөртүче: **Наил Кадыйров.**

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).
Җаваплы сәркатип һәм проза бүлеге – 222-09-83 (өст. 1613)
Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).
Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).
✆: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.12.2018, график буенча 29.12.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-1. Тираж 4104.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2019 ел

ЯҢА ЕЛГА – АК ЫШАНЫЧ БЕЛӘН!

Без барыбыз да мәңгелек юлның мосафирлары... Чиксез юл буйлап туктаусыз сәфәр кылабыз, барысы да ачык тоелган билгесезлеккә ашыгабыз. Кая килеп чыгарбыз, нинди хәлләргә тарырбыз, мәңгелек сәяхәттә кемнәрне очратырбыз? Шушы озын-озак юлның тар вә киң сукмаклары булган кебек, җавапсыз сорауларның да иге-чиге юк. Иң мөһиме: шушы олы юлда тузан гына булып адашып калмыйча, үзеңнән соң якты исем калдырып китү. Бу исә һәркемнең дә кулыннан килми. Монда үткәннәрдән, тарихтан гыйбрәт алыр дәрәҗәдә хәбәрдарлык та, гореф-гадәтләрне, алдагы буыннарны хөрмәт итү дә, киләчәккә ныклы адымнар белән атларлык гыйлемгә, яңа фикергә ия булу да, үз юлыңнан тайпылмыйча туры барырдай максатчанлык та – барысы да сорала. Тагын да әһәмиятлерәге: яныңда чын мәгънәсендә аркадаш дип аталырга лаеклы юлдашларың булу...

Әнә шундый уйлар белән чираттагы бер еллык әйләнешкә нокта куеп, алдагысына аяк бастык. Һәр яңа башланган ел теләк-максатларга бай инде ул. Нишләтәсең, бу дөньяда адәм баласын өмет яшәтә, өмет алга әйди. Әмма бары тик киләчәгең ачык күзалланганда гына бүгенге көнең тулы була ала. Ә без шулай ерак карап эш итә алабызмы соң?

Мөгаен, киләчәк сүзе – безнең халкыбыз өчен аеруча да кадерле, якын, серле, өмет уята торган сүздер ул. Милләт яшәсенгә, һәрвакыт, һәр гасырда көрәш барган: җир-дәүләт өчен, дин өчен, тел өчен... Һәр татар үзеннән соң ана телендә уйлый-яши торган балалар, оныклар тәрбияләп калдырган һәм милләт бөтенлеге өчен кирәкле шартлар тудырылган очракта гына алдагы язмышыбыз турында ышаныч белән сөйләргә мөмкин. Бүгенге вазгыять исә халкыбыз өчен аеруча зур сынау чоры, димәк, алдагы буын татарлар язмышын без бүген кайгыртырга тиеш. Әлбәттә, глобальләшү шартларында югалтуларыбыз күп, әмма халкыбызның гасырлар дәвамында тупланган генофонды күпмедер дәрәҗәдә киләчәккә өмет уята әле...

«Казан утлары» – милли тормышыбыздагы барометрларның берсе, ул халкыбызның рухи халәтен чагылдыра. Журналның язмышы ничек күзаллана соң? Һич югы, киләсе дистә ел турында сүз йөртә алабызмы? Бу – катлаулы сорау, әлбәттә. Укучылар санын алсак, соңгы дистә елда тираж бертөрле саклана, Россиянең утыздан артык төбәгендә, дистәгә якын илдә журналыбызны яздыралар. Авторларыбыз да, шөкер, әсәрләргә кытлык тудырмый. Әмма, милләт язмышы кебек үк, журналыбызның киләчәге өчен һәрдаим көрәшү мөһим. Бүген безгә һәр талантлы каләмдәшебез, һәр укучыбыз кадерле. Һәр югалту исә шәхси фаҗигагә тиң. Әнә шушы бергәлекне тоеп, аңлап эш иткәндә генә генофондыбызны баетуга өлеш кертә алабыз. Димәк, безгә яңа буын авторларны, укучыларны эзләп табу, аларны үстерү-тәрбияләү, әдәбиятыбызның географиясен саклап калу-киңәйтү кебек олы бурычлар да йөкләнә...

Һәркемгә билгеле: кеше юлда сынала. Алдагы сәфәребездә дә бергә-бергә, иңне-иңгә куеп атлыйк, шатлык-сөенечләребезне уртаклашыйк, кайгы-хәсрәтләрнең урап узуын телик тә... киләчәккә ак ышаныч белән хак мосафир юлын дәвам итик.

Хәерле Яңа еллар сезгә, кадерле укучыларыбыз, хөрмәтле каләмдәшләребез!

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН

Рафис
Корбан

ВАТАН*

РОМАН

Беренче бүлек

1

Муса күзен ачты. Озак ятканмы шушы хәлдә – һич аңлый алмады. Аның гимнастёркасы юеш, саз былчырагы белән капланган иде. Ул торырга дип талпынды, ләкин сул кулбашының сызлавына түзә алмыйча, ыңгырашып куйды. Таң атып килә идеме, әллә кичме – тирә-як караңгы, баш өстендә, ара-тирә үскән усак ботаклары арасыннан, кургаш болытларга салынган зәңгәр ямаулык сыман күк йөзе ачылып-ачылып китә. Тагын да талпынып, уң кулына таянып торып утырды. Күзләрен ачканчы кулбашы авыртуын тоймаган иде, хәзер аның сулкылдап-сулкылдап сызлавына чыдарлык түгел. Яңадан җиргә сузылып ятты. Шул хәлдә авыртуы бераз басылган кебек булды. Муса үз алдында гөрселдәп бомба шартлаганын, көчле дулкын аны шушы сазлык эченә атып бәргәнен исенә төшерде. Бу баткаклыкта күпме ятуын хәтерли алмады. Тирә-юнь тып-тын. Бары тик, колакны тондырып, йөзләгән, йөзләгән генә дә түгел, меңләгән озынборын безелдәве тудырган нәзек гүләү тавышы гына ишетелә. Озынборыннар битен сырып алган икән: исән кулының учы белән битен сыпырды. Хәшәрәтләр күпме канын эчкәннәрдер – аның уч төбе озынборыннар сытылудан кып-кызыл канга батты. Муса битенең шешенеп чыгуын сизде. Шунда үзенең куен дәфтәрен исенә төшерде, кабаланып гимнастёркасының эчке кесәсен капшады. Дәфтәр урынында иде. Дәфтәрдә аның «Отвага»да эшли башлагач язган унлап шигыре бар. Аларның берничәсен генә Казанга, Гази дустына җибәрергә өлгереп калды. Кызганыч, соңгы шигырьләрем үзем белән бергә үләрләр микәнни, дигән уй күңелен телеп узды.

Әллә нинди сәер тынлык урнашты. Кошлар да сайрамый. Бакалар бакылдаганы да ишетелми. Ашыйсы килгәнне тойды. Ашыйсы килүе үзен сиздерүгә, бала чагын хәтергә төшерде. Менә ул әле дүрт-биш яшьләрендәге малай. Иртән әнисенең нәрсәдер эшләгән тавышына уянып киткән, имеш.

* Журнал варианты

Рафис КОРБАН (1957) – *шагыйрь; «Алмалы төн», «Бәхет телим», «Яра» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

Ә әнисе мич алдында куәс чиләгеннән камыр алып ипи әвәли. Ул аны киң агач көрәккә салып, инде уты сүнгән, күмерләре чит-читкә җыеп куелган мич эченә этәрә дә, көл өстендә калдырып, икенче ипине әвәләргә тотына. Кайнар мичтән өй эченә рәхәт җылылык бөркелә. Шул арада әнисе тәмле кабартмалар да пешереп куйган икән. Улының уянуын күреп, каз каурыеннан ясаган пумала белән, эреткән туң май сылап, аңа дип шул тәмле кабартмаларны табынга куя. Туган авылыннан чыгып киткәннән соң, беркайчан да ашаганы юк Мусаның мондый тәмле кабартмаларны! Аларны искә төшерү аның ашыйсы килү теләген тагын да көчәйтеп җибәрде. Ул янында гына үскән үлән сабакларын өзеп авызына капты. Ләкин чәйнәргә дә өлгермәде, кайдадыр, якында гына автомат теркелдәгән тавыш ишетелде. Тынлык дигәне дә алдавыч тынлык кына булган икән. Автомат артыннан ук кеше тавышлары да ишетелде. Тавышлар аңа таба якыная иде. Муса, ашыйсы килүен дә, яралы икәнен дә онытып, янә сикереп торырга омтылды, ләкин ярасы шунда ук үзен сиздерде. Авыртуга түзә алмыйча, ыңгырашып алды. Тавышын килүчеләр дә ишетте. Берсе чит телдә: «Verwundeter Russe!»[1] дип кычкырды. Бу кичәге һөҗүмнән соң сазлыктагы рус яралыларын эзләп йөрүче немец солдатлары төркеме иде. Алар яралының хәле бик начар булса, аягына торып баса алмаса, урынында атып китәләр, баса алганнарны, торгызып, машинага төйиләр иде. Муса, һич югы бер-ике фашистны атып үтерергә иде, дип, пистолетын эзли башлады. Яраланып егылганчы ул аның кулында иде. Аннан соң кая киткәндер, кулында да, кобурасында да, тирә-ягында да күренми. Ул арада янына өч немец солдаты килеп басты. Иңбашы канга баткан яралы рус солдатының ыңгырашканын ишетеп, алар аның тере икәнен аңлаганнар иде. Солдатларның берсе, нәрсәдер әйтеп, итек үкчәсе белән аның канга баткан яралы иңбашына төртеп алды. Каты төртмәсә дә, ярасы ачылып, кан саркый башлады; авыртудан, ул тагын авыр итеп ыңгырашты, ләкин күзләрен ачмады. «Атып кына китсәләр ярар иде», – дигән уй зиһенен яндырып узды. Ләкин немецның аны атып үтерү уенда юк иде бугай, ул үз теләндә: «Steh auf!»[2] – дип кычкырды да бу юлы бар көченә исән кулбашына китереп типте. Муса, авыртуга түзә алмыйча: «Хайван!» – дип куйды. Немец, торырга кушып, тагын нидер акырды, автомат түтәсе белән төрткәли үк башлады. Муса сыкрана-сыкрана торып басты. Икенче солдат, автомат көпшәсен аркасына терәп, аңа алга барырга ымлады. Муса, бер-ике адым атлауга, агач ботагына сөрлекте, йөзтүбән җиргә капланды. Немец бу юлы да атарга уйламады. Тагын торырга кушып акырынды.

Ике немец солдаты Мусаны ике җиңеннән тотып җилтерәтеп торгыздылар да, өстерәп диярлек, каядыр алып киттеләр. Бераз баргач, аны ычкындырып, үзенә атларга боердылар. Муса, кулбашының авыртуын җиңеп, саз ера-ера, немец артыннан атлады. Озак та үтмәде, үзе шикелле үк саз былчырагына баткан бер төркем совет солдатлары янына китереп куштылар. Муса, алар арасыннан берәр таныш йөз күренмәсме, дип, күпме генә каранса да, беркемне дә танымады. Аның белән бер машинада, чолганыштан чыгучы редакция хезмәткәрләренең берсе дә бу төркемдә юк иде. «Үлеп беттеләр микәнни?» – дип уйлады ул. Сазга кереп баткан машиналарын чыгару өчен, әрҗәдән төшеп, арттан этә генә башлаган мәлләрендә әллә каян гына снаряд килеп төште дә, шартлау дулкыны аларның барысын да төрле якка чәчеп таратты. Башкалар кая китте икән соң? Ул яткан җирдә дә юк иделәр. Монда да күренмиләр.

[1] Яралы урыс *(нем.)*
[2] Торып бас! *(нем.)*

Берничә көн элек кенә немецлар фронт өчен кирәк-яраклар ташый торган самолётлар өчен аэродром итеп файдаланылган кырны басып алдылар. Армиядә тәртипсезлек башланган иде. Муса шул көнне, командирларга буйсынмыйча, ничек тә безнең якка чыгып калырга тырышып, үлгән солдатларның кесәләрен актарып, мародёрлык итеп йөрүче берничә солдатны штаб алдына тезеп атканнарын карап торды. Гомерләре болай да кыл өстендә торганда, фашистларга каршы көрәшәсе урында, шундый вәхшилек юлына баскан ул мәхлук җаннар, бер караганда, кызганыч та иде. Җаннарын саклап калу өчен шул эшкә барганнардыр инде, мескеннәр. Ә икенче караганда, бәхетлеләр – коллык богавын кимиләр, әсирлек газабыннан котылдылар. Аларны да менә хәзер кулларын күтәртеп, лагерьга алып китәрләр иде. Туган илгә «сатлыкҗан» дигән исемнәре кайтыр иде, өсләренә «халык дошманы» дигән кара тамга салыныр иде. Ә болай... Штабта әле аларның атып үтерелүләре хакында хәбәр итәргә дә өлгермәгәннәрдер, мөгаен.

Бераздан, әсирләрне бер рәткә тезеп бастырдылар да, төптән юан чыккан бер немец офицеры саф буенча йөреп, тазаракларын, яраланмаганнарын аерып, алга чыгарып бастыра башлады. Ул һәр солдат каршына туктап, утлы күз карашы белән сөзеп, үзенә ошаганнарын сайлап, алга чыгарга кушты. Унлап әсирне аерып алгач, автоматчылар аларны каядыр барырга эткәли башлады. Ул арада, шул тирәдә торган автомашина янына җиткәч, әрҗәдән алып, кулларына көрәкләр тоттырдылар. Муса, «Нишләргә җыеналар икән?» дип уйларга да өлгергәнче, көрәкле егетләрдән җир казырга тотындылар.

– Кабер казыталар, – дип куйды Муса белән янәшә басып торган яралы солдат. – Безне тереләй күмәргәме әллә исәпләре?

– Юктыр, – диде Муса. – Монда килгәндә күрмәдеңмени, бер өем мәет ята иде. Бер якта – үзләренекеләр. Икенче якта – безнекеләр.

– Бер кабергә күммәкче булалар микәнни?

– Үзләренекеләрне туган җирләренә озаталардыр. Әнә бит, табутлар да китереп тутырганнар...

Чынлап та, янәшәдә генә табутлар белән тулы ике машина тора иде. Озынлыгы – биш, тирәнлеге ярты метр чамасы чокыр казылгач, туктарга дигән әмер булды. Чокыр төбенә саркып су җыела башлаган иде. Әсирләрнең барысын да, Муса кебек яралыларны да үлекләр өеме янына китереп, аларны берәм-берәм чокыр янына ташытты. Тазарак егетләр бер мәетне, яралылары, аягыннан-кулыннан күтәреп, икесенә бер мәетне алып килүгә, аларны шунда ук чокырга ташларга боердылар. Шулвакыт ике яралы солдат күтәргән егет ыңгырашып куйды. Егетләр, ни эшләргә белмичә аптырап, яралы егетне ипләп кенә җиргә салдылар. Моны күреп торган автоматлы сакчыларның берсе алар янына йөгереп килеп җитте.

– Ул тере! – диде мәет ташучыларның берсе. – Аны лазаретка илтергә кирәк.

– Русиш капут! – дип кычкырды фриц һәм, автоматын иңеннән алып, яралы егеткә атып җибәрде.

– Фашист, – дип куйды Муса, тешләрен кысып.

Аның шул сүзен ишеткән сакчы, арттан килеп, автомат түтәсе белән Мусаның яралы кулбашына китереп бәрде. Муса йөзе белән былчырак өстенә капланды. Сакчы, автоматын саклагычыннан ычкындырып, йөзтүбән яткан Мусага төбәде. Моны күреп торган юан командир «Хальт!» дип кычкырды һәм сакчының автомат көпшәсенә ябышып, аны өскә таба борды. Әсирләр барысы да авыр сулап куйды. Сакчының автоматка ябышуын күргәч, «Хәзер

ата, хәзер барысы да бетә, котылам бу мәхшәрдән», – дип уйлап, күзләрен йомып, башын кулы белән каплаган Муса, кайчан ата инде, дигәндәй өнсез торды. Ләкин ату тавышы яңгырамады. Бары тик юан немец:

– Aufstehen![3] – дип кенә кычкырды.

Муса бу юлы да исән калды. Нишлисең, тәкъдире шундыйдыр. Аңа әсирлек михнәтләрен татырга, «Муса илен саткан!» дигән нахак яла сүзләрен ишетергә язгандыр, күрәсең. Иң хәтәре – аның «сатлыкҗан» дигән яманаты туган илгә әйләнеп кайтачак. «Сатлыкҗан хатыны», «сатлыкҗан баласы» дигән нахак сүзләрне хатыны Әминәгә, сөекле кызы Чулпанга да күтәрергә туры киләчәк. Алар гына булса әле?! Беренче мәхәббәте Рауза белән улы Альберт, икенчесе Зәкия белән кызы Люция дә, бер гөнаһсыз килеш, гомерләре буе шул нахак яла сүзләрен ишетеп яшәргә мәҗбүр булачак. Яшьлегендә күп булды шул ялгыш адымнары. Хәзер менә бер гаепсез кешеләрне – сөекле кешеләрен авыр тәкъдир чүкече астында калдыра. Ичмасам пистолеты да каядыр юкка чыккан. Үз-үзен атып үтерер иде дә, «хәбәрсез югалган» дигән аты гына кайтыр иде туган илгә.

Үлгән көрәштәшләрен юеш саз куенына салгач, Мусаның кәефе тагын да ныграк бозылды, маңгаендагы кан тамырлары шартлардай булып киерелде һәм сулкылдап-сулкылдап сызларга тотынды. Аның миен әнә шундый авыр уйлар игәүләде.

Мәетләрне җирләгәч, аларны бер колоннага тезеп, каядыр алып киттеләр. Аяк асты сазлык, һәр адымны ясар өчен, итекләрен былчырактан көч-хәл белән сөйрәп алырга туры килә. Ә бу болай да ничә көн инде юньле ризык күрмәгән әсирләрнең хәлен тәмам бетерде. Кайберәүләр аяктан егыла башлады. Немецлар андыйлар белән артык мәшәкатьләнеп азапланмады, автомат түтәсе белән артларына китереп тондырды да, аягына торып баса алмаганнарны ауган җирләрендә мәңгелеккә калдырып, колоннаны алга таба куалады.

Икенче көнне инде Волхов сазлыклары артта иде. Сугыш башланганнан бирле сөрелмәгән, сарут, әрем, шайтан таягы баскан, элек иген кыры булган басулар, сирәк агачлы урман, елга тугайлары буйлап бара торгач, ниндидер тимер юл станцасына килеп җиттеләр. Бу Ленинград өлкәсенә караган Чусская дигән урын булып чыкты. Аларны шушы станцадан ерак та түгел элекке бер колхозның терлек абзары булган, хәзер бараклар итеп үзгәртелгән, берничә бинадан торган лагерьга китергәннәр икән. Лагерьга килеп җиткәндә, әсирләрнең сафы шактый сирәкләнгән иде. Мусаның хәле тагын да начарланды. Аяклары шешеп чыкты. Итекләрен беренче көнне үк чучка шикелле симез бер фриц салдырып алып калган иде. Лагерьга килгәч, аңа һәм аның шикелле үк итексез берничә тоткынга агач шакмакларга киндер ыштыр кадаклап ясалган сандалилар бирделәр. Мусаның кулбашындагы яра тагын да тирәнәйде. Снаряд кыйпылчыгы умырып алган җәрәхәт шактый ялкынсынып, кып-кызыл иткә әверелгән, әледән-әле сакчы-конвойчыларның автомат түтәсе белән суккалаулары нәтиҗәсендә, бер дә төзәлергә уйламый иде. Лагерьда медпункт бар, диделәр. Станцага китерелгәч, бер немец Мусаны шунда алып китте. Медпункт дигәнең ат абзарының бәләкәйрәк бер араны булып чыкты. Яралыларны әсирләр арасыннан табылган ике ветеринар дәвалый икән. Аларның мөмкин кадәр шәфкатьле булырга тырышулары күренеп тора иде. Мусаның ярасын ачып карауга, җылымса су белән тиз генә юып алдылар. Ниндидер сыекча сөртеп, эренли башлаган җәрәхәтен тузаннан чистарттылар. Аннары ат духтырлары җәрәхәтләнгән колхоз сыерларына сөртә торган сары

[3] Тор *(нем.)*

төстәге, сасы һәм ачысы күздән яшьләр китергән мазь белән сылап, әйбәтләп тарттырып бәйләделәр. Табиблар Мусаның хәлен башкалар белән бергә яшәргә яраклы дип таптылар һәм, көн саен килеп, ярасын бәйләтергә кушып, лагерьның әсирләр урнашкан бүлегенә озаттылар.

Мусага урынны беренче баракның иң аргы башыннан билгеләделәр. Ике катлы сәндерәнең икенче каты эләкте. Озатып килгән конвойчы аңа өскә үрмәләргә ымлап һәм урысчалап:

– Урының шунда булыр! – диде. Озынча, ябык чырайлы бу бәндәне ул фрицтыр дип уйлаган иде. Баксаң, фашистларга хезмәткә ялланган урыс солдаты булып чыкты.

Үз ишләре янына барып урнашуга, аның ятагы алдына кулына амбар кенәгәсе тоткан бер немец офицеры килеп басты һәм фамилиясен сорады. Муса чак кына «Җәлилов» дип ычкындырмады. Әсирлеккә төшкәннән соң, ул менә ничә көн инде, юл буе фашистларга үзенең чын исемен белгертергәме, юкмы дип уйлап килде. «Муса илен саткан!» дигән нахак яла туган Ватанына кайтачак, аның саф намусына, данлы исеменә, гаиләсенә, хатыннарына, балаларына кара корым булып ягылачак дигән уй туктаусыз бимазалады. Ул кесәсендәге бөтен документларын сазлык баткагына ташлап калдырды. Гимнастёркасындагы политрук икәнен белгертә торган петлицасын өзеп, урынын саз пычрагы белән сылап куйды. Ә фамилиясен үзе өчен бөтенләй чит-ят исем белән, Гомәров дип яздырырга булды. Бу лагерьда аны танып белгән бер генә кеше дә юк иде. Димәк, берсе дә аңа чын исем-фамилиясе белән эндәшмәячәк дигән сүз. Ә Гомәров аның атасы да түгел, бабасы да түгел. Мәктәптә аларны Гомәров фамилияле бер укытучы укыткан иде. Карт большевик, авылның абруйлы кешесе, олысы-кечесе хөрмәт итә торган укытучы иде ул. Фашистларга үзенең чын исемен күрсәтмәү, бер караганда, куркаклык та, мескенлек тә. Ләкин, икенче караганда, Муса яраткан укытучысының фамилиясен алып, үзен бу карт большевикның ил алдында, Ватан алдындагы данлы хезмәтен дәвам иттерүче булырмын, дип уйлады. Аның исеме белән, фашистларның үз өнендә дә аларга каршы яшерен көрәш алып барырга мөмкин дигән фикергә килде. Фронт газетасы корреспонденты булып йөргәндә, фашист самолёты ташлап киткән листовкаларны укыган вакытта ук, Мусаның башына андый уйның килгәне бар иде инде. Чөнки соңгы айларда Волхов фронтында хәлләрнең катлаулана баруын, немецларның аларны әсир итеп алу ихтималының зурлыгын ул яхшы аңлады, шул хакта күп уйланды. Бары бер нәрсә аны тынычландыра иде: әгәр әсирлеккә төшү куркынычы туса – пистолетын үз чигәсенә төбәү. Ләкин тәкъдир аның өчен башка язмыш язып куйган булып чыкты.

2

Соңгы айларда Волхов фронтында хәлләр чынлап та аяныч иде. Иң хәтәре – фашистларның Ленинградка бару юлын кисү максатында оештырылган әлеге фронтны тотып торган Икенче удар армиягә бернинди дә хәрби ярдәм күрсәтелми диярлек. Җәй айларында сугыш хәрәкәтләре алып баруы гаять кыенлашкан бу сазлыклы җирләрдә техника ярдәменә бернинди дә ышаныч булуы мөмкин түгел. Авыр танклар, автомашиналар, суга төшкән таш шикелле, саз төбенә китә, пушкаларны күчереп йөртүе шулай ук җайсыз. Артиллерия тупларын тартырга тиешле атларның, сугышчыларның күз алдында саз төбенә суырылуы тетрәндергеч күренеш иде. Ярдәм бары тик һавадан, самолётлар белән генә күрсәтелә. Алар ташлап киткән коралларның да күбесе сазлык

төбенә юл ала, азык-төлек тә сугышчыларга барып җитә алмый. Самолётлар исә яхшы ныгытмаларга ия булып алган фашист зенитчылары тарафыннан атып төшерелә. Менә шундый шартларда сугыш алып бару бернинди уңай нәтиҗә дә бирмәде. Киресенчә, армиянең һәлакәтен көннән-көн тизләтеп, ахыргы сәгатьләрен якынайта иде.

Көннәрнең берендә Мусалар лагере тоткыннарына Волхов фронтында сугышучы Икенче удар армиянең башлыгы генерал Власовның бөтен гаскәре белән фашистлар ягына чыгуы турында листовка тараттылар. Листовкада Власовның Рус Азатлык Армиясен төзүе, шул армиядә хезмәт итәргә чакыру сүзләре язылган иде.

Советлар Союзының данлыклы генералы Андрей Власовның дошман ягына чыгуы хак булса, бу Муса өчен акылга сыймаслык көтелмәгән бер нәрсә иде. Муса өчен генә түгел, гади солдатлар, бигрәк тә әсирлеккә эләгүчеләр моны үзләрен төрле уйларга этәрә торган вакыйга буларак кабул итте. Листовкадагы «Әсирлеккә төшкән рус солдатларын Россиядә халык дошманы дип атыйлар. Аларны, азат ителсәләр дә, илләрендә зиндан көтә!» дигән сүзләр куркуга да төшерә иде.

Андрей Власов, сугыш башланганда, иң шөһрәтле хәрби начальникларның берсе булып саналды. Сугыш алдыннан Львов астындагы дүртенче механикалаштырылган корпусны җитәкләгән генерал Киевны саклаучы 37 нче армия командующие итеп билгеләнә. Ләкин немецларның көтелмәгән һәм көчле һөҗүме нәтиҗәсендә Киевны калдырырга туры килә. Сталинның Киевтан китәргә дигән карары чыкканда, Власов армиясе инде камалышта калган була. Нәтиҗәдә, ярты миллионлап солдат һәлак була. Әмма Власов, армиясен калдырып, үзенең сөяркәсе белән качып котыла. Үзенә үзе атып, ул сугышта яраланuы турында әкият уйлап чыгара. Нәтиҗәдә, госпитальгә эләгә. Бу көннәрдә Мәскәү астында көчле сугышлар бара. Сталин госпитальдә дәваланучы генералны Мәскәүне саклаучы частьларның башлыгы итеп билгели. Власов госпитальдән торып кына төрле боерыклар бирә. Ул арада дошман Мәскәү астыннан йөзләрчә чакрымга алып ташлана һәм бу уңышларны Власовның зирәк командалык итүе белән бәйлиләр. Хәтта Власов турында «Сталин полководецы» дигән китап та язып чыгаралар. Ул Георгий Жуков белән бер дәрәҗәдәге полководец итеп күрсәтелә.

Волхов фронты сазлыкларында котылгысыз һәлакәткә якынаючы Икенче удар армиянең башкомандующие итеп егерменче апрельдә генерал Власовның билгеләнүен Муса һәм ул эшләгән «Отвага» газетасы редакциясе хезмәткәрләре батып баручы кырмысканы үлемнән коткару өчен сузылган салам шикелле кабул иткәннәр иде. Ләкин гаять авыр шартларда сугышучы армияне Власов ничек кенә коткара алыр да ничек кенә алар камалыштан чыгарлар – бу могҗизага беркем дә ышанмый да, өметләнми дә иде. Дөрес, листовкадагы хәбәргә дә Мусаның бигүк ышанасы килмәде. Ничек инде армия хәтле армия белән җитәкчелек итүче генерал хыянәтче булсын?! Ләкин утсыз төтен чыкмаган шикелле, күңелдә кайбер шикләр дә уянды.

Кич җитеп, йокларга команда бирелгәч, күрше сәндерәдә ятучы егет Мусадан, татарчалап:

– Ышанасыңмы бу әкияткә? – дип сорады.

Муса аның татарча дәшүеннән бераз сискәнеп куйды. Үзебезнең татар егете булса да, әле танышырга да өлгермәгән бу әсир алдында ачылып китмәүне хуп күрде:

– Кем белгән инде аны... Минем татар икәнемне каян белдең? – дип сорауга сорау белән җавап кайтарды.

– Фельдфебельгә фамилияңне Гомәров дидең бит. Муса Гомәров...

– Ә-ә-ә... Ишетеп калдыңмыни?.. Үзең кай яклардан?

– Казаннан.

– Исемең?

Ләкин күршесе тиз генә җавап бирергә ашыкмады. Ул Мусага беркавым сынап карап торды. Аннан соң:

– Бернинди дә Гомәров түгел бит син, – дип, Мусаны гажәпкә калдырды.

Муса, ишетмәделәрме икән дигәндәй, шик белән, як-ягына каранып алды да:

– Каян беләсең? – дип сорады. – Бик шаулама... – дип, шунда ук үзен сатты.

– Мин дә бит Мясной Бордан эләктем монда. Синнән өч көн генә элек. Муса Җәлил бит син. «Отвага» хәбәрчесе. Күптән түгел генә безнең частька килеп, бер егетебез турында очерк язам, дип, аның белән очрашып киткән идең. Язгансыңдырмы, «Отвага»ның соңгы санын укырга өлгермәдем. Габидуллин фамилияле очучы...

– Яздым. Тик гәзиттә чыгарырга өлгермәдем. Чолганыштан чыкканда, редакция машинасы әрҗәсендә калды язмам. Снаряд төшеп, безне яралады. Мин аңыма килгәндә, янымда беркем дә юк иде.

– Синең кем икәнеңне белсәләр, шундук атып үтерәчәкләр бит.

– Шуңа күрә исемемне яшердем бит инде.

– Төрле кеше бар. Дөнья түгәрәк бит ул. Мин дәшмәсәм, башкалар танып сатарга мөмкин. Сине монда китергән конвоирның урыс икәнен күрдең бит.

– Сатсалар саталар инде. Атып үтерсәләр, илгә сатлыкҗан дигән яманат кайтмас.

– Анысы хак. Тик син минем сорауга җавап бирмәдең.

– Утсыз төтен булмый, диләр бит. Үзе сатылмаса да, чолганыштан чыкканда эләктергән булулары мөмкин. Хәзер менә аның исеме белән сату итәләр. Кырыгынчы елда СССРга көчләп кушылган Көнбатыш Украина, Латвия, Литва, Эстония халыклары арасында күп булырга мөмкин андый армиягә язылырга теләүчеләр.

– Монда татарлардан Кызыл Армиягә каршы сугышырга легион төзиләр икән дигән сүзләр дә йөри, дөрес булса.

– Аны бит инде Мясной Борда чакта ук листовка итеп өскә самолёттан ташлаганнар иде.

– Шулай бугай шул. Мин ул хакта күп уйладым.

Муса тагын як-ягына каранып алды:

– Тс-с. Шаулама. Нәрсә, язылыргамы әллә исәбең?

– Язылырга да, сугышка кергәч, безнекеләр ягына чыгарга.

– Ансат кына уйлыйсың түгелме? Безнекеләр ышаныр дисеңме? Шундук атып үтерәчәкләр.

– Үтерсәләр, барыбер үлем бит инде безгә.

– Алай димә әле син. Мин дә күп уйлыйм ул турыда. Карале, син дә бит үз исемеңне әйтмәдең.

– Салих исемле мин. Ганиев Салих. Казаннан. Курыкма, ышанычлы кешемен. Укытучы идем.

– Бик әйбәт. Менә нәрсә уйлыйм мин бу хакта: легионга язылырга һәм шул легион эчендә яшерен эш алып барырга. Легионерларны сугышка керер алдыннан, бөтен командирларны юк итеп, батальон белән Кызыл Армия ягына чыгарга үгетләргә.

– Шәп идея бу! Ләкин куркыныч.

– Шәп. Бүредән курыккан урманга йөрмәс, дигәннәр. Тик ятарга инде алай булгач үлем көтеп. Йә, безнең гаскәрләр кайчан килеп коткарырлар икән, дип. Коткарсалар да, яшәргә бирерләрме? Сатлыкҗаннар, дип атып үтермәсләрме?

– Карале, Муса дус, син агитацияңне башладың да бит инде. Әйбәт агитатор чыгар иде синнән. Яшерен оешмаңның ышанычлы бер сугышчысы бар, дип исәпли аласың. Мин риза!

– Бик шәп! Ярар, бүгенгә җитәр. Алда тагын күз күрер. Иртәгесе көн бүгенгедән хәерлерәк, дигәннәр борынгылар. Йоклыйк. Бу сөйләшү ике арада гына калсын.

– Юк, Муса, калмасын. Башкаларны да агитларга кирәк. Лагерьда ышанычлы егетләр җитәрлек. Йә, ярар алайса, йоклыйк...

3

Волхов фронты 1941 елның декабрендә оештырылды. Киев чолганышыннан чыкканда, үз кулына үзе атып яраланган генерал Власов ул чакта госпитальдә яткан килеш кенә, дошманны Мәскәүгә җибәрмәс өчен, канкойгыч сугышлар алып барган егерменче армия башкомандующие итеп билгеләнгән иде. Волоколам юнәлешендә сугышучы 316 нчы укчы дивизия егетләре инде Мәскәүне алдык дип бәйрәм итүче немец башкисәрләрен башкаладан йөзләгән чакрымга алып ташлаганнан соң, Андрей Власовның абруе тагын да үсеп китте. 28 гыйнварда Мәскәүне саклауда күрсәткән батырлыклары өчен бүләкләнүчеләр арасында аның да фамилиясе бар иде. Мактаулы командармга генерал-лейтенант дәрәҗәсе бирелде. Үзе Волхов фронтында авыр шартларда сугыш алып баручы Икенче удар армиянең башкомандующие итеп, бер үк вакытта фронт башлыгы генерал Кирилл Афанасьевич Мерецковның урынбасары буларак билгеләнде.

Яз җитте. Карлар-бозлар эрегәч, сазлык җирдә сугыш алып бару тагын да кыенлашты. Сталин Мерецковны Мәскәүгә чакыртып алды. Сугышның икенче көнендә НКВД тарафыннан кулга алынып, Берия палачларының һәртөрле мыскыллауларына дучар ителгән, 1940 елдан ук Советлар Союзы Герое исемен йөрткән армия генералы яңадан Ставка башлыгы каршында җавап тотарга тиеш иде. Кирилл Афанасьевич декабрь ахырында гына Сталиннан хат алган иде. Ул анда Волхов фронты алдында торган бурычның әһәмияте һәм мөһимлеге турында язган, дошманга каршы сугышны вак бәрелешләр белән генә түгел, бөтен фронт буенча алып барырга кирәк дигән күрсәтмә биргән иде. Берия тырнагыннан да Мерецковны Сталин коткарып калды дигән сүзләр йөргәнлектән, Кирилл Афанасьевич Ставка башлыгына хөрмәт һәм беркадәр курку белән дә карый иде.

Ставка утырышына алар Георгий Константинович Жуков белән бергә, турыдан-туры юлдан, итекләре дә саз былчырагыннан арынмаган килеш, соңга калып килеп керделәр. Верховный кабинеты ишеге төбендә утыручы секретарь соңлаган өчен шелтәләп алды да, алар үзләрен тәртипкә китергәнне дә көтмичә, кабинетка керергә куштты. Кабинетта Үзәк Комитет Политбюросы утырышы бара иде. Политбюро әгъзалары тулы составта. Кирилл Афанасьевич соңга калулары өчен гафу үтенде дә:

– Гафу итегез, Иосиф Виссарионович, бер минутка гына киредән чыгып, үземне тәртипкә китереп керергә рөхсәт бирсәгез иде? – диде.

– Үзегез гафу итегез, Кирилл Афанасьевич, шулай ашыгыч чакыртырга туры килде. Сугышын сугыш, ләкин генерал ялтырап торырга тиеш! – диде Сталин.

Рәислек итүче Алексей Антонов Мерецковка биш минут вакыт бирде. Кирилл Афанасьевич, киемнәрен каккалап, итеген чистартып кергәндә, стена буена барып баскан һәм уң кулына төрепкәсен тоткан Сталин сөйли иде.

– Без Волхов һәм Ленинград фронтларын берләштереп зур хата ясадык. Генерал Хозин Волхов юнәлешендә утырса да, эшләре начар барды. Ул Икенче удар армияне күчерү буенча Ставка директиваларын үтәмәде. Нәтиҗәдә, немецлар армия коммуникацияләрен үз кулларына төшерде һәм аны камалышта калдырды. Сез, иптәш Мерецков, Волхов фронтын яхшы беләсез. Сезнең алга, иптәш Василевский белән бергә, Икенче удар армияне, бернигә дә карамыйча, авыр коралларны һәм техниканы калдырып булса да, камалыштан чыгару бурычы куела. Волхов фронтын торгызу буенча директиваны иптәш Шапошниковтан алырсыз. Урынга барып җитү белән, кичектермичә, фронтта командалыкны үз кулыгызга алырга кирәк булачак.

Сталин, сөйләп бетерүгә, урынына барып утырды. Аннары Кирилл Афанасьевич сүз сорады.

– Мөмкинме, Иосиф Виссарионович?

– Тыңлыйбыз, иптәш Мерецков.

– Иосиф Виссарионович, Икенче армия солдатлары озакка сузылган тәртипсез вак бәрелешләрдән соң нык йончыган. Аларны кыска гына вакытка булса да ял иттереп алырга иде. Шуннан соң группировкаларны бер йодрыкка туплап, югалтуларны яңа көчләр белән тулыландырып, контрһөҗүмгә күчәргә кирәк. Шунда гына немецларның божрасын өзәргә мөмкин булачак.

Ләкин Мерецковны тыңларга теләүче булмады.

– Иптәш Кирилл Афанасьевич, Политбюро директивасы әзер, кабул ителгән. Сездән үтәү сорала, – диде Сталин. Хәтта Жуков белән Василевскийга да сүз бирергә теләмәде. – Алексей Михайлович, сезнең алга бурыч куелды. Аны кичектерергә ярамый, – дип, Василевскийга авыз ачарга да мөмкинлек калдырмады.

Мерецков белән Василевский, кабинеттан чыккач, Шапошников бүлмәсенә кереп, секретареннан политбюро директивасы язылган кәгазьләрне алдылар һәм Георгий Константинович Жуковны көтеп, аның белән киңәшләшеп карарга булдылар.

Жуков киңәшмәдән соң да генералларның үзен көтеп торуларын аңлады һәм, озын колаклардан читтәрәк сөйләшү өчен, аларны урамга дәште:

– Киттек, егетләр, юл уңаенда сөйләшербез, – диде, беренче үзе сүз башлап. – Егетләр, Волхов фронты – баш бетәрлек урын. Ачуланмагыз, мин ул сугышның өметле чишелешен күрмим. Сезгә Ходай ярдәм бирсен инде, – дип куйды. – Сез анда өчәү – Андрей Андреевич Власовның башы шәп эшли. Ничек тә ерып чыгарсыз.

– Бәла дә шунда шул: Георгий Константинович, Власовның куллары бөтенләй салынган. Бөтен өмете бүгенге киңәшмәдә иде. Ә монда киңәш түгел, боерык кына бирелде.

– Өстәмә көчләр бирелмәсә, ул җәһәннәм божрасын өзү мөмкин булмаячак, – дип, Мерецковның сүзләрен куәтләде Василевский.

– Киңәш дисәгез, мин шуны гына әйтергә телим: сезгә ничек тә чолганыштан чыгарга кирәк. Моның өчен иң зәгыйфь урынын табып, дошман божрасын өзәргә, һәм шунда тар гына булса да коридор ясап, солдатларны безнең якка чыгарырга. Сталин әйтте бит, ике фронтны бергә кушу хата булды, дип. Яңа көчләргә өмет юк. Бөтен көчләр Сталинград өчен сугышка туплана. Сез

божрадан чыга алсагыз, калганын алга таба күз күрер. Ә хәзер бөтен максат – Сталинград. Иделне бирмәскә! Дошман, бар көчен туплап, шунда ыргыла. Кышкы салкыннарга хәтле шәһәрне алырга ашкына. Мәскәү астындагы кышкы суык арт сабакларын укытты ул мәлгуньнәрнең.

4

Волховка кайткач, Жуков биргән киңәш буенча эш иттеләр Мерецков белән Василевский. Армиянең исән калган төркемнәре бергә тупланып, 21 июнь көнне, Мясной Бор авылы тирәсендә дошман божрасын өзеп, чолганыштан чыгу өчен коридор ачуга иреште ләр. Частьлар төркем-төркем булып та, солдатлар аерым-аерым да киңлеге 300-400 метрлар чамасы шул коридор буенча безнең якка чыгарылды. Икенче армия солдатларының кинәттән ясаган һөҗүменнән югалып калган немецлар ис-акылларына килгәләгәнче, үзебезнең җиргә аяк басарга ашыктылар. Ләкин өченче көнне фрицларның контрһөҗүмнәре башланды. Чолганыштан чыгарга өлгермәгәннәр һәлак булды. Бу өч көндә Икенче удар армия 150 меңләп сугышчысын югалтты. Немецлар армиянең зур җир белән элемтәсен юк итүгә ирешеләр. Калган гаскәрләргә идарә итү мөмкинлеге бетте. Чолганыштан иң соңыннан чыгарга тиешле армия штабы һәм башкомандующий Власов яңадан фашистлар божрасында калды.

* * *

Язмыш Андрей Власовны икенче тапкыр зур сынау алдына куйды. Узган елның сентябрендә ул шундый ук сынауны җиңеп чыга алган иде. Бу вакытта, Киевны саклаучы 37 нче армиянең башкомандующие, штаб медпунктында хезмәт итүче хәрби табибә Агнесса Подмазенко белән икәүдән-икәү генә торып калдылар. Власов яшьли үзенең авылдашы Анна Воронина исемле кызга өйләнгән иде. Сугыш башлангач, Анна үзенең Горький өлкәсендәге туган авылында яшәүче әти-әнисе йортына китте. Кырык яшьлек ир уртасы өчен хатынсыз яшәү, әлбәттә, җиңел хәл түгел иде. Шуңа күрә дә ул теләсә нинди очраклы хатыннар белән чуалганчы дипме, армия штабының табибәсе Агнессаны сөяркәсе итте. Бу чибәр ханымда ул хатынының чагылышын күргәндәй булды. Аңа хәтта үзенең хатыны дигән документлар ясатты, документларга фамилиясен дә Власова дип яздырды. Генералны өзелеп яраткан Агнесса аның белән теләсә нинди кыенлыкларны кичәргә дә риза иде. Киевны немецлар басып алгач та, ул аны ташлап качмады. Хәер, Агнесса Власовның өйләнгәнлеген, туган авылында хатыны калуын белми иде.

Инде менә Волховта да шул ук хәл кабатланды. Андрей Андреевич армия штабының шеф-пешекчесе Мария Воронова белән икәүдән-икәү дошман божрасында үлем элмәген киделәр. Бары тик элмәкне тарттырасы да бугазларыннан кысасы гына калды. Ләкин Власовның үләсе килми иде. Ул өметләнде, үзен ташламаслар дип көтте.

Алар башта армия штабының исән калган утыз-кырык сугышчысы белән чолганыштан чыгу юлын эзләделәр. Аннары һәрберсе аерым-аерым үзенә юл саба башлады. Соңга таба дүртәү калдылар: Власов, Мария, Власовның адъютанты һәм штаб начальнигы Виноградов. Адашып йөри торгач, Чудово шәһәре янындагы Мостки дигән бер авылга килеп чыктылар. Виноградов авыру һәм нык хәлсезләнгән иде. Власов аңа шинелен салып бирде һәм адъютанты белән икесенә шушы авылда калырга кушып, үзләре Мария белән икенче авылны эзләп киттеләр.

– Сталин мине ярата. Ул мине онытырга тиеш түгел. Самолёт җибәрерләр, – диде Власов юлда Мариягә.

– Юк, Андрей, без исән калырга тиеш түгел! Кая пистолетың, ат син мине. Аннары үзеңә ат. Безне барыбер үтерәчәкләр!

– Ашыкмыйк, Мария. Немецлар армияне кырып бетердек, дип уйлый хәзер. Командирлар инде күптән качкан, дип уйлый. Ә безгә ничек тә үзебезнең якка чыгарга кирәк. Партизаннар бардыр, аларны эзләргә кирәк.

– Немецларга очрасак?! Әсир төшәргә ярамый. Сталинның әсир төшүчеләрне халык дошманы, дип игълан иткәнен яхшы беләсең.

– Сталин... Нәрсә Сталин?! Ул үзе гаепле минем бу хәлгә төшүемә! Армиягә чигенергә рөхсәт бирмәде. Күрәләтә ут эченә китереп тыкты. Ленинградны коткара, имеш. Сазлыктан торып ничек коткарып булсын Ленинградны?! Томана!

– Чү, Андрей! Тынычлан. Хәзер инде соң. Эш узган.

– Узган, узган! Үзе ята анда халыктан качып. Сугыш булмый, немец безнең дус, дип лыгырдады-лыгырдады да, әнә хәзер нишли! Бөтен хәрби начальникларны, полководецларны кырдырып бетерде! Сволочь! Сугыш алдыннан бит! Әле сугыш башлангач та тынгылык бирми, кабахәт! Мерецков, әнә, дәшми генә, мескен. Сугышның икенче көнендә ябып куйдылар ласа. Ничек кенә мыскылламадылар үзен. Хәзер шуларга хезмәт итә, борыны белән җир сөрә. Бернинди дә горурлык хисе юк икән. Мине бу мәхшәргә китереп тыгучы да ул! Дәрәҗәмнән, исемнәремнән, бүләкләремнән көнләшеп, Сталинны котыртты, шушы тишеккә китереп тыктырды, кабих! Үзе йөри инде Берия җәлладлары күрсәткән мыскыллауларны күңелендә күтәреп.

– Нишләсен инде ул? Каршы дәшсә, бетерәчәкләрен белә бит. Үзең әйтәсең ләса, кемнәрне генә бетермәделәр!

Власов белән Мария, сазлык ера-ера, озак йөрделәр Чудово тирәләрендә адашып. Йөри торгач, алар кайсыдыр авылга килеп чыктылар. Урамда беренче очраган кешедән авылның исемен сорадылар.

– Сенная Кересть, – диде урта яшьләрдәге, чыраен сакал баскан бу зат.

– Бик ачыктык, ашарга булмас микән? – диде Власов. Үзе шундук кулыннан көмеш беләзекле сәгатен салып аңа тоттырды.

– Көмешмени? – дип сорады сакаллы. Сәгатьне әйләндереп-әйләндереп карады да түш кесәсенә салып куйды. Аннары аларны өйгә алып кереп, өстәлгә мичтән чүлмәге белән чикмәнле бәрәңге чыгарып утыртты. Хатынына чоланнан сөт алып керергә кушты.

Власов белән Мариянең күптән болай тәмләп сыйланганнары юк иде. Күңелләре булды. Ашап туйгач, Власов хуҗадан:

– Бу тирәдә партизаннар юкмы? – дип сорады.

– Каядыр бар бугай, авылга килеп чыккалыйлар.

– Безне шулар янына илтсәң әйбәт булыр иде, – диде Власов.

– Авылда немецлар. Күренеп йөрергә ярамый, тотсалар, мине дә алып китүләре бар.

– Кая?

– Кая булсын, Германиягә. Авылның эшкә яраклы бөтен ирләрен, хатыннарын төяп алып киттеләр.

– Сиңа тимәгәннәр бит.

– Мин – авыру, гарип. Эшкә яраксыз, дип таптылар.

– Алайса партизаннарны бирегә алып килә алмассыңмы?

– Анысын карап кararга була. Тик сезне каядыр яшереп торырга кирәк. – Бераз уйланган итенеп, сакаллы сүзен дәвам итте: – Киттек. Мунчада торып торырсыз. Кичкә кайтып җитәрбез.

Хуҗа Власов белән Марияне мунчага кертеп, тыштан йозак белән бикләп куйды да хатынына:

– Урамга чыгып йөрмә, өйдә генә утыр, – диде дә капкага юнәлде.

* * *

Мосткида калган адъютант һәм Виноградов, авыл читендәге бер йортка кереп, шулай ук ашарга сорадылар. Йорт хуҗасы кунакларны табынга утыртуга, хатынына аларны сыйларга кушты да үзе, каядыр барып кайтасым бар, дип, чыгып китте. Ул арада, хатын өстәлгә ризыклар куярга да өлгермәде, урамда машина килеп туктаган тавыш ишетелде. Капкадан автоматлы ике немец иярткән хуҗаның кайтып кергәне күренде.

Ишекне киң ачып кергән озын буйлы немец солдаты, боларга автоматын төбәп:

– Aufstehen! Hände hoch![4] – дип кычкырды.

Немецларның берсе, генерал шинеле кигән рус офицерын күргәч:

– О-о, генераль Влясовь! – дип, шатлыктан кычкырып җибәрде.

Виноградов чынлап та беркадәр Власовка охшап тора иде. Аларны шунда ук, кулларын күтәртеп, урамга алып чыгып киттеләр. Немецларның шатлыктан башлары күккә тиярлек булган иде. Нинди кешене кулга төшерделәр бит! Моның өчен аларга зур бүләкләр эләгәчәк!

Тоткыннарны машина әрҗәсенә утыртуга, кабинадагы телефон шалтырады.

– Юк, генераль Влясовны без әсир иттек! Тизрәк штабка илтеп тапшырасы бар, сезнең янга барып тормыйбыз, – диде телефоннан сөйләшә башлаган немец. Шалтыратучылар да боларга генерал Власовны кулга төшерүләре, кайтышлый үзләрен кереп алырга кирәклеге турында хәбәр итәләр иде.

Шалтыратучыларның үзләре янына килергә катгый таләп итүләренә немецлар аптырашып калды. Ничек инде генералны әсир иткәннәр?! Генерал алар кулында лабаса!

Генерал Власов белән сөяркәсе Мария Воронованы мунчага бикләп, урманга партизаннар алып кайтырга чыгып киткән сакаллы бәндә шул авылның старостасы булып чыкты. Ул да урманга түгел, туп-туры авылда урнашкан немец солдатлары янына чапкан икән. Күптәннән сагынышкан икәү яратыша башлауга, ишекне ачып, яннарына автоматлы немец солдатлары килеп керде. Куркып калган генерал, шундук үзен кулга алып:

– Атмагыз, мин командарм Власов! – дип кычкырды.

– О-о! Генераль Влясовь! Гут, гут!

Власов, боларны ышандырыр өчен, кесәләрен актарып, таныклыгын чыгарып күрсәтте.

– Менә, карагыз. Сталин үзе кул куйган!

Бу немецларның да шатлыклары эчләренә сыймый иде. Алар старостага рәхмәтләр яудыра башладылар:

– Danke! Danke![5]

Староста шатлыктан нишләргә белмәде.

[4] Торып бас! Кулыңны күтәр! *(нем.)*
[5] Рәхмәт! Рәхмәт! *(нем.)*

5

Муса лагерь тормышына ияләшергә дә өлгермәде, аларны, атна-ун көн үтүгә, ишегалдына чыгарып, бер сафка тезделәр. Лагерь коменданты һәр тоткын алдында аерым туктап, барчасын баштанаяк күздән үткәрде. Таза, нык солдатларны тагын бер адым алга чыгарып бастыра барды. Хәлсез, яралы әсирләргә, артка чигенеп, үз урыннарына басарга боерды. Мусаның ярасы әле төзәлмәгән иде, һаман сызлавын дәвам итте. Бәлки, сафта калдырырлар, эшләргә, таш ташырга алып китсәләр, нишлисе булыр, дип уйлап куйды ул. Начальник Мусага озак кына карап торгач, янындагы фельдшердан нәрсәдер сорады. Тегесе кыска гына җавап тотканнан соң, начальник Мусага да бер адым алга чыгарга әмер бирде. «Таш карьерына җибәрәләр икән», дип уйлап куйды Муса. Сафта яңа танышы Салих Ганиевнең дә булуы аның күңелендә үз-үзенә ышаныч тойгылары уяткандай итте. «Ничек тә ташламас, авыр моментта таяныч булыр», – дигән уй аның күңелен җылытты. Мусаның «Отвага» гәзитендә эшләвен лагерьда берничә кеше белә иде инде. Алар барысы да диярлек аерып алынучылар сафында иде. Бары тик берничә көн элек танышкан Гариф Хафизов атлы егет кенә лагерьда калачак икән. Муса шулчак куен дәфтәре хакында исенә төшерде һәм дәфтәрне, сакчыларга сиздермичә, ничек тә Гарифка бирергә кирәк, дигән уй күңеленә килде. Бәлки, котыла алыр. Дәфтәрне Казанга алып кайтып җиткерер.

Аерып алынганнарны читкә куалый башладылар. Муса, беренче сафта басып торган Гариф яныннан узганда, сакчылар күрмәгән арада, аның кулына бөкләп тоткан куен дәфтәрен тоттырды. «Гариф дус, сакла, котыла алсаң, Казанга алып кайтып, редакциягә тапшыр», – дип әйтергә өлгерде.

Аларны икенче барак артындагы келәт янына китереп бастырдылар һәм анадан тума чишенергә боердылар. «Мунча кертәләр микән әллә?» – дип уйларга да өлгермәделәр, солдат киемнәре – гимнастёрка, чалбар һәм ботинкалар өләшеп чыктылар. Алар кайсыдыр солдатлардан салдырылган киемнәр булып чыкты. Мусага кайсыдыр ил солдатының (венгр, булды, ахры) киемнәре туры килде.

– Менә хәшәрәтләр, бөтен дөньяны талаганнар, – дип мыскыллы көлеп куйды Муса. Ботинкалары иске, кибеп кыйшайган, аякның тубык сөяген кырасы күренеп тора иде. – Болар белән ничек йөрерсең? Элекке ботинкаларым чүпрәк кенә булса да уңайлы иде, – диде ул, иске киемнәр арасында югалып калган элекке ботинкаларын эзләп.

Киемнәрен алмаштыргач, яңадан сафка тезеп, һәрберсе овчарка җитәкләгән конвойчы озатуында, каядыр көнбатышка таба алып киттеләр.

Мусага барган саен авыррак була барды. Бердән, ботинкасы, чынлап та тубыгын кырды. Озак та үтмәде, тиресен сыдырып та чыгарды. Болай ерак китеп булмасын аңлаган әсир аларны салып кулына тотты. Башта атып бәрергәме дип тә уйлаган иде, ләкин башка аяк киеме бирмәсләр, ял итәргә туктагач, тубыкны кыра торган турысын кисеп атасы булыр, дип, ташламаска уйлады. Икенчедән, сул кулбашы сызлый иде. Ярасы ачылып, гимнастёркасына кан саркып чыкты.

– Түз, бераздан ялга туктатырлар, – дип, аны тынычландырды Салих дусты. Чынлап та, беркадәр баргач, аларны ялга туктаттылар. Барысы да, төенчекләрен чишеп, юлда ашарга дип бирелгән коры-сары ризыкларын чыгарырга ашыкты.

– Эх, тәмәке дә булса, – диде кемдер.

– Тәмәкесез дә хәлне алалар әле монда.

Муса төенчегеннән алюмин кашыгын чыгарып, бер ягын таш белән кырып кайрарга тотынды.

– Нишлисең? – диде Салих.

– Пычак ясыйм. Ботинканың тубык турысын кисеп ташларга кирәк.

Ул, шулай итеп, чынлап та, кашыгының бер ягын шактый юкартты. Азаплана торгач, ботинка каешын кисеп ташлый алды. Итеген алыштырганда, Муса ыштырын чалбар балагы астыннан бәйләп, яшереп калдырган иде. Моңа кадәр ялан аякка кигән ботинкасын аягына ыштыр чолгап, суелган тубыкларын каплап киде. Менә хәзер атларга җиңелрәк булачак инде, дип уйлады. Эшен бетергәч, тиз-тиз генә төенчегеннән чыгарган ризыкларны ашарга кереште. Ләкин озак юанырга туры килмәде, колоннаны аякка бастырдылар һәм алга таба куарга тотындылар. Муса төенчеген тиз-тиз генә төйнәде дә, ипиен ашый-ашый, атларга булды.

Шактый баргач, алар ниндидер бер латыш авылына килеп керделәр. Капка төпләренә хатыннар, карт-коры һәм бала-чага чыгып баскан иде.

Авыл сугыштан әллә ни зур зыян күрмәгән. Өйләр таза-сау килеш. Берничә өй генә янып, урыннарында күмергә калган бүрәнәләр арасыннан кап-кара мич моржалары тырпаеп тора иде.

Шулвакыт Мусаның күңелен нечкәрткән һәм күзеннән яшьләр килергә мәҗбүр иткән гаҗәп хәл булып алды.

Ул бер аякка аксап, көч-хәл белән генә өстерәлеп, колоннада башкалардан шактый артка калып кына атлый иде. Авылны инде чыгып бетәбез дигәндә, ахыргы йортларның берсенең капка төбендә ялгызы гына моңаеп басып торган урта яшьләрдәге – Муса яшьләрендә булыр – бер хатын аңа нәрсәдер кычкырды да, ашыгып, капкадан ишегалдына кереп китте. Ул-бу була калса, ярдәм итәргә дип, колоннадан артка кала башлаган Муса янында барырга тырышкан Салих моны күрде дә аңа: «Сиңа нидер бирәм, көтеп тор, диде бугай», – дип туктап калды. Ул арада аларның болай да артта сөйрәлүләренә ачуы кабарып, тик нигәдер моңа кадәр берни дә дәшмичә түзеп барган конвойчы:

– Weiter so![6] – дип акырып җибәрде һәм кулындагы резин дубинка белән Салихның сыртына тондырды.

Шунда, капкадан, кулына пар күн итек күтәргән теге хатын килеп чыкты да Мусалар артыннан йөгерә башлады. Конвойчы аны этеп екты, ләкин хатын мүкәләп торып басты да яңадан йөгерде. Сыртына дубинка төшүдән сынын күтәрә алмыйча яткан Салих янына килеп җиткәч, ул итекләрен аңа тоттырды да артка чапты. Хатын Мусаның аксап баруына игътибар итеп, аягындагы ботинкаларының ертык икәнен күрергә өлгергән һәм икенче аяк киеме бирергә уйлаган икән. Күрәсең, сугышка киткән иреннән калган итекләрдер. Әле шактый таза, яңа ук булмаса да матур күренәләр. Муса хатынга: «Спасибо!» – дип кычкырды. Аның күзләреннән яшь атылып чыкты.

– Халык безнең яклы, – диде Муса Салихка. – Ярдәм итәргә тырышалар. Без барыбер җиңәчәкбез!

Конвойчы итекләрне тартып алмаса да, киергә бирмәде, резин дубинкасын айкап, аларны башкалар артыннан куды.

– Бераз түз инде, озак бармабыз, привал ясарлар, – диде Салих, Мусаны тынычландырып.

– Минем аркада сиңа эләгә. Ачуланма инде, дус, – диде Муса, җиңе белән күз яшьләрен сөртеп.

[6] Артка калмаска! *(нем.)*

– Юкны сөйләмә. Сиңа авыррак, күрәм бит мин. Түзик.

Берничә сәгать баргач, алар Рига шәһәре читендәге сыра заводы ишегалдына килеп керделәр. Әсирләрне ярымҗимерек бинага кертеп тутырдылар. Шушында төн чыгасылар, димәк.

Муса белән Салих, бер аулаграк урын табып, үзләренә ятак әзерләделәр. Муса ботинкаларын салып ташлады да теге итекләрне киеп куйды. Алар бераз бушрак та иде әле. Шуңа күрә лыштырдабрак торалар, ләкин аякны кыра торган туфлигә караганда, олы итек киеп атлавы барыбер җиңелрәк булыр, дип уйлады ул.

Салих, ашарга яраклы берәр нәрсә табып булмасмы, дип, бина буйлап эзләнергә китте. Беркадәр вакыттан соң ул, чынлап та, каяндыр табып, бераз чикмәнле бәрәңге күтәреп кайтты. Әсирлеккә төшкән көннән бирле мондый тәмле ризык ашаганнары юк иде инде. Шуның белән тамак ялгап, алдан әзерләнгән урыннарына бөгәрләнеп ятып йоклап киттеләр.

Мусага итеген киеп йөрергә туры килмәде. Дөресен әйткәндә, язмаган булып чыкты. Иртәгесен аларны тагын сафка тезделәр. Итекле әсирне күреп, бер сакчы автомат түтәсе белән Мусаның сыртына тондырып этеп екты да, аларны йолкып, аягыннан салдырып та алды. Акай күзле җирән чәчле офицер исә шаркылдап көлде дә, саф алдына басып, нәрсәдер сөйләргә тотынды. Тәрҗемәче аның сүзләрен урысчалаштырып барды.

– Бүген лагерьда бәйрәм! – дип кычкырды Акайкүз.

«Нинди бәйрәм тагын?» – дип, пышын-пышын сөйләшү башланды. «Фашистлар әллә Ленинградны алганнармы?» – дигән сорау ишетелде.

– Бүген бездә бәйрәм! – дип дәвам итте фриц сүзен. – Бүген безгә зур кунак килә. Шуңа күрә сезне әйбәт итеп сыйлаячаклар. Иртәнге аштан соң кабат шушында тезеләбез!

Иртәнге аш дигәннәре, чынлап та, моңа кадәр әсирләрнең төшенә дә кермәгән аш булып чыкты: һәр әсиргә яшькелт сары төстәге берәр кружка кайнар чәй, көрпә кушып пешерелгән берәр телем арыш ипие һәм бер шакмак дуңгыз мае белән ике кисәк бәрәңге йөзеп йөргән бер җамыяк баланда...

Шулай да нинди кунак икән соң ул шулкадәр нигъмәтләр белән сыйларлык булгач? Барысы да шул хакта сөйләшә иде.

Иртәнге аштан соң һәммәсен дә яңадан сыра заводының ишегалдындагы мәйданга чыгарып тезделәр. Бераздан завод идарәсе урнашкан бинадан бер төркем немец офицерлары килеп чыкты да әсирләр сафына якынлаша башлады.

– Киләләр, – дип пышылдады кемдер.

Акай күзле җирән офицер сүзен «Ахтунг!» дип акырудан башлады. Аннары ул әсирләрне үзенә ияреп килгән кунак белән таныштырды. Кунак дигәннәре кичәге Власов армиясе офицеры икән. Волхов сазлыкларында әсирлеккә төшкәч, Мусага барып эләккән листовкада язылган сүзләр дөрескә чыкты болай булгач. Ләкин Мусаның Икенче удар армия командирлары арасында бу офицерны күргәне юк иде. Өр-яңа хәрби киемнәрдән, каян гына тапкандыр, түшенә заманында патша армиясендә бирелә торган тәре рәвешендәге медальләр тагып куйган.

– Тапканнар бит кешесен дә, – дип куйды Муса янында басып торган Салихка.

– Тыңлыйк әле, нәрсә дип сайрар икән.

Дөрестән дә, Акайкүз, беренче булып сүзне шушы кабихкә бирде.

– Кадерле ватандашлар! – дип башлады ул. – Бүген безнең алда зур мөмкинлекләр ачыла! Бүген данлыклы рус генералы Власов оештырган Рус

Азатлык Армиясенең беренче солдатларын теркәү башлана. Ул солдатлар – сез, кадерле ватандашлар! Коммунистлар коткысына бирелеп ялгышканыгызны аңлагансыздыр дип уйлыйм. Германиянең җиңәчәге ап-ачык! Тагын берничә көннән ул Сталинградны тез чүктерәчәк! Аннан соң инде Идел буйлап Казанга, Мәскәүгә юл ачыла! Ул җиңүне якынайту өчен, сезгә дә үз өлешегезне кертү мөмкинлеге тудырыла! Ялгышмагыз, гомергә бер бирелә торган шансны ычкындырмагыз! Кызыл Армия җиңәчәк дип уйлаучылар булса, бик нык ялгышасыз. Ул җиңгән очракта да сезгә совет илендә көн булмаячак. Сезне анда Себер көтә! Сталин әсирлеккә төшүчеләрне халык дошманы дип игълан иткәнен беләсездер. Ләкин сез үз халкыгызның дошманнары түгел! Шулай дип уйлыйсыз икән, димәк, сез дөрес юлда! Ә хәзер Рус Азатлык Армиясенә язылырга теләүчеләрне, теркәлер өчен, берәм-берәм өстәл янына килүегезне сорыйм. Алга, ватандашлар! Туган илгә, әти-әниләр, хатыннар, балалар янына кайту өчен, дөрес юлны сайлагыз. Рус Азатлык Армиясенә язылыгыз!

Кунак, чыгышын тәмамлап, урынына барып басты. Сүзне яңадан Акайкүз алды. Аның әйткәннәрен тылмач урысчага аударып барды. Алдан килешеп куйганнар күрәсең, ул да шул ук сүзләрне кабатлады.

– Дөрес сөйләде, каһәр, – дип куйды кайсыдыр, пышылдап.

– Үз шкурасы турында кайгырта. Илдә яшереп калдырган байлыкларын кайтарырга өметләнә, эмигрант кисәге!

– Ул байлыкларны коммунистлар күптән ашап кәк иткән инде, хыялланмасын. Ну дөресен сөйли үзе.

– Бар алайса, языл! Беренче солдат, дип, медаль бирмәсләрме.

Әсирләр арасында киткән пышылдаулар дулкыны чыгыш ясаучылар колагына да барып иреште. Акайкүз нидер кычкырды. Тәрҗемәче, аны урысчага әйләндереп:

– Разговорчики! – дип акырды.

Пышылдаулар аңа карап кына тукталмады.

– Татарлар да үзләренең легионнарын төзи икән, – дип куйды арадан кемдер. – Алар инде, әнә, язылганнар, Мамай токымнары!..

Бу сүзләрне Салих белән Муса артында басып торган әсир әйтте. Ул аны астыртын гына, үзара татарча сөйләшүче Муса белән Салихка карап, барысы да ишетелерлек итеп кычкырды. Әлеге сүзләрдән соң пышылдашучылар дулкыны көчәеп киткән кебек булды.

– Ялган сөйләмә! Татарлардан да батыррак сугышчы күрмәдем әле мин, – дип, кайсыдыр аларны яклап җавап кайтарды. – Бик герой булсаң, әсирлеккә төшәсең юк иде. Бар, әнә, тот та языл Азатлык армиясенә!

Шуннан соң әсирләрне, берәм-берәм өстәл янына чакыртып, исемлеккә яздыру башланды. Ни сәбәптәндер, исемлеккә татарларны язмадылар. Кайсының башына килгән фикер булгандыр, бер әсирдән милләтен сорауны кирәк дип таптылар. Муса белән Салихка да, татар икәнлекләрен әйткәч, кире үз урыннарына басарга куштылар. Ләкин Азатлык армиясенә язылырга урыслар арасыннан да ашкынып торучылар бик юк иде. Күбесе, төрле сәбәпләр табып, лагерьда калуны кулай күрде. Кайсы үзен каты яралы, кайсы – чирле, аксак, чукрак, начар күрәм, дип хәйләләп котылды. Кайсы, татар булмаса да, милләтен татар дип күрсәтергә тырышты. Иң кызыгы теге «татарлар үз легионнарын төзи икән» дигән бәндә иң беренче булып үзен татар дип күрсәтмәкче иде. Каян белгәннәрдер, өстәл янындагылар аның чалбарын салдырып карадылар.

– Охо, русиш! – дип кычкырды Акайкүз, аның сөннәтсез икәнен күреп.

Әсирләр дә гөрләтеп көлешеп алдылар.

Мескенне көчләп диярлек «Рус Азатлык Армиясе» дип аталган сатлыкҗаннар исемлегенә теркәп куйдылар. Армиягә язылучылар әллә ни күп булмады. Аларны, автомашина әрҗәләренә төяп, каядыр алып киттеләр.

Икенче көнне калган әсирләрне дә яңадан, колоннага бастырып, сыра заводы капкасыннан алып чыгып киттеләр. Инде юллары ераккарак – Польшага илтәчәкләр икән, дигән сүз таралды.

6

Генерал Власовның әсирлеккә төшүе билгеле булуга, Мәскәүдә аның хатыны Анна Воронинаны – сигез, сөяркәсе Агнесса Подмазенконы биш елга ирекләреннән мәхрүм итеп, лагерьга җибәрделәр. Ә үзен иң югары хөкем чарасы көтүе генерал өчен көн кебек ачык нәрсәгә әверелде. Аның акылы белән ничек тә исән калырга иде, дигән хайвани теләк идарә итә башлаган иде. Ә моның өчен бары тик бер генә юл бар: рус әсирләреннән Советлар Союзына каршы сугышучы армия төзү. Һәм ул Гитлерга Рус Азатлык Армиясе оештырырга теләвен белдерергә кирәк дигән катгый карарга килде. Русларның бу сугышта җиңүе аның өчен катастрофа дигән сүз. Большевикларны яратуяратмавы да, Сталинны күралмау дигән нәрсәнең дә аның өчен бернинди әһәмияте юк иде. Ничек тә исән калырга һәм моның өчен бары тик Гитлерның җиңүенә ирешү – бөтен максат шул. Аның алга таба эшчәнлеге әлеге максатны тормышка ашыруга юнәлдерелгән булырга тиеш. «Бу юлда сатлыкҗан дип атарга беркемнең дә хакы юк! – дип уйлады ул. – Кемне сата соң ул? Хатынын, сөекле кешеләрен бер гаепсезгә лагерьга җибәргән Сталин режимынмы? Большевиклар властька килмәгән булса, патша төшерелгәннән соң, хакимлекне буржуаз-демократик хөкүмәт үз кулында тотып калса, Россия аның Ватаны булудан туктар иде мәллә?! Юк, ул Ватанына хыянәт итми, ул үзе өчен көрәшә. Бу җирдә яшәү бер генә тапкыр бирелгән, һәм ул аны үзе теләгәнчә яшәп чикләргә хаклы!»

Ләкин Гитлер һич кенә дә алай җиңелчә фикер йөртми иде. Гомумән, үзенең көрәшендә Власов кебек илен саткан бәндәләргә ихтыяҗ күрми. Ул бары тик сугышны тиз арада аз югалтуларсыз тәмамлап, Россияне җир йөзеннән себереп түгү һәм бөтен дөньяга кара афәт булып таралучы большевистик чуманы юк итү турында гына уйлады.

* * *

СССРга каршы сугышның егерме бишенче көнендә, 1941 елның 16 июлендә, Гитлер Рейхстагта партия лидерларын, империянең барлык министрларын һәм хәрби начальникларны җыеп киңәшмә үткәрде. Анда Герман Геринг, Альберт Шпеер, Генрих Мюллер, Мартин Борман, Йозеф Гиббельс, Генрих Гиммлер, Иоахим фон Риббентроп, Альфред Розенберг, Уильгельм Кейтель, Ганс Ламмерс һәм башка хәрби начальниклар, генераллар катнашты. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә – сугышучы якларның һәр икесе өчен дә бик мөһим булган әсирләр мәсьәләсе иде.

Беренче булып Герман Геринг сүз алды. Геринг Гитлер командасында аңа иң якын, иң йогынтылы кеше, күп кенә дәрәҗәле постлар биләгән абруй иясе. Ул – бер үк вакытта Рейхстаг председателе дә, Пруссиянең президент-министры да, авиация рейхсминистры да, тагын әллә никадәр вазифалар башкаручы, кыска гына әйткәндә, Гитлердан кала Германиядә икенче кеше. Көн

тәртибендәге мәсьәлә, әлбәттә, аның эшчәнлегенә турыдан-туры кагылмаса да, ул Германия алдында килеп туган бу четерекле хәлдән читтә торып кала алмый иде. Ни өчен четерекле дигәндә, әсиргә алынучылар саны көннән-көн арта бара, җитмәсә йөзләр, меңәрләп кенә түгел, хәтта йөз меңнәр белән исәпләнә башлады. Шушы егерме-егерме биш көн эчендә ул җиде йөз меңнән артып китте. Аларны каядыр урнаштыру мәсьәләсе килеп туды.

– Юлбашчыбыз! Данлы Германия гаскәрләренең җиңүле сугышлары нәтиҗәсендә кыска гына вакыт эчендә җиде йөз меңнән артык урыс солдаты әсирлеккә төште. Алга таба аларның саны бермә-бер артыр дип көтелә. Безнең алда кыска срокларда хәл ителергә тиешле зур мәсьәлә килеп туды – әсирләрне урнаштыру. Шул уңайдан берничә эшлекле фикер бар. Кайберләрен тыңлап үтәргә тәкъдим итәм. Рәхим итегез, Риббентроп әфәнде.

– Юлбашчым минем! Дөрес аңлагыз, әсирләрне урнаштырыр өчен, концлагерьларга кытлык булмаячак. Германиянең үз территориясендәге лагерьлардан тыш, басып алынган мәйданнарның һәрберсендә абзарлар җитәрлек. Бу сүзләрне Генрих Гиммлер әфәнде дә раслый ала. Монда әсирләрне СССРга каршы сугышта файдалану турында сүз бара. Украина, Белоруссия, Балтыйк буе республикаларыннан әсир төшкән сугышчыларның күбесе СССРга каршы сугышырга теләк белдерә. Рус дәүләте – урыс булмаган халыкларны үзенә буйсындырган күпмилләтле дәүләт. Шуңа күрә ул халыклар арасында да урыс армиясенә каршы сугышырга теләк белдергән әсирләр байтак, – дип башлады сүзен Иоахим фон Риббентроп.

– Тагын бер кызыклы нәрсә бар, – дип дәвам итте сүзен фон Риббентроп. – Сталин әсирлеккә төшкән урыс солдатларын халык дошманнары дип игълан итте. Чолганышта калган урыс солдаты ике юлның берсен сайларга тиеш: яки чолганыштан чыгу юлын табарга, яки үзен-үзе атып үтерергә. Өченче юл юк, ул әсирлеккә төшәргә тиеш түгел. Әсирләргә карата мондый мөнәсәбәт безнең файдага эшли. Илендә дошман дип игълан ителгән солдат ватанына каршы икеләнмичә сугышка керергә мөмкин.

– Дөрес мантыйк! – дип сүзгә кушылды Уильгельм Кейтель. – Ләкин без сугышта урыслар ярдәменнән башка да җиңеп чыгачакбыз, юлбашчым минем! Вермахтның данлы армиясе зур адымнар белән ул җиңүгә таба бара инде. Җиңү көнен күрергә күп калмады!

Уильгельм Кейтель – Германия хәрби көчләре башкомандованиесенең штаб начальнигы, генерал-фельдмаршал, бу киңәшмәдән соң нәкъ ике ай үткәч, 1941 елның 16 сентябрендә, фашистларга каршы батырларча сугышучы совет халкын юк итү максатыннан, «үтерелгән бер немец солдаты өчен илледән йөзгә хәтле коммунистны атарга» дигән вәхши әмер чыгарды.

Киңәшмәдә катнашучылар арасында Германиянең җиңүе нәтиҗәсендә дөнья картасында яңа дәүләтләр барлыкка килер дип өметләнгән һәм шул кушны кулдан ычкындырмау турында уйлаучы сәясәтчеләр дә бар иде. Шундыйларның берсе – Альфред Розенберг. Розенберг 1933 елның 1 апреленнән нацистлар партиясенең тышкы сәяси идарәсе башлыгы булып тора.

– Мәсьәләгә аек акыл белән карарга кирәк, юлбашчым минем! – дип сүзгә кушылды Альфред Розенберг. Ләкин аңа озак сөйләргә туры килмәде, аны бүлдереп, Адольф Гитлер үзе сүз башлады:

– Бер нәрсәне аңлагыз, дусларым! Әйе, ашкынулы адымнар белән безнең бөек җиңү көнебез якынлаша. Без һич беркемнең ярдәменнән башка да бу җиңүне яулаячакбыз. Ләкин әлеге сугышта Россиягә каршы бары тик немец

солдаты гына корал тотып сугышырга тиеш. Бу – безнең милли көрәшебез! Бу бөек немец милләтенең башка милләтләрдән өстен булуын раслаучы көрәш һәм җиңү булачак! Без – аерым милләт! Без – ариецлар! – Гитлер сүзен тәмамлап, бүлдергәне өчен Розенбергтан гафу үтенеп, дәвам итүен сорады.

– Юлбашчым минем! Җиңү килер, бернинди дә шик юк. Ләкин җиңү эйфориясенә бирелеп, дөньябызны онытмаска кирәк, дип уйлыйм. Мин СССРның сугыштан соң нинди булырга тиешлеге турында уйларга вакыт җитте, дип саныйм.

– Безнең алда бу гаять зур бәлешне телемнәргә бүлгәләү бурычы тора, – дип, сүзгә Гитлер яңадан кушылды. – Аңа, беренчедән, хуҗа булырга, икенчедән, идарә итәргә, өченчедән, эксплуатацияләргә тиешбез. Ләкин әлеге территориянең Уралга хәтле өлеше дә хәттин ашкан. Бары тик шушы территориядә безгә каршы бернинди дә хәрби көч булмаганда, бер генә корал да безгә төбәлмәгән очракта гына тулы иминлегебез тәэмин ителергә мөмкин! Безнең бөек җиңүебездән соң җир йөзендә Россия дигән дәүләт калырга тиеш түгел! Бу хакта инде күп тапкырлар сөйләштек. Украина, Московия, Кавказ һәм Белоруссия! Бары тик шушы дүрт дәүләт булачак!

– Юлбашчым минем! Рус дәүләте ул урыс булмаган йөзләрчә милләт ватаны да. Аның аеруча зур территорияләрендә төрки халыклар яши. Без алар турында да онытмыйк, – дип, үз фикерен җиткерде Розенберг.

Ләкин Гитлерның сүзе бетмәгән иде әле.

– Альфред дустым, кемнәр дисең әле? Төркиләрме? Бу уенда катнашмаган бердәнбер ил – Төркия. Төркиләрне уенга кертәсегез килә икән, Төркия белән мөнәсәбәтләрне үзгәртергә туры киләчәк. Сезнең ул «Идел-Урал» легионы турындагы утопик хыялыгыз барып чыкмаячак. Уйлап карадыгызмы, урыслар белән ул татарлар Чыңгыз хан заманнарыннан бирле үзара тугланып, буталышып беткән, бары тик ике телдә сөйләшүче бер үк милләт! Уйлап караганыгыз бармы: казагы да, кыргызы да, үзбәге дә, азәрбайҗан белән татары да шул бер үк халык бит – Чыңгыз хан токымнары?! Бик дөрес уйлап табылган аларга уртак исем – төркиләр! Алайса, әйдәгез, мине дә хан дип атый башлагыз! Ләкин минем хан булырга бернинди теләгем дә юк!

Дусларым! Алда әйтелгән дүрт комиссариатның милли үзенчәлек буенча төзелмәве хакында сүз күп булды. Сүз хәзер бары тик сәяси-административ берәмлекләр турында гына барырга мөмкин. Урыслар, әнә шул комиссариатларның берсе Московиядә яшәсеннәр. Тик үзләренең большевистик идеяләреннән башка гына. Бөек Германиянең вассаллары булып. Ә татарлар, калган төрки туганнары белән, аерым ил булып, Идел артында Туран дәүләте төзесеннәр! Безнең тышкы эшләр буенча министрлыгыбыз бар. Мин СССР яуланганнан соң барлыкка килгән территорияләр белән эшләр өчен яңа министрлык, басып алынган Көнчыгыш территорияләр министрлыгы оештырырга кирәк дигән фикердә торам. Һәм бүгенге сөйләшүнең нәтиҗәсе – шул министрлыкны төзү турында карар чыгару дөрес булыр дип уйлыйм. Яңа министр итеп бу эш белән турыдан-туры шөгыльләнгән һәм шушы территорияләр буенча зур белгеч Альфред Розенберг кандидатурасын тәкъдим итәм. Кемдә нинди фикерләр бар?!

Гитлерга каршы килеп ни дә булса әйтергә теләүче күренмәде.

– Алайса, фәрманны әзерләгез, – диде Гитлер, фельдмаршал Кейтельгә мөрәҗәгать итеп. – Иртәгә кул куярмын.

Барысы да Альфред Розенбергны котларга ашыкты.

7

Ләкин нацистлар партиясе, җиденче ноябрьдә, октябрь революциясе көнендә, Мәскәүдә зурлап бәйрәм итәбез, дип көткән җиңү тиз генә килергә ашыкмады. Инде Мәскәү чикләренә җиткән немец солдатларының бер өлеше, совет сугышчыларының туктаусыз яудырган уклары астында баш күтәрә алмыйча, ноябрь-декабрь суыкларында өшеп-туңып, башкала янындагы кырларда мәңгегә ятып калса, исәннәре йөзләрчә чакрымга чигенергә мәҗбүр булды.

Кырык икенче елда сугышны яшен тизлегендә үткәрү планнары барып чыкмавын аңлаган Гитлер партиясендә яңа сугыш тактикасы турында уйлана башладылар. Гитлерның «Немец булмаган теләсә кайсы милләт кешесенең кулына бернинди дә корал бирелергә тиеш түгел!» дигән тәгълиматы шик астына алынды. Бигрәк тә Розенберг алга сөргән идея – әсирләрне милләтләре буенча төрле төркемнәргә бүлеп, Советлар Союзына каршы сугышта файдалану планы тормышка ашырыла башлады. Альфред Розенберг планы буенча, Россиянең Европа өлеше немец колониясенә әверелергә, ә Уралның аръягындагы җирләр, Себер – руслар тарафыннан буйсындырылган халыклар яши торган ил булып калырга тиеш була. Розенбергның үгетләүләре нәтиҗәсендә, Гитлер рус булмаган милләтләр әсирләрен Россиягә каршы сугышта файдаланырга дигән нәтиҗәгә килә. Шуңа күрә Власовның Рус Азатлык Армиясенә караганда, заманында руслар буйсындырган милләтләр Россиягә каршы теләбрәк сугышачак, дигән уйдан чыгып, Гитлер «татар легионы төзү» идеясен тормышка ашыра башларга фатиха бирә. Розенберг 1942 елның март аенда Көнчыгыш мәсьәләләренә багышланган фәнни конференция үткәрә һәм анда төп чыгыш ясаучы итеп профессор Герхард фон Менде билгеләнә. Көнчыгышны өйрәнү буенча зур белгечкә әверелгән Мендега Көнчыгыш территорияләр министрлыгының бүлек мөдире вазифалары тапшырыла. Министрлык каршында шулай ук төрки әсирләр буенча шөгыльләнүче «Татар арадашлыгы» дип аталган комитет төзелә. Аңа җитәкче итеп адвокат Гайнц Унгляубе билгеләнә.

* * *

Кырык икенче елның җәендә, татар эмигрантлары татар легионы төзү турында әле сүз куерткан гына заманда, генерал-лейтенант Вагнер биргән директива нигезендә, Төньяк, Үзәк һәм Көньяк армияләре төркемнәре партизаннарга каршы сугышта файдалану өчен ирекле казак берләшмәләре оештыру эшен актив алып баралар иде инде. Көнчыгыш территорияләр министрлыгының бүлек башлыгы Герхард фон Менде, Сталинград өчен каты сугышлар барган көннәрнең берендә, үзенә Гайнц Унгляубены чакыртып алды.

– Үзегезгә ышанып тапшырылган вазифаны җиренә җиткереп үтәмисез! – дип, үгезне мөгезеннән эләктерде фон Менде.

– Эш бара, хөрмәтле профессор, – дип ялагайланды Унгляубе.

– Нинди эш?! Арадашчылыкка җитәкче итеп сезне билгеләү зур хата булды бугай! Бер ай эчендә хәлне уңай якка үзгәртмәсәгез, үзегезгә үпкәләгез, эшне башка кешегә тапшырырга туры килер! Күрмисезмени, Сталинград өчен каты сугыш бара. Урыслар Сталинградның һәр карыш җире өчен җаннарын кызганмый! Ялгышмасам, Сталинград – элекке татар ханнары яшәгән җирләрдә төзелгән кала. Бу сугышка нәкъ менә татарларны җибәрү мөһим!

– Аңлыйм, хөрмәтле профессор! Таянып эшләрлек бер кеше юк бит. Татар әсирләре арасында эш алып барыр өчен, аларны әйбәт белгән белгечләр юк.

– Ничек булмасын?! Инициатива бит татар эмигрантларыннан чыкты. Шулар белән сөйләшегез.

Унгляубе, дөрестән дә, бу эштә очраклы кеше иде. Моңа кадәр ул татар дигән милләт барын да белми иде. Беренче татар кешесен ул Польшадагы Остров лагеренда әсирләрне милләте буенча төрле лагерьларга аеру комиссиясендә эшләгәндә генә күрде. Төрле милләт кешесенең холык-фигыле буенча үзенчәлекләреннән чыгып, ул үзе аларны төрле лагерьларга урнаштырырга кирәк, дигән фикергә килгән иде. Бу эштә активлык күрсәткән адвокатны җитәкчелек тиз күреп алды һәм, шәрык халыклары белән эшләү буенча махсус әзерлек үткәннән соң, профессор фон Менденың тәкъдиме белән, ул Татар арадашлыгына җитәкче итеп билгеләнде.

Петрикен лагеренда Унгляубе үзенә ярдәмче булырлык бер әсирне тапты. Бу немец телен яхшы гына чамалаган, сугышка кадәр Уфа шәһәрендә педагогия институтында укыган Гариф Солтанов атлы татар егете иде. Сугышның беренче көннәрендә үк әсирлеккә эләгеп, бер елдан артык ачлы-туклы яшәп, исән калуына тәмам өметен өзгән бу егет Унгляубеның үз тәрҗемәчесе булып йөрергә, дигән тәкъдименә бик теләп риза булды. Аның белән бергәләп алар шактый гына татар әсирен легионга язылырга күндерделәр. Ләкин легионга яздыру тагын да уңышлырак барсын өчен, ярдәмчеләр кирәк иде. Ә аларын табарга Гайнц Унгляубега 1941 елда гына филология докторы дигән дәрәҗәгә ирешкән Әхмәт Тимер ярдәм итте.

Әхмәт Тимер үзе – тумышы белән хәзерге Әлмәт шәһәреннән. Ул туган 1912 елда Әлмәт әле Бөгелмә өязенә кергән дүрт йөз хуҗалыклы, өч мәчетле, өч мәктәпле зур гына авыл була. Әхмәтнең чын фамилиясе – Яруллин, атасы Рәшит Әлмәтнең беренче мәхәлләсе мәчетендә имам һәм мәчет каршындагы мәдрәсә-мәктәптә өлкән укытучы булып эшли. Ул елларда Әлмәтнең икенче мәхәллә мәчетендә Һади Атласи имамлык итә. Әхмәтнең әнисе Зәйнәп абыстай да Рәшит мулла мәхәлләсе мәдрәсәсендә кызлар укыта. 1920 елда Рәшит мулла имамсыз калган Бөгелмә мәчетенә күчерелә. Әмма шул елларда муллаларны эзәрлекләү башлана. Күп имамнар, дин эшлеклеләре белән аралашып, башта мәдрәсәдә, аннары Бөгелмә лицеенда укып, шактый гына гыйлем туплаган улы Әхмәтне, алга таба да белем алсын дип, әтисе Төркиягә озата. Озак та үтми, Рәшит мулла тарихта «Һади Атласи эше» булып кереп калган Төркия файдасына шпионлык итүдә гаепләнеп, Һади Атласи, Кәбир һәм Фазыл Туйкиннар белән, барысы тугыз мулла кулга алыналар һәм атып үтереләләр. 1929 елда Төркиягә киткән Әхмәт Төркия Бөек Милләт Мәҗлесе вәкиле Йосыф Акчура ярдәмендә Трабзон шәһәренең мөгаллимнәр әзерләү мәктәбенә укырга керә. Аннары ул Әнкара университетында тел, тарих һәм география буенча укып югары белем ала һәм фән юлыннан китә. 1934 елда Әхмәт әтисе ягыннан туганы булган Әкъдәс Нигъмәт Курат белән очраша, аның киңәшенә таянып, 1936 елда Германиягә китеп, Берлин университетында телләр өйрәнә. Биредә Гаяз Исхакый белән таныша. 1941 елда докторлык диссертациясен яклап, филология фәннәре докторы дәрәҗәсенә ирешә. Үзенә «Тимер» дигән тәхәллүс алып, Әхмәт Тимер дигән исем белән йөри башлый.

Татар әсирләрен барлау өчен, махсус лагерьлар буйлап эзләнеп йөргән арада Әхмәт Тимер утызлап әсирне легионга язылырга кодалаган иде. Беренче сөйләшүдә үк риза булучылар, аның уенча, иң ышанычлылар һәм алар белән

эш йөртергә була, дигән нәтиҗәгә килгән Әхмәт Тимер бу утыз әсирне Вустрау лагерена агитаторлар булып йөрер өчен махсус әзерлек үтәргә җибәртте.

Гитлер өчен сугышның төп максаты – Россияне тар-мар итү һәм яһүд-большевиклар хакимлеген себереп түгү иде. Ләкин революциядән соң Англия, Франция, Германия, Төркия кебек Европа илләрендә сыену тапкан ак эмигрантларның күбесе, туган илләренә әйләнеп кайтып, үз милли дәүләтләрен торгызу турында хыялланды. Бу хыялларын тормышка ашыру өчен, алар Гитлерга, хәлләреннән килгән кадәр, үз ярдәмен күрсәтергә әзер торуларын белдерергә ашыктылар. Шундыйлар арасында төрки халыкларның вәкилләре дә шактый иде. Аларның күбесен, нигездә, Төркия үз канаты астына сыендырды. Шуларның берсе заманында Башкортстан Республикасын оештырып, Сталинның мәкерле сәясәте аркасында ярык тагарак алдында утырып калуына үпкәләп, башта Урта Азиядә басмачлар хәрәкәтенә җитәкчелек иткән һәм соңыннан илне ташлап Төркиягә чыгып качкан, 1935 елда Вена университетын тәмамлаганнан соң, Бонн, Түбән Саксониянең Гёттинген университетларында укыткан, Германиядән, 1939 елның 1 сентябрендә Икенче Бөтендөнья сугышы башлангач, яңадан Төркиягә әйләнеп кайткан Әхмәтзәки Вәлиди иде. Сугышның беренче көннәрендә үк Вәлиди Германиянең тышкы эшләр министрлыгында Вернер Отто фон Хентиг атлы чиновник белән очрашты. Вәлидинең Азат Башкортстан җөмһүрияте төзү турындагы хыялы шушы очрашуда ук чәлпәрәмә килде. Чөнки әңгәмәдәше аңа Гитлерның Германия җиңүеннән соң СССР территориясендә бернинди дә милли дәүләтләр төзелмәячәк, дигән катгый карарын әйтте.

Вәлиди шикелле үк эмиграциягә китеп, Төркия, Польша һәм Германиядә эшчәнлеген җәелдергән Гаяз Исхакыйның исә фашистларга карашы, гомумән, тискәре булды.

1942 елда Германиядә татар әсирләреннән «Идел-Урал» легионын оештырырга җыенулары һәм сугыштан соң шул исемдәге дәүләт төзүне күздә тотулары хакында сүзләр чыкты. Ә бу әле СССР дәүләте төзелгәнче үк Казан татарлары хыялланган «Идел-Урал штаты» идеясе Вәлиди өчен шәхси трагедиягә әверелгән бер нәрсә иде. Әгәр бу идеяне тормышка ашыру буенча хәрәкәт башланса, Әхмәтзәки Вәлиди үзенең кан дошманына әйләнгән Гаяз Исхакый алдында бер мәхлук җанга, бөҗәккә әвереләчәк.

Ә Гитлерның СССРны бүлгәләү буенча төп максаты ачык. Ул шуларны тормышка ашыру эше йөкләнгән Альфред Розенберг җитәкләгән министрлык даирәләрендә туган «Идел-Урал» легионын оештыру идеясе белән янып йөрүче Әхмәт Тимерләр хыялланган бәләкәй бер штаттан күпкә колачлырак иде. Төрки халыкларны берләштерү максатында туган пантюркизм, пантуранизм идеясен тормышка ашырып, СССРда яшәгән барлык төрки халыкларны бер дәүләткә берләштерүне күз алдында тотты. Һәм бу хәлләрдән Гаяз Исхакый яхшы хәбәрдар булып, аның әлеге легионны оештыру эшендә бөтенләй дә катнашасы килү теләге юк иде. Шуңа күрә мәйданга башка каһарманнар чыкты.

Татар, башкорт, чуваш милләтеннән булган әсирләрне бер лагерьга туплау әлеге шул филология фәннәре докторы Әхмәт Тимергә тапшырылды. Ләкин Әхмәт төрле сәяси уеннар, интригалар нәтиҗәсендә, бу эштән читләшергә мәҗбүр иде. Идел-Урал дәүләте төзү идеясе белән рухланып йөрүчеләр арасында сәясәттән бигрәк, сәүдәгәрлек эшендә киң танылган Шәфи Алмас дигән бер зат пәйда булды.

Шәфи Алмас 1885 елда Алат юлы өстендәге Олы Солабаш дигән авылда

туган. Чын исеме – Габдрахман Гыйбадулла улы Галиуллин. Шәфи тәхәллүсен ул үзенең дәү әтисенең атасы Шәфигулладан алган. Аның ата-бабалары сәүдә эше белән шөгыльләнгән. Габдрахман үзе дә Казанда, Оренбургта, Мәскәүдә кибетләр тоткан хәлле генә сәүдәгәр. Революциядән соң ул Төркиягә эмиграциягә китә. Анда төрек гражданлыгы ала. Егерменче елларда, беркадәр Мәскәүдә Төркия илчелегендә эшләгәннән соң, 1928 елда Германиягә китә. Күчемсез милек – биналар сатып ала. Сәясәт белән шөгыльләнми. Ләкин сугыш башлангач, Германиядәге татар эмигрантлары кыставы буенча, татар легионын оештыру эшенә тартыла. Сугыш барышында Шәфи Алмас үзенең ялгыш юлдан китүен аңлый һәм 1944 елда бу эштән читләшә. Яңадан эшмәкәрлек белән шөгыльләнә башлый.

8

Мусалар төркеме Польшага җиткәнче, әле Каунас лагеренда тукталыш булып алды. Ләкин Польшага аларның барысын да җибәрмәделәр. Муса әнә шул сайланылган әсирләр арасында иде. Салих дусты белән аларга Каунаста аерылышырга туры килде. Аны Польшага китүчеләр арасына кертмәгәннәр иде.

Демблин лагере әйләнә-тирәсе су эчендә утырган борынгы бер кирмән иде. Үзара чәнечкеле тимер чыбыклар белән уратылып алынган өч зонага бүленгән. Беренчесендә яңа китерелгән әсирләрне кабул итү һәм баштагы чорда шунда яшәтү каралган. Ул тулысынча дистәләгән кеше сыйдырышлы казармалардан тора. Икенче зона – лазарет. Монда яралыларны, чирлеләрне дәвалыйлар. Өченче зона – тулысынча берничә блокка бүленгән казамат-казармалар. Боларында инде әсирләр тора.

Октябрь ахырларында Мусаны ни өчендер лагерь комендланты чакыртып алды. Аны иртән торуга салкын душта коендырдылар, киемнәрен алмаштырттылар. Иске гимнастёркасын, чүпрәк ботинкасын салдырып, килешле генә кәчтүм-чалбар, туфли киерттеләр. Әсирлеккә төшкәч, шактый ук ябыгып, сөякләре тырпаеп калган болай да бәләкәй буйлы Мусаның өстендә бу киемнәр, чит кешедән салдырып киертелгән булуын әллә каян сиздереп, буш капчык шикелле, иңбашларыннан ук асылынып торса да, алар аның гражданский киемнән йөрмәгәнгә ел ярымлап вакыт узуын исенә төшереп, ничектер күңелен нечкәртеп җибәрде. Урамда көз. Октябрь. Мәскәүдә хәзер яңгырлардыр инде. Ә монда җылы, ләкин дымлы һава. Агачлар да гел Казандагы, Мәскәүдәге кебек, саргаеп, соңгы яфракларын җиргә коеп бетереп яталар.

Комендант кабинетында аның үзеннән кала тагын өч кеше бар иде.

– Guten tag, Муса Жалилёв!

Фамилиясен ишетүгә, Муса сискәнеп китте. Ләкин, үзен кулга алырга тырышып:

– Guten Tag! – дип җавап кайтарды. – Ләкин мин Җәлилов түгел. Мин – Гомәров, herr коментант!

– lüge nicht, Herr Jalil![7]

Муса Мәскәүдә укыганда немецча беркадәр өйрәнгән иде. Шуңа күрә ул комендант белән тылмачсыз гына сөйләшә башлады. Тылмач исә аның ярым татарча сүзләрен немецчага авыштыруны кирәк дип тапты. Шулвакыт сүзгә комендант бүлмәсендә утыручылардан берсе, илле-илле биш яшьләр

[7] Алдашмагыз, Җәлилов әфәнде! *(нем.)*

чамасындагы, чама белән Муса буендагы, чәче чалара башлаган, шадра йөзле бер әфәнде кушылды. Мусаны сискәндереп, ул аңа татарча эндәште:

– Алдашасыз бит, Муса әфәнде. Сезнең бернинди дә Гомәров булмавыгызны бик яхшы беләбез, – диде ул.

Муса үзенең чынлап та алдашуына беркадәр читенсенеп куйды, аның йөзенә алсулык йөгерде.

– Ә сезне кем дип белик? – дип сорады ул бу әфәндедән.

– Без сезнең әсәрләрегезне яратып укыйбыз. «Хат ташучы» поэмагызны минем кызларым бик ярата! Сез мине белмисез, әлбәттә. Мин 1923 елдан бирле Германиядә яшим. Үзем Казан арты егете. Олы Солабаш дигән авылдан. Шәфи Алмас атлы кеше булам.

– Эмигрант, димәк.

– Шулай булып чыга.

– Ә минем биредә икәнемне каян белдегез?

– Әсирлеккә төшкән беренче көнегездән үк хәбәрдар без. Нәрсә, әллә каты яралы килеш атып үтерелмичә, шушы көнгәчә исән йөрүегез тиккә генә дип уйлыйсызмы? Сезнең кебек яралыларны монда иркәләп тотучы юк, күренекле шагыйрь икәнегезне белмәгән булсалар, күптән инде Волхов сазлыгы төбенә олагыр идегез. Менә шулай кадерләп, саклап кына Германия җиренә хәтле китереп җиткерә яздык үзегезне.

– Рәхмәт инде. Минем исәнлегем сезгә нигә кирәк булды икән, сер булмаса?

– Нинди сер булсын, Муса әфәнде!

Аларның үзара сөйләшкәннәрен тылмач комендантка тәрҗемә итеп бара иде. Соңгы җөмләдән соң сүзгә комендант та кушылырга булды:

– In Deutschland organisierte Tatarenlegion[8].

– Was ist meine Sache?[9]

– Бар, Муса әфәнде! Бар! – дип сүзгә комендант бүлмәсендәге икенче бер әфәнде кушылды. – Сез монда үзегезнең коммунист икәнегезне сайрый күрмәгез тагын. Югыйсә, бу бүлмәдән чыга да алмый калырсыз. – Ул шулай диде дә, тылмачка бу сүзләрне тәрҗемә итмәскә дип ишарә ясады.

– Ә сезне кем дип белик инде? – диде Муса.

– Сез мине дә белмисез, Муса әфәнде. Мин дә эмигрант. Германиядә утыз алтынчы елдан бирле яшим. Ләкин Шәфи әфәнде кебек коммерсант түгелмен. Галим кеше мин. Тюрколог. Сугыш башланыр алдыннан гына Гамбург университетында диссертация якладым. Кем белә, бәлки ишеткәнегез дә бардыр. Әхмәт Тимер атлы кеше булам. Мин дә Татарстаннан – Бөгелмә якларыннан.

Утыз яшьләр тирәсендәге, борын өстендәге зур түгәрәк пыялалы күзлеге йөзенә тирән акыллы гыйлем иясе кыяфәте биреп торган бу егетне Муса чынлап та белми иде.

– Менә бу егет тә үзебезнең яклардан, Муса әфәнде, Уфадан. Уфа педагогия институтында сезнең әсәрләрне өйрәнгән студент – минем ярдәмчем, кем әйтмешли, уң кулым, Гариф Солтанов, – дип, тылмач белән таныштыруны кирәк тапты Әхмәт Тимер.

Гариф чынлыкта «Татар арадашлыгы» комитеты җитәкчесе Гайнц Унгляубеның тылмачы иде. Унгляубе Гарифны Әхмәт Тимер әсирләр арасында агитация эшләре алып барган вакытларда аның белән йөртте.

[8] Германиядә татар легионы оештырыла *(нем.)*

[9] Минем анда ни эшем бар? *(нем.)*

– Менә шул, Муса әфәнде, ишеткән булырга тиешсез, Германиядә татар-башкорт әсирләреннән легион оештырыла. Сезне шунда кушылырга кодалыйбыз. Үзегез генә дә түгел, легионга башка милләттәшләребезне чакырып пропаганда эше белән шөгыльләнергә тәкъдим итәбез.

– Акылыгыз алтын икән, үзегез көмеш булсагыз да.

Сүзгә Шәфи Алмас кушылды:

– Алай димәгез әле, Муса әфәнде. Уйлап карармын, диегез. Бәлки, чынлап та уйлап карарсыз. Сез – совет кешеләре өчен әсир булган көнегездән бирле халык дошманы. Сезне бит, илгә исән-сау әйләнеп кайтсагыз да, Себер көтә. Гаиләгез, балаларыгыз. Алар рәхәт яши, дип беләсезме әллә? Хәбәрсез югалган көнегездән үк хатыныгызга көн күрсәтми башладылар бит инде коммунистлар. Хатыныгыздан хат килмәгәч тә, аңламыйсызмы әллә?

Шәфи Алмас ничек тә Мусаны күндерергә, үз ягына авыштырырга тырыша иде. Аның сүзләрендә хаклык та бар иде кебек. Бер Әминә белән сөекле Чулпаны гына түгел, Рауза белән улы Альбертны да, Зәкия белән кызы Люцияне дә тынычлыкта калдырмаганнардыр... Мусаның күңеленнән яшен тизлеге белән әнә шундый уйлар сызылып узды.

– Озак уйламагыз, Муса әфәнде. Бу эш белән фюрер үзе кызыксына. Бигрәк тә генерал Власов Урыс Азатлык Армиясен төзү турында тәкъдим ясагач, Гитлерның планнары үзгәрде.

– Аннан соң, сез үзегез генә түгел, легионга язылырга теләк белдерүчеләр күп. Агитация алып барырга вәгъдә бирүчеләр дә бар, – дип, Әхмәт Тимер Шәфи Алмас сүзен куәтләргә ашыкты.

– Кемнәр инде ул, сер булмаса? Мин беләмме? Мине беләләрме? Безгә бергә эш алып барырга туры киләчәк бит.

– Әлбәттә, әлбәттә, Муса әфәнде! – Шәфи Алмасның тавышында ниндидер ныклык, ышаныч чалымнары барлыкка килде. Моны комендант та сизде. Тылмач аңа тәрҗемә итеп барса да, ул ышанып бетмичә, аннан кайта-кайта сорады:

– Stimmt dem zu? Stimmt dem zu?[10]

– Ja ja herr komentant![11]

– Мин эшләремне Шәфи әфәндегә тапшырам, Муса әфәнде. Сез исә аның ярдәмчесе – уң кулы булырсыз дип уйлыйм.

– Каян килгән үз-үзеңә ышану?! Мине легион агитаторы булыр дип каян шулай ышанып сөйлисез? Әле ул легионыгызга язылу турында да уйлап карарга кирәк!

– Сезне якын дустыгыз Абдулла Алиш үрнәге дә кызыксындырмасмы? – диде Шәфи Алмас, Мусага үтәли сынаулы карашын төбәп.

– Кем соң ул? Мин андый кешене белмим, – диде Муса, күзен дә йоммыйча.

– Башыгызны юләргә салмагыз, Муса әфәнде. Сез бит Татарстан Язучылар оешмасы рәисе булып эшләгән кеше. Үз коллегаларыгызны да белмәгәч, нинди рәис инде сез?!

– Ул язучының әсирлеккә төшүен беренче ишетәм.

– Алайса, сугышның беренче елында гына да миллион ярым совет солдатының әсирлеккә төшүе хакында да белмисез. Менә шул, Муса әфәнде: ул миллион ярым әсирне тәккә ашатып яткызу Германия өчен зур юмартлык булыр иде. «Кем эшләми, шул ашамый» дигән әйтемне большевиклар бик яхшы файдалана түгелме соң?! – дип сүзгә кушылды Әхмәт Тимер. – Менә

[10] Ризалашамы әллә? *(нем.)*

[11] Әйе, әйе, комендант әфәнде! *(нем.)*

шул, Муса әфәнде: озак уйламагыз, бер төн сезгә, иртәнгә соңгы сүзегезне көтәбез. Бәлки, иртәгә үк Алиш белән дә очраштырырбыз. Ул менә, сездән аермалы буларак, үзенең Ватан алдындагы бурычларын дөрес аңлады.

* * *

Муса казармасына суга төшкән чебеш кебек, канатларын салындырып кайтып керде. Беркем белән сөйләшмәде, беркемне күрергә теләмәде.

«Менә йөр син үзеңне Гомәров дип, мине монда белмиләр дип. Муса Җәлил икәнеңне дә, сугышка кадәр Язучылар союзы рәисе булып эшләгәнеңне дә белеп торалар. Каян, ничек?» Мусага шул сораулар тынгылык бирмәде. Сәндерәсенә менеп яткач та күзенә йокы кермәде. Аның башында мең төрле уй бөтерелде. Миен мең төрле сорау бимазалады. «Нишләргә соң? Салих Ганиев дустына сер итеп кенә ачкан хыялын монда инде аның күптәнге дуслары тормышка ашырып ята түгелме соң?! Юк, юк, алар легионга язылырга гына агитлап йөрмиләрдер. Алар да Муса шикелле үк уйлаганнардыр. Легионга язылып, безнекеләргә каршы сугышка җибәрелгәч, командирларны юк итеп, автоматларны дошманның үзенә төбәргә агитлыйлардыр алар әсирләрне. Иһ, тизрәк таң атсын иде дә, тизрәк үзләрен күрәсе иде.

Әхмәт Тимер, «Ватан алдындагы бурыч», дип, хисләрдә уйнарга маташты. Ә бит Ватан бер генә! Әхмәт Тимер өчен дә, Шәфи Алмас өчен дә, Исхакый өчен дә, Вәлиди өчен дә! Сталин канга батырган, Гитлер юк итәргә теләгән Ватан да шул ук Ватан бит ул! Шәфиләрнең, Исхакый, Вәлидиләрнең нинди гаебе бар иде соң шулай ватаннарын ташлап чит илгә качарлык? Бер караганда, аларда да хаклык бар кебек. Муса, кулына мылтык алып, сугышка киткән икән, шул ук Ватанны дошманнарга бирмәс өчен киткән бит!»

Муса бик озак әйләнеп-тулгангалап ятты сәндерәсендә. Күзенә йокы кермәде. Сорауларга да бертөрле генә җавап таба алмады. Ахырдан Шәфи Алмас белән Әхмәт Тимернең тәкъдимен кабул итәргә, дигән фикергә килде. Абдулла Алиш белән очрашып, үз фикерләрен уртаклашырга кирәк дигән уй белән, көзге таң беленә башлаганда гына йоклап китте.

9

Әхмәт Тимер һәм Шәфи Алмас Мусаны Абдулла Алиш белән очраштырабыз, дисәләр дә, бу хәл әле икенче көнне генә тормышка ашмады. Дөрес, ул көнне кидергән киемнәрен Мусадан бүтән салдырып алучы булмады. Ә берничә көннән соң, ноябрь башларында, Муса очраклы рәвештә генә күптәнге танышы Гайнан Кормашны очратты. Бер үк лагерьда ничек моңа хәтле күрешмәгәннәр? Бактисәң, Гайнан «Капут-команда»да мәетләр күмеп йөри икән.

Ул көнне Муса яшәгән блокта, аның күршесендәге сәндерәдә ятучы бер әсир үлде. Лагерьга китерелгәндә үк каты яралы, көч-хәл белән генә тын ала, озак тормас, «котылыр» дигәннәр иде иптәшләре. Шулай булды да. Мәетне алырга носилка күтәргән дүрт әсир килде. «Капут команда» әсирләренең берсе Мусага ничектер таныш кебек күренде. Ул да аңа игътибар итте. Муса, гадәттә, үзен танымасыннар өчен, яңа кешеләргә йөзен күрсәтмәскә тырыша, шагыйрь Муса Җәлил икәнлеген белдерәсе килми иде. Ләкин мичкә керсәң, артыңнан таныйм, дигән шикелле, Муса бу егетне шундук танып алды. Гайнан Кормаш бит бу! Казакъстаннан, шагыйрь егет! Гайнанны ул соңгы тапкыр 1939 елда Казанда күрде. Ул чакта Муса Язучылар союзы рәисе булып эшли иде. Ә Гайнанның Кызыл Армиягә китеп барышы икән. Муса Мәскәүдә «Октябрь баласы» журналында эшләгәндә, Мари Республикасының Бәрәңге районында

педтехникумда укып йөргән Гайнан Кормашев журналда бастыру өчен аңа шигырьләрен җибәргәли иде. Ләкин аларның берсе дә ул чакта журналда басылып чыкмады. Аннан соң Гайнан башта Бәрәңге районында укытучы булып эшләгән. Соңыннан туган якларына кайтып, башта укытучы, унтугыз яше дә тулмаган килеш Актүбәдә мәктәп директоры булып торган. Фин сугышы алдыннан гына егерме яше тулган егетне Кызыл Армиягә алып китәләр. Укыган җиреннән ниндидер кәгазь кирәк булган да, Бәрәңгедә булганнан соң, Гайнан Казанга да сугылып чыгасы иткән. Муса абыйсын күрер өчен, Язучылар союзына килгән иде. Менә шул егет аның белән бер лагерьда!

Муса Гайнанны күргәч, танышын гына түгел, ничектер якын дустын, кадерле кешесен очраткандай булды. Аңа күренмәскә тырышуы өчен читенсенеп тә китте хәтта. Ләкин бу уңайсыз хәлдән Гайнан үзе коткарды. Ул да Җәлил абыйсын таныган иде.

– Муса абый, сез түгелме соң?! – диде ул үзенә арты белән баскан әсиргә.

Муса борылды да:

– Гайнан! Синме?! Менә шатлык! Туганымны очраткан кебек булдым! – дип, аны кочаклап ук алды. Ләкин «Капут команда»га ияреп йөрүче сакчы аларга озаклап сөйләшеп торырга бирмәде. Нәрсәдер җикеренеп, баракта чыгып китәргә ашыктырды.

– Мин эштән бушагач, сезнең янга керермен, Муса абый! – диде Гайнан.

Ике-өч сәгать үтмәгәндер, Гайнан Муса янына килеп тә җитте.

– Әйдә, казармадан чыгып сөйләшик, – диде Муса, анда яралылардан кала әллә ни кеше күп булмаса да.

– Мин дә шулай димәкче идем, – диде Гайнан һәм ишеккә таба атлады. – Ят колаклардан читтә сөйләшүең хәерле.

Алар коридор артына чыгып, «патшалар җәяү йөри торган урын» урнашкан блокка таба атладылар.

– Сез күптән мондамы, Муса абый?

– Атна-ун көн бар бугай. Әсирлеккә егерме алтынчы июньдә үк төштем. Өч-дүрт лагерьда булырга өлгердем инде. Тагын кая ташлар бу башны язмыш, белгән юк. Үзең соң, үзең ничек?

– Мине бит утыз тугызынчы елда ук кече командирлар әзерләү курсларына алып киттеләр. Кече лейтенант дәрәҗәсендә фин сугышында катнаштым. Немецлар сугыш башлаганда, Гомель өлкәсендә хезмәт итә идем. Радиоэлемтә эше буенча укыттылар. Дошман тылына илтеп ташладылар. Шунда чолганышта калып, әсир төштем дә, сугышның беренче көннәреннән үк дияргә була, лагерь баландасын чөмерәм. Инде ел башыннан бирле Демблинда. Үзегез күрдегез нәрсә белән шөгыльләнгәнне.

– Күңелле эш түгел. Нишлисең инде, башыңа төшсә, башмакчы булырсың, дигәннәр. Ә шигырьләр? Өметле генә шигырьләр яза идең.

– Кайда ул, шигырь кайгысымы соң?! Кәгазь-каләм тотып утырырга мөмкинлек бармыни?! Армиядә чакта язгалый идем. Актүбәгә җибәргән хатларда сакланадыр, бәлки.

– Алай икән...

Муса, легион турында сүз кузгатыргамы, юк микән дип, шикләнеп, бер Гайнанга, бер бараклар ягына карап алды.

– Ә үзегез соң, Муса абый, язасызмы?

– Минем дә шул инде, Гайнан дус, икебез бер хәлдә. Фронтта язган шигырьләремне аерым дәфтәргә теркәп, әсирлеккә төшкән көннәрдә, бер

Уфа егетенә биреп калдырган идем, икенче лагерьга күчәр алдыннан. Нишләткәндер, аерылыштык. Ул Ленинград өлкәсендәге Чусская дигән станция янындагы лагерьда калды. Аны да анда гына яткырмаганнардыр. Кача калса... дигән идем. Белмим инде. Унбишләп шигырь иде. Кайберләрен хәтерлим дә бераз. Җай чыкса кәгазь битенә төшереп куярмын әле.

– Сезнең монда шагыйрь икәнегезне беләләрме соң?

– Белмиләр дисәм... Ялгышканмын икән. Кичә генә аңладым. Мин бит Волхов фронтында идем. Сазлык эчендә. Бөтен документларым яраланган җирдә юкка чыкты. Сазлыкка төшкәнме, кесәдән алганнармы? Белмим. Немецларга фамилиямне Гомәров дип яздырдым. Син алай-болай сата күрмә тагын.

– Сез нәрсә, Муса абый?! Сатаммы соң! Булмаганны. Мин генә кече офицер икәнемне яшерә алмадым. Ярады тагын, бу мәет күмүчеләр командасына «өлкән» итеп билгеләп куйдылар. Муса абый, ишеткәнсездер инде, монда татар легионына язылырга өндиләр бик каты.

– Ишеттем. Ничек уйлыйсың соң, язылыргамы исәбең?

– Муса абый, – Гайнан як-ягына каранып алды. – Муса абый, бер нәрсә бар. Сер итеп кенә әйтәм...

– Нәрсә бар?

– Без монда яшерен оешма төзедек. Легионга язылмаска исәп. Оешмабызны тагын да ныгытып, зурайтып, восстание оештырырга. Лагерь башлыкларын юк итеп, партизаннарга качарга.

– Оешмагыз зурмы соң? Ничә кешелек?

– Бер утызлап.

– Татарлар гынамы?

– Төрлесе бар. Татарлар күбрәк.

Шулвакыт ашханә урнашкан блок янындагы дар агачына асып куелган тимер калакка суга башладылар. Сөйләшә торгач, сизми дә калганнар: караңгы төшеп килә икән. Кичке аш вакыты җиткән.

– Ашарга чакыралар, – диде Гайнан.

– Шулай шул. Гайнан, сөйләшеп бетереп булмады. Әйтәсе сүзләр калды. Иртәгә тагын күрешергә кирәк.

– Бүгенге вакытта, эштән бушагач килермен, Муса абый. Хәзер аерылыйк. Аерым-аерым барыйк. Бергә күрмәсеннәр. Болай да күзәтеп кенә торалар.

– Сөйләштек. Бар, йөгер.

Гайнан, ашыгып, ашханә ягына таба атлады.

«Молодец егет, тик ятмый. Комсомолларча, яшьләрчә эшли, – дип үзалдына сөйләнде Муса. – Тик ялгыша бераз, яшьлек дуамаллыгы бар бугай. Оешмаларында нинди кешеләрдер тагын?..»

Муса беркавым крепость диварлары артындагы дәрьяга карап торды. Ул ничектер серле дә, шомлы да бер тынлыкка чумып, күңелне әллә нинди караңгы уйларга этәрә иде. Кичә генә язган шигырен искә төшерде.

«Төн утырып шагыйрь шигырь язды,
Ак кәгазьгә тамды яшьләре.
Тышта давыл иде; бертуктаусыз
Күк күкрәде, яшен яшьнәде...

Шигырь язган юк, ди Гайнан. Юктыр да шул. Шигырь язар өчен тетрәнү кирәк бит. Ә ул күнеккәндер инде бу рәхимсез бертөрле тормышка».

* * *

Икенче көнне алар шул ук урында, ләкин бераз соңрак очраштылар. Муса Гайнанның килүен түземсезлек белән көтеп алды. Мәетләр шактый булды, ахрысы, Гайнан тиз генә бушамады. Лагерьда көн саен дистәләгән әсир үлә. Кыш якынлаша. Ачлык һәм суык кешеләрне мур урынына кыра. Узган кышта лагерьда унҗиде мең кешедән ике меңе торып калган, ди. Җәйге якта үлүчеләр шактый кимеде кимүен. Әсирләрне ашату беркадәр яхшырды. Бигрәк тә легион төзелә, дигән сүз чыккач. Ачлыктан шыр сөяккә калганнарның да тәннәренә ит куна башлады. Волховта үткән чакларын кушып исәпләгәндә, сигез ай буе ачлы-туклы яшәгән Мусаның да йөзе алсуланып китте. Ә бит нинди таза, кем әйтмешли, төптән юан чыккан егет иде. Яшьтән көрәш белән мавыкты. Егет чагында авыл Сабан туйларында көрәшми калганы юк иде. Спорт белән үк булмаса да, физзарядка белән шөгыльләнде. Гер күтәрде – ике потлы герләрне ике кулында туп шикелле уйнатты. Кышын чаңгыда йөрергә яратты. Ябыгуы Волхов сазлыкларында башланды. Ашау начар иде. Аннан соң борчу-стресслар, көн саен мәет күрү дә йөрәген нык какшатты. Болар барысы да сәламәтлекне бетерә торган нәрсәләр икән. Кигән киемнәре дә капчык кебек салынып тора башлады. Ә инде лагерь тормышында сиксән биш килолы гәүдәсе чырага әйләнеп калды.

– Көттердемме? – дип сорады Гайнан, кичәге урында үзен көтеп торучы Мусаны күреп.

– Түзәрлек. Мәетләр күп булды, ахры?

– Шулайрак. Аннан үзебезнең егетләр белән күрешеп алдык. Сезнең турында сөйләдем үзләренә.

– Шагыйрь Муса Җәлилне күргәнеңне әйттеңме?

– Юк, сүз бирдем бит инде. Сүземне боза торган егет түгел мин. Бик якын бер танышымны очраттым, дидем.

– Әйбәт булган. Минем турында үзләре белән аралаша башлаганчы ләммим. Араларында төрле кеше булуы мөмкин. Карале, Гайнан, кичәге сүзгә кайтыйк әле. Яшерен оешма төзедек, дидең. Ниндирәк инде ул? Нәрсә белән шөгыльләнәсез соң?

– Иң беренче эшебез – әсирләрне татар легионына кермәскә үгетләү. Шул хакта алар арасында сөйләшүләр алып бару.

– Ни өчен андый фикергә килдегез? Киресен эшләргә кирәкмиме икән, ә?

– Болай да Сталин аларны «Халык дошманнары» дип игълан иткән бит инде. Легионга язылып, тагын безнең гаскәрләргә каршы сугышка да кертсәләр, кем булырлар соң Ватан алдында?!

– Үзем дә шулай уйлый идем башта. Өченче көн генә шул легионны оештырып йөрүче сатлыкҗаннар белән очраштым, беләсең килсә. Алар мине дә легионга язылырга, ул гына да түгел, легионга язылыгыз, дип башкаларны үгетләп йөрергә димләделәр. Баракка кайткач, төн буе шул хакта уйлап чыктым, күзгә йокы кермәде, әллә ниләр уйлап бетердем.

– Йә, нинди фикергә килдегез?

– Беләсеңме, Гайнан, мин ул сатлыкҗаннар тәкъдимен кабул итәргә кирәк, дигән фикергә килдем.

– Ничек инде? Үзегез дә сатлыкҗан булып чыгасыз түгелме соң? Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, диләр бит.

– Менә сезнең яшерен оешма оештыруыгыз бик әйбәт булган ул. Эшне башлап та җибәргәнсез.

– Аңлап бетермәдем.

– Беләсеңме, Гайнан, легионга керергә һәм аның эчендә яшерен оешма оештырып, легионерларны, сугышка кергәч, безнең якка чыгарга өндәргә. Моның өчен алар белән аңлату эшләре алып барырга. Бу бик авыр эш, җаваплы эш, куркыныч эш. Әгәр дә без шуны башкарып чыга алсак, никадәрле легионерга үз өстеннән «халык дошманы» дигән хурлыклы исемне алып ташларга мөмкинлек бирәчәкбез. Ул гына да түгел, аларга мылтыкларын дошманның үзенә каршы борып, җиңүне якынайту өчен үз өлешләрен кертергә юл ачабыз. Уйлап кара әле, аек акыл белән, шулай түгелме?

Муса абыйсының сөйләгәнен тын да алмыйча дикъкать белән тыңлап торган Гайнанның маңгаена тир бөртекләре бәреп чыкты. Ул: «Кызык», – дип куйды.

– Кызык шул. Бердәнбер дөрес юл – шул, Гайнан, безнең шартларда. Ярар, җаен туры китереп качарсыз да. Партизаннарга да килеп чыгарсыз. Ләкин сезгә кем ышаныр? Диверсантлар, дип, шундук кырып бетерәчәкләр.

Исән калсагыз да, илгә кайтып җитә алырсызмы, кайткач, үзегезнең фил түгеллегегезне исбатлый алырсызмы?

– Бер караганда дөрес әйтәсез кебек.

– Икенче караганда да, өченче караганда да иң дөрес юл – шул, Гайнан. Мин инде ул хакта күптән уйланып йөрим. Әле Рига, Каунас лагерьларында чакта ук килде ул фикер минем башка. Ләкин кем белән эшне башларга, кем белән сөйләшергә белми йөрдем. Бер якташны очратып, аңа серемне дә ачкан идем, ләкин безне аердылар. Әле ярый менә син очрадың да, үзебезнең сатлыкҗаннар кара эшләренә димләделәр. Беләсеңме, ул сатлыкҗаннарның тәкъдимен кабул итү безгә эшне җиңеләйтәчәк. Ничек, дисеңме? Легион агитаторлары булып, безгә әсирләр арасында ирекле йөрергә мөмкинлек чыгачак. Төрле лагерьларда булырга юл ачылачак. Агитация дигән сүз ул газета, радио дигән сүз. Шулар безнең кулда булачак. Концертлар оештырып, тыңлаучылар арасында листовкалар таратып күпме агитация эше алып бара алачакбыз. Син менә шуларны уйла.

– Чынлап та шулай бит, әй. Ничек минем башка килмәгән бу, Муса абый.

– Аның каравы, син инде эшне башлагансың. Яшерен оешманы төзегәнсең. Безгә хәзер шул оешма егетләре арасында аңлату эше үткәрергә кирәк, әгәр син минем белән килешсәң.

– Килешәм, Муса абый. Сезне тыңлап-тыңлап торам да, сүзләрегезнең хаклыгы иманымны ныгыта бара.

– Алайса безгә эшне озакка сузмаска кирәк, иртәгә үк, юк, бүген үк сөйләшүләрне башларга кирәк.

– Бүген үк булмас. Без төрле баракларда. Иртәгә мин «Капут команда» егетләре белән сөйләшермен. Безнең оешманың егермеләп кешесе «Капут команда»да.

– Әйбәт икән! Ышанычлы егетләрме соң?

– Сезгә ышанган кебек ышанам мин аларга, Муса абый.

– Ярый алайса, сөйләшүләрне башла. Аннары калганнары белән дә очрашып сөйләшербез. Озакка сузарга ярамый. Югыйсә легион төзүче сатлыкҗаннар агитация төркеменә үз кешеләрен урнаштырып бетерүләре бар. Ә безгә ул эшне үз кулыбызга алырга кирәк!

– Аңлашылды.

10

Гайнан белән очрашканнан соң, лагерьда Мусаның танышлары күбәеп китте. Кайберләре хәтта Казанда чакта ук белгән дуслары булып чыкты. Шуларның берсе – Абдулла Баттал белән ул аеруча якынайды. Абдулла белән Казанда, аның абыйсы, шагыйрь Салих Баттал янында танышкан иде. Салих 1934 елда Татарстан Язучылар союзы төзелгән көненнән үк аның әгъзасы иде. Бик үзенчәлекле шагыйрь, Муса аны хөрмәт итте. Абдулла да холкы белән абыйсыннан бер дә калышмый, аның шикелле үк туры сүзле, әйтәсен конфет кәгазенә төреп, матурлап маташмый, бәрә дә әйтә, хет егыл, хет үпкәлә. Сугышка рядовой булып кергән булса да, каян табып алгандыр, әсирлеккә төшкәч, Кызыл Армия лейтенанты киемнәрен киеп куйган, бернидән дә курыкмыйча, лагерьда шулай кызыл командир булып йөри иде. Гайнан аларны очраштырган көнне үк Абдулла Муса барагына күченде.

Яшерен оешма әгъзаларының тагын берсе Рушат Хисаметдинов атлы егет булып чыкты. Әле шушы көздә генә әсирлеккә төшеп, Демблинга эләккән. Лагерьда, Муса шикелле үк әсирләр күз алдында ай ярымда сиксән биш килолы әзмәвердәй егеттән шыр сөяккә калып ябыккан. Сугышка кадәр Рушат Кыргызстанның Ош каласында ат духтыры булып эшләгән.

Гайнан белән икенче тапкыр очрашкан көннең кичендә Муса тагын бер кызыклы егет белән танышты. Кичке аштан соң үзенең сәндерәсенә үрмәләп, Гайнан белән сөйләшүдән алган тәэсирләре кочагына чумып, уйланып ята иде, якында гына, аскы сәндерәдәге бер егет моңлы итеп татарча җыр сузып җибәрде.

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә...

Муса, җырны ишетүгә, сәндерәсеннән төште дә җырчы янына ашыкты.

– Шәп җырлыйсың! – диде ул аның җырлап бетергәнен көтеп. Аннары: – Болай да сагыш баскан җанны эретерлек берәр күңеллерәк җыр җырла әле! – дип сорады.

– Ниндине?

– «Сагыну»ны беләсеңме?

– «Гөл чәчәкләрен өзәм»неме?

– Шул үзе.

– Беләм. Анысы да сагышлы бит.

– Булса да, якты сагыш ул. Рәхәт сагыш.

– Иһ, сагындыра шул! – диде дә егет Муса сораган җырны сузды.

Гөл чәчәкләрен өзәм мин,
Юлларыңа тезәм мин.
Бик сагындым, бәгърем,
Бик сагындым сине,
Әле дә ничек түзәм мин...

Егет икенче куплетын башлагач, аңа Муса да кушылды.

Иңемә шәл ябынырмын,
Әгәр сагынып кайтыр булсаң,
Каршы чыгып алырмын.

– Кыз-хатыннар җыры булса да, күңелнең әллә кайсы җирләрен чеметеп-чеметеп ала. Сагышлы җыр... – диде җырчы егет, җырлап бетергәч. – Үзең дә матур җырлыйсың икән бит.

– Кыз-хатыннар җыры булса да, сүзләрен ир кеше язган аның.

– Каян беләсең? Их, күрергә иде шул егетне! Яңа җырлар яздырырга иде. Йөрәк яна, дускай, йөрәк яна! Әнә шул янган йөрәк турында язсын иде ул! Явыз дошманга каршы сугыш бара. Ә без монда ачлыктан интегеп, сасы беткә кан эчереп, үлем көтеп ятабыз.

– Ә ул яза! Беләсең килсә, ул үлем тырнагында да дошманга үч һәм нәфрәт тулы шигырьләр язуын дәвам иттерә. Менә тыңла!

Муса күкрәген киереп бер сулап куйды да шигырь укырга тотынды:

Аерылганда миңа йөрәк дустым
Бүләк итте ефәк яулыгын.
Мин ярама яптым ул яулыкны,
Басар өчен агышын канымның.

Кан табыннан куе кызыл төстә
Яулык минем йөрәк турында,
Сөйли миңа аның җылы назы
Һәм ялкынлы сөюе турында.

Мин чикмәдем, дускай, бер карыш та,
Батырларча алга атладым.
Яулык шаһит: сине һәм илемне
Йөрәк каным белән сакладым!

– Әллә үзең яздыңмы моны? – дип сорады җырчы егет. Җавап та көтмәстән: – Шагыйрь икәнсең бит! – дип куйды.

– Каян чыгып әйтәсең?

– Муса Җәлилме әллә син? Гайнан Кормаш әйткән иде, Муса Җәлил дә безнең арада, дип.

– Тыс-с, шаулама.

Муса сизми дә калган, ул шигырь укыган арада алар янына тоткыннар җыйналган иде.

– Курыкма, туган, безнең арада сатлыкҗаннар юк, – диде шунда тыңлап торучылар арасыннан чандыр гына озын буйлы бер егет.

– Алла, сакланганны саклармын, дигән. Булмаса, бик әйбәт. Әйе, Муса Җәлил мин. Ләкин миңа Гомәров дип дәшәрсез. Муса Гомәров. Фашистлар мине шулай дип белә. «Сагыну» җырын да без композитор Заһид Хәбибуллин белән бергә яздык. Егетләр, бер үтенеч бар: кайсыгыз карандаш белән кәгазь таба ала?

– Шигырь язарга дисәң, табарбыз, – диде җырчы егет. Ул шунда ук Мусага кулын сузды: – Таныш булыйк, мин Гарәфетдин атлы булам. Ташкенттан. Кыскартып кына Гарәф дип йөртәләр. Җырчы булу – яшьлек хыялым иде. Төзүче булып китәргә туры килде. Нишлисең, ә җырдан аерылган юк. Җыр бит сагышны да тарата, юата да, күңелне дә күтәрә.

– Баштан кичкәннәрне дә искә төшерә, – дип сүзгә кушылды кайсыдыр.

– Тагын берәр шигырь укы әле, Муса абый?

– Була ул. Менә, тыңлагыз:

Кичер мине, илем, синең бөек
Исемең белән килеп сугышка,
Данлы үлем белән күмәлмадым
Бу тәнемне соңгы сулышта.

Юк, мин сине тузан бөртегедәй
Сансыз гомерем өчен сатмадым.
Волхов шаһит: изге сугыш антын
Соң чиккәчә керсез сакладым...

Муса әле ике көн элек кенә язган бу шигырен яттан белеп бетерми иде. Ул аны куен кесәсенә бөкләп тыккан кәгазь битен чыгарып, шуңа карый-карый сөйләп чыкты. Әсирләр шигырьне тын да алмыйча тыңладылар.

– Гел минем күңелдәген язгансың, – диде тыңлаучыларның берсе. – Өченче көн карап яткан идем, «Нәрсә яза икән бу?» – дип. Хат язса, кем тапшырыр икән ул хатны, дим. Шигырь булган икән.

– Шигырь язам, дуслар, шигырь. Тик язар өчен карандашым бетте. Кәгазь дә бик кирәк.

Шунда бер әсир кесәсеннән язулы кәгазь бите чыгарып, Мусага сузды:

– Менә, бер көнне ниндидер азатлык армиясенә язылырга өндәмә тараткаННар иде. Буш урыннары бар. Шунда язарга була.

– Андый листовка миндә дә бар.

– Карале, мин дә мендәр астына берничә битне яшереп куйган идем, хәзер алып киләм, – дип, тагын бер әсир үз сәндерәсе янына барып килде.

Кемнеңдер кесәсендә карандаш кисәге дә табылды.

– Иҗат белән шөгыльләнер өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылды болай булгач! – дип шаяртып куйды Муса, әсирләрне көлдереп. – Утырып язарга берәр кабинет белән өстәл дә бирсәләр... Ярар, егетләр, таралышыйк, хуҗалар килеп бу чыра утын сүндереп куйганчы, – диде ул, түшәмдә асылынып торган сүрән генә яктылык сибеп торучы һәм көн дә кичке сәгать унда сүндерелә торган электр лампасына күрсәтеп.

11

Икенче көнне Муса белән бер танышы арасында легионга язылуның мөһимлеге турында тагын сөйләшү булып алды.

Инде биш айга якын вакыт узса да, Мусаның кулбашындагы җәрәхәте һаман төзәлеп бетми иде. Көне буе җир казу эшендә йөреп, кичкә таба җәрәхәте ачылган Муса, кәчтүм иңенә кан саркып чыгуын күреп, лагерь лазаретының яраларны бәйләү пунктына барып күренергә булды. Аны өлкән табиб Аркадий Львович үзе кабул итте. Алар Волхов фронтыннан ук танышлар иде. Аркадий Львович та аның белән бер үк көннәрдә әсирлеккә төшкән. Бу яһүд кешесен немецлар шулай ук татар дип беләләр, чөнки ул да, әсирлеккә төшкәндә, документларын сазга батырган булган. Ә яһүд түгеллеген Рига янындагы сыра заводы ишегалдында тикшерү вакытында гаурәтен күрсәтеп исбатлады. Аннары сугышка кадәр Донбасста татарлар арасында яшәве һәм татарчаны шактый гына сукалавы да ярдәм итте. Югыйсә аны да йә Власовның Рус Азатлык Армиясенә язасылар, йә атып ук үтерәселәр иде. Чөнки ул көнне, яһүд икәнлеген белеп, берничә әсирнең башына җиттеләр. Аркадий Львович, ул чакта, Ригадан Каунаска барганда, Мусаны берничә тапкыр карап, ярасын бәйләде. Алар шуннан танышып, хәтта дуслашып ук калдылар.

Аркадий Львович Мусаның Җәлилов икәнен яхшы белсә дә, аны күрүгә, лагерьдагы фамилиясе белән:

– О, Гомәров! Собственной персоной! – дип каршы алды.

– Исәнмесез, Арыслан абый, – дип шаяртты Муса да.

Аркадий Львовичның чынлап та фамилиясе Лев иде. Муса аның белән гел Арыслан абый, дип күреште.

Табиб Мусаның җилкәсендәге канны күрде дә эшнең нәрсәдә икәнен шундук аңлады.

– Тагын ачылдымы? Хәзер ямыйбыз аны. Чишен, сал костюмыңны, – диде.

Муса, ыңгыраша-шыңшый, киемен салды. Табиб яраны карады да:

– Ничава, зыяны юк. Туйга хәтле төзәлер, – дип шаяртты, шкаф киштәсен ачып, бинт һәм мазь алды, чүпрәк юешләп, яраны сөртте, мазь сылап, тарттырып бәйләп тә куйды. – Менә булды. Йә, сөйлә, нинди яңалыклар бар

дөньяда? – диде. Җавап көтмәстән, үзе үк сөйли башлады. – Татар легионы төзиләр, дип ишеттем. Язылырга уйламыйсыңмы?

– Сөйләвен сөйлиләр дә ул. Мине хәтта агитатор булырга да кодалый кайбер «дуслар», – диде Муса.

– Ә нәрсә, булырга кирәк. Ике дә уйлап торма.

– Ике генә түгел, күп уйладым инде. Бер фикергә килгән юк ләкин.

– Агитатор булуы тагын да мөһимрәк әле аның. Сине легионга язылырга агитларга кушсалар, син легионга язылганнарны Кызыл Армия ягына чыгарга агитлап йөр. Бу эшнең кирәклегенә никадәр күп кешене ышандыра алсаң, Ватан алдында шулкадәр гаебеңне юарсың.

– Бернинди дә гаебем юк минем Ватан алдында, Аркадий Львович.

– Үзең юк дисәң дә, бар дип уйлаучылар булуын онытма. Алар алдында йөзең ак булыр. Әсирләргә дә гадел исемнәрен кайтарырга ярдәм итәрсең. Төшенәсеңме?

– Анысы шулай инде.

– Алайса, ялгышмаганмын сине дустым итеп сайлап. Молодец! Тагын бер нәрсә, легионга агитлап кына калма, үзең дә языл һәм, кулыңа корал алып, Ватан өчен дошманга каршы сугышка кер. Легионерларны тәкъдир иркенә ташлама, командирлары булып, ут эченә ыргыл. Монда, тоткынлыкта ачлыктан мәгънәсез үлем белән үлүгә караганда, сугыш кырында кулыңа мылтык тотып һәлак булу күпкә мәртәбәлерәк! Үзең үрнәк күрсәт, әсирләрне язмыш иркенә ташлау дезертирлык белән бер, беләсең килсә!

– Рәхмәт, Аркадий Львович, икеле-микеле шикләремне сыпырып аттыгыз. Тик бу сөйләшү ике арада гына калсын, берүк, – диде Муса һәм чыгып китте.

– Ходай ярдәм бирсен! – дип озатып калды табиб.

* * *

Аркадий Львович белән сөйләшү Мусаның Әхмәт Тимер һәм Шәфи Алмас белән сөйләшүдән соң туган уйларының дөреслегенә инануын тагын да ныгытты. Бу кичне ул тагын ике егет белән танышты. Егетләр икесе дә Гайнан Кормашның яшерен оешмасыннан иде бугай. Муса белән танышырга аларны Гайнан үзе иәртеп килгән иде.

– Менә тагын ике егет алып килдем, Муса абый, – диде Гайнан, егетләр белән таныштырып. – Бусы – Фоат Сәйфелмөлеков.

– Исәнмесез, Муса абый, – диде Фоат, Мусага кулын сузып.

– Бусы – Зиннәт Хәсәнов – Татарстан егете. Сарман якларыннан.

– «Сарман» җырын җырлатабыз икән, болай булгач, – дип, Муса исәнләшергә дип үрелгән Зиннәткә кулын бирде.

– Җырлыйбыз аны! Сугышка да «Сарман»ны җырлап киттек.

Муса сәндерәсе янына Гайнан Кормаш килеп басканын күрүгә, Гарәф Фәхретдинов та алар янына үрмәләде. Алар күптәнге танышлар булган күрәсең, Фоат белән дә, Зиннәт белән дә кочаклашып күрештеләр.

– Менә Гарәф инде безнең җырчы, Муса абый. «Сарман»ны аннан гына җырлатырбыз, – диде Зиннәт, Гарәф белән күрешкәннән соң. – Әйдәле, Гарәф дус, җырлап җибәр булмаса «Сарман»ны.

Гарәф ялындырып тормады, ярым пышылдап, җырлый да башлады:

Сарман буйларында яшел алан,
Печәннәре җитәр бер заман.

Бергә булулары, һай, күңелле,
Әмма аерылышу бик яман...

Җыр ишетеп, Җәлил сәндерәсе янына әсирләр җыела башлады. Ул бу мөмкинлектән файдаланып калырга кирәк, дип уйлап куйды.

– Нәрсә, егетләр, легионга язылабызмы?

– Тоткын булсак та, без сатлыкҗан түгел, агайне. Син безне агитлап маташма инде, – диде әсирләрнең берсе. – Ватанны сату – ул атаң-анаңны, балаларыңны сату. Ватанны сатарга әле безнең башка тай типмәгән.

– Кызмале син, ахири, – дип, Мусаны яклап, сүзгә кушылды яңарак кына Муса белән танышкан Фоат атлы егет. – Менә без дә шул турыда киңәшләшергә телибез. Мәсьәләгә төрле яклап килергә кирәк. Уңай якларын да исәпләп карарга, тискәресен дә.

– Уңай инде, өстеңә немец обмундированиесен киясең дә, иңбашыңа немец автоматын асып, үз иленә каршы сугышка чыгып китәсең. Матур гына, авылыңа хәтле барып җитәсең дә үз ата-анаңа төбисең автоматыңны. «Һинде hoh, күтәр кулыңны!» дисең. Юк, егетем, бара торган эш түгел бу. Сөйләмә дә, үгетләмә дә.

– Ә нигә авылыңа кайтырга ашыгасың?! Иң мөһиме – кулыңа автомат тотып сугышка керү. Ә анда инде авылыңа кайтасыңмы, авылга кайтырга куган немец командирын юк итеп, автоматыңны Берлин ягына борасыңмы – анысын үзең хәл итәсең.

– Итәрсең. Тот капчыгыңны. Әллә сугышта булмадыңмы, нәнә?! Анда бер адым да артка чигенмәскә, дип, артыңнан мылтык төбәп, НКВДның кызыл петлицалы егетләре торганын бер дә күрмәдеңме? Немецларда да шундый ук артыңда торучылар булмас дисеңмени?!

– Шуңа күрә, алдан хәзерләнеп, немец командирлары аны-моны сизгәләгәнче барысын да юк итәргә, аннары инде безнең гаскәрләр ягына чыгарга.

– Чыгарсың, бар. Көтеп торалар ди сине анда безнең гаскәрләр.

– Шуңа күрә алдан әзерләнергә кирәк дип әйтәм бит. Алдан партизаннар белән элемтәгә чыгып, кайчан сугышка керәсен хәбәр итеп куярга. Бу эш белән махсус шөгыльләнергә.

– Барып чыкмаса... Немец киемнәре кигән, немец автоматлары тоткан солдатларны күреп, ипи-тоз белән каршы алырлар дип уйлыйсың мәллә?! Кайсы немец киемендәге безнең әсир дә, кайсы чын фашист – аны кем тикшереп тора ул чакта?!

– Син, агайне, дөрес сөйлисең, – дип сүзгә кушылды боларның бәхәсен тыныч кына тыңлаган Муса. – Барысы да булырга мөмкин. Беркем дә йөз процент гарантия бирә алмый. Аның каравы, үләсең икән инде, кулыңа мылтык тотып, фашистка каршы барып үләсең. Монда, тоткынлыкта бетләп, ачлыктан интегеп үлгәнгә караганда күпкә яхшырак! Әгәр Кызыл Армия килеп коткармаса, безне бары тик шундый үлем көтә. Ә Кызыл Армия коткарсын өчен, аңа ярдәм итәргә кирәк. Фронтта ярдәм итә алмыйбыз икән инде, дошманның үз өнендә таркату эше алып барырга кирәк. Шуны аңлагыз сез. Теләмисез икән, беркем дә сезне көчләми. Ә менә фашистлар көчләп кулыгызга автомат тоттырырга мөмкин. Анысын инде булмас, дия алмыйсың. Ул чагында ихтыярсыз, авылыңа кайтырга, ата-анаңа мылтыгыңны төбәргә мәҗбүр булырсың. Бигайбә!

Дөрес әйтәмме мин, егетләр? – дип, Муса үз тирәсенә җыйналган әсирләргә мөрәҗәгать итте.

Әсирләр гөрләшеп алдылар. Берәүләр:

– Дөрес! – диештe.

– Кем белгән инде аны, – дип шикләнде икенчеләр.

– Ә сез, егетләр, шикләнергә хаклы. Ләкин уйлагыз, киңәшләшегез. Хаклык бәхәстә туа, дигәннәр борынгылар. Бер фикергә килергә кирәк. Югыйсә, үзегез теләп язылмасагыз һәм мин әйткәннәргә колак салмасагыз, соң булып куюы бар. Немецлар үзләре дә легион төзергә кирәк дигән карарга килгәннәр. Озакламый легионга көчләп яза башлаячаклар. Ә безгә үзебез теләп язылырга да, әсирләр арасында алга таба нишләргә кирәклеге турында агитация эше алып барырга! Мин сезгә агитатор булыгыз димим. Кыскасы, уйлагыз, хәл итегез.

– Артка юл юк, егетләр. Ә алга юл әллә ничә юнәлештә: уңга китсәң – уңасың, сулга китсәң – суласың. Әкияттәгечә әйтсәң, уңга китсәң – башыңны кисәрләр, сулга китсәң – суга батарсың, туры юлдан китсәң – туңып үләрсең. Менә шул. Үзегез сайлагыз инде, мин үз киңәшемне бирдем.

– Синеке дөрес бугай, – дип куйды Фоат белән ярсый-ярсый бәхәсләшкән егет.

– Йә, ярый, бетерергә кирәк. Муса абый, шигырь укы әле. Кичә карандаш та, каләм дә таптык үзеңә. Шигырь язмый калмагансыңдыр, иншалла.

Муса кәчтүменең эчке кесәсеннән дүрткә бөкләп тыккан кәгазь битен чыгарды да:

– Яздым, егетләр. Укымыйча түзә алмам, ахры, – дип, аны ача башлады. Менә, тыңлагыз:

Ирек

Кая гына башым куйсам да,
Кайгы талый йөрәк итемне.
Кич ятсам да, иртә торсам да,
Әллә нәрсәм җитми шикелле.

Аяк-кулым бөтен бөтенең,
Буй-сынның да сизмим кимлеген,
Бар нәрсәм дә җитә җитүен,
Җитми бары иркем-хөрлегем.

Үзем теләп йөртер булмагач,
Юк аягым минем, юк кулым.
Нәрсә соң ул, иркем булмагач,
Бар булуым белән юклыгым.

Атам-анам юк та, илем дә,
Әйтегез, мин ятим идемме?
Мин югалттым «д»... җирендә
Анамнан да якын илемне...

Муса дүртенче куплеттагы «дошман» сүзе урынына «д» хәрефе генә куйган иде. Ул моны шигырь дошманнар кулына килеп керсә, «дошман» дигән сүз булмасын өчен шулай эшләде.

Шигырь укылып бетүгә, «Әйбәт!», «Булдыргансың!», «Кай арада гына язасыңдыр?!» дигән хуплау сүзләре яңгырады.

– Тагын укы әле, Муса абый, – дип сорады шунда җырчы егет Гарәф. – Мөмкин булса, кичәгеләрен укысаң да ярый.

Муса ялындырып тормады, кесәсеннән дәфтәр шикелле нәрсә чыгарып, тагын берничә шигырь укыды. Кичә әсирләр биргән листовкаларның чиста өлешләрен бергә тегеп, ул бәләкәйрәк кенә «кенәгә» әмәлләгән иде.

– Монысын дәфтәргә язарга өлгермәдем, – дип, яңа шигырен дә бөкләп, кенәгә битләре арасына кыстырды. – Ә хәзер таралышыйк. Утны сүндерер вакыт җитә, – диде. – Бүгенге сөйләшүне мыекларыгызга чорнап куйгансыздыр. Дөрес нәтиҗә чырарырсыз дип ышанам, егетләр. Хәзергә таралыштык. «Татлы йокы, тәмле төш», дип әйтә торган иде миңа әни...

12

Лагерьда хәл яхшы якка үзгәрә башлады дип торганда, көннәрдән бер көнне, Мусага карата киресенчә, мөнәсәбәт начарланып китте. Хәер, бер Мусага карата гына түгел: Гайнан Кормаш белән Абдулла Батталны да гомум баракларыннан аерып, өчесен бер камерага ябып куйдылар. Камера дисәң, гадәттәге камерадан үзгәрәк: мәйданы унбиш квадрат метрлап булыр, һәрберсенә аерым тимер койка, берәр урындык һәм бер өстәл. Башта алар моны үзләренә карата игътибармы әллә дип уйлаганнар иде. Ләкин беренче көнне үк, киресенчә, ни өчендер халыктан аеру икәнен аңладылар. Чөнки, ишек бикләнде, ашарга ашханәгә йөртмиләр, ишек тәрәзәсе аша гына бирә башладылар. Шул үк баланда. Ишегалдына йөрергә каравылчы күзәтүе астында гына алып чыгалар. Бер нәрсәгә шатландылар: камерада ни эшләсәләр дә күрүче юк. Рәхәтләнеп шигырь язарга мөмкинлек туды. Аеруча Муса сөенде. Бер нәрсә борчый – кәгазь. Тора торгач, анысы да хәл ителде тагын. Ашарга-эчәргә китерүче, камераны чистартучы кеше әсирләр арасыннан татар егете булып чыкты. Фашистларга каршы берәр корткычлык эшләүдә шикләнделәрме алардан – һич кенә дә аңламадылар.

Шәфи Алмаска әсирләр арасында абруе зур булган, сүзе үтә торган Муса шикелле бер лидер кирәк иде, әлбәттә. Әхмәт Тимер белән килеп әсирләрне легионга керергә агитлап йөрергә үгетләүләрен кабул итмәве өчен үч алу булдымы бу? Алай дисәң, Гайнан белән Батталның монда ни катнашы бар? Дөрес, әсирләр арасында төрле кеше очрый. Комендатурага Гайнан оештырган яшерен оешма турында имеш-мимешләр барып җиткән булырга да мөмкин. Шуңа күрә халыктан ерактарак тотарга теләүләре дә ихтимал. Ни булса да булгандыр, ләкин егетләр бу хәлне үзләре өчен файдага дип кабул иттеләр.

Муса көн саен диярлек шигырьләр яза башлады.

Баланда чөмереп, пычкы чүбе кушып пешерелгән көрпәле икмәк белән яшел үлән чәе эчеп, койкасына барып ауган Муса:

– Менә шулай, җәмәгать, эмиграциядәге татар байларыннан бер дә ким түгел хәлебез. Аякны аякка кушырып, түшәмгә төкереп, баба шулпасы тәменә кикереп ятарга гына калды. Рәхәт яшибез! – дип куйды.

Ул арада камера ишеге шыгырдап ачылды, савыт-сабаларны алырга әсир егет килеп керде.

– Җитмәсә, махсус хезмәтче тотабыз, – дип өстәде Муса. – Татар байларыннан кай җиребез ким?!

– Әйтмә инде. Кем уйлаган әсирлектә шундый абруйга ирешербез дип, – диде Баттал, Җәлилнең шаяртуын куәтләп.

– Карале, энекәш, исемеңне кем дип дәшик? – диде Муса, хезмәтче егеткә.

– Баязит исемле мин, Муса абый, – диде егет.

– Мине беләсеңмени?

– Белмәскә. Сезне бөтен лагерь белә бит.

– Алай үк дип әйтмәс идем. Алай абруем зур булгач, бер изгелек эшли алмассың микән?

– Әйтеп карагыз.

– Кәгазь кирәк иде.

– Шигырь язаргамы?

– Каян беләсең?

– Әйттем бит инде, сезне бөтен лагерь белә, дип.

– Алайса, өметләнергә була?..

– Тырышып карармын.

– Тырыш инде, Баязит энекәш. Ватан онытмас үзеңне.

Баязит чыгып киткәч, Гайнан:

– Бу шымчы янында авызны саграк ачарга кирәк. Тиккә генә безгә хезмәт күрсәтергә куймаганнар моны, – дип, ишек янына барып тыңлап торды.

– Шымчы булса булсын, безгә файдасы тисен ул йомышчы малайның. Кәгазь табып китерү аның вазифасы булырга тиеш. – Муса, куен кесәсеннән кәгазь белән карандаш чыгарып, өстәл янына барып утырды. – Бүген күңелгә бер шигырь килде. Язмыйча калдырып булмый, егетләр.

– Безгә нишләргә соң? – диде Баттал. – Ярый сезнең һөнәрегез бар.

– Ә сез листовка языгыз. Ул да эш. Эшнең дә ниндие әле!

– Мөмкинлектән файдаланып калырга кирәк, дөрес әйтәсең. Болай аерып озак тотмаслар, – диде Гайнан һәм, Батталга мөрәҗәгать итеп: – Комачауламыйк иҗат кешесенә. Әйдә, кил монда, – дип, аны үз койкасы янына дәште.

Ә Муса язам дип утырса да, шигырен тиз генә башлый алмыйча интекте. Кәгазенең башына «Аерылу» дип шигыренең исемен язып куйды да тынып калды. Сызып-бозып, язганын төзәткәләп утырырга аңа кәгазь кытлыгы ирек бирми иде. Элек рәхәт булган икән: ошамаса, сызасың да яңадан башлыйсың. Бозылса, йомарлап ташлыйсың да башка кәгазь аласың. Ә монда бер һәм берәгәйле итеп язарга кирәк.

Ниһаять, ул бөтен зиһенен бер максатка туплап, язарга кереште. Алдагы көннәрдә уйлап йөргән сүзләре күңелгә килде.

Читен дә соң артык һичбервакыт
Күрешмәсне сизеп аерылу.
Мәхәббәт һәм дуслык җир йөзендә
Булган чакта бөтен байлыгың.

Кинәт кенә ачы язмыш җиле
Аера сине якын дустыңнан.
Соңгы тапкыр үбү һәм күз яше
Чыкмый аннан мәңге исеңнән.

Мәхәббәт һәм дуслык җебе белән
Багланганда керсез күңелләр,
Бер-берсеннән башка бар мәгънәсен
Югалтканда җирдә гомерләр.

Күпме булды минем якын дуслар,
Күпме иде сөйгән иптәшем,
Калдым ялгыз, саклап яңагымда
Һәркайсының кайнар күз яшен...

Муса җиңел генә шушы дүрт куплетны язып куйды да, төртелеп, туктап калды. Уйлар өермәсе аны, бөтереп, ераста калган еллар кочагына очырып алып китте. Ул карандашын кәгазь өстенә куйды, койкасына барып ятты. Үзара киңәшләшә-киңәшләшә, аңа комачауларга теләмичә, пышылдап кына сөйләшеп, листовка язып утырган иптәшләренә карап, уйга талды.

Шигырендә Муса үзен сугышка озатып калган Әминәсе белән кызы Чулпаннан аерылу турында язарга, дип уйлаган иде. Ләкин уйлар өермәсе аның чанасын салулатып, Әминәгә хәтле булган мәхәббәтләре дөньясына илтеп ташлады.

Муса бик хисчән, тиз һәм тирән гашыйк булучан, йөрәгендә мәхәббәт уты бер кабынса, көчле бер янгын булып дөрли торган егет иде. Мондый холкы аны күп тапкырлар бик авыр һәм җитди сынаулар каршында да калдыргалады. Ул зур гына хаталар да ясады. Төзәтеп булмый торган хаталар ясады. Сугыш башланып, фронтка киткәч, ул шул хаталары өчен еш кына үзен тирги, ләкин бернинди дә аклану таба алмавына үкенеп бетә алмый иде.

Йөрәгендә тирән яра эзе калдырган беренче олы мәхәббәте – Сембер кызы

Рауза белән булды аның. Дөрес, Раузага кадәр дә күп тапкырлар кайнар сөю утында янды. Ләкин Рауза аны, Такташның урман кызы кебек, үзенең сихерле һәм тылсымлы дөньясына урап алды да бик озак вакытлар күзгә күренмәс җепләр белән шул тылсым эчендә тотты.

Рауза Ульян өлкәсенең Чардаклы районыннан – татар Калмаюр авылы кызы иде. Ул яшьли Казанга килеп, театр училищесын тәмамлап, Академия театрына эшкә урнашкан. Муса белән алар Мәскәүдә, татар театры башкалага гастрольгә килгәч таныштылар. Шул чакта Муса Мәскәүдә чыга торган «Коммунист» гәзитенең әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булып эшли иде. Раузага ул беренче күрүдә үк гашыйк булды. Гашыйк булмаслык та түгел, кыз чибәр, сөйкемле, бит уртасында үзенә тартып тора торган бәләкәй генә чокыр да бар. Раузаның үзенең дә Муса беренче озаткан кичтә үк, аны ошатып, йөрәгендә сөю уты кабынып калды бугай, театр Казанга кайтып китеп, аерылышкач та, алар арасында хатлар йөри башлады. Беренче хатны Муса язды. Рауза ул хатка сөенеченнән нишләргә белмәде. Шул кичне үк утырып җавап юллады. Хатында хисләрен яшермичә, үзен онытмавы өчен чын күңеленнән рәхмәт белдергән иде. Муса, җае чыккан саен, Казанга кайтып килү турында уйлады. Бер ел буе шулай әле хатлар аша, йә Муса үзе Казанга кайтып, очрашып тордылар. Танышуларына бер ел дигәндә, 1934 елның октябрь бәйрәме көннәрендә Муса Казанга Рауза янына соңгы тапкыр кайтты. Соңгысы булыр дип уйламаган иде ул. Киресенчә, аның кулын сораргa, өйләнешергә дип кайткан иде.

Театрның Межлаук белән Бауман урамнары чатындагы ике катлы тулай торагында, Рауза яшәгән бәләкәй генә бүлмәдә, алма төшәрлек тә урын юк иде ул кичне. Мәскәү кунагын күрергә театрның бөтен яшьләре дә килгән диярсең. Кызларның күбесе Муса тирәсендә бөтерелде. Көлешеләр, күңел ачтылар. Зифа Басыйрованың җырлавы Мусаның күңелендә әле дә яңгырап торган шикелле. Шул елны Татарстанда Язучылар союзы оешып, Мусаны да беренчеләрдән булып союзга алганнар иде. Аның Казанга кайтканын ишеткән бер төркем язучы егетләр дә килде очрашу мәҗлесенә. Туфан, Кутуй, Нәҗмиләр, – барысы да хатыннары белән. Мусаның ул чакта абруе зур – Мәскәүнең үзендә, олы бер гәзитәнең әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли бит. Аңа хәтле алдагы елларда гына Мәскәүдә чыгучы «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы» журналларының редакторы булып эшләп, аларны Казанга күчереп, егетләрне шунда эшкә урнаштырып калдырган иде.

Муса егетләрнең барысыннан да яшьрәк, әле өйләнмәгән дә. Аны Казанга кайткан саен дуслары, өйлән инде, йөрмә болай каңгырып, дип аптыраталар иде. Бу юлы да сүз күбесенчә Мусаның буйдаклыгы хакында барды.

– Туймадыңмы әле, Муса, буйдак булып йөреп? Япан җирдә ялгыз каласың бит болай. Утызга җитәсең бит инде, – дип, сүзне турыдан ярып башлады Сара Садыйкова.

– Торсам ашым, ятсам башым, диләрме әле? Бер кайгы-хәсрәтем юк, рәхәтләнеп яшим, – дигән булды Муса.

– Тот та өйлән менә үземә. Бүген үк чыгам. Бала үстерәсем бар дип тә кайгырасың юк, Әлфиям үсеп килә дәү булып.

– Син, Сара, бер ир белән яшәп карагач, беләсең ир кадерен. Муса кызлар кулы тотып караган егет түгел бит әле ул.

– Нишләп тотмасын, менә бит, кыз кочагына ашкынып кайткан, – дип, каршы төште Зифа.

Зифа дустының сүзләреннән Раузаның йөзе комачтай кызарып чыкты.

– Әллә безнең Рауза Мусага пар килмәгәнме?!

– Чиләгенә күрә капкачы инде, – дип күтәреп алды Зифаның сүзләрен Луиза Салигаскәрова. – Менә безнең кебек: мин – артистка, Туфан – шагыйрь.

– Нәрсә яшьләргә бәйләнеп утырабыз соң әле? Үзләре белерләр, нишләргә икәнен бездән сорап тормаслар, – диде Зифа, сүзне икенчегә борырга теләп. – Әйдәгез, шагыйрьләр, шигырь укыгыз әле. Такташ булса, күптән шигырьгә күчкән булыр иде инде!

– Мусадан укытыйк! Без монда сезнең шигырьләрне көн дә ишетеп торабыз. Муса ниләр яза икән? – дип, Сара тагын Мусага һөҗүм итте.

– Сорыйбыз! Сорыйбыз! – диештеләр кызлар.

Муса торып басты, Раузага карап, тамагын кырып куйды да шигырь укырга тотынды.

...Таң җилләре, исегез таң сызылганда,
Аңар сәлам әйтегез Чулпан туганда.
Таң шикелле сөйкемле йөзенә карагыз,
Кара урман шикелле чәчен тарагыз.
Белсә иде ул ничек сагынганымны!..
Бер карашы көченнән кабынганымны!
Күңелле соң сөелеп, сөеп яшәве...

– Браво! – дип, кулларын чәбәкләде Сара. – Махсус язып кайткансыңдыр, ахры?!

– Ә хәзер Зифадан җыр сорыйбыз, җәмәгать!

– «Су буйлап»ны җырла әле, Зифа, матурым? – дип, Туфанга кушылды Муса.

– Гармун юк бит. Гармунсыз әллә ничек, – дип, Зифа Басыйрова карышып маташкан иде, тулай торакта Рокыя Ибраһимова да яши икән. Ике-өч минутта кызлар җилтерәтеп аны да китереп җиткерделәр бүлмәгә. Алагаем олы баянын да күтәргән, мескен.

– Әйдә, Рокыя, синнән башка яме юк дөньяның! Уйнап җибәр әле «Су буйлап»ны, – дип, Кави Нәҗми Рокыяга эш тә кушарга өлгерде. – Мәскәүдән кунак кайткан бит. «Су буйлап» җырын ишетәсе килә кунакның.

Муса: «Исәнме, Рокыя!» – дип, аның белән күрешүгә, анысы баянын шыгырдатып алды да сузып та җибәрде. Бер-ике аккорд алуга, Зифа өздереп, моңлы итеп җырлый да башлады. Бер куплетын бетергәч, җырга барысы да кушылып, шактый гына гөрләшеп алдылар.

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул.
Караңгы төн, болытлы көн –
Без аерылган көн бит ул.

Кыскасы, мәҗлес бик күңелле, озакка истә калырлык булып узды. Муса өчен тагын да истәлекле: аларның икесенең тормышында да тирән эз калдырган кичә булды ул.

Инде таралышабыз дип торганда, Муса сүз алды. Аны үзләренә кунарга алып кайтырга җыенган Туфан белән Луизаны гаҗәпкә калдырып, ул барысы өчен дә көтелмәгән белдерү ясады:

– Дусларым, кич буе мине өйләп дә өйләп, дип димләдегез. Бу юлы мин Казанга шул ният белән кайткан идем. Сезнең сүзләрегез ниятемне ныгытты гына. Рәхмәт сезгә. Рөхсәт итсәгез, мин хәзер Рауза дустыгызның кулын сорар идем.

Ул шулай диде дә, Раузаны кулыннан алып, үзенә таба тартып китерде һәм кочагына кысты. Көтмәгәндә ясалган бу тәкъдимнән югалып калган Рауза ни әйтергә дә белмичә, бераз каушап, бернинди дә каршылык күрсәтмичә, Мусаның кочагына сеңде.

– Ә никах?! Никахсыз өйләнешү гөнаһ була! – дип чәчрәп чыкты шунда Сара.

– Комсомолларга нинди никах ди инде ул?! Без никахсыз өйләнештек әле, бер дигән итеп торбыз, – дип каршы төште Кави Нәҗми.

– Әйе, шулай булган, ди. Ышанмагыз, Рауза, ышанмагыз. Алдаша Кави абыегыз. Никахыбыз да булды. Мулла бабай бөтен шартын туры китереп үзе укыды. Сара дөрес әйтә, кирәк никах, – дип, Сараның сүзен куәтләде Сәрвәр.

– Шулай булдымыни? Онытылган да инде. Без өйләнешкәнгә бишбылтыр бит инде, – дип, хатыны белән теләр-теләмәс килеште Кави.

– Алай булгач, шәригатьчә булсын инде, – дип куйды Муса. – Кем укыр икән соң? Арада берәр суфи бармы?

Мәҗлес буе мыек астыннан гына көлеп, сүзсез утырган Кутуйга да тел кердe, мулла дигәч.

– Театр Шәриф абыйның «Хаҗи әфәнде»сен куйганда, әллә ничә тапкыр карап утырган бар. Хөснетдинме әле анда никах укучы?

– Мөгаллим укый, – дип төзәтте Муса.

– Ие, мөгаллим бугай шул. Мин аның сүзләрен яттан беләм. Әйдә, алай булгач, шарт дисез икән, шартына туры китереп, үзем укып бирим никахыгызны, – дип, Кутуй түр башына менеп утырды. – Тәк, ике шаһит кирәк булыр, җәмәгать, – дип, рольгә дә кереп китте. – Кемнәр була инде шаһитлар? Ярар, берсе син булырсың инде, Туфан дус. Икенче шаһит – Кави.

– Һибәтулла улы Нәҗметдинов, ягъни мәсәләң, – дип, тулы исемен атады Кави.

– Тәк, ничек әле, – дип дәвам итте Кутуй. – Ә-ә, сез шаһитлар, кызның ризалыгын барып сорагыз хәзер.

– Кыз риза, риза, Кутуй әфәнде, – дип пырхылдады Туфан.

– Шаярып утырмагыз, егетләр! – дип кисәтү ясады Сара. – Никах уен-муен эш түгел. Гомердә бер була торган бик мөһим вакыйга.

– Сара ханым, комачауламагыз әле. Тәк, эшне дәвам итик. – Кутуй битен сыпырып куйды да төп эшкә күчте. – Кыз риза булса, мәһәре ничек була инде? Баштан бирелә торганы, соңыннан биреләчәге?

– Бер генә тапкыр ярамыймыни соң? Муса үзе нәрсә дип әйтә инде, безнең кесәләр такыр, Кутуй хәзрәт, – диде Туфан.

– Әйе, Муса үзе нәрсә дип әйтә... – Минем дә кесәгә Сәрвәр җиңгәгез хуҗа.

– Менә, мәһәрен үзем бирмичә булмас, тот, мулла абзый, – дип, Муса кесәсеннән тиенле акчалар чыгарып, Кутуйның учына салды.

– Мәскәү егете өчен бик әз түгелме соң бу? – диде, Кутуй биргән тиеннәрне санап.

– Әйдә, кыланып утырмагызсана. Җитмәгән тагын сиңа, белер-белмәс укыган никахыңа! – дип, Сәрвәр Кутуйның бөреренә төртеп алды.

– Ярар алайса. Дәлше дәвам итик. Ничек дигән әле Шәриф абыйда? Ә-ә! Кызны кияүгә бирүче кем була соң инде монда? Ата-анасы биредә түгел бит.

– Менә, без, театр артистлары – Луиза, Зифа, Рокыя, мин! – дип чәчрәп чыкты Сара. – Әйдә, озакка суздың. Чын никахтан бер дә ким түгел.

– Бәй, уйнап утырмыйбыз лабаса. Чын никах булмыйча, нәрсә булсын

инде?! Алайса, Рауза Шәйхетдин кызы Хасиятуллинаны Муса Мостафа улы Җәлиловка хәләл җефетлеккә бирәсезме?

– Бирәбез бит инде, күреп торасың.

– Алай итеп түгел, дөрес итеп әйтегез. Үзегез әйтмешли, шартына туры китереп.

– Бирәбез.

– Син, Муса Мостафа улы, Рауза Шәйхетдин кызын хәләл җефетлеккә алдыңмы?

– Сезнең рөхсәт белән алдым, хәзрәт.

– Дөрес итеп әйт, алдыңмы?

– Алдым.

– Менә булды. Сезгә бәхетле матур тормыш телим. Совет җәмгыятенең беренчел ячейкасын матур итеп корыгыз. Илгә матур кызлар, батыр уллар үстерегез! – Кутуй, Муса белән Раузаның кулларыннан кысып, шундый сүзләр белән үзенең эшен төгәлләде.

– Рәхмәт, дусларым! Чын үзебезчә булды бу! Алдыгызда йөзегезне кызартмабыз! – диде Муса һәм Раузасын кочып, оялудан алсуланган битеннән үбеп алды.

Ләкин аларга бергә матур гаилә тормышы белән яшәү язмаган булып чыкты. Муса ике төнне Рауза куенында үткәрде дә Мәскәвенә китеп барды. Мәскәүдә көтелмәгән эшләр, мәшәкатьләр килеп чыгып, ул ике айдан артык Казанга кайта алмады. Ләкин ни өчендер, Раузаны сагынып язган хатларына баштарак җавап алса да, соңга таба Казаннан хатлар килү тукталды. Яңа елга ашкынып сөекле хатынын күрергә дип Казанга кайтса, ниндидер кара эчле бәндәләр: «Син Мусаның бердәнбере түгел. Мәскәүдә аның синең шикелле сөяркәләре әллә нихәтле», – дип котыртып, Раузаның күңелен биздереп куйганнар иде.

Ә 1935 елның 3 июлендә Рауза ир бала тапты.

***

Гайнан белән Абдулла листовкаларын язып бетерделәр дә әле һаман да койкасында яткан Мусага борылдылар.

– Шигыреңне тиз яздың, ахры, Муса абый? Баядан бирле тик ятасың, – диде Гайнан, тирән уйларга чумган Мусаны сискәндереп.

– Ә-ә... Юк, егетләр, бүген язылмый. Бетереп булмас, ахры, – диде Муса, торып утырып. – Ә сезнең ничек? Берәр нәрсә чыктымы?

– Менә, укып кара әле. Булды шикелле, – дип, Гайнан кәгазен аңа тоттырды.

Муса кәгазьне алды да, тынсыз гына, язуны укып чыкты.

– Булган бу, егетләр, – диде ул. – Моны хәзер кеше танырлык итеп, басма хәрефләр белән күчереп язарга кирәк. Бер-ике җирен рәтләп җибәрәсе бар бугай. Менә карагыз әле, «Кызыл Армия фашистларны Идел аръягына чыгармас өчен, Сталинград астында каты сугыш алып бара», дигәнсез. Немецлар өчен бу сугышта җиңүнең әһәмияте нидән гыйбарәт булуын күрсәтергә кирәк түгел микән? Аларны бит Иделгә чыгармау гына Кызыл Армия алдында торган бурыч түгел. Сугышның масштабы киңрәк. Фашистлар бу сугышта Иделне генә түгел, Дон үзәнен дә кулларына төшерергә, Мәскәүнең СССРның үзәк районнары белән элемтәсен өзәргә, аннары бай нефть ятмалары булган Кавказны басып алырга ният тоталар. Менә шуларны да өстәп язганда, бик әйбәт листовка килеп чыгачак. Егетләр, нишләптер кәеф китеп тора. Мин нәүм базарына китим булмаса. Сез үзегез рәтләп бетерегез инде.

– Яхшы, үзебез карап бетерербез, сез ял итегез, Муса абый, – дип, Гайнан кәгазьне кире алды. Муса: «Тыныч йокы, егетләр», – дип, ятагына ауды.

13

«Аерылу» шигырен икенче көнне дә язып бетерә алмады Муса. Ул әле һаман да кичәге уйларыннан арына алмый иде.

Рауза улына Альберт исемен үзе кушты. Альбертка җиде яшь тулды быел. Мәктәптә укыйдыр инде. Улы белән бер тапкыр да очрашып, аның белән сөйләшкәне дә, уйнатканы да булмады бит аның. Рауза Мусага бик нык үпкәләде. Үпкәләргә сәбәбе дә бар иде шул. Муса башта аның балага узганлыгын белмәде. Яңа елга кайткач, «ирең башка кызлар белән чуала» дигән сүзләргә хәтере калган хатын очрашырга да теләмәде ул чакта. Ә үзе көмәнле булган икән. Муса әллә ничә мәртәбә күрешергә теләп, артыннан барса да, якын җибәрмәде. Ләкин Мусаны ялгызлык тәмам туйдырган иде инде. Ул, өйләндем, инде гаилә тормышым башлана, дип канатланып йөрсә дә, Рауза никахлашкан көннәрдә үк аңа ияреп Мәскәүгә китми калды. «Үзеңнең дә яшәргә урының юк, кеше почмагында йөрисең, башта фатир ал, аннары күчеп килермен, җәйгә чыккач», – дип, Казанда калды да, шушы хәлләрдән соң Мусага борылып та карамады. Муса баштарак бик борчылган иде, соңга таба кул селтәде. «ЗАГСка барып язылышмаган ич алар, башка егете булгандыр. Кем белән нинди хәл булмый, дип, җиңелрәк карады. Ә беркөнне шулай Раузаны килештереп булмасмы, дип, Казанга кайткач, телеграфта күптән күзе төшеп йөргән танышы Зәкияне очратты.

Зәкия белән алар әле «Октябрь баласы»нда эшләгән чакта очрашканнар иде. Донбасста яшәүче Зәкия исемле бер кыз, журналда бастырыгыз әле, дип, шигырьләр җибәргән иде. Муса аларны укып чыкты да: «Акыллым, шигырьләрең ошады. Без аларны журналда бастырып чыгарырга булдык. Фотосурәтеңне җибәр», – дип җавап хаты язды. Җавап озак көттермәде. Конверт эчендәге кыз сурәтен күргәч, Муса шундук аңа читтән торып гашыйк булды. Гашыйк булмаслык түгел – кыз чибәр, сөйкемле һәм алма кебек тулып пешкән иде.

Зәкия Казанда туып үскән кыз икән. Аңа унөч яшьләр тирәсендә, әти-әнисе Донбасс якларына күчеп киткәннәр. Зәкия шунда Кузнецк дигән шәһәрдә укытучылар техникумында укыган. Ә бераздан аларның гаиләсе киредән Казанга әйләнеп кайткач, Зәкия телеграфта өйрәнчек булып эшкә урнашты. Бу 1932 ел ахырлары иде. Муса эшләгән «Октябрь баласы» журналы Казанга күчерелеп, аның редакция оештырырга дип Казанга кайткан чагы иде. Журналга редактор һәм башка җаваплы хезмәткәрләр табарга кирәк. Муса шунда ук Зәкияне искә төшерде. Редактор ук булмаса да, җаваплы сәркатип урынына бер дигән кадр», дип уйлады. Ул аны эзләп, телеграф урнашкан бинага килде. Вахтёрдан: «Зәкия Садыйкова исемле кыз биредә эшлиме?» – дип сорады.

– Көтеп торыгыз, хәзер чакырам, – дип, вахтёр хатын өске катка менеп китте. Озак та үтмәде, баскычтан бәләкәй генә, бөтерчек шикелле түгәрәк бер кызның тәгәрәп төшкәне күренде.

– Кем мине сорый? – диде ул, баскытан төшеп җитмәс борын. Үзе аста торган егетне шундук танып алды. «Бәрәч, Муса Җәлил ич бу!» – дип уйлап куйды һәм, телеграф аппаратын көйләп ятканда, машина маена буялган кулларын сөртергә дә онытканын аңлап, читенсенеп, кулларын артка яшерде. Аннары аптыраулы, сөенечле тавыш белән:

– Муса абый, исәнмесез?! – дип исәнләште.

– Менә нинди икән син! – диде Муса, сокланuын яшермичә.

– Нинди?

– Кечкенә генә.

– Кечкенә дә төш кенә!

– Анысын күрербез, – диде Муса.

– Күрсәтсәләр күрерсез.

– Бүген мин сине бер очрашуга чакырсам, килерсеңме?

– Нинди очрашудыр бит.

– Казанда «Октябрь баласы» журналы ачыла. Казан яшьләрен җыеп, шул турыда сөйләшәбез.

Матур кызлар күрсә, шундук йөрәген йөгәнли алмаган Муса бу юлы да Зәкиягә гашыйк булды да куйды. Аннан соң шактый вакытлар Мәскәү–Казан арасында Муса белән Зәкиянең йөрәк серләрен саклаган хатлар йөрде. Муса бер кайтканда Зәкиягә, әйдә, өйләнешик, дип, тәкъдим дә ясап карады. Ләкин Зәкия, кайда торырбыз, мин – Казанда, син – Мәскәүдә, фатир ал башта, аннан карарбыз, дип, төпле генә торыр урыны булмаган, әле тулай тораКта, әле кеше почмагында яшәп көн иткән Мусага мәсьәләне кабыргасы белән куйды. Шуннан соң аралар беркадәр суынган кебек булган иде. Тиз гашыйк булучан Мусаның Зәкия белән булган соңгы сөйләшүеннән соң әле тагын әллә ничә кызга күзе төште. Ул өйләнергә кирәк дигән ныклы карарга килгән иде. Утыз дүртенче елда татар театры Мәскәүгә гастрольгә килгәч, Рауза исемле артисткага гашыйк булуы соңгысы иде. Ләкин Рауза белән аерылышып, Зәкияне кабат очратканда, ул Раузаның көмәнле булып калуын да, Мусадан бәби табуын да, ул бәбинең инде ике айлык булуын да белми иде шул.

Муса сентябрь аенда, Зәкияне әти-әнисеннән сорарга дип, соңгы тапкыр Казанга кайтты. Ләкин Зәкиянең үз туксаны туксан. Шулай да кызның әнисе, Муса бик гозерләнеп ялынгач, күршедән бер бабайны чакырып никах укытты. Ә Зәкия белән Муса, такта белән генә бүленгән икенче бүлмәдә шырык-шырык көлешеп, аларны тыңлап утырдылар. Муса ул кичне кыз өендә кунарга калды. Берничә көннән кабат Мәскәвенә китеп барды.

Ә бер кавым вакыт үткәч, Зәкия үзенең күптәнге танышы Раузаның Мусадан бала табуы турында ишетте. Муса Зәкияне алырга дип Мәскәүдән Казанга кайтса, анда аны һушын алырлык яңалык көтә: ул Альберт исемле малайның атасы, имеш! Зәкия исә, Рауза шикелле үк, үпкәләп, чемоданнарын тутырып, үзенең балачак дусты янына Ташкентка ук китеп барган. Муса бу юлы да Ташкентта икенче баласы – кызы Люциянең тууын белмичә кала.

Зәкия белән алар шулай кушылмыйча да диярлек аерылдылар.

Инде нишләргә? Мусага утыз яшь тулды. Ул – әле чынлап торып гаилә дә кормаган килеш, ике баланың атасы. Альбертын белсә дә, Люциясе турында берни дә белми, чөнки Зәкия китте дә югалды, бернинди хат-хәбәре юк. Әнисе берни сөйләми, хәер, үзе дә белми иде бугай.

Мәскәүдә Муса күптәннән инде Әминә исемле кыз белән очраша иде. Баштарак аларның танышлыгы тирән мәхәббәт белән бәйләнмәде дә. Әминә – Казанда туып үскән кыз. Алар өч туган – апасы, энесе һәм үзе – өчесе дә, Казаннан Мәскәүгә килеп, югары белем алганнар. Соңыннан балалары янына әти-әниләре дә күченгән. Мәскәү астындагы Загорянка бистәсендә яшиләр. Әминә төзелеш оешмасында техник-конструктор булып эшли. Сөйкемле генә кыз. Мусага мәхәббәте сизелеп тора. Мусаның гына күңеле һаман сайлана, принцесса килеп чыкканын көтә. Ә ул принцессалар дигәне гел горурлар, борыннарын югары тоталар. Аларга егете дә булсын, фатиры да булсын, дан-дәрәҗәсе дә. «С милым и в шалаше рай» дигән

урыс әйтемен ишеткәннәре дә юктыр, күрәсең. Ике тапкыр уңышсыз никахтан соң, Муса, бүтән эзләнмәскә, дигән карарга килде. Тотты да тәкъдим ясады Әминәгә. Ә Әминә шуны гына көтеп йөргән – бернинди никах та кирәк булмады, ЗАГСка барып, кушылуларын рәсмиләштереп куйдылар да, Мусаның шул сигез метрлы кысан, тар бүлмәсендә яши дә башладылар. Альбертка – ике, Люциягә бер яшь тулган тирәләрдә Мусаның үзенә охшаган һәм туп шикелле түгәрәк, алма кебек алсу йөзле, орчык кебек кенә бәләкәч кызчык – Чулпан дөньяга килде. Әминә Мусаның барлык мәҗараларын яхшы белсә дә, бернинди үпкә-көнләшү күрсәтмәде, ир кеше өчен бер дигән иптәш булып чыкты.

***

Менә хәзер, Муса Демблин крепость-лагереның кысан, тар камерасында утырганда, үзенең сөеклеләрен – хатыннарын һәм балаларын уйлады. Аларның «хәбәрсез югалган», бәлки әле тагын да хәтәррәк «сатлыкҗан» дигән яманаты чыккан гөнаһ иясе ирләре – Муса Җәлилнең, хатыннары булулары аркасында нинди җәфалар, михнәтләр күреп яшәүләрен уйлап борчылды. Мусаның авыр уйларга чумып утыруын бүлмәдәшләре дә күрде, ләкин берни сорашмадылар, борчымадылар да... Ул аларга «Аерылу» дигән шигырь язуы турында әйткән иде, бары тик шул сөйгән хатыныннан, сөекле кызыннан аерылу хәсрәтеннән тирән уйларга чумгандыр, дип кенә фаразладылар бугай.

Муса, ниһаять, карандашын алып, башлаган шигырен язарга кереште. Аерылган, ераkта калган кадерле кешеләрен сагыну хисләре аның күңелендә мөлдерәмә булып тулган иде, ул сүз арты сүз, юл арты юл язып, тиз арада шигыренең соңгы җөмләсенә нокта да куйды.

...Күп татыдым җирдә мин ачысын
Үзәк өзгеч авыр сагышның.
Елатып һәм кайнар үбештереп,
Дустым белән, язмыш, кавыштыр!

Айлар түгел, еллар... авыр хәсрәт
Тавы булып торды йөрәктә.
Бер минутлык күрешү бәхете белән
Инде, язмыш, мине бүләклә!

– Булды бу, – дип, тирән сулап куйды Муса, дусларына карап. – Ә сезнең эшләр кайсы тирәдә?

– Утырабыз менә, көтеп, кайчан ашарга кертерләр икән, дип?

– Бәй, әле ашарга да кертмәдемени теге шымчы егетебез?

– Юк шул, онытты.

Шуны гына ишеткәндәй, әллә уйлары барып җиттеме, камераның авыр тимер ишегенең эшермәсен кузгаттылар. Шыгырдап ишек ачылды һәм өчесенә бер мискигә салган баланда белән чәйнек күтәргән Баязит күренде.

– Әллә безне онытттыңмы дип торабыз? – диде Баттал.

Баязит дәшми-тынмый гына җамаякларына аш салып чыкты.

– Минем йомышны үти алдыңмы, Баязит дус? – дип, Муса кәгазь турында искә төшерде.

– Юк шул, мөмкинлек чыкмады, – диде Баязит.

– Алайса, менә бу кәгазьне минем сәндерә күршесендә, аста ятучы Гарәф атлы егеткә бирә алсаң, әйбәт булыр иде.

– Нинди кәгазь соң ул? Немецларга каршы язылган нәрсә түгелме? – дип төпченде Баязит.

– Курыкма, шигырь бу. Сөекле хатыннарыбызны, балаларыбызны сагынып язган шигырь генә.

– Шигырь генә булса ярый, тапшырырмын. Листовка яза күрмәгез тагын, сез шагыйрьләрдән барысын да көтәргә була. Башны бетертәсез аннары.

– Кемгә кирәкле баш соң ул? Монда безне барыбер ачтан үтерәчәкләр, – диде Гайнан. Күрмисеңмени, көн саен күпме кеше кырыла, мур урынына?!

– Мин үлмәм, минем эшләр көйләнде хәзер, – диде шымчы.

– Кеше өстеннән әләк-мазар ясап йөрсәң, тамагың тук килеш тә үлеп китүең бар, туганкай, – диде Баттал, егетне куркытырга теләп.

– Мин кеше сатмыйм, Аллага шөкер.

– Сатма шул, бездән дә сиңа шул киңәш.

– Ярар, бир шигыреңне, Муса абый. Шулай да сезнең хакта бик сорашалар комендатура кешеләре.

– Ә син нәрсә дисең инде?

– Нәрсә дим... Берни дә белмим, берни дә күрмәдем, дим.

– Молодец, һаман шулай дип җавап бир. Без дә берни язмыйбыз, эшләмибез дә ул фрицларга каршы. Белеп тор, яме, туганкай, – дип, Муса аңа шигырен суздыы.

Баязит камераны җыештыргалаган арада егетләр, баландаларын чөмереп, кибәкле ипи кыерчыгы белән яшькелт төстәге сыек чәйләрен эчеп тә куйдылар. Баязит, озак маташмыйча, чәйнек белән мискине алып чыгып та китте.

– Шигыреңне безгә укымадың, Муса абый, – диде Баттал. – Берсенә дә бирмичә, юкка чыгарса?

– Чыгармас, белербез нишләткәнен.

– Ничек? Әйтер дисеңме?

– Мин анда шигырьнең урта бер җиренә бер куплет итеп Гарәфкә записка да яздым. Ул Баязит аркылы җавабын бирергә тиеш.

– Башың эшләгән. Шулай да, рисковать иткәнсең.

– Курыкма, Баттал дускай, минем, үзең әйтмешли, әлегә, Ходайга шөкер, баш эшли. Шигырьне икенче кәгазьгә күчереп алдым мин.

Уналтынчы елда туган Баттал, сугыш башланганда, инде егерме биш яшендә булса да, әле өйләнергә өлгермәгән. Армиядә хезмәт иткән чагында ул аягын авырттырып, гарипләнеп кайткан. Аннан соң сугыш башланды. Гарип булса да, үз теләге белән фронтка китеп барды. Чолганышта калып, аңын югалткан килеш, кышкы салкында ятып, аяк бармакларын өшетте. Әсирлеккә төште. Лагерь лазаретында аның уң аягының бармакларын кистеләр. Аксап-туксап кына йөрсә дә, егет беркайчан төшенкелеккә бирелми иде. Лагерьда ул, урыс әйтмешли, «Первый парень в деревне!» булды. Һәрчак күңеле – көр, теле – җор, хисчән егет иде. Абыйсы Салих Баттал кебек үк шагыйрь булмаса да, яттан күп шигырьләр белә. Кич җиттеме, шигырь сөйләп, әсирләрнең күңелен күтәрде.

– Шигырь китте сәяхәткә. Ә листовканы нишләтәбез, егетләр? – диде Муса. – Бу малайга биреп булмый. Укып караса, сатачак. Күренеп тора.

– Шулайрак шул. Көтик әле, берәр җае чыкмасмы, – диде, үзен-үзе юаткандай, Гайнан.

– Нишлисең, көтәргә инде.

Камерада утырганда, Муса тагын озын-озын өч шигырь язды. Иркенләп, ашыкмыйча язарга вакыт та күп, комачаулаучы да юк иде. Күңелдән бикләп калган элегрәк язган шигырьләрен дә искә төшереп, кәгазь битенә күчерде. Баязит икенче көнне Мусага берничә бит кәгазь алып керде. Аның Баязит аркылы Гарәфкә язган заданиесе шул иде. Шымчы, мескен, үзе дә аңламыйча, Мусаның йомышын үтәгән булып чыкты.

Аларны камерада озак тотмадылар. Нәкъ ике атна дигәндә, башка әсирләр арасына чыгардылар. Һәм икенче көнне үк, әсирләрне легионерлар итеп теркәп, төрле лагерьларга бүлгәләү башланды.

14

Әхмәт Тимер һәм Шәфи Алмас белән очрашудан соң, Муса гел Алиш турында уйлап йөри башлаган иде. Хәзер кайда икән соң Алиш? Легионга язылды микән, юк микән? Нишләп аны искә төшерделәр икән? Бер әйткәч, нишләп очраштырмыйлар? Мусага әнә шундый сораулар тынгы бирмәде.

Шәфи Алмас, чынлап та, Алишны күргән иде. Ләкин аның легионга язылуы турында сүз Шәфинең шыттыруы гына. Алиш белән ул Седльце лагеренда очрашты. Демблинга килер алдыннан гына Шәфи Алмас, Гайнц Унгляубега иярeп, легионга язылырга өндәп, төрле лагерьлар буйлап йөреп чыктылар һәм Седльцеда да булганнар иде. Биредә комендатурада аларга Абдулла Алиш исемле татар язучысының әсирлеккә төшүе турында әйттеләр. Шәфи Мусаны агитлаганда, аның якын танышы булган Алиш исеме белән хисләрендә уйнап алырга ниятләгән иде. Алар ул чакта Алишны да легионга язылырга кыстадылар. Алиш Шәфине язучы буларак кызыксындырды. Аңа «Идел-Урал» гәзитәсен чыгарыр өчен хезмәткәрләр кирәк иде. Алишны ул бу эш өчен бер дигән табыш дип күрде. Комендатурада әсирләр белән очрашуда Фуат Булатов, Кави Ишмурзин исемле тоткыннар да бар иде. Шәфи гәзит чыгару өчен язучылар гына түгел, хәреф шомартучылар, типография эшчеләре дә кирәк булачак, дип, аларны да бу эшкә тартырга маташты.

***

Сугышның беренче айларында ук үз теләге белән фронтка киткән Алиш, өч ай үтүгә, Брянск тирәсендә барган каты сугышларда Десна яры буенда дошман тылында чолганышта калып, каты яраланган хәлдә әсирлеккә төшкән. Литвадагы Алитус шәһәрендә, Чехословакиядә, Германиядә, Польшаның Краков лагерьларында булганнан соң, 1942 елны ул Седльцега күчерелгән. Бирегә китерелгәндә, инде ул тәнендә чыкмаган җаны гына калган, чирле, зәгыйфь бер күләгәгә әйләнгән иде. Бәлки, озак та тормыйча, җан тәслим дә кылган булыр иде, язучы икәнлеген белеп, «Идел-Урал» легионында хезмәт итәргә бер дигән кандидат булуын истә тотып, аңа мөнәсәбәт беркадәр яхшы якка үзгәреп китте. Ләкин бу көннәр килгәнче, Алишка Седльцеда бик күп михнәт чигәргә, лагерь тормышының бөтен авырлыкларын татырга туры килде әле.

Лагерьда хәллерәк әсирләрне Польша паннарына хезмәткә йөртәләр иде. Алар анда ашап-эчеп, тамакларын туйдырып кайталар. Мөмкинлеге булганнары лагерьда калганнар өчен дә калдык-постык ризыклар кыстырып кайтырга тырыша. Ләкин Алиш, лагерьдан лагерьга йөреп, тәмам сәламәтлеген какшаткан, кемгәдер хезмәтче булып эшләрлек рәте юк иде.

Көннәрнең берендә Алиш үзе белән бер бараста тотылучы Газыйм исемле егет белән танышты. Газыйм аның юл биштәреннән кәгазь, карандаш чыгарып, нәрсәдер язып утырганын күрде дә: «Хат язасызмы әллә?» – дип кызыксынды.

– Хат түгел, әкият язам, – диде Алиш.

– Әкият? – дип гаҗәпләнде егет.

– Әйе, әкият.

– Нәрсә турында, сер булмаса?

– Сер түгел. – Алиш, кәгазь белән карандашын бер читкә куеп, күңелдән

генә яза торган әкиятенең эчтәлеген сөйли башлады. – Бер урманда, агач төбендә, үзенә оя ясап, бер елан яшәгән ди. Көннәрнең берендә бу еланны оясы янында керпе күргән дә, мине дә үз яныңа яшәргә керт әле, дигән. Елан риза булган. Шуннан соң болар икесе бер өндә яши башлаганнар. Ләкин бу керпе бигүк яхшы күңелле булмаган ди. Ул энәләре белән еланны чәнчи икән. Елан ризасызлык күрсәтсә дә, керпе аны чәнчүдән туктамаган, җае туры килгән саен, аңа кадалуын дәвам иткән. Шуннан соң елан, керпенең үзен генә калдырып, оясыннан чыгып китәргә мәҗбүр булган. Менә шундый әкият.

– Кызык. Ә кем өчен язасыз инде бу әкиятне?

– Ничек кем өчен? Балалар өчен.

– Немец балалары өченме?

– Нишләп немец балалары өчен булсын, татар балалары өчен. Минем Казанда ике улым калды. Шулар өчен.

– Сез язучымыни?

– «Сертотмас үрдәк» әкиятен ишеткәнең бармы?

– Бар, булмыйни. Әллә ул әкиятне дә сез яздыгызмы?

– Мин яздым. «Нечкәбил»не дә, «Алтын әтәч»не дә.

– Сез әллә язучы Абдулла Алишмы?

– Шул үзе.

– Менә бит, нинди кеше белән очрашканмын икән! Сезне бит, сугышка җибәрмичә, кадерләп саклап кына тотмалы булган! Балалар өчен иң кадерле кеше бит сез, Абдулла Алиш абый! Сезне танырлык та түгел, йөзегезне сакалмыек баскан. Күптән кырынганыгыз да юк, ахры.

– Язучылар, сугышка бармыйча, өйдә качып ятсалар, кем сугышыр соң ул фашистлар белән?! Без, татар язучылары, барыбыз да үзебез теләп фронтка киттек.

– Ә бу хәшәрәтләр, язучы икәнегезне белмичә, нинди михнәт күрсәтеп яткыралар шушы тәмуг оясында. Бертуган әкиятче Гриммнарның әкиятләрен укып үскәннәрдер бит инде ул мәнсезләр дә.

– Бәлки, укыганнардыр.

– Сезнең әкиятләр бит Гриммнарныкыннан бер җире белән дә калышмый, Абдулла абый. Сезнең «Ана әкиятләре» китабыгызда нинди кызык әкиятләр!

– Укыдыңмыни?

– Укыдым. Улларыма укыдым. Минем дә бит авылда ике улым калды. Шуларга дип алып кайткан идем. Әниләре укыйдыр инде хәзер. Кahәр суккан сугыш башланды бит. Әйләнеп кайтып та булмас инде.

– Кайтабыз әле без... Карале, исемең кем булды инде, танышмадык та.

– Газыйм минем исемем, Абдулла Алиш абый. Якташлар без сезнең белән. Иделнең сул ягында – сезнең Болгар, уң ягында – безнең Апас. Апас районының Куллар авылыннан мин. Монда әле тагын бер якташыбыз бар – Кайбыч егете, Янсурино авылыннан керәшен Володя Мершинов.

– Менә бит, Җир түгәрәк түгел димә син. Җәһәннәм чигенә китереп тә күрештерә.

– Мин сезне, Абдулла Алиш абый, күптән күзәтеп йөрим инде. Беркөнне базарда пәке сатып утырганыгызны да күрдем. Кулыгыз эш белә икән. Алдылармы соң?

– Юк шул. Менә ул, үзем белән йөри. – Алиш юл капчыгыннан бер җәбе пычак, бер җәбе кашык итеп ясалган сөяк саплы пәке чыгарды. – Алмасалар, үземнән дә артмый әле. Ашарга гына юк менә.

– Абдулла Алиш абый...

Газыйм сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, Алиш аны, бүлдереп:

– Абдулла Алиш абый да Абдулла Алиш абый дисең. Берсен генә әйт әле. Алиш абый дисәң дә җитә бит.

– Шулай инде анысы. Әллә ничек бит, сез олы язучы. Ярар алайса... Алиш абый, сез поляк паннарына эшләргә дә йөрмисез, лагерь баландасы белән генә тамак туймыйдыр шул. Моннан соң мин сезнең өчен хуҗалардан калган ризыкларны кыстыргалап кайтырмын әле.

– Начар булмас иде. Рәхмәт инде, хәлгә керергә тырышасың.

– Алиш абый, әйдәле, бер җиргә барып килик.

– Кая?

– Барак артында ашханәнең чүплек базы бар. Шунда ашарга яраклы нәрсәләр дә ыргыткалыйлар, хәшәрәтләр.

Алар, баракдан чыгып, сак кына як-якка карангалап, ашханә артына юнәлделәр. Чүп өемнәре өстендә чынлап та бер күч бәрәңге кабыгы аунап ята иде. Ләкин баз чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган койма артында. Чыбык аша кулны сузып, җыеп алырга буладыр да, ләкин чыбыкка кул тисә, эш харап, сигнализация эшли башлый. Койманың теге башындагы каланчага менеп баскан сакчы, качучылар дип уйлап, атып үтерергә дә бик мөмкин. Шулай булып чыкты да. Дөрес, атмадылар атуын, ләкин ике әзмәвер килеп, типкәли-типкәли, аңнарын югалтканчы кыйнадылар. Аннары нәрсәдер сүгенделәр-сүгенделәр дә ашханә подвалына сөйрәп илтеп ташладылар. Аңнарына килгәндә, подвал эче кап-караңгы булган, төн җиткән. Җитмәсә, идәне сулы икән, киемнәре лач су, күшеккән тавыкка әверелгәннәр иде. Шуның өстенә авыртмаган җирләре юк.

– Алиш абый, син исәнме? – дип тавыш бирде Газыйм.

– Исән бугай. Нык кыйнаганнар, каһәрләр. Баш чатный. Бөтен җир авырта.

Алар, башларын күтәреп, бер-берсенә караштылар. Киемнәре пычрак инде, анысы аңлашыла, битләре дә шакшыга каткан иде.

– Монда су җыелып тора, шуның белән битләрне юыйк булмаса, – диде Алиш.

Битләрен юарга да өлгермәделәр, подвал ишеге ачылды. Ахрысы, сөйләшкәннәрен ишеткәннәр, бер немец сакчысы кереп: «Russische Schweine!» – дип акырды.

– Урыс дуңгызлары, ди, – дип тәрҗемә итте Алиш. – Тагын кыйнарлар микән инде?

Немец подвал утын кабызды. Сүрән генә яна торган лампа икән. Ул арада фриц кесәсеннән зуррак лампочка чыгарды да, сүрән яна торганын борып алып, шунысы белән алыштырып куйды. Ул прожектор шикелле яп-якты нур сибә башлады.

– Schau dir das Licht an![12] – дип кычкырды фриц.

Күзне сукырайта торган яктылык иде бу. Утка карамасаң да, күз каралары зураеп, берни күрми торган булып калды. Немец кычкырып көлде дә подвалдан чыгып китте, һәм ишекне бикләп куйды.

– Фашист тек фашист! – диде Алиш. – Кайчанга кадәр тотар икән инде бу безне шулай?

– Иртәнгә хәтле инде. Күзләрне йомып, уч төбе белән капларга кирәк. Югыйсә сукыр калабыз.

Алар, шушы хәлдә, аякларына чүгәләп, төнне үткәрергә мәҗбүр булдылар. Ләкин фашистның җәзалавы моның белән генә бетмәгән икән әле. Иртән подвал ишеген киереп ачты да: «Willst du essen?[13] – дип сорады.

[12] Утка карагыз! *(нем.)*
[13] Ашыйсыгыз киләме? *(нем.)*

– Әллә иртәнге ашка чакыра инде? – дип куйды Алиш.

– Мәрхәмәте килгәндер, бәлки, – диде Газыйм. – Ай-һай, килде микән?!

Фриц аларны урамга алып чыкты, кулларына котелоклар тоттырды.

– Mit kleinen Steinen füllen![14] – дип боерды һәм вак таш сибелгән ком өстенә тезләндерде. – Һier ist ein Durcheinander![15] – дип шаркылдап көлде.

Ул көнне алар бөтенләй ач калдылар. Газыйм да көндәгечә поляк байларына хезмәткә бара алмый калды. Көне буе мүкәләп җыйсалар да котелокларын вак таш белән тутыра алмадылар. Аның каравы Алиш Газыймга үзенең шигырьләрен сөйләде. Кайта-кайта сөйләде. Газыймның хәтере яхшы булып чыкты, тиз ота торган сәләте бар икән. Алишның әллә нихәтле шигырен ятлап алырга өлгерде.

– Мин боларны бер дәфтәргә күчереп куям әле, – диде ул.

– Бик әйбәт булыр. Исән-сау илгә әйләнеп кайтсаң, Рокыяма илтеп тапшырырсың. Рокыя – хатыным ул.

– Үзегез дә кайтырсыз, Алла боерса, Алиш абый, – диде Газыйм.

– Бирсен Ходай. Ләкин ни булмас бу хәшәрәтләр илендә. Ә болай ышаныч арта. Беребез булмаса, беребез алып кайтыр шигырьләрне.

15

Әгәр дә дөньяда тәмуг бар икән, ул, мөгаен, шушы Седльце лагередыр, дип уйлый башлады Алиш. Моңа кадәр күпме лагерьда булып та, биредәге вәхшилекне, мондагы явызлыкны ул беркемнән дә күрмәде. Фашистлар аеруча мәрхәмәтсез, кешелексез булып тоела башлады аңа.

Каян килә кешегә шул кадәрле явызлык? Ә бит Германия дөньяда СССРдан соң икенче булып социализм юлыннан китәр дип көткәннәр иде алар моннан егерме еллар элек кенә. Эшчеләр азатлыгы өчен көрәшү идеясе беренче булып шушы илдә туган бит. Социаль-демократик хәрәкәт теоретиклары Карл Маркс белән Фридрих Энгельс шушы илдә яшәгәннәр. Карл Каутский, Роза Люксембург... Революцион хәрәкәт теоретиклары булган әлеге күренекле немецлар. Барлы-юклы ике дистә ел эчендә ничек итеп җәмгыять тормышы асты-өскә килеп үзгәрергә мөмкин? Революцион хәрәкәтләрдә кайнаган бер генә кеше дә калмады микәнни бу Германиядә?

Алишның башында шундый сораулар кайнады. Немецларның бу кадәр мәрхәмәтсез булулары һич кенә дә аның аңына барып җитә алмый иде.

Әле ярый арада Газыйм кебек мәрхәмәтле кешеләр очрый. Ләкин алар да бу тәмуг оясында бер көн дә тормыйча, мөмкинлек чыгуга качып китәрләр иде. Тик бу мөмкин түгел – әсирләрне бик нык каравыллыйлар. Аз гына шикле күренгәннәрне, бигрәк тә качу турында уе булганнарны сизенсәләр, шундук атып үтерәләр иде. Алиш та мәгънәсез үлемнән берничә мәртәбә чак котылып калды.

Беркөнне шулай бараста ялгызы гына калырга туры килде. Хәллерәкләр поляк паннарына хезмәткә китте. Калганнарны да, лагерь тирәсендәге вак-төяк эшләргә кушып, барактан алып чыгып киттеләр. Алиш, ялгызлыктан файдаланып, юл биштәреннән кәгазь һәм каләм чыгарып, шигырь язарга ниятләде. Ул күптәннән инде күңеленнән хатыны Рокыяга багышлап иҗат итә башлаган шигырь юлларын кабатлап йөри иде. Утырып язарга гына ничек тә җай таба алмый изаланды. Бүген менә шул җай чыгып тора. Беркөнне генә

[14] Вак таш белән тутырыгыз! *(нем.)*

[15] Менә сезгә ботка! *(нем.)*

кулына килеп кергән листовканың буш җиренә: «Тормыш иптәшем Рокыяга багышлыйм», дип язып куйды.

Син идең ул минем мәхәббәтем,
Күктә янар якты йолдызым.
Мин табындым сиңа, бары сиңа,
Оныттым мин хәтта җир йөзен...

Алиш, шушы урынга хәтле, кәгазьдән карандашын алмыйча да диярлек, тукталмыйча язды. Инде ничә көн шушы турыда уйлап йөргәнгәме, шигырь юллары чишмә кебек, үзләреннән үзләре агылды.

...Уйлар Алишны ераккa, хатыны Рокыя белән уллары Айваз һәм Алмаз янына алып китте... Әтиегезнең фашист әсирлегендә җәфа чигүен белмисездер. Инде бер ел араларда хатлар да йөрми. Бәлки, үлгән дип уйлыйсыздыр. Бер елда олы егетләр булып үскәнсездер...

Алиш шулай, дөньясын онытып, татлы уйларга чумып утыра иде, янына автомат тоткан ике сакчының килеп басуын сизмичә дә калды. Аларның берсе: «Schreibt eine Broschüre!»[16] дип кычкырып җибәрде һәм Алиш кулындагы кәгазьне йолкып тартып алды. Икенчесе, әшәке итеп сүгенеп, автомат түтәсе белән карандаш тоткан кулына тондырды. Алиш авыртудан кычкырып ук җибәрде.

Фрицларның кәгазьне алганы аны икенчесенә сузып:

– Lesen![17] – дип боерды.

Тегесе фриц киемнәрен киеп алган урыс булып чыкты. Кәгазьне әйләндергәләп карады да, листовка икәнен аңлап:

– Это листовка... Dies ist ein Flyer, – диде.

– Сатлыкҗан икәнсең, кahәр! Шулхәтле каты итеп сукмасаң! – дип куйды Алиш, авырткан кулын кочаклап тоткан килеш.

Фриц кәгазьне, тартып алып, тагын бер кат әйләндергәләп карады да, басма хәрефләр белән язылган текстның чыннан да листовка булуын аңлап, икенче яктагы карандаш белән язылган сүзләрне укытырга дип, сатлыкҗанга кире бирде.

– Und hier das?[18]

Тегесе кулдан язылган, җитмәсә татарча текстны көч-хәл белән генә танып, хәрефләп диярлек укый башлады.

– Син иден ул минем махаббатем,

Куктэ янар якты йолдызым...

Дерселве верс, майн hepp![19]

Фриц листовкада нәрсә турында язылганлыгы белән кызыксынды.

– Рус Азатлык Армиясенә агитация, – диде сатлыкҗан.

– Was der Dichter schreibt?[20]

– Über den Stern mein Lord[21].

Урыс сакчының тәрҗемәсе фрицка ошады булса кирәк, ул, кәгазьне Алишка кире бирeп, иптәшенә үз телендә нәрсәдер әйтеп шаркылдап көлде дә, баракtан чыгып киттеләр. Сатлыкҗан гына, ишектән чыкканда:

– Листовка язма дип әйтә! – дип кычкырды.

[16] Листовка яза! *(нем.)*
[17] Читай! *(нем.)*
[18] Ә монда нәрсә? *(нем.)*
[19] Бу бит шигырь, әфәндем! *(нем.)*
[20] Нәрсә турында яза шагыйрь? *(нем.)*
[21] Йолдыз турында, әфәндем. *(нем.)*

– Бөтен уйларны чуалттылар, хәшәрәтләр, – дип, үз алдына сөйләнде Алиш. – Идея әйттеләр бит әле болар! Яңадан кереп тикшермәсләр, шәт иншалла, иркенләп листовка язарга да мөмкин хәзер, кеше-кара югында.

Алиш, биштәреннән яңа кәгазь бите чыгарып, листовка язарга кереште. «Власов армиясенә язылыгыз!», «7 ноябрьдә Сталинградта парад булачак!» дигән дошман листовкаларына җавап итеп, мондый ялганнарга ышанмаска чакырып, листовка язарга күптән уйлап йөри иде инде. Менә бит нинди җай чыгып тора. Алиш, озак уйлап тормыйча, биштәр төбенә тегелгән кесәсеннән, кадерләп саклап кына йөрткән химик карандашын алып, төкереге белән очын юешләп, өч-дүрт җөмләдән генә торган листовка язып атты.

«Ватандашлар! Дошман Сталинградны алуы турында әкият тарата. Бу сүзләргә ышанмагыз! Мәскәү астында сыртын сындырган кебек, Сталинградтан да аягын алып качачак фриц. Тиздән союзниклар икенче фронтны ачачак. Җиңү безнең якта булачак!»

Листовканы язып бетерде дә, Алиш барак ишеге янында ятучы яралы әсиргә сиздермичә генә барып, кәгазьне ишек ярыгына кыстырып куйды һәм ишегалдына юнәлде. Анда чыккач, кая сугылырга белмичә аптырап йөри торгач, Седльце базарына барып килергә булды. Седльце лагеренда шунысы рәхәт: ул ачык лагерь иде. Тоткыннарга шәһәргә чыгарга, җирле байларга, фермерларда тамак ялына эшләп кайтырга мөмкинлек бирелә иде.

Алиш баракка халык кичке ашка барырга җыенганда гына кайтып керде. Үз сәндерәсе янында ул Газыйм дусты көтеп торганын күрде.

– Исәнме, Алиш абый, – диде Газыйм. – Кайда йөрдегез? Сез югында монда ыгы-зыгы булып алды бит әле. Фрицлар бөтен баракны аякка бастырды.

– Нәрсә булды? – дип сорады Алиш.

– Кайсыдыр ишеккә листовка ябыштырып куйган.

– Нәрсә дип язганнар соң?

– «Дошман Сталинградны ала алмаячак. Тиздән икенче фронт ачылачак», дип язганнар.

– Дөресен язганнар бит. Молодцы, курыкмый егетләр! – дип куйды Алиш. – Син ашадыңмы әле?

– Чакырмыйлар бит. Ашыйсы килә инде. Бүген тамак туярлык ашатмадылар поляк паннары.

– Алайса, алар чакыргалаганчы, бер эшем бар иде. Шуны башкарып чыгыйм булмаса, – дип, Алиш, юл биштәреннән кәгазь һәм карандашын чыгарып, ижатка кереште. – Яза башлаган шигырем бар иде. Шуны бетерергә кирәк.

Ләкин аларны ашханәгә дәшмәделәр. Алиш бөтенләй ач калды. Көне буе ачлы-туклы йөреп, эштән арып кайткан Газыймның Алиш абыйсы белән сөйләшәсе килсә дә, комачауларга теләмәде. Илһам килгәндә язсын шигырен, дип, сәндерәсенә менеп ятты.

Алишның язасы шигыре күңелендә күптән туган иде инде, ул аны шушы утыруда язып та бетерде. Көндез язган өч строфасын уртада калдырып, шигырен башлап, яңадан өч куплет өстәде. Баштагы исемне багышлау итеп кенә калдырып, «Мин ул төшне кабат күрерменме?» дигән яңа баш куйды.

Язып бетергәннән соң, аның шигырен кемгәдер укып күрсәтәсе килде. Әлбәттә инде, бер генә кешегә укырга мөмкин: Газыйм дустына. Ләкин Газыйм йоклаган иде инде. Алиш түзмәде, аны кабыргасына төртеп барыбер уятты.

– Кемгәдер укымыйча түзеп булмый. Сиңа укымыйча, кемгә укыйм тагын,

тыңлале, Газыйм дус, – дип, шактый озын гына килеп чыккан шигырен бер тында диярлек укып та чыкты.

Ә Газыйм аны тын да алмыйча тыңлады.

– Озын булмаганмы? Арымадыңмы тыңлап? – диде Алиш.

– Мондый шигырьне тыңлап туймаслык? Мин дә күчереп алырмын әле, Алиш абый, – диде Газыйм.

– Күчерү генә түгел, ятлап та алырсың әле. Килешүне онытмагансыңдыр бит.

– Ятлармын, ятлармын, Алиш абый. Их, Рокыя апаның үзенә укытасы иде моны!

– Укытырбыз, исән-сау котылыйк кына бу тәмугтан. Туган илгә кайткач, бәйрәм ясарбыз әле без! Шигырьләр дә укырбыз, җырлар да җырларбыз!

...Берничә көннән лагерьга Гайнц Унгляубе белән Шәфи Алмас килеп, әсирләрне «Идел-Урал» легионына язылырга өндәделәр. Абдулла Алиш белән тагын берничә әсирне комендатурага алып кереп, аларны Германиягә, Берлинның үзенә барып, редакциядә эшләргә үгетләделәр. Лагерьда күргән мәсхәрәләүләргә түзмәгән Алиш күңеленнән редакциягә эшкә барырга, дигән ныклы карарга килде. Юк, бу аның фашистларга хезмәт итәргә дигән карары түгел иде. Ул «Идел-Урал» гәзитәсе аша легионны таркату эше алып барырга мөмкин булачак дип уйлады. Комендатурага Газыймны чакырмадылар. Алиш үз фикерен аның белән дә уртаклашты:

– Сине дә Берлинга баручылар исемлегенә керттерергә тырышырмын, Газыйм. Кирәкләрен бирербез ул фашист мәлгуньнәрнең! Безне мәсхәрәләүләре өчен үчне алырбыз әле!

Ләкин Газыймга Алиш белән бергә Германиягә китү язмаган икән. Төркемнәргә бүлеп, төрле лагерьларга озатканда, Газыймнар төркеменең Франциягә җибәрелүе билгеле булды.

– Бәлки, киләчәктә тагын очрашырбыз, Алиш абый. Мин сезнең шигырьләрне көн саен яттан кабатлыйм. Дәфтәрләремне тартып алсалар да, күңелемдә кала. Исән-сау илгә кайтырга насыйп булса, Рокыя апага илтеп тапшырырмын, Алла боерса!

– Рәхмәт, Газыйм! Мин үлсәм дә, ышанам, син исән калырсың! Шигырьләрем илгә кайтыр!

16

1941 ел ахырында Көнчыгыш легионнары төзү турында карар кабул ителеп, 1942 елның апрель азагы – май башларында Берлинның Адлон отеленда СССРдан көнбатыш илләренә эмиграциягә киткән күренекле шәрык сәясәтчеләрен киңәшмәгә җыйдылар. Ләкин анда башлыча Кавказ республикалары вәкилләре булып, Идел буе татарлары арасыннан чыккан Гаяз Исхакый, Әхмәтзәки Вәлиди кебек эмигрантлар катнашудан баш тартты. Аларның икесенең дә бу мәсьәләгә карата үз фикерләре бар иде. Киңәшмә Германиянең тышкы эшләр министрлыгы белән, басып алынган Шәрык территорияләре министрлыгы арасында барган совет әсирләрен сугышта катнаштыру мәсьәләсе буенча килеп чыккан конфликтны кискенләштерде. Бу тарткалашта Шәрык министрлыгы өстен чыгып, нигъаять, Идел буе татарлары легионын төзү мәсьәләсе уңай хәл ителде һәм көз айларында легион оештыру эшләре киң колач белән алып барыла башлады. Инде алда сөйләнеп киткәнчә,

министр Альфред Розенберг командасында эш күрсәтүче Әхмәт Тимер, Шәфи Алмас, Галимҗан Идриси, Искәндәр Яушев кебек татар эмигрантлары Берлинда «Идел-Урал» легионын оештыру комитетын төзеп, аның башлыгы итеп Әхмәт Тимер билгеләнеп, шул исемдәге гәзитә дә чыгара башладылар. Гәзитнең баш редакторы итеп комитетның башлыгы Шәфи Алмас тәгаенләнде.

* * *

«Татар барда хәтәр бар», «Татар башын татар ашар» дигән әйтемнәрне бездә бигүк яратып бетермиләр. Ләкин болар татарны мыскыл итү, кимсетеп күрсәтү өчен генә уйлап чыгарылган сүзләр түгел бугай, бәлки татар тормышын чагылдырган, татар дөньясыннан алып әйтелгән мәкальләргә охшый. Кайда гына яшәсә дә, татар интрига кормыйча, берсен-берсе юкка чыгармыйча яши алмый. Бәлки, бу башка милләтләрдә дә очрыйдыр, бәлки әле, бөтен кешелек дөньясына хас күренештер.

1942 ел ахырларында «Идел-Урал» комитеты тирәсендә дә көтмәгәндә-уйламаганда шундый ук тарткалаш булып алды. Гитлерның фатихасын алып, «Идел-Урал» комитетын төзеп, комитет каршында арадашчы дип аталган бер оешма да булдырып, колачны киң җәеп, эшне алып бара башлаган заманда, адвокат Унгляубеның уң кулы булып, комитет президенты дәрәҗәсенә ирешкән Әхмәт Тимергә бу масштаблар гына тар тоелды. Ул эшне тагын да киңрәк, колачлырак алып бару хыяллары белән саташа башлады. Мескен Гитлерның Туран дәүләте турындагы мыскыллы шаяртуын чынга алып, бу дәүләтнең дә башына менеп утырырга ниятләде, ахрысы, шул хакта үзенең ярдәмчесе Шәфи Алмас белән киңәшләшергә булды.

– Карале, Шәфи абый, бер хәбәр ишеттем: имеш, Гитлер җиңүдән соң бөтен төркиләрне берләштереп, Туран дәүләте төзергә җыена икән.

– Бик әйбәт булыр. Татар, башкорт, үзбәк, казакъ, кыргыз, балкар... тагын кемнәр бар соң әле?.. Барыбыз бер халык бит инде без – төркиләр. Безнең «Идел-Урал» да шул татар белән башкортны берләштерүне күздә тоткан нәрсә иде бит. Димәк, нимес колачлырак карый мәсьәләгә.

– Шулаен шулай да ул, кардәш туганнар үз дәүләтләрен төзү турында хыяллана бит, безнең шикелле үк. Тик Гитлер менә бернинди дә милли дәүләт булмаячак, дип әйткән, ди. «Идел-Урал»га тәрҗемә итәргә Унгляубедан килгән мәкаләдә шул турыда сүз бара.

– Алай булгач, безне нишләтәләр соң инде? Таратырлар микәнни?

– Сүз ул турыда түгел, Шәфи абый, сезнең белән киңәшмәкче идем.

– Нәрсә турында?

– Безнең «Идел-Урал» шикелле үк Төркестан комитетын төзеделәр бит. Менә шуның башлыгы – үзбәк Вәли Каюм-хан.

– Соң, ул Вәли энекәш җир читендә тормый бит, үзебезнең күршедә генә. Барып сөйләшергә, киңәшләшергә кирәк, – диде Шәфи, хуҗасына зур киңәш биргәндәй, эреләнеп. – Тагын бер кеше белән киңәшләшеп алу зыян итмәс, Әхмәт энем. Эшне колачлырак алып барырга телибез икән инде, дин әһелләре белән бергәләп алып бару мәслихәт. Менә шул: Варшауга барып, мөфти-хәзрәт белән киңәшләшеп алырга кирәк. Ул төрки легионнарны ислам нигезләрендә оештыруны хуп күрә. Аның да хуплавын алсак, Вәли Каюм-хан, һичшиксез, ризалашыр бу тәкъдимгә.

Әхмәт Тимер, әнә шулай ярдәмчесе Шәфи Алмасның хуплавын алып, тимерне кызуында сукмакчы булып, икенче көнне үк мөфти хәзрәт янына

Рәис Саматны юллады. Варшау мөселман диния нәзарәте мөфтиятендә Шәфи Алмасның тәкъдимен ике куллап каршы алдылар. Мөфти үзе дә Әхмәт Тимер шикелле үк шөһрәт, дан яратучы кеше буларак, дәрәҗәсенең тагын да күтәрелүен күз алдына китерде. Рәис Саматка, комитет башлыгының фикерен хуплавын җиткерергә кушып, озатып калды.

Ләкин Шәфи Алмас та гаять астыртын эш йөртте. Бердән, аның үзенең дә кәнәфисез каласы килми иде. Туран дәүләте төзелсә, «Идел-Урал» булмаячак дигән сүз бит. Әхмәт Тимер Вәли Каюм-хан белән сөйләшкәләгәнче, ул Төркестан комитетындагы казакъ дусларын күргә ашыкты. 1941 елның декабрендә, серле рәвештә, лидерлары Мостафа Шокай үлеп киткәннән соң, Төркестан комитетында икенче рольгә калган казакъ эмигрантлары арасында Вәли Каюм-ханны күралмаучы танышлары шактый иде аның. Шәфи Алмас алар арасында Вәли Каюм-ханның татарлар белән берләшергә ният итүләре турында коткы таратып, казакълар белән үзбәкләр арасына чөй какты. Ике арада төрле сүзләр китте. Шәфи Әхмәт Тимернең Варшау мөфтие белән сөйләшергә җибәргән илчесе Рәис Самат өстеннән гестапога яшерен донос язып, аны кулга алдырды. Мескенне чак кына концлагерьга җибәрми калдылар. Мәсьәлә Унгляубе штабында каралды. Нәтиҗәдә, Әхмәт Тимерне «Идел-Урал» комитеты президенты вазифасыннан азат итеп, аның урынына Шәфи Алмас билгеләнде.

17

Камерадан чыгарылган көнне үк, Мусаны Демблин крепосте комендантты янына алып керделәр.

– Hallo, Herr Gumerov![22]

Муса тылмач тәрҗемә иткәнне дә көтмичә җавап кайтарды:

– Исәнмесез.

– О-о, сиз немецча анлисыз! – дип гажәпләнгәндәй итенде комендант, үзе дә татарча сөйләшеп.

– Вузда укыганда өйрәндем. Безнең илләр дус иде бит.

Комендант, Мусаны аңламыйча, тылмачка карады.

– Lernte als ich in der High School war, weil unsere Länder Freunde waren, – дип тәрҗемә итте анысы.

– Natürlich, natürlich![23] – дип, комендант Муса белән килешүен белдергәннән соң, аның легионга язылу буенча нинди карарга килүе белән кызыксынды.

Муса үзенең риза икәнлеген һәм инде легионга башка әсирләрне дә язылырга агитлап йөрүе турында әйтте.

– Очень корошо! – диде комендант, урысчага күчеп. Аннары ул иртәгәдән легионга язылучыларның Вустрау лагерена күчерелүләре турында белдерде.

Муса легионга язылырга агитлау буенча тагын берничә әсир дусты булуы турында әйтте. Комендант моның өчен дә рәхмәт белдерде һәм алар белән аерым очрашып сөйләшергә теләвен, аларның исемлеген язып бирүне сорады. Шундук аның алдына кәгазь һәм каләм куйды.

Муса беркадәр уйлаган итенде дә исемлеккә Гайнан Кормашов, Абдулла Батталов, Гарәф Фәхретдинов, Рушат Хисаметдинов, Фоат Сәйфелмөлеков исемнәрен язды. Ул әле тагын берничә исем язмакчы иде дә, аларга тулысынча ышанып бетмәгәнлектән, тукталып калырга мәҗбүр булды. «Вустрауга баргач, күз күрер тагын», дип уйлады эченнән.

[22] Исәнмесез, Гомәров әфәнде! *(нем.)*
[23] Әлбәттә! *(нем.)*

Комендант, «Гут, гут!», дип, Мусаның җилкәсеннән какты да, юлга әзерләнә башларга кушып, ишектән озатып калды. Бераздан ул язып биргән исемлек буенча башкаларны да чиратлап комендант хозурына чакырдылар. Муса аларны озатканда, һәрберсенә коммунистларны артык сүкмәскә, немецлар яклы булып та артык кыланмаска, киресенчә, икеле-микеле генә сөйләшергә дип өйрәтеп калды. Арттырып җибәргәндә, фрицның шикләнеп калуы, берәр төрле астыртын зарарлы эш өчен шулай тырышулары дип уйлавы бик мөмкин иде.

Вустрау ике зонадан торган лагерь булып чыкты. Беренче зона – ябык. Ул Муса моңа кадәр күргән башка лагерьлардан берние белән дә аерылмый иде. Шундый ук ашату, авыр эш, режим белән генә яшәү. Бер үзгә ягы бар – биредә советка каршы көчле агитация алып барыла. Моның өчен махсус укыту оештырылган. Көн саен занятиеләр үткәрелә, әсирләр белән сөйләшүләрдә һәрьяклап кылларын тарткалап карыйлар. Ышанычлымы, әллә алдашып, күз буяп кына йөриме? Аз гына шикләнсәләр дә, лагерьда калдырмыйлар, элекке лагерьларга озаталар.

Мусаны һәм ул язып биргән исемлектәге барлык иптәшләрен, күрәсең, ышанычларын аклаганнар, фрицлар беренче көнне үк икенче зонага, ачык лагерьга чыгардылар. Биредә аларны лагерь начальнигы оберштурманфюрер Френцель үзе каршы алды.

– Сез бөек Германиягә хезмәт итәргә ризалык белдердегез! Димәк, сезне большевизмның дошманнары дип атарга була, – диде ул. – Ләкин сез ялгышмадыгыз! Сез дөрес эшләдегез. Ике айлык курслар үткәннән соң, сезнең һәрберегезгә Германия гражданины паспорты бирелачак. Германиядә яшәп калырга мөмкин булачак. Ләкин без сезне юк ителгән СССР территориясендә Германия вәкилләре булып эшләргә әзерләячәкбез. Һәрберегезгә дә үз туган җирегездә эш табылачак.

Начальникның шушы кыска гына чыгышыннан соң әсирләрне, хәер, хәзер инде аларны әсирләр дип атамасаң да буладыр, агитаторларны юынырга алып бардылар. Юыну өчен махсус мунча әзерләгәннәр иде. Барысын да анадан-тума чишендереп, душ астына кертеп бастырдылар. Кулга мунчала, сабын тоттырдылар. Әсирлеккә төшкәннән соң, беренче тапкыр, кайнар су астында, бөтен тәнен сабынлап, яхшылап ышкый-ышкый юынды Муса.

Мунчадан соң аларга кием өләштеләр. Монысында кемнәндер салдырылган солдат гимнастёркасы түгел, пөхтә итеп үтүкләнгән киндер күлмәк-ыштан һәм кәчтүм-чалбар иде. Аякка әйбәт штиблет ботинкалар кидерделәр. Әйтерсең, җиңү сәгате суккан да, алар туган илләренә кайтып, бәйрәмгә чыккан кебек сандык төбендә яткан, кешелеккә генә кия торган әйбәт киемнәрен кигәннәр, диярсең.

Киендергәннән соң, аларны ашханәгә алып килделәр.

– Бүген бездә бәйрәм! – дип каршы алды аларны ашханә начальнигы. – Бүген без легион өчен солдатлар туплаучы төркемне кабул иттек. Безнең табыннар мул. Тамагыгыз туйганчы ашый аласыз. Моннан соң башка көннәрдә дә шулай булачак. Әмма бүген лагерь начальствосы хисабыннан һәрберегезгә яхшы сигара һәм затлы маркалы шәраб! Сыйланыгыз, күңел ачыгыз, рәхәтләнеп ял итегез. Теләге булганнарга чибәр кызлар хезмәт күрсәтәчәк.

Мусалар төркемендә унлап татар егете иде. Аларның барысын да бер өстәл тирәли утырттылар. Муса шуңа игътибар итте: һәр өстәлгә аерым бер милләт кешеләрен утыртканнар иде. Татарлар бүтән өстәлләр тирәсендә күренмәде. «Рәхәтләнеп яшерен оешманың беренче утырышын уздырырга була, бүгенгә хәтле болай җыелышырга мөмкинлек чыкканы юк иде әле», дип уйлап куйды ул. Ләкин арада беренче тапкыр күргән өч-дүрт кеше бар иде. Шуңа күрә

Муса иптәшләренә шыпырт кына: «Бер-беребезне белүебезне сиздермәскә кирәк», – дип пышылдады.

Өстәл янына утырышкач, сүзне беренче булып Баттал башлады:

– Йә, танышыйк, минем исемем Абдулла, фамилиям Батталов була. Татарстанның Биләр районыннан, Олы Тигәнәле авылы егете. Өйләнмәгән. Бүген менә монда берәр фрау мадамны эләктереп булмасмы, дип уйлап утырам әле, – диде, үзенчә шаяртып.

– Тигәнәледә Абдуллам кайларда йөри икән, дип сагынып көтеп торучың булмаса, фрау мадамнар да ярап тора инде, – дип, сүзгә кушылды Гарәф. – Мин дә Татарстаннан, Казан филармониясе артисты Гарәф Фәхретдинов булам, – дип, ул үзе белән таныштырды да, Мусага карап күз кысты.

«Конспирация өчен шәп нәрсә! Беркатлыланып, артык ачылып китмәгәндә дә ярагандыр да, – дип уйлады Гарәфнең кайдан икәнен яхшы белгән Баттал эченнән генә. – Ләкин эш узган иде инде, чыпчык очып чыкты авыздан. Тигәнәледән икән, Тигәнәледән булсын, ярар, белмәгәннәр дә белеп торсыннар».

Берәм-берәм Гайнан, Фоат, Зиннәт тә үзләрен төрле яклардан итеп күрсәтеп, таныштырып чыктылар. Муса да, үзен Гомәров дип таныштыргач, таныш булмаган егетләрнең берсенә сорау бирде:

– Ә сезне кем дип белик инде?

– Гафаров Мурат исемле булам. Сембер якларыннан.

– Әсирләрне легионга агитларга булдыгыз инде алайса?

– Сезне дә шул максаттан йөрүчеләр дип уйлыйм. Әллә ялгышаммы?

– Ялгышмыйсыз. Вуструау анкетасы сорауларына ничек җавап бирдегез соң? Партиядә идегезме?

– Партиядә булу-булмавым сезгә нәрсәгә кирәк?

– Ә ни өчен әсирләрне легионга агитлыйсыз?

– Илгә кайтудан бигрәк, Германиядә берәр баронга хезмәткә ялланып булмасмы, дип уйлыйм. Сугыш беткәнче шунда эшләп торсам, сугыштан соң күз күрер тагын.

– Ә легионда сугышырга исәбегез юкмыни?

Мусаның сораулары бу бәндәне туйдыра башлады бугай, ул дорфа җавап бирүгә күчте.

– Анда сезнең, гомумән, ни эшегез бар? Үзегезне белегез дә, кеше эшенә тыгылмагыз, әфәндем, кем дидегез әле исемегезне, Гомәров Муса бугай...

– Аңлаштык сезнең белән... – диде Муса һәм, иптәшләренә борылып: – Әйдәгез, татар легионерлары исәнлегенә берәр чәркә тотып куйыйк булмаса! – дип, тост тәкъдим итте.

– Менә бу тост ичмасам! – диде Абдулла, Муса белән чәкештереп. – Легионерлар саулыгына!

Абдуллага башкалар да кушылды.

Табын чынлап та шактый мул иде. Аларга официантлар хезмәт күрсәтте. Җамаякларга табын уртасына чыгарып куелган олы гына кәстрүлдән гадәттәге баланда урынына берничә бәрәңге телеме һәм ит кисәге йөзеп йөргән кәбестә ашы сосып бирделәр. Аштан соң бәрәңге боламыгы чыкты. Өч кешегә бер шешә исәбеннән куелган шәрабны кружкаларга бушаткач, Гайнан да тост әйтергә торып басты.

– Туганнар! Без авыр һәм җаваплы эшкә алындык. Бөек җиңүне якынайту өчен хәлебездән килгәннең барысын да эшләргә тиешбез. Җиңү таңын азат

туган илебездә, гаиләләребез, хатыннарыбыз, балаларыбыз янында каршы алсак иде. Мин бу тостны җиңү өчен эчәргә тәкъдим итәм.

– Кемнең җиңүе өчен? Аңлашылып бетми тостың, – дип каршы килде Гафаров.

– Кулга корал тотып, кем өчен сугышырга барабыз соң? Легион ни өчен оештырыла? Аңлашылмыймыни? – диде Муса, Гайнанның тостын хуплап. – Мин бу тостка басып эчәргә тәкъдим итәм. Ура, җиңү өчен!

Мусага башкалар да кушылды. Барысы да басып, кружка төбен ялтыратты.

– Ура! Җиңү өчен!

Ул арада өстәл янына өч кыз-хатын килеп, егетләрнең муеннарына сарылды.

Муса, үзенә сырганак кебек килеп ябышкан кызны этәреп:

– Гафу итегез, фрау мадам, кәефем юк. Әнә теге егеткә барыгыз, – дип, Гафаров ягына күрсәтте.

Кыз Гафаров муенына асылынуга, тегесе аны, кочаклап алып, алдына тартып утыртты да, күкрәкләрен капшарга ук тотынды. Кызны озак кына кочып кыскалап утыра торгач, кыз, чыркылдый-чыркылдый, Гафаровны каядыр чакыра башлады. Алар торып, табын янынан читкә китеп бардылар. Кызларның калган икесе дә Мусаларга таныш булмаган егетләр кочагына сырышып, аларны каядыр читкә өстерәде. Кызларның берсе Абдулла кочагын үз итмәкче иде дә, ул аның белән артык назланып тормагач, икенче егеткә күчте. Шулай итеп, таныш булмаган егетләр дүртесе дә фраулар белән мавыгып, каядыр кухня артындагы бүлмәләргә китеп юк булды.

– Менә хәзер сөйләшергә була, – диде Муса, үзләре генә торып калгач. – Егетләр, бу перевалочный лагерь икән. Безне монда озак тотмаячаклар. Бүген-иртәгә дигәндәй, төрле-яры таратачаклар. Кайберләребез Берлинга китәчәк. Күпләребез Едлино лагерена җибәрелә. Едлино ул татар легионы урнашкан урын. Кайда гына булсак та, үз бурычыбызны онытмаска кирәк. Бурычыбыз – Кызыл Армиягә каршы сугышка кергәч, легионерларны безнең якка чыгарга агитлау. Командирларны юк итү һәм коралларын дошманга каршы юнәлтергә үгетләү. Бу оешма турында беркем дә белергә тиеш түгел! Без күп түгел. Ләкин үз эшебезне беркемгә дә сиздермичә, җиренә җиткереп үтәргә тиешбез.

– Аңлашыла, Муса абый. Бурычыбызны намус белән үтәрбез! – диде Гайнан.

Ашханәдән соң аларны баракларга тараттылар. Татарларны иң соңгы баракның арткы өлешенә урнаштырдылар.

Икенче көнне агитаторларны махсус программа нигезендә укыту башланды. Иң беренче чиратта, немец телендә сөйләшергә өйрәттеләр. Һәр тыңлаучыга Гаяз Исхакыйның «Идел-Урал» дигән китабын өләштеләр. Бу 1933 елда Парижда басылып чыккан юка гына китапчык иде. Башта, китап буенча лекцияне Гаяз Исхакый үзе укый икән, дигән сүзләр таралган иде. Ләкин ул күренмәде. Дәресләрне Әхмәт Тимер алып барды. Махсус чакырылган дин әһеле ислам тарихы буенча лекцияләр укыды.

Вустрауда Муса өчен көтелмәгән очрашу булып алды. Ул әле Каунас лагеренда ук аерылышкан дусты Салих Ганиев белән күреште. Салих урау юллар узып, төрле лагерьларда булып, Муса сүзен тыңлап, татар легионына язылырга, дигән карарга килгән иде һәм 1943 елның башында Вустрау лагерена килеп эләкте.

– Дөрес карар кылгансың, – диде Муса Салихка, легионерлар арасында күптәнге дустын күрүенә шатлануын яшермичә. – Әле синең белән дә аерым әңгәмә үткәрмичә калмаслар. Шунда сак бул, сүзеңне үлчәп сөйлә. Советларны

артык сүгеп ташлама. Сиңа юри шундый провокацион сораулар бирерләр. Артык шапырынып ташласаң, киресен эшләп куюың бар.

– Ә сез монда күптәнме соң?

– Монда озак тотмыйлар. Әңгәмә үткәргәннән соң, йә шунда ук легион урнашкан Едлино лагерена озаталар, йә Германия предприятиеләренә эшләргә җибәрәләр. Үзләре өчен аеруча ышанычлы дип тапканнарын Берлинга, «Идел-Урал» комитетына эшкә алырга мөмкиннәр. Кая гына эләксәң дә, бер максатка хезмәт итәргә кирәк: легионны эчтән җимерү эшенә, фронтка җибәрелгәч, легионерларны безнең якка чыгарга агитлауга.

Салихны һәм аның белән бергә китерелгән тагын берничә әсирне төшке аштан соң, комендатурага алып бардылар. Аны комендант янына соңгы кеше булып алып керделәр.

– Уие гehт эс иhнен, hерр Ганеф?[24] – дип сорады комендант.

– Терпимо, – дип, урысча җавап кайтарды институтта укыганда немец телен өйрәнгән Салих, комендантның соравын шунда ук аңлап.

– Гедульдет, – дип тәрҗемә итте тылмач.

– Корошо! По немецки понимаете, – дип, комендант үзе дә урысчага күчте.

Комендант Салихтан ни өчен легионга язылырга теләк белдерүе белән кызыксынды. Салих, Муса өйрәткәнчә, легионга керергә теләге артык зур булмаса да, исән калырга теләгенең зур булуын әйтте.

– Легион бит Кызыл Армиягә каршы сугышыр өчен оештырыла. Сугышта үлеп калырмын дип курыкмыйсызмы?

– Нишлисең инде, димәк шулай язган.

– Юк, безгә сезнең исән булуыгыз кирәк. Болай итәрбез: сезне Германия заводларына эшкә җибәрербез. Сез ризамы?

– Мин каршы түгел, – диде Салих.

– Яхшы, сезне артык тоткарламыйбыз.

Шул сүздән соң Салих комендант белән хушлашып чыгып китте.

Чыккач та алар тагын Муса белән күрештеләр.

– Германия заводларында да безнең җиңүне якынайту өчен корткычлык алып барырга ышанычлы кешеләр кирәк. Бик әйбәт булган, – диде Муса. – Монда татар эмигранты Искәндәр Яушевның хәрби заказлар башкарып ятучы заводына эшчеләр төркеме җыялар, дип ишеттек. Дошман көчен арттыру өчен тырышып ятучы ул заводның көлен күккә очырганда начар булмас иде.

– Әйбәт идея бу. Күптән кирәк ул буржуйларның арт сабагын укыту.

Икенче көнне ачык лагерьга тагын ике егетне китерделәр. Дәресләр башланыр алдыннан танышканда, егетләрнең берсе Муса янына килеп:

– Исәнмесез, Муса абый, – дип, күптәнге танышын күргәндәй, күрешергә кул сузды.

– Исәнмесез. Танып бетермим, кем буласыз? – диде Муса, шикләнеп кенә. «Үзен Җәлил буларак белә торган кешеме икән әллә?» дип уйлап куйды. Утыз яшьләр тирәсендәге бу егетне аның, чынлап та, беренче күрүе иде шикелле. Ә егетнең хәтере яхшы икән, һәм ул аны әле малай чагыннан ук белә торган булып чыкты.

– Муса абый, сез мине хәтерләмисездер. Без бит авылдашлар. Мин сездән күпкә яшьрәк. Танымавыгыз гаҗәп түгел. Ләкин минем әти Мостафа мәктәбендә укытучы иде. Ул сезне дә укыткан кеше. Һади Надиев дигән укытучыгызны хәтерлисезме?

– Шулаймыни?! Һади абыйның улы Назыйфмыни син? – диде Муса, әле

[24] Хәлләр ничек, Ганиев әфәнде? *(нем.)*

ундүрт-унбиш яшьләрендә чакта үзләренең урамнарында яшәгән укытучы абыйсының тузан туздырып чабып йөргән биш-алты яшьлек кара борынлы малаен исенә төшереп. – Күпме гомер үткән, күпме сулар аккан бит инде. Кем уйлаган менә шушы җәһәннәм тишегендә авылдашны очратырмын дип! – Чын күңелдән сөенде Муса.

– Ә мин сезнең биредә икәнегезне белеп килдем, – диде Назыйф. – Ат аунаган җирдә төк кала, диләрме әле. Сез булган лагерьларда да эзләрегез кала, Муса абый.

– Нинди эз инде ул? – дип аптырады Муса.

– Шигырьләрегез. Демблинда егетләр сезнең шигырьләрегезне укытты. Кулдан кулга йөри алар. Сезнең әле күптән түгел генә Вустрауга җибәрелүегезне әйттеләр. Менә шуннан инде күрешмичә калмабыз, дип уйлаган идем.

– Күрештек менә. Авылга кайткан кебек булдым.

– Миндә дә шундый хисләр, Муса абый. Сез бит зур кеше булдыгыз. Авылда сезнең белән горурланалар.

– Шулаймы? Ә легионга ни өчен язылырга уйладың?

– Качар өчен, Муса абый. Сугышка керүгә, үзебезнең якка качам мин. Бөтен максат шул. Илен саткан икән, дип уйлый күрмәгез тагын.

– Син, Назыйф энекәш, сугышка керергә бик ашкынма. Ничек тә Берлинга эләгергә тырыш. Анда «Идел-Урал» комитеты оешкан. Шушы легионга әсирләрне агитлый торган. Комитет менә шунда, берәр эшкә урнашып калырга тырыш. Урнаша алсаң, анда, бергә-бергә эшләрбез.

Вустрау әсирләрне бер лагерьдан икенчесенә күчерү ролен башкару урыны буларак оештырылган иде. Биредә аларны озак тотмыйлар, һәрберсе белән аерым әңгәмә үткәреп, кемнең нәрсәгә сәләтле икәнен ачыклыйлар, кыска сроклы өйрәтү үткәргәннән соң, кайсын легионга, кайсын киредән лагерьларга озаталар. Лагерь шулай ук агитация алып бару өчен дә бик уңайлы урын булып чыкты. Муса шуңа күрә дә моннан каядыр китәргә ашыкмаска булды. Төп максаты – яшерен эш алып бару. Ул, лагерь җитәкчелегенә, легионга агитлау өчен уңайлы, дигән булып, бөтен иптәшләре төрле лагерьларга таралышып беткәндә дә, Вустрауда торып калды. Монда яшерен эш белән шөгыльләнү өчен яңа иптәшләр дә тапты. Иң көткән очрашу Абдулла Алиш белән булды. Гайнц Унгляубе һәм Шәфи Алмас Берлинга барып, комитет штабында эшләргә бик чакырган булсалар да, Алишны Седльцедан башта Вустрауга китерделәр.

Муса белән алар кочаклашып күрештеләр. Бик сагынышканнар иде.

– Син легионда түгелмени әле? – дип гажәпләнеп сорады аннан Җәлил.

– Ник алай дисең?

– Миңа Шәфи Алмас: «Алиш күптән инде легионда, хәтта легионга язылырга әсирләрне агитлап йөри», – дип әллә кайчан әйткән иде. Шуннан синең дә әсирлектә икәнеңне белдем. Әле синең белән очраштырам, дип тә шапырынган иде.

– Чынлап та, мине агитаторлар төркемендә эшләргә үгетләде ул. Берлинга барып, «Идел-Урал» гәзитенә тәрҗемәче булып урнашырга чакырды.

– Әйбәт эш бит. Барырга кирәк.

– Мин дә шулай уйлыйм. Диверсия белән шөгыльләнеп ятарга шуннан да уңайлы урын булмаячак. Легионерлар арасында таркату эше алып бару өчен зур мөмкинлекләр ачылачак, димәк...

– Безгә бер тирәгә тупланырга кирәк. Шул «Идел-Урал» комитетыннан да ышанычлы урын булмастыр. Гәзитне үз кулыбызга алырга.

– Егетләр арасында артистлар да бар. Ансамбль оештырганда, начар булмас иде. Лагерьларга йөреп, концертлар куярга. Әсирләр арасында яшерен агитация алып барырга.

– Син беләсеңме, ышанычлы егетләр әле тагын да бар безнең арада.

– Кемнәр ул?

– Монда бит әле Гайнан Кормашев белән Абдулла Батталов та безнең беләи. Абдулланы беләсең инде, Салих Батталның энесе.

– Ә Гайнаны кем?

– Гайнан Кормаш «Октябрь баласы»на шигырьләр җибәреп тора иде. Казакъстаннан. Беләсеңме, безгә оешмада кемнәр булуын беркемгә дә белдермәскә кирәк. Беркайчан да бергә җыйналмаска. Үзара элемтәчеләр аша гына аралашырга. Иң мөһиме – Берлинга җыйналырга, «Идел-Урал» комитеты тирәсенә тупланырга. Мин бер ялгышлык эшләдем эшләвен. Бәлки, үтеп китәр, сизмәсләр. Кем белә, сизеп куюлары да бар.

– Нәрсә булды соң?

– Легионга агитаторлар итеп билгеләгез дип, үзебезнең оешма кешеләренең исемлеген язып бирдем, каһәр. Берәребез тотылса, шул исемлек зацепка булып куярга мөмкин.

– Ялгышкансың бераз. Ярар, бәлки, онытырлар ул исемлекне. Сак булырга кирәк.

Алишны икенче көнне үк, СС солдаты обмундированиесенә төреп, кулына Германия гражданы статусы бирә торган паспорт тоттырып, Берлинга, «Идел-Урал» редакциясенә тәрҗемәче итеп җибәрделәр. Муса исә, яшерен оешмага яңа кешеләр эзләү нияте белән, легионга Вустрауда яшәп агитация алып барам, дигән булып, ачык лагерьда торып калды.

Кичен Муса, үзенең шагыйрь икәнлеген исенә төшереп, шигырь язарга утырды. Күптәннән инде, Әхмәт Тимер янында тылмач булып йөрүче студент Гариф Солтановны күргәннән бирле, аның бу егет турында язасы килү теләге күңеленә тынгылык бирми йөдәтә иде.

Муса бу егет турында берни дә белми, әлбәттә. Ул да аның үзе кебек үк әсирлеккә төшкән. Аның шикелле үк легионга язылган. Легионга язылучылар меңнәр. Аларның барысын да Сталин «халык дошманы» дип саный. Барысын да, туган илгә әйләнеп кайтырга язган булса, «сатлыкҗан» дип каһәрләү көтә. Менә шул егет турында нинди шигырь язарга була? Аны гаепләргәме, акларгамы? Һәркемнең дә яшәргә хакы бар. Бер тапкыр дөньяга килгәнсең икән, инде син яшәргә тиеш. Яшәү өчен көрәшергә! Ләкин ничек? Илеңне сатып, дошман ягына чыгып, аңа хезмәт итепме? Бәлки, ул егет тә, Муса шикелле үк, яшерен эш алып барадыр. Бу хакта кешегә сөйләп кенә йөрмидер. Муса да бит, фриц, «Һинде hoh!» дип, аның янына килеп баскач, кулларын күтәрде.

Шуларны уйлап утырды да Муса кәгазенә «Кол» дип, шигыренең исемен язып куйды. Аннары күптәннән уйлап йөргән юлларны яза башлады.

Ул, куркып, дошманы алдында
Калтырап, күтәрде кулларын.
Сугышның иң кызган чагында
Ташлады кулыннан коралын.

Муса шунда үзенең әсирлеккә төшкән минутларын күз алдына китерде. Ул көн аның да коллыкка төшкән көне иде бит. Нәрсә эшли алды соң ул бу хәлгә төшмәс өчен? Тәкъдире дошманы алдында кулын күтәрткән солдатка илдә мөнәсәбәт нинди булачагын бик яхшы белә иде бит.

Юк сиңа кешечә көн итү,
Бикләдең син гомер юлыңны...
Дошманың алдында, егетем,
Бер куркып күтәргәч кулыңны.

Йә сугыш син яклап хаклыкны,
Йә сайла кызганыч коллыкны.
Беренче юл нинди данлыклы,
Икенчесе нинди хурлыклы.

Юк, гаепләми иде Муса әсирләрне. Бу шигырьне язу аларны үз язмышлары хакында уйландырырга теләү максатыннан иде. Әле соң түгел, аларның әле легионга язылып, үз илләренә каршы сугышка кергәндә, командирларын юк итеп, безнекеләр ягына чыгарга мөмкинлекләре бар. Аларга менә шуны исләренә төшерү, шундый юл барлыгын күрсәтү максатыннан язды Муса бу шигырьне. Һәм ул бу шигырен, һичшиксез, әсирләр арасында таратачак, җае чыкса, бәлки, укып та күрсәтер.

Ә Гариф Солтановка килгәндә, аны гаепләргә дә була, бер караганда, акларга да мөмкиндер, бәлки. Сугышка киткәнче Уфа педагогия институтында ул елларда аеруча популяр булган германистика бүлегендә белем алган, әле мәктәптә укыган чагында ук немец телен өйрәнгән, хәтта ипи-тозлык сөйләшә дә алган бу егеткә әсирлек михнәтләреннән котылу, исән калу өчен тылмач булып эшләү Алла үзе биргән форсат лабаса! Нигә шул мөмкинлектән файдаланып калмаска?! Әле, җитмәсә, мәгънәсез совет режимыннан каһәрләнгән нәсел баласы. 1924 елда Эстәрлетамак белән Мәләвез арасындагы сәүдә юлында урнашкан Җиргән дигән авылда хәлле генә тормыш алып баручы Нигъмәтулла атлы олаучының биш балалы гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә Гариф. Сигез аты, тарантаслары, йөк ташу арбалары була Нигъмәтулланың. Ике яктан ишекле зур өйләре, алачыклы зур мунча, келәтләре, алмагач бакчалары була. Кыскасы, хәлле генә тормыш алып барган бер мәлдә колхозлашу башланып, боларны кулак дип Җиргәннән куалар. Сөргенгә үк җибәрмәсәләр дә, Нигъмәтулла Ишембай каласында эш тапканчы, авылдан авылга күченеп шактый гына йөрергә туры килә. Менә шундый михнәтләр күреп үскән егеттә, әлбәттә инде совет властена карата уңай гына мөнәсәбәт булмагандыр. Ә аннары сугыш... 1941 елны институтның беренче курсын гына тәмамлаган студент, җәй көне бераз акча эшләп булмасмы дип, Днепропетровскига китеп, металлургия заводына эшкә урнаша. Завод эшчеләре белән бергә турыдан-туры сугышка барып керә. Сугышның беренче көннәрендә үк әсирлеккә эләгә һәм кыен өстенә кыен күреп, ачлыктан чак исән калган егет, легион оеша, дигәч, озак уйлап тормый, беренчеләрдән булып шунда керергә карар кыла.

Муса Гариф Солтановның башыннан кичкән хәлләрдән бихәбәр иде. Аның, йөгерә-йөгерә, фашист Гайнц Унгляубенның тәлинкә тотучысына әверелүе генә бу егеткә карата нәфрәт хисләре уята иде. Ә бүген аның күңелендә бу егеткә карата да күпмедер кызгану һәм кичерү хисләре уянды. Әгәр аны очратмаган булса, әсирләрдә коллыкка нәфрәт һәм коллыкка төшерүчеләргә каршы көрәш дәрте уяткан «Кол» дигән шигыре дөньяга туар иде микән? Ул шул хакта уйлады.

Беренче бүлек тәмам.



Факил Сафин

МӘҢГЕЛЕКТӘН КИЛГӘН КӨНЕМ...

Җанга эндәшү

И Җан, җаным! Һәр тибешең
Яңарта кан тавышын.
Тоям бары синең аша
Серле вакыт агышын.
Мин дөньяга карый алам
Үләнкүзе аша да.
Үләннең бәбкәч кыягын
Галәм үзе ача ла!

Биек Күкләрдән ирешә
Өметле якты аһаң.
Син бит, Җаным – рухи чакма! –
Кыйммәттән кыйммәт бәһаң.
Тоям гомер юлым каян
Узганын, узачагын.
Давыл чыгачак мәлләрне,
Җилнең бер тыначагын...

Бер сере юк, барысын беләм,
Талларын, гөлен, кошын.
Кайчан назлы яз иңәсен,
Кайчан киләсен кышның.
Һәм белмим дә... Берни белмим.
Шундый сәер дөньям син.
Ачылмаган сер катламы,
Менеп җитмәс кыя син.

Факил САФИН (1954) – *шагыйрь, прозаик; Г.Исхакый һәм А.Алиш исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Саташып аткан таң» роман-трилогиясе, «Биек тауның башларында», «Галәм күзе» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Сүтелмәгән йомгак кебек,
Яңа яуган кар кебек.
Җир-галәмнәр гажәп иркен,
Бер карасаң, тар кебек...

Бер карасаң – шундый ерак,
Бер карасаң – якын син.
Кайчан гына боз идең син.
Инде менә ялкын син.

Әллә чынлап, әллә көлеп,
Мине сынап карыйсың.
Мең яшәгән карт кебек син,
Яңа туган сабый син.
Араларга и тырыштым,
Төрле шаукым, бәладән.
Ни күрсәң дә, якты калдың,
Димәк, Рух нык, сәламәт.

Җан зурлыгын Күкләр тоя,
Мин сыенам биеккә.
Моңлы былбыл кебек тә син,
Салмак бөркет-киек тә.
Синнән үзгәсе кирәкми,
Җебек булмадың, Җаным!
Ачылмаган сандык бит син –
Ниләр табылыр тагын?..

Мәңгелек бер көн

Үтеп барган тансык көнем...
Һаваларда эрер микән,
Далаларда йөрер микән,
Хәлсезләнеп ятар микән,
Агымсуда батар микән? –
Ниләр көтә бу көнемне?

Мәңгелектән килгән көнем...
Шыксыз җилләр кисәр микән,
Кат-кат искә төшәр микән,
Төшкә кереп йөдәтерме,
Акыл булып сүз әйтерме? –
Ниләр көтә бу көнемне?

Мәңгелекнең тик бер көне...
Чишмә булып тибәр икән,
Каным булып кибәр микән,
Үтәр микән синең эздән,
Үбәр микән керфегеңнән,
Ниләр көтә бу көнемне?

Миннән киткән бу көнемне
Ниләр көтә, ниләр көтә?..
Тыгызлана Галәм төше –
Җаннан җанга ак нур күчә.
Сиздермичә, сизелмичә,
Җан йомгагын сүтә-сүтә,
Үтеп барган бу көнемне
Ниләр көтә, ниләр көтә?..

Чынлык

Яшь наратлыкта йөримен:
Һавасы биек, иркен.
Шундый тынлык, тыгыз тынлык,
Күзгә чалынмый беркем.

Аяк асты чуарланган –
Пошилар үткән эзләр.
Ял иткәннәр су юлында,
Йөргәннәр ылыс чемләп.

Матур булганнардыр алар,
Мөгез очында – кояш.
Ешлыкны ярып үткәннәр,
Салкын чык койган тояк.
Төз наратлар биеклектән
Торганнардыр сокланып.
Уйнап кына сөзешкәннәр,
Чама белеп, сакланып.

Әнкә поши имезгәндер
Колынын-нарасыен.
Күңелгә рәхәт йөгерә
Шушы мизгелне тоеп.

Яшь наратлыкта йөримен,
Тынлыкка колак салам.
Кайдадыр пошилар уйный,
Кайдадыр тормыш бара...

Бу – дөньяның гүзәл мәле,
Ямьле гаме, валлаһи!
Монда һәммәсе – чынлыктан,
Һәммә нәрсә Илаһи!
Мәңгелектән килгән эзләр –
Аяк асты чуп-чуар.
Өметсез түгел бу дөнья –
Яктырып кояш чыга!

Үзгәртәсем килде...

...Кроме детства и сказать-то не о чём.
Роберт Рождественский

Диңгез эзләп киттем – чишмәм калды,
Таулар эзләп киттем үзәннән.
Кайттым – мине чишмәм танымады,
Үзәннәрдә кипкән үләннәр.
Үзгәртәсем килде бу дөньяны,
Язмыш белән чыктым алышка.
Биек күкләр, чиксез ерагаеп,
Әйләнгәннәр зәңгәр сагышка.

Йөрәгемдә чишмә челтерәве,
Үзәннәрдә – уйнак колыннар.
Малай чагым тезен канаткан да
Еламсырап кайта болыннан.
Йөрер юлда ташлар калкып чыга.
Абындыра тигез барганда.
Баш очымда керәшәләр оча, –
Абынырга ташлар юк анда.

Диңгезләрнең тозлы суын эчтем.
Кырысланып ярга бәрделәр.
Тау төренгән чалма-болытларга
Менгән саен юлны бүлделәр.
Үзгәрдемме? Белмим... Кайтып киләм.
Җил бәйләнә уйчан камышка.
Җанда уйный сагыш дулкыннары –
Ни әйтәсең иләс язмышка?

Күңел-җанны сукыр тоя алмас:
Галәм күзе бага – сыныйдыр.
Офыкларым кире чигенәләр,
Айга карап хәтер елыйдыр...
Үзгәртәсе килде яшәү төсен,
Күз яшемне мин дә тыялмам –
Малай чагым карап тора сүзсез,
Кулларында алсу багалма...

Кошлар очкан чакта. Тәфсир

...Аллаһтан безне дөнья аерып тора...
Коръән. Ганкәбут (Үрмәкүч)
сүрәсе. 64 нче аяттән.

I

Кемдә булмый хисси адашулар? –
Тилемсәлек керә акылга.
Болыннарда өскә карап ятам,
Биек-биек күкләр... якында.
Олы сулар ярылыр кап урталай,
Таулар тирән тамыр җибәрер.
Күпме генә кылма игелекләр,
Күргәннәрең булыр гел җәбер...

II

Яшен булып өскә курку килә,
Кабат туу – өмет яшәтә.
Кайнарлана кышның буранары,
Җәй сулышы таңны өшетә.
Шагыйрьлекне Ходай биргән, диеп,
Ышанам мин бары бер Хакка.
Кош югала кояш үзәгендә,
Дөнья тулган ялган, нахакка.

III

Фанилыкка теш-тырнагы белән
Ябышкан да кеше, тырмаша.
Бу дөньяга кире кайтарылмый
Торган көне кыла тамаша.
Уяу, дисәк, җаннар шундый сүлпән,
Үз-үзеңә яуга чыгасы?..
Җан һәм нәфес мәңге тарткалаша,
Кайтарылыш – Хакның догасы.

IV

Дөнья белән килешмәгән чагым.
Килешмәскә сәбәп җитәрлек.
Чукрак булып, сукыр булып җирдә
Яшәүләргә исең китәрлек!
Мең ел яшәп китәм, дисәң дә, ул –
Аллаһының бары бер көне.
Яшел болын, күккә карап ятам,
Очып үтте кошлар төркеме...

Бүләк

1

Шундый язмыш бүләк иткән миңа:
Ходай тыны – изге сулыштыр.
Ерак өннәр җанга сарылалар,
Бөтен галәм – шигъри куышым.

Гөрләвекләр йөгерә дәрья эзләп,
Умырзая калка, боз чатный.
Рәхәтем дә, михнәтем дә минем
Шигырь зурлыгында – Җан чаклы.

2

Ярда калу әйбәт. Боз аккан ын
Учак ягып ярдан күзәтү.
Минем өлеш – ташу кайнаганда,
Боз өстеннән торып сүз әйтү!
Шигырьсезлек качсын җирдән, күктән!
Шифа булып яусын яңгырлар.
Алтын яфрак яуган чакта да бит
Чит итмәде мине яз-моңнар.

3

Нәрсә калыр бездән –
Зур галәмнең
Кыл уртасын ярып узганда?
Киек казлар юлын үткән чакта
Үксез калмас җаным ызанда.
Шигырьләрдән җәяү качып барган,
Үзгәртергә теләп дәверне,
Нурга тулып, дөнья буйлап очам,
Аккош каурыена әверелеп.

4

Меңнәр арасыннан берәү булыр,
Моңдашым ул, шигъри юлдашым.
Киткән көнем булыр киләчәккә
Тәүге адым – иркен юл башым.
Берәү булыр, бәлки... күбрәк тә,
Җандашларның таныйм йөзләрен:
Гомер буе сезнең күңел түрен
Яктыртырлык сүзләр эзләдем!

5

Шуңа күрә сезнең йөзләр якты
Карашыгыз шуңа ягымлы! –
Сезнең өчен көн дә сугардым мин,
Аллы-гөлле шигъри багымны.
Һәм шуңа да миңа шундый җиңел,
Ап-ак каурый – очам ал таңда.
Һәм чәчеләм, тоташ нурлар булып,
Иксез-чиксез дәрья-җиһанга!

Редакциядән:

Бу айда каләмдәшебез үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.



Чыңгыз
Айтматов

ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ

«БЕР КӨН – БЕР ГОМЕР» РОМАНЫНА НИСБӘТЛЕ ПОВЕСТЬ*

Романга повесть тәкъдим итәм. Бу ни соң – яңа жанрмы? Билгеле, мондый жанр була алмый. Шулай да тормышта төрле хәлләр очраштырып торуын искә алсаң, язганымның «Бер көн – бер гомер» дигән романга өстәлгән повесть икәнлеге аңлашылыр. Хәер, ул өстәлгән дә түгел, ә баштагы варианттан төшеп калган өзек кенә; идеологик басым чорында, барысын күреп-белеп торган цензорлар һәм «өстәгеләр» фикере әсәр язмышын административ тәртиптә хәл иткән заманнарда бу текстның ничек, ни өчен «кыскартылуы» турында сөйләп тормыйм. Китабың чыксын дисәң, көчле давыл вакытында, укучы ярларына таба кузгалган корабка артык йөк төямәс өчен, ни барына шөкер итәргә туры килә иде.

«Җырланып бетмәгән җыр»ны очлап бетерү бик сирәк очракта насыйп була. Әмма бу юлы нәкъ шундый мөмкинлек туды. Мин менә иске «яңа» романымның әлеге өлешен укучыма тәкъдим итәм. Әйтергә кирәк, әлеге бәянда Чыңгызхан турында күчмә халыкларның телдән-телгә йөргән бер риваяте, – чынбарлыкка дәгъва итмәсә дә, тарихи хәтерне яңарта торган миф файдаланылды.

Автордан

Бу якларда поездлар кояш чыгышыннан кояш батышына һәм кояш батышыннан кояш чыгышына таба йөри иде...

Салкын Сарүзәк киңлекләреннән җилләр бертуктаусыз күтәреп торган ак томанны аралап баручы поездларның машинистларына кар-буранлы ул февраль төннәрендә, даладагы кар көртләре арасыннан кечкенә Буранлы станциясен күрмичә узып китмәс өчен, шактый нык тир түгәргә туры килә. Күбекләнеп торган җил-давыл белән уралган поездлар, тынычсыз йокы вакытында сискәнә-сискәнә күргән төш сыман, караңгылык эченнән килеп чыгалар да алдагы төн карасына таба тәгәрәүләрен беләләр...

Мондый төннәрдә дөнья яңадан яратылган сыман; сулышлары капкан Сарүзәк далалары исә, дөм караңгылык белән көрәшкән яктылыкка башларын күтәреп карау белән, янә ак давылга әйләнеп калучы дәрьяны хәтерләтә...

Менә шул бөек бушлык уртасында һәр төнне, таңга кадәр сүнмичә, кечкенә

* Әсәр тулы вариантта тәкъдим ителә. *Ред.*

Чыңгыз АЙТМАТОВ (1928-2008) – *дөньякүләм танылган язучы, Кыргызстан Республикасының халык язучысы; Ленин премиясе, СССРның өч Дәүләт (1968, 1977, 1983) премиясе лауреаты. «Бәхил бул, Гөлсары!», «Ак пароход», «Бер көн – бер гомер» һ.б. китаплар авторы.*

станциянең бер кечкенә тәрәзәсе яктырып тора – әйтерсең лә анда, шул тәрәзәчек артында, ниндидер җан иясе ачыргаланып бәргәләнә, әйтерсең лә анда, үз-үзенә урын таба алмыйча, кемдер рәхимсез чир белән көрәшә яки аяусыз йокысызлыктан интегә. Ул станция янында гына Әбүталип Котлыбаев гаиләсе яшәгән барак тәрәзәсе иде. Әйе, алар – хатыны белән балалары – төнгелеккә дә ут сүндерми аны көтәләр, ә Зарифа төн уртасында лампа филтәсенең янган өлешен берничә мәртәбә кискәләп ала. Яңадан дөрләп киткән ут яктысында, теләсә-теләмәсә дә, пар эт балалары кебек йоклап яткан улларына – кара чәчле ике ташбашка – моңаеп карап тора. Салкыннан аның эчке күлмәк кенә кигән тәне калтырый, күшеккән кулларын күкрәк турысына кушырып, бер төенгә йомгакланып, ул аларга янә бер күз ташлый да коты алына: төшләренә аталары керер дә, алар, кулларын җәеп, елый-елый, көлә-көлә, узыша-узыша, бөтен көчләренә аңа таба йөгererләр, әмма барыбер ул күздән югалганчы барып җитә алмаслар да күз яшьләренә манчылып уянырлар дип куркуга төшә... Кара-каршы килүче составларны үткәреп җибәрә торган бу кечкенә станциядә ярты гына минутка булса да туктап ала торган теләсә кайсы узгынчы поезддан аталарын өндә дә көтә бит алар. Тормозларын шыгырдатып поезд туктау белән, малайлар, аңа ташланырга әзер торган кебек, тәрәзә буеннан нечкә муеннарын сузалар. Әмма көннәр дә, поездлар да уза тора, аталары һаман күренми, аның турында ник бер хәбәр ишетелсен, әйтерсең лә ул таулардан кинәт ишелеп төшкән галәмәт зур кар көрте астында калган, аның белән кайчан, кайда ни булганын һичкем белми иде.

Ул төннәрдә тагын бер тәрәзәдә – тик ул кара тимердән коелган нык рәшәткә белән капланган һәм Җирнең икенче читендә урнашкан Алматы тикшерү изоляторының ярымподвалыннан мәхбүс күзләре белән карап тора – шулай ук таңга кадәр ут сүнми. Менә инде бер ай булгандыр, Әбүталип Котлыбаев түшәмдәге тәүлекләр буена сукырайтып янган көчле «Ильич лампасы»ннан интегә. Ул аңа күктән төшкән ләгънәт иде булса кирәк. Кая барырга белмичә, бораулап, ит пычагы кебек тураклап торучы электр яктысыннан сызлый башлаган күзләрен ничек сакларга икән дип, бер мизгелгә булса да онытылып, ни сәбәпле монда китереп ябулары турында уйлаудан туктап һәм аңардан ни-нәрсә таләп итүләрен белергә теләвен басып торыр өчен, хәсрәтле башын коткару әмәлен таба алмый ул. Төн җиткәч, күлмәге белән шул кайгылы башын каплап, мәче косыгы төсенә буялган стенага таба борылуы гына була, ишек күзеннән карап торучы назир-надзиратель шунда ук камерага ыргылып керә, аны тар сәкедән бәреп төшерә дә типкәләргә керешә: «Стенага борылып ятма, адәм актыгы, кабахәт! Башыңны каплама, хәшәрәт! Власов ялчысы, бәдбәхет!» Үзенең власовчы түгеллеген әйтеп, ул күпме генә тәкрарласа да, моңа һичберсенең исе китми.

Шуннан соң Әбүталип, рәхимсез электр утына йөзен яңадан куеп, ялкынсынган, сызлаган күзләрен учлары белән каплап, гомумән, күзләре генә түгел, баш миенең дә тереклек итүдән тукталуына, һичбер яктылык төшми торган, кабердәге сыман караңгылыкта калуына сусап-изаланып ята. Менә шул көн җитсә, инде ичмасам, бер назирның, бер тикшерүченең дә аны түзә алмаслык җәза – ут яктысы белән, йокыдан мәхрүм итү һәм кыйнаулар белән газапларга хәленнән килмәс иде.

Назирлар чиратлашып алышына тора, әмма барысы да, бериш булып, каты бәгырьле иделәр – аларның берсе дә мәрхәмәт күрсәтмәде, тоткынның стенага борылып басуын яки ятуын күрмәмешкә салышмады, киресенчә,

шуны көтеп кенә торалар һәм һәркайсы, ярсып, сүгенә-сүгенә кыйнарга керешә иде. Әбүталип Котлыбаев төрмә назирының вазифасы һәм бурычлары нидән гыйбарәт икәнлеген чамаласа да, кайчак, өметсезлектән ачыргаланып, үзеннән үзе сорый: «Нишләп мондый соң алар? Карап торуга, адәм балалары кебек бит. Шулкадәр явызлыкны үзеңдә ничек асрап йөртергә мөмкин?! Минем аларның берсенә дә һичнинди зыяным тигәне юк лабаса. Моңарчы алар мине белмиләр иде, мин – аларны, әмма кан үче алган сыман кыйныйлар, мыскыл итәләр. Нигә шулай? Кайдан килә икән мондый бәндәләр? Ничек шундый булып җитешәләр алар? Ни өчен мине газаплыйлар? Ничекләр түзәргә, ничек акылдан язмаска да ничек башыңны стенага бәреп ярмаска?! Бүтән котылу юлы юк ич».

Бер тапкыр ул барыбер түзмәде. Әйтерсең лә эчендә ак яшен камчысы шартлап алды. Үзен типкәләргә керешкән назирга ничек барып ябышканын аңламый да калды. Алар, ярсып йолкыша-сугыша, идән буйлап тәгәрәделәр. «Мин сине фронтта күптән инде тилергән эт кебек атып үтергән булыр идем!» – дип, назир гимнастёркасының якасын шытырдатып умыра-умыра, катып калган бармаклары белән аның бугазын кысып ыжылдады Әбүталип. Әгәр коридордан тагын ике сакчы кереп өлгермәсә, моның ни белән бетәсе билгесез иде.

Әбүталип икенче көнне генә үз аңына кайтты. Иң элек бөтен тәне авыртуын тойды, аннары томан арасыннан түшәмдәге мәңге сүнми торган лампа уты бәреп чыкты. Нинаять, өстендә нидер сихерләп маташучы фельдшерга күзе төште.

– Ят, миленький, син инде хәзер теге дөньяга китә алмыйсың, – дип, аның яраланган маңгаена бинт кисәкләре куя-куя, әкрен генә эндәште фельдшер. – Әйдә, бүтән болай жүләрләнмә. Сине әле дә, сакчыларга һөҗүм иткәнең өчен, сытып, эт урынына чыгарып ташлый алган булырлар иде, һәм синең өчен һичкем җавап бирмәс иде. Тансыкбаевка рәхмәт укы, – аңа синең үләксәң түгел, ә үзең кирәк, тере килеш. Аңладыңмы?

Әбүталип эндәшмәде. Алга таба ни булачак, язмышы кайсы якка борылыр – бу мизгелләрдә аңа барыбер иде. Күңеленең – газапланууны, хәтта тәненең авыртуны тою сәләте дә тиз генә кайтмады.

Ул көннәрдә вакыт-вакыт аның аңы томаланып алгалады, хәер, чынбарлыкны аермыйча, ярымөндә, ярымтөштә яшәү аны саклаучы, коткаручы бер халәт булгандыр әле. Шундый мәлләрдә Әбүталип үзенә юнәлтелгән уттан да качарга, котылырга теләмәде, киресенчә, аны акылдан шаштыручы, котылгысыз җәзага дучар иткән яктылыкка таба омтылды, аңа, берөзлексез сукырайтып торучы утның көчен җиңәр өчен, үзен ирексезләп, әлеге авырту, ярсыту чыганагына якыная-якыная да җисемен тоймыйча эреп югаладыр һәм төпсез бушлыкта очып йөридер кебек тоела иде.

Ләкин шул чакта да изаланып беткән аңындагы үткәндә калганнар белән бәйләп торучы бер ефәк жеп өзелми, аны йөрәгеннән суырып тарта, аз гына вакытка да ычкындырып тормый... Ул – иксез-чиксез сагыш, гаиләсе, балалары өчен туктаусыз курку иде.

Сарүзәктә калганнар турында уйлап, түзә алмаслык газап эчендә янган Әбүталип үз-үзен хөкем итәргә, гаебен аңларга, ни өчен чынлап та җәзаларга тиешләр дигән сорауга җавап табарга тырышты. Ләкин җавап таба алмады. Чолганышта калырга туры килгән башка меңнәр кебек үк, әсирлеккә төшкәне, немец тоткынлыгында булуы өчен дисәң генә инде. Тик, шул иске җәрәхәтне кузгатып, күпме интектерергә була? Сугыш инде артта калды. Барысы өчен дә артыгы белән түләнгән – кан белән дә, лагерьлар белән дә. Сугышта булганнарның күбесенә кабергә кереп ятар вакыт җитеп килә, ә

чиксез хакимияткә ия зат әле һаман аларны эзәрлекли, һаман тынычлыкта калдырмый. Бу хәлләрне ничек аңлыйсы? Җавап таба алмагач, Әбүталип, үзе белән аянычлы аңлашылмаучылык кына килеп чыккандыр, бүген булмаса иртәгә шул ачыкланыр, дигән өмет белән яши, әгәр шулай булып чыкса, Әбүталип Котлыбаев шунда ук бөтен-бөтен үпкәләрен онытыр иде; тизрәк азат итсеннәр дә тизрәк өйгә җибәрсеннәр генә, ул анда, Сарүзәктә, Буранлы станциясендә, әтиләрен көтеп арыган балакайлары Эрмек белән Даул, карлы далада сабыйларын яралы канаты астында, ярсып типкән йөрәгенә кысып саклаучы, күз яшьләре һәм иксез-чиксез ялварулары белән язмышны үзләренең гөнаһсыз икәнлегенә ышандырырга тырышучы, иренә котылу насыйп булсын өчен, Алладан мәрхәмәт сораучы хатыны Зарифа янына йөгереп, юк, очыплар кайтыр иде.

Хәсрәтеннән үкереп еламас өчен, акылыннан тәмам язмас өчен, тынычлык эзләп, Әбүталип үзен үзе алдамакчы була: менә ул хыялга бирелә – бер гаебен дә раслый алмаулары аркасында, акланып, кинәт өенә кайтып керүен күз алдына китерә. Имештер, ул, юл уңае туры килеп, өенә кадәр утыртып кайткан товар вагонының баскычыннан сикереп төшә дә өенә йөгерә. Имеш, хатыны белән балалары аңа каршы чабалар... Әмма мондый минутлар тиз уза, һәм ул, махмырдан соң айнып киткән кебек, кабат күңел төшенкелегенә бирелә, шул чакта аңа, үзе язып алган «Сарүзәктә җәзалап үтерү» риваятендәгедәй, бер гөнаһсызга асып җаны кыелган ата-ананың газапланулары, аларның яңа туган сабый белән бәхилләшүләре мәңге дәвам итә торган, хәзер инде аның үзенә дә кагылучы хәл булып тоела. Ул да аерылу җәзасына дучар ителде ләбаса. Ә бит балаларны ата-анадан бары тик үлем генә аерып алырга мөмкин, бүтән һичкемнең моңа хакы юк...

Әбүталип шундый сагышлы минутларда, үз-үзеннән оялып, әкрен генә елый, нык яңакларын ташка сибәләп яуган яңгыр сыман чылатып аккан күз яшьләрен ничек тыярга белми. Хәтта сугышта да ул болай ук газап чикмәгән иде бит, ул чакта, «кайгым юк буранда, атым юк урамда» дигәндәй, үзалдына гамьсез генә яши төсле иде, ә хәзер, бер карасаң, гап-гади күренештә – балаларда – тормышның иң бөек мәгънәсе тупланган, һәм һәрбер очракта, һәркем өчен нәсел дәвамы булудан да зуррак бәхет юклыгына, шуңардан мәхрүм калу исә фаҗига икәнлегенә инана бара... Инде ул югалтыр алдыннан фани дөньяның никадәр мәгънәгә ия булып алдыңа килеп басуына, иң соңгы сәгатьтә, йөрәкне талаган ут балкышыннан котылып, мәңгелек караңгылыкка кереп чумар алдыннан, бөтен тормышына йомгак ясар вакыт килеп җиткәненә ышанды. Әйе, яшәүнең төп йомгагы балалар икән. Ихтимал, табигатьтә ул шулай корылгандыр да – ата-ананың тормышы үзләренең дәвамын үстерүгә сарыф ителә. Ата-анадан балаларын аерып алу – җинаять, кешене бу дөньядагы төп бурычын үтәү мөмкинлегеннән мәхрүм итү, аның тормышын буш башакка әйләндереп калдыру дигән сүз. Менә шулай аңы ачылган чакларда, кайчан да бер мөмкин булыр кебек тоелган күрешү мәлләрен ап-ачык диярлек күз алдына китергәч, күңелең нечкәреп, төшенкелеккә бирелми калуың бик кыен шул; өметенең тормышка ашмасын Әбүталип, әлбәттә, аңлый һәм шуңа күрә чарасызлык корбанына әверелә иде. Көн узган саен, сагыш аның күңелен тирәнрәк били, аяусызрак кимерә барды һәм, ихтыяр көчен суырып, тәмам хәлсезләндерде. Өметсезлек текә тау битендәге юеш кар сыман, аның менә һич тә көтмәгәндә ишелеп төшүе якынлаша сыман иде...

МГБ (Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы) тикшерүчесе Тансыкбаевка

шул гына кирәк тә: ул, нәкъ менә эзлекле һәм максатчан рәвештә, мәкерле ниятенең барып чыгуына омтылды – элеккеге хәрби әсир Әбүталип Котлыбаевның, Югославия һәм Англия разведкалары белән бәйләнештә булып, Казакъстанның ераграк төбәкләрендәге җирле халык арасында корткычлык фикерләрен таратуы турында, иблис кебек, үзе уйлап чыгарганнан соң, өстәге башлыкларының хуплавына таянып, «үрә башлаган» бик хәтәр «эш» иде бу. Аның гомуми кысасы бик гади, Тансыкбаевның чиктән тыш сәяси уяулыгын һәм хакимияткә хезмәт итәргә ашкынып торуын расларга тиешле үрмәкүч тозагы корып куелды инде. Әбүталип – менә дигән корбан. Билгеле, алда әле кайбер нечкәлекләрне ачыклау, бәяләү – үзенә күрә тикшерү эше тора, тик моңарчы Котлыбаевның җинаятен үзе тулысынча тануы кирәк. Әлеге «эш» Тансыкбаев өчен аның тормышындагы зур уңыш булса, Әбүталип Котлыбаевны ул өметсезлек чоңгылына батырырга көтеп тора иде, чөнки мондый капкыннан котылу юлы юк. Бу – тулысынча алдан хәл итеп куелган очрак, мондый гаепләүне тагу ул заманда үзе үк инде җинаятьне берсүзсез исбатлау дип санала иде.

Шуңа күрә Тансыкбаевка әлеге мәкерле эше ничек барып чыгар дип борчылмаска да була. Ул кышны, ниһаять, кем әйтмешли, аның кар ера-ера карьерага бару сукмагы алдан ук көрәп куелган иде. Хезмәтендә вак кына хата китү аркасында, ул берничә елга майор дәрәҗәсендә тоткарланып калды. Ә хәзер, күрәсезме, көтелмәгәндә яңа мөмкинлек ачылырга тора. Үзәктән читтә Әбүталип Котлыбаев эшенә охшаган нәрсәдер табуы бер дә еш була торган хәл түгел. Менә бит, уңса да уңар икән майор!

Әйе, 1953 елның карлы-буранлы февраль көннәрендә дөнья барышы Тансыкбаевка мәрхәмәт күрсәтте: әйтергә мөмкин, ил тарихы аның мәнфәгатьләренә хезмәт итәр өчен генә яшәгән кебек иде. Аңлаудан бигрәк, сиземләү аша, ул бу тарихта үз хезмәтенең әһәмиятен беренче дәрәҗәле итеп куеп, гел генә көчәйтеп торучы, шуның белән аның үзен дә торган саен ныграк күтәрә баручы изге көчне тойды, шуңа күрә яңа «эш»кә тагын да дәртләнебрәк алынды һәм чиксез рух күтәренкелеге кичерде. Хәзер көзгегә караса да, ул гажәпкә кала – аның керфек какмый торган лачын күзләре күптән болай яшь булып балкымыйлар иде бит. Менә ул иңнәрен турайтып, канәгать төс белән, борын астыннан гына саф русча җырлап җибәрә: «Мы рождены, чтоб сказку сделать былью...» Аның ни-нәрсәгә өметләнеп яши башлаганын белеп-хуплап торучы хатыны шулай ук кәефле генә күренә һәм, җае чыккан саен: «Ярар, тиздән без дә үзебезгә тиешлене алырбыз әле», – дип куйгалый иде. Өлкән класста укучы уллары, комсомол активисты, ул да, кайвакыт атасын тыңламаган чаклары булса да, мондый форсатны күргәч, чын күңелдән сораша, әледән-әле: «Әти, подполковник йолдызлары белән котлыйсы көн ерагмы әле?» – дип, атасының күңелен күреп тора. Тансыкбаевка турыдан-туры кагылмаса да, мондый ашкынуның үз сәбәпләре бар иде...

Эш шунда ки, чагыштырмача күптән түгел, ярты еллап кына элегрәк булыр, Алматыда ябык процесс уздырдылар: хәрби трибунал казакъ буржуаз милләтчеләренең бер төркемен хөкемгә тартты. Хезмәт халкының бу явыз дошманнары аяусыз рәвештә һәм мәңгелеккә юк ителде.

Икесе, казакъ телендә язган, яңа чынбарлыкны инкяр итеп, кайбер суккан патриархаль-феодаль үткәннәрне идеаллаштырган фәнни хезмәтләре өчен иң югары җәзага – атып үтерелүгә лаек дип табылды, Фәннәр академиясенә караган Тел һәм әдәбият институтының ике хезмәткәре егерме бишәр ел

каторга алды... Калганнары, дөрес, унар ел белән генә котылды... Шулай да иң мөһиме: әлеге процесс белән бәйләп, буржуаз милләтчеләрне фаш итүдә һәм аларның тамырларын рәхимсез рәвештә куптарып ташлауда турыдан-туры катнашкан махсус хезмәткәрләргә үзәктән зур дәүләт бүләкләре кайтты. Ул бүләкләрне яшереп кенә бирделәр-бирүен, әмма, аңа карап, бәяләре кимемәде. Кушылганны үрнәк төстә үтәгән өчен, погоннарга вакытыннан алда йолдызлар тагу, орденнар һәм медальләр өләшү, зур акчалар белән бүләкләү, боерык белән рәхмәт белдерү һәм башкача игътибар күрсәтү органнарда хезмәт итүчеләрнең тормышын бик бизәде, минсиңайтим! Аеруча тырышлык күрсәткәннәргә яңа фатир ачкычларын бирү дә бик ярап куйды. Боларның һәммәсе аларның тавышын көрәйтте, аяк асларындагы туфракны ныгытты, итек үкчәләре дә ышанычлырак шакылдый башлады.

Тансыкбаев, үзе әлеге дәрәҗәләргә ирешкән һәм бүләк алганнар төркеменә кермәсә дә, хезмәттәшләренең тантана итүендә актив катнашты. Һәр кичне диярлек хатыны Айкумис белән алар чираттагы яңа дәрәҗә, орден, фатир алуларны «юу» мәҗлесенә юл тоттылар. Бәйрәм табыннары Яңа ел алдыннан ук бер-бер артлы башланып китеп, бик матур, онытылмаслык булып уза иде. Салкын, начар яктыртылган Алматы урамнарыннан, өшеп, җиңелчә калтыранып кергән кунаклар, әнә, бусагадан узуга ук, яңа фатирларында көтеп торган хуҗаларның якты чыраен күреп, күңел җылысын тоеп кинәнәләр. Ишек төбендә каршылаучы йөзләрнең, күзләрнең шулкадәр җанлануын, бер горурлык хисе белән ничек балкуын күрсәгез иде! Чыннан да, болар сайлап алынган, бәхет тәмен яңабаштан татучы бу кемсәләрнең күңел һәм корсак бәйрәме булып чыкты. Ул чакта, әле сугыш елларының күптән түгелге хәерчелеге һәм ачлыгы онытылып җитмәгәндә, илнең моның кебек читтәге төбәкләрендә яңа, нәзакәтле уңайлыклардан, канәгатьлек хисеннән башлар әйләнерлек иде. Биредә, провинциядә, кыйммәтле коньяклар, бәллүр кандилләр һәм затлы савыт-саба әле яңа гына модага кереп бара. Түшәмнәрдән трофей люстраларның күзне һәм җанны иркәләүче көмеш яктысы сирпелә, яңа явып киткән кар кебек ап-ак эскәтер ябылган өстәлләрдә немецтан алып кайтылган сервизлар җем-җем итә, боларның барысы да кәефне күтәрергә, хуҗаларга тирән хөрмәт күрсәтергә этәрә, һәм бу халәт килгән кунакларның да күңелен биләп ала: әйтерсең лә тормышның иң югары мәгънәсе шул люстраларда, сервизларда гына, әйтерсең лә дөньяда игътибарга лаеклы бүтән берни дә була алмый.

Ишекне ачуга, аш пешерү бүлмәсеннән таныш исләр килеп бәрелә, анда, башка ризыклар белән бергә, иң кирәкле, иң затлы тәгам – бабайларның күчмә тормышыннан килүче, яңа диварларда да ераста калган дала хуш исләрен хикмәтле рәвештә аңкытып торучы, йомшак, яшь ат ите пешә. Җыелганнарның барысы да, уртак аш табынының тәмен алдан сизеп, селәгәйләрен агыза һәм урындыкларга әдәпле генә утырыша башлый. Шул ук вакытта табынның мәгънәсе ашауда гына түгел икәнлеге аңлашыла, чөнки, туйгач та, кеше, эченнән генә, өстәл янындагы сүзләрдән – котлаулар һәм изге теләкләр әйтешүдән бигрәк, алдындагы ризыкның күплегеннән, муллыгыннан газаплана башлый, ә бит бу йолада бетмәс-төкәнмәс татлы хыялларның тормышка ашуына сөенеч йомарланып ята, һәм шушы хикмәтле хис тирә-юнеңдәге бар нәрсәне сыйдыра, үзенә сеңдерә бара. Хәтта көнчелек тә, вакытлыча гына, көнчелек үк түгел, ә кече күңеллелеккә, үзара дустанә мөнәсәбәткә охшап ала, икейөзлелек исә кыска вакытка гына булса да риясызлыкка әверелә кебек.

Катнашучылардан һәркайсы, гажәеп рәвештә яхшы якка үзгәреп, башкалар белән, үз ихтыярларыннан тыш, игълан ителмәгән ярышка кушыла да мөмкин кадәр акыллырак, ә иң мөһиме – матуррак итеп сөйләргә тырыша. Ah, бу һич кабатланмас, үзенчә мавыктыргыч бер тамаша иде! Табын хуҗасы, драма театрында тәхеткә менүче корольне уйнаган артист сыман, шулкадәр кукраеп утыра, аннары, бәлки, үз гомерендә беренче тапкырдыр, шулкадәр тәэсирле итеп нотык сөйләргә алына.

– Асыл достар! (Кадерле дуслар!) – дип башлый подполковник, шул ук вакытта, үзенә тулы, җитди игътибар таләп иткән кебек, өстәл тирәли утырганнарны мәһабәт карашы белән капшап чыга. – Үзегез түсенесиздер (төшенәсездер), бүген минем йөрәгем мөлдерәмә – бәхетем диңгез кебек тулышкан. Түсенесиздер. Минем дә бер сүз әйтәсем килә. Бүген минем сәгатем сукты, һәм минем сүз әйтәсем килә... – Подполковник тиешенчә каралмаган көзге юлдан баручы иске машина кебек батып калырга чамалый, әмма сер бирми, барыбер сүзен дәвам итә. – Түсенесиздер. Мин һәрвакыт имансыз булдым. Комсомолда үстем. Мин – какшамас большевик. Түсенесиздер. Һәм шуның белән бик горурланам. Алла – минем өчен буш урын. Алланың юклыгы һәркемгә, һәр совет мәктәп баласына билгеле. Ләкин минем бөтенләй башка нәрсә турында әйтәсем килә, түсенесиздер, дөньяда Алла бар бит ул! Бер генә минутка сабыр итегез, мыек астыннан көлемсерәргә ашыкмагыз, кадерлеләрем... Кара син аларны! Мине сүземдә тоттык, дип уйлыйсыз бугай. Юк, бер тамчы да ялгышмадым! Түсенесиздер. Мин инкыйлабка кадәр эшче халыкны изеп яшәүчеләр уйлап чыгарган Алланы күздә тотмыйм. Безнең Алла, – гәзитләрдә язылганча, үз ихтыяры белән Җир шарында тулы бер дәверне башлап, адым-адым тормышка ашыра торган һәм безне җиңүләрдән җиңүләргә, коммунизмның дөньякүләм тантанасына алып баручы хакимият иясе; ул дәһи жолбасшыбыз, – түсенесиздер, – кәрван башлыгы иң алдагы дөянең нуктасын тоткан кебек, дәвер үзәңгесен нык кулларына алган, – ул безнең Иосиф Виссарионович! Һәм без аның артыннан ияргәнбез, кәрванны ул иртеп бара, ә без аның артыннан – бер үк сукмактан. Һәм бездән аермалы уйлаучы яки безнеке булмаган идеяләрне күңелендә йөрткән берәү дә безгә тимер Дзержинский васыять итеп калдырган, аяусыз җәзага тартучы чекист кылычыннан качып котыла алмаячак. Түсенесиздер. Дошманнарга без соң чиккәчә көрәш игълан иттек. Аларның нәселе, гаиләсе һәм аларга теләктәшлек белдерүчеләр, пролетариат эше хакына, түсенесиздер, көз көне бер күчкә җыеп утта яндырылган сары яфраклар төсле юк ителәләр. Чөнки идеология бер генә була. Түсенесиздер, бүтән бернинди идеология була алмый. Менә без сезнең белән җирне идеологик дошманнардан – буржуаз милләтчеләрдән һәм шуның ише башка чүп-чардан арындырабыз, түсенесиздер, дошман кайда гына яшеренсә дә, кем булып кына кыланса да, аңа бернинди шәфкать күрсәтү юк. Һәркайда сыйнфый дошманны фаш итәргә, дошман агентурасын ачыкларга, түсенесиздер, иптәш Сталин өйрәткәнчә, дошманны кыйнарга, халыкларның рухын ныгытырга – менә безнең девиз. Бүген, минем хезмәтемне югары бәяләгәндә, вакыты җиткәнче үк яңа дәрәҗә бирү турында боерык укылган чакта, мин алга таба да, һичкая тайпылмыйча, Сталин сызыгыннан барырга, түсенесиздер, дошманны эзләргә, табарга һәм аның җинаятьчел ниятләрен ачарга ант итәм. Түсенесиздер, төп милләтчеләрне без инде коралсызландырдык, әмма институтларда һәм редакцияләрдә аларга теләктәшлек итүчеләр посып калды әле. Ләкин бер дошман да бездән беркая

китә алмас, һәм аларга һичнинди рәхим-шәфкать булмаячак. Ничектер, сорау алу вакытында миңа бер милләтче әйтә, түсенесиздер, барыбер, ди, сезнең тарих тар тыкрыкка – тупикка керәчәк, һәм сезгә, мөртәтләргә, иблис ялчыларына, ләгънәт төшәчәк, ди. Түсенесиздер?!

– Андыйларны шул урында ук атып үтерәсе иде! – дип, түзмичә, сүз кыстырды Тансыкбаев һәм хәтта, ярсып, урыныннан ук тора башлады.

– Дөрес, майор, мин дә шулай эшләгән булыр идем, – дип, аны хуплаган булды подполковник, – тик әле ул тикшерү эшләре өчен кирәк иде, һәм мин аңа әйттем, түсенесиздер: без тар тыкрыкка кергәнче, син, бәдбәхет, күптән инде бу дөньяда булмассың! Эт өрә, ә Сталин кәрваны алга бара...

Барысы берьюлы шаркылдап көлеп җибәрделәр, теге, тузан бөртегедәй вак милләтчене урынына утырткан зирәк җавапны хуплап, кул чәбәкләделәр, әзер бокалларын сузып, барысы бергә урыннарыннан купты. Бер тын алдылар да: «Сталин өчен!» – дип, һәммәсе дә, әйтелгән сүзләрнең хаклыгын һәм аларга тугрылыклы булуларын раслагандай, бушаган бокалларын бер-берсенә күрсәтеп, дәррәү эчеп куйдылар. Аннары да бу фикерне дәвам итүче тагын күп тостлар әйтелде. Һәм бу сүзләр, яңадан туып, ишәя-ишәя көч алган, агулы һәм күп булуларын тойганлыктан усаллана барган, үзләренә яшертен ачу һәм ярсу туплап, тузгыган кыргый шөпшә күчедәй, монда җыелган кешеләрнең баш очында әле озак әйләнделәр.

Тансыкбаевның күңелендә исә, үзенең фикерләрен кузгатып, аның тәвәккәллеген ныгытып, кайнар дулкыннар бәргәләнә иде, һәм бу – әлегедәй сөйләнүләр аның өчен яңа булганлыктан түгел, һич юк, киресенчә, аның бөтен гомере, шулай ук күпсанлы хезмәттәшләренең яшәү рәвеше, аларның күзаллавын чолгап алган җәмгыять тормышы көнмә-көн нәкъ шул берөзлексез камчылап тору, «сыйнфый» дип аталган һәм шунлыктан бөтен яктан тулысынча аклана торган ярсулы көрәш мохитендә кайный бит... Ләкин монда яшерен бер мәсьәлә бар. Көрәшне даими кыздырып торыр өчен, корбаннарның яңадан-яңасы, фаш итүләрнең моңарчы булмаган юнәлешләре кирәк; чөнки күбесе инде чәйнәп төкерелгән: тулы бер халыкларны Себер һәм Урта Азиядәге һәлакәтле сөргенгә озату ише кайбер алымнары балы суыртылган кәрәз кебек бушап калган; шуңа күрә әлеге «оя»лардан яңа уңыш җыеп алу, әйтик, ил читендәге милли төбәкләрне буржуаз-феодаль милләтчелектә җиңел генә гаепләү дә торган саен кыенрак була бара. Ачы тәҗрибә тупланган саен, теге яки бу затка, идеологик яктан шик ташлап, кечкенә генә яла ягудан да аның үзен харап итүләрен һәм шунда ук якыннарыннан үч алыну ихтималын истә тоткан кешеләр инде хәтәр хаталардан башларын саклыйлар, милләтчелек чагылышы дип талкырга мөмкин булган берни дә сөйләмиләр һәм язмыйлар. Киресенчә, күпләр кирәгеннән артык дәрәҗәдә сак һәм алдын-артын карап эш итә башладылар ки, инде теләсә нинди милли байлыклардан, бөтен кеше ишетерлек-күрерлек итеп, ачыктан-ачык баш тартып, туган телләреннән йөз чөерүгә кадәр барып җиттеләр. Бар, син аны тотып кара, ул бит бары тик Ленин телендә генә сөйләшкәнен һәм уйлаганын адым саен тукып-тәкрарлап тора...

Һәм нәкъ менә шул, вакыйгаларга ярлыланып киткән, яңа яшерен дошманнарны ачыклау буенча көрәшне алга таба үстерү кыенлашкан бу дәвердә майор Тансыкбаевка, очраклы гына булса ни, барыбер бәхет елмайды бит әле. Беркемгә билгесез диярлек кечкенә Буранлы станциясеннән Әбүталип Котлыбаев өстеннән килгән әләк – аның кулына әһәмияте белән әллә ни искитәрлек булмаган, җитди тикшерүдән битәр танышып чыгар өчен

генә бирелгән бер мәгълүмат кыйпылчыгы иде югыйсә. Әмма Тансыкбаев үзенә тиешлене казып чыгара алмыймы, ә чыгарганнан соң, кулыннан ычкындырамыни соң! Сиземләве алдамады. Иренмәде Тансыкбаев, урында ачыклыйм әле дигән булып, шул якларга барып кайтты һәм инде менә беренче карашка гади генә күренгән эшнең дә, тиешенчә борып җибәрә белсәң, шактый саллы булып китүе мөмкин икәнлегенә көннән-көн ныграк ышана бара. Һәм, димәк ки, бөтенесе дә кирәгенчә, ягъни ул теләгәнчә барып чыкса, өстәгеләрнең бүләкләре тәгаен аны да әйләнеп узмас. Бу мәлдә әлеге табын янында, шундый зур тантана шаһиты булып, Алла-Хакимияткә бөтен күңеле белән бирелгән һәм шунлыктан өстәлдәге, түшәмдәге бәллүр ялтыравык-юанычлар эчендә ләззәтләнә торган, үзенә яхшы таныш бу кешеләр арасында тиккә генә утырамыни, мондый эшләрнең ничек әвәләнгәнен белмимени ул?! Әмма дә ләкин Алла-Хакимияткә илтүче юл бер генә, ул – йөзләрен битлек астына каплаган дошманнарны ачыклау һәм фаш итү, кара тиргә батып, армый-талмый, аңа хезмәт күрсәтү.

Ә дошманнар арасыннан кем әсирлектә булып кайткан, шуларга бигрәк тә уяу шымчылык итәргә кирәк. Алар – маңгайларына пуля җибәрмәүләре белән үк җинаятьчеләр, чолганышта калсалар да, кулларын күтәрмәскә, үләргә һәм шуның белән уңга-сулга тайпылмауны – үлсәң үл, әмма әсирлеккә төшмә, дип таләп иткән Алла-Хакимияткә чиксез бирелгәнлекне исбатларга тиешләр иде. Кем дә кем әсирлеккә төште, ул – шул үк мизгелдән җинаятьче, һәм моның өчен котылгысыз җәза бирү һәркемгә, бөтен заманнарга, барча буыннарга кисәтү булып хезмәт итәргә тиеш. Юлбашчының – Алла-Хакимиятнең күрсәтмәсе шундый. Тикшерү өчен кулга алынган Котлыбаев исә – нәкъ менә элеккеге хәрби әсирләр сафыннан, шуның өстенә аның эшендә гадәттән тыш мөһим, әле зур хаҗәте чыгасы бер ябышыр нәрсә, бик кирәкле «сөял» беленеп тора; әгәр Котлыбаевтан шул «сөял»не куптарып ала алсаң, әллә ни әһәмиятле факт та булмасын, ди, тик аның, тиешле урынга кагып куелган кечкенә кадак сыман, зур эшне беркетүдә – Сталин хуплавыннан башка гына Югославиянең аерым үсеш юлына дәгъва кылучы Тито – Ранкович ревизионистлар өеренең баштан ук сатлык уй-ниятләрен фаш итүдә кирәге чыгуы бар... Кара син аларны, нәрсә кырмакчы булалар! Әле сугыш кайчан гына бетте, ә алар инде аерылырга маташалар. Барып чыкмас! Сталин бу идеяне, көлгә әйләндереп, җилгә очырыр. Һәм менә шул чакта, бәләкәй генә фактка таянып та, Югославиядәге сатлык ревизионист идеяләренең инде күптән – сугыш елларында ук партизан командирларында туганлыгын һәм Англия махсус коткы тарату хезмәтләренең турыдан-туры йогынтысыннан килеп чыкканлыгын тагын бер мәртәбә исбатлау һич артык булмас иде. Ә Әбүталип Котлыбаев язмаларындагы югослав партизаннарының ничек итеп англичаннар белән очрашуы турындагы истәлекләр... – һәрхәлдә, хәзерге мәлдә аңардан ни сорала – шуны теленнән тартып әйттерү өчен, менә дигән нигез бар. Шәт, шулай икән, моңа ничек кенә булса да ирешергә кирәк. Ярылсаң сигезгә ярыл, әмма бу Сарүзәк кәгазь кортыннан бөтен кирәкле сүзне сытып чыгар. Сәясәттә җил искән уңайга оча торган бөтен нәрсә дә ярап куя. Һәр вак-төякнең хаҗәте чыгуы бар, идеяләр бугазга-бугаз килгәндә, дошманның башын тишәрлек ташка да әйләнергә мөмкин алар. Шуңа күрә, хәтта чуерташ хәтле генә булса да, аны табып алырга кирәк, тапкач та, аны символик рәвештә, әмма чын йөрәктән Алла-Хакимиятнең үз учына саласың, ул исә әлеге ташны, үзе атмаса, тиешле кешесенә тоттырыр да, гәзитләрдә язылганча, мәче косыгы

кебек җирәнгеч ревизионист Тито һәм аңа тагылган Ранковичның куштан койрыкларына тондырырга әмер бирер. Ә инде бөтенләй эшкә ярамаса, ташың ваграк, дип әйтсәләр, барыбер тырышлык исәпкә алынмый калмас... Күрерсең дә торырсың, бу өстәл тирәсендә утыручыларның һәммәсе әле аңа да килер, менә шулай, бик шәп вакыйганы билгеләп үтәр өчен, аның өендә утырышырлар. Яшәүнең мәгънәсе – бәхеттә, ә бәхетнең башы – уңыштыр!

Әлеге чакырулы кичәдә шоңкар күзле Танысыкбаевның башына менә шундый уйлар килде, һәм, табын янындагы гәпләшү вакытында башкалар белән сүз атышкан булып утырганда да, ул, дәрьяның ургылына чумудан ләззәт алган оста йөзүче-гаувас сыман, артканнан-арта баручы дәртле омтылышлары һәм көчле теләкләре дулкынында тирбәлә иде. Ирен яхшы белгән хатыны Айкумис кына аның, төнлә ауга чыккан һәм инде табышының исен сизеп котырынган кыргый җанвардай, ниндидер көчле кичерешләр белән көрәшүен сизде. Ул моны иренең күзләрендә, вакыт-вакыт әле боз кебек каткан, әле кайнар дулкынлану белән эреп алган, керфек тә какмый торган лачын карашында күрде. Шуңа күрә ул аңа: «Моннан бүтәннәр белән бергә чыгабыз да бары тик өйгә генә кайтабыз», – дип пышылдады. Танысыкбаев теләр-теләмәс кенә ым кагып җавап бирде. Кешеләр алдында каршы әйтәсе килмәде, бәлки, әйтергә дә ярагандыр. Аның башында яңа, тагын да колачлырак хәрәкәт планы өлгереп килә иде. Котлыбаев белән бергә югослав партизаннары янында башка күп әсирләр булган бит, алар бүген илнең төрле почмакларында качып утыра, димәк, алар да нәрсәдер белергә, искә төшерергә мөмкин, Котлыбаевны үз ишләре арасыннан аеруча активларын атарга мәҗбүр итү әллә ни кыен булмастыр. Ни бар мәгълүматны күтәрергә, иртәгә үк тиешле урыннардан соратып мөрәҗәгать итәргә кирәк. Йә инде үзенә мөмкин кадәр тизрәк башкалага барырга, ачыкларга, казып чыгарырга һәм аннары Котлыбаевны кирәкле исем-фактларны расларга мәҗбүр итәсе генә калачак. Ә шуннан соң, имештер, аның күрсәтүләренә таянып, Югославиядә сугышкан элеккеге әсирләрне гаепләргә, ул затларны, бер-берсен әләкләмәгәннәре, Советлар Союзына кире кайтару комиссиясен узганда, хыянәтчел ниятләрен яшергәннәре өчен, яңадан җавапка тартырга кирәк. Мондый төр кешеләр йөз яки мең генә дә булмаска мөмкин, соңыннан бу халыкны лагерьларга куып ябарга һәм шуның белән барысына да нокта куярга! Әлеге шәп идеяне, мөгаен, югарыга яшерен хат рәвешендә җиткерергә туры килер.

Төрле аш-су һәм коньяк рюмкалары тезеп куелган табын янында кинәт кенә башына суккан бу фикердән күңеле күтәрелгәнен сизде Танысыкбаев, аның тагын эчәсе килде, тагын кабымлык йотасы, гомумән, үз-үзеннән канәгатьлек кичереп, тормышында ниндидер яңа борылыш буласын алдан тоеп җырлыйсы һәм күршеләренең «сакалы белән уйнап», алардан көләсе килде. Янәшәсендә утырганнарны серле ялтырый башлаган күзләренең рәхмәтле карашы белән айкап алды: мондагыларның һәркайсы аңа туганыдай үз, якын, барысы да бер тавык чебиләре кебек бит, һәм шунлыктан бу мәлдә алар белән шундый рәхәт, ә менә ул мәхлуклар аңарда нинди бөек идеяләр туу мизгелендә катнашуларын сизмиләр дә. Боларның һәммәсе Танысыкбаевның болай да кызган башына кайнар кан йөгертә һәм тантана итүче йөрәген шатлыктан шауларга, еш-еш дөпелдәргә мәҗбүр итә иде.

Күңеленә килгән уй-ният аны хезмәт юлы буенча өскә үрмәләүнең шактый чынга ашардай буласына өметләндерә, бу – акылга һәм мантыйкка да муафыйк лабаса: посып торган дошманнарны никадәр ныграк таптасаң, үзең шулхәтле биегрәк үсәсең. Ниятләгәненең уңыш белән төгәлләнәчәге бүгеннән үк

күңеленә канатлар куя иде, һәм ул, эченнән генә булса да, беркадәр әтәчләнеп уйлады: «Акыллы кешеләр үз эшләрен менә шулай оештыралар! Мин дә, бу күпмегә генә төшсә дә, ярты юлда туктап калмам!» Кичекмәстән хәрәкәт итәсе – хәзер үк гараждан машина чакыртып барасы һәм Әбүталип Котлыбаев утырган, тикшерү изоляторы дип атала торган, тәрәзәләренә рәшәткә кагылган ярымподвалга йөгереп керәсе дә, вакытны әрәмгә уздырмыйча, эшкә тотынасы иде – шунда, камерада ук, сорау алуны башлап җибәрергә һәм шундый итеп куркытырга ки, тегенең җаны, эчәкләреннән савылып, авызына килсен. Шулай итсәң, эшнең барып чыгуы турында һич тә ике төрле сөйләшеп тору юк: Котлыбаев гаебен таный, англичаннар белән югославлар кушканны үтәргә алынуын раслый, аның белән бергә партизанлыкта булганнарның барчасын да исемләп атый, шуннан соң 58 нче статьяның 1 нче б пункты белән 25 ел лагерь мөддәтенә хөкем ителә; әгәр инде гаебен танымаса, ватанга хыянәт иткәне, чит ил махсус службалары белән агентура хезмәттәшлеге урнаштырганы һәм җирле халык арасында идеологик җимерү эшләре алып барганы өчен, аны атачаклар. Әйдә, ныклап уйласын.

Тансыкбаев күп кенә нәрсәләрне: сорау алу вакытында сөйләшүнең ни рәвешле барасын, Котлыбаевның ничек үҗәтләнеп каршы торасын һәм аны сындырыр өчен нинди чаралар күрергә туры киләсен дә алдан чамалап тора иде, әмма ул шунысын да белә: тегесе барыбер беркая китә алмас, яшисе килә икән, аның бүтән сайлар юлы юк. Билгеле, аяк терәп акланырга тырышыр, имештер, бернидә дә гаепле түгел, әсирлек хурлыгын, кулына корал тотып, югослав партизаннары белән бергә иңгә-иң торып сугышканда, каны белән юды, сугыш беткәч, илгә кайтару комиссиясен узды, сугыштан соң намуслы хезмәт итте һәм башкалар, һәм башкалар, ә бит боларның барысы да – буш сүз. Үзенең мондый сыйфатта түгел, ә бөтенләй башка максатта хаҗәт икәнлеген һәм тиздән, әгәр барысы да Тансыкбаев уйлаганча барып чыкса, дәүләтнең әлегә кайдадыр посып ятучы дошманнарын төбе-тамыры белән корыту эшендә коточкыч бер пәри туеның үзәгендә буласын мәхлук Котлыбаев кайдан белсен инде. Ул бу хәтәр чылбырда үз артыннан бөтенесен тартып-ияртеп китәрлек беренче буын буларак кына кирәк. Дәүләт мәнфәгатьләреннән өстенрәк ни була ала? Кайберәүләр уйлый, кеше тормышы дип. Диваналар! Дәүләт – бертөрле генә ягулык-утын – кешеләр тормышы белән дөрли торган мич ул. Дәүләт – һәрдаим янып торучы мич! Утын өстәп тормасаң, бу мич сүнә башлаячак һәм аның кирәге дә калмаячак. Әмма шул ук кешеләр үзләре аның авызына керәләр, чөнки дәүләттән башка яши алмыйлар. Ә яндырып торучылар (кочегарлар, ягъни мәсәлән) мичкә утынны берөзлексез өстәп-бирәп торырга тиешләр. Дөньясы шуңа корылган.

Мул табын янында хатыны белән янәшә утырганда, уйларын аңардан яшерүе кыен кебек тоелса да, Тансыкбаев әңгәмәдәш күршеләренә баш кагып һәм аларның сүзен җөпләп өлгерә, берара партия мәктәбендә укып йөргәндә, классик тәгълиматлар турында кайбер нәрсәләр колагына чалынып калганга, боларның һәммәсе уңаеннан үз-үзе белән эченнән фәлсәфә куерта һәм шым гына кешенең нинди әкәмәт зат булуы белән хозурлана. Менә, мисал өчен, бу компаниядә, чакырылган кунак булып утыра ул, шушы мизгелләрнең мәгънәсенә баштанаяк һәм тулаем мөкиббән киткән кыяфәт ясый, ә үзе бөтенләй башка нәрсәләр турында уйлый. Йә, кем күз алдына китерә ала: кая төбәлгән бу адәмнең игътибары, башында нинди уй-ниятләр җитлегеп килә?! Тыныч кына өстәл янында утыргач та, әлегә беркемнең дә аның ихтыярына

гына бәйле кырып-җимереп бетерерлек, котылгысыз куәте булган нәрсәдер бар икәнлеге хакында, әлеге яшертен уй-ниятләренең көче гамәлгә аша калса, бәндәләрне – аның алдында, ә аның аша Алла-Хакимиятнең үз алдында да мүкәләп йөрергә мәҗбүр итәчәге турында хәбәре юк, һәм бу багланышта Алла-Хакимиятнең котларны алып торган тәхет баскычына таба илтүче күптин-күп, шулай да санаулы адымнар арасында берсе нәкъ менә ул булып торуын аңлау, аңарда, тәмле ризыктан авыз итүне яки шашынуны алдан тоеп-көтеп зарыккандагы шикелле, җисми ләззәт, хозурлык һәм сабырсызлану хисләрен уята. Чираттагы һәр рюмкадан соң бу әсәрләнү артканнан-арта һәм, бөтен тәнен мәмрәтеп, кан тамырлары буйлап тарала, аның барлыгын били, инде бу халәттә тыелып торуы да кыен, уйлаганын тормышка ашырырга иртәгәдән соңга калмый башлаячагын, әле барысына да өлгерәчәген үз-үзенә тукыр өчен, аңа шактый көч куярга туры килә

Алдында торган эшнең аерым кисәкләрен аңында берәмтекләп аралый торгач, Тансыкбаев үз ниятләренең төпле булуыннан, фаразларының мантыйкка тап килүеннән тирән канәгатьлек хисе кичерә. Шулай да нидер җитмәгән кебек бер тойгы калды әле, тагын нәрсәнедер уйлап бетерү таләп ителә, кайсыбер җинаять эзләренең төбенә төшми калынган кебек.

Мисалга, Котлыбаевның маңкорт турындагы язмалары арасында барыбер нидер яшеренеп ята бит. Маңкорт! Зиһене томаланып, анасын үтерүгә барган маңкорт! Әйе, әлбәттә, иске риваять бу, әмма аны язып алган Котлыбаев бер-бер максатны күздә тоткандыр, мөгаен?! Бөтен иген-җиген китереп, тырыша-тырмаша, очраклы рәвештә һәм тиктомалдан гына язып алмаган лабаса ул тарихны. Шулай, маңкорт, маңкорт... Ни яшерелгән монда, әгәр инде читләтеп әйтелгән икән, нәкъ менә нинди фикер соң ул? Һәм иң мөһиме, Котлыбаев маңкорт фәлсәфәсен үзенең коткы тарату максатында файдаланырга җыенган, дисәк, – ничек итеп? Маңкорт турындагы риваятьтә идеологик яктан шикле ни-нәрсәдер барын элем-чалым гына сиземли Тансыкбаев, мәгәр әле аны анык кына аңлый да, катгый итеп раслый да алмый, тәгаен фаш итәсенә тулысынча ышанып та җитми. Менә әгәр әлеге риваятьне, мондый очракларда тиеш булганча, халыкка каршы дип атап булса һәм шуның өчен җаваплылыкка тарттыра алсаң иде кана, тик ничек итеп? Бу эшкә Тансыкбаевның теше үтми, ул моны үзе дә белә. Берәр галимгә сүз катып карасаң инде. Менә бүген «юып» утырган вакыйга – буржуаз милләтчеләрне фаш итү дә – шул юл белән уңышка иреште ич: башта ниндидер төркемне казып чыгардылар, аннары бер яктагы белгеч-галимнәрне икенчеләренә каршы өсләттеләр, тегеләре инде үз ишләрен милләтчелектә, Сталинның социализм төзү дәверенә зыян салу максатында үткәннәрне мактауда гаеп ташларга әзер тора иде, һәм, тегермән ташы тәүлекләр буе әйләнә башласын өчен, шул җитә калды... Ә шулай да Котлыбаевның маңкорт тарихын ничек җентекләп язып алуында бер-бер хикмәт яшеренеп ята бит, ята! Аны яңабаштан дикъкать белән, һәр сүзенең төбенә төшеп уку кирәк, әгәр кечтеки генә ябышыр урыны табылса, их, риваять язмасын да эшкә җигәргә, гаепкә бөгәргә, «эш»кә теркәргә мөмкин булачак.

Моннан тыш, Котлыбаев кәгазьләре арасында тагын бер риваятьнең кулъязмасы табылды әле, анысы Чыңгызхан заманнарыннан калган, «Сарүзәктә җәзалап үтерү» дип исемләнгән иде. Тансыкбаев бу борынгы тарихка ни өчендер башта ук игътибар итмәгән икән һәм әле генә шул хакта уйга калды. Исәпләп карасаң, анда бит ниндидер сәяси ишарә күрергә була...

***

«Бөек Азия киңлекләреннән Кояш баешы илләрен яуларга халкын-чирүен ияртеп яу белән барганда, Чыңгызхан Сарүзәк далаларында бер җәзалап үтерү мәрәкәсе китереп чыгарды – сугышчы-йөзбашын һәм тантаналы ефәк һоруң-байракларның киң иңнәрен, авызларыннан ут-ялкын ургытып торучы аждаһалар белән бизәп, укалап чигүче яшь хатынны астырды.

Ул вакытка Азиянең зур өлеше Чыңгызхан үкчәсе астында калган, аның малайлары, оныклары һәм сәргаскәрләр (чирү башлыклары) арасында олысларга бүлгәләнеп беткән, хәзер инде нәүбәттә Идел аръягындагы төбәкләр язмышы, тулаем Аурупа язмышы тора...

Сарүзәк далаларына көз сулышы кагылган чак. Җәй дәвамында артык кипшенеп киткән күлләр һәм елгалар тоташ яуган яңгырлардан соң кабат үз хәленә кайта – инде атларны ничек сугару турында кайгырасы юк дигән сүз. Шулай да даланы иңләп-буйлап килгән чирү адымын тизләтте. Сарүзәк җирләре аша кичү юлның бигрәк тә авыр өлеше санала иде.

Өч чирү – унар мең сугышчыдан торган өч төмән, – канатларын киң җәеп, алдан ерып, Идел тарафына таба бара. Төмәннәрнең куәте турында аларның адымы – ат тояклары астыннан күтәрелеп, дала янгыныннан соң дөньяны каплаган төтен сыман, офыктан офыкка эленеп торган тузан буенча фикер йөртеп була иде. Янә кирәге чыкса, дип алынган алмаш атлары, олау-йөкләре һәм һәркөнне ашка суяр өчен кысыр мал көтүләре белән ике төмән арттан килә, – моңа ышану өчен, бер каерылып карау да җитә, – анда, шулай ук ярты күкне каплап, тузан өермәсе уйный. Әле ерактарак булганга гына күренеп тормый торган бүтән сугышчан көчләр бар. Аларга һәркайсында өчәр төмән булган сул («суңавыл») һәм уң («баравыл») канатларга барып җитәр өчен генә дә, атка атланып, берничә көн юртырга кирәк... Суыклар башланганчы, Идел ярына басып, хан тирмәсендә барлык унбер төмәннең дә сәргаскәренә алга таба хәрәкәт итүне килештерү һәм Чыңгызхан үзенә буйсындырырга хыялланган, аның яубашларының гына түгел, һәр җайдагының татлы хыялы булган бай вә шанлы илләргә таба Идел бозы аша кичүгә керешүнең тәртибен билгеләү күздә тотыла иде.

Яу сәфәрендәге чирүләр шулай, як-якка карамыйча, тоткарланмыйча, вакытны югалтмыйча, алга барды да барды. Хатын-кызлары да олаулары белән аларга тагылган иде, һәм бөтен бәла дә шулардан килеп чыкты.

Чыңгызхан үзе, озата баручы ярты меңләп кизүвыллары (кизүдә торган сакчылары) һәм яраннары – ясавыллары (ярдәмчеләре) белән, йөзмә утрау шикелле, әлеге хәрәкәтнең уртасында чайкала иде. Әмма ул алардан аерылыбрак – алданрак бара. Дөньяның Дүрт Тарафы Әмире, бигрәк тә яу сәфәре вакытында, дәшмәвең артык булып, алга карау һәм эш турында гына уйлау тиеш чакта, үз тирәсендә күп кеше буталуын яратмый иде.

Аның ияре астында, – бәлки, ярты дөньяны кичкәндер, чыныккан, чуерташ кебек шомарган, күкрәге һәм җилкәсе таза, ак яллы, кара койрыклы, ефәк кебек тигез-шома атлый торган яраткан юргасы Хуба. Чыдамлык һәм тиз йөреш ягыннан ким булмаган, кирәкләре чыга калса дип, сыбайлылар карамагындагы ике алмаш ат ялтырап торган бизәкле хан дирбиясендә йөксез генә бара. Хан атларны, тирли башлавы белән, юл уңаенда алыштыра.

Әмма игътибарга иң лаегы Чыңгызханның тирә-юнендәгеләр – гомерләренә аларның үзләреннән бигрәк Чыңгызхан ия булган, шуңа да бит инде алар,

хәнҗәр йөзе кебек, бик күпләр арасыннан берәмтекләп сайлап алынган – курку белмәс кизүвыллар һәм ясавыллар, шулай ук аларның табигатьтә сирәк табыла торган саф алтын төсле менә дигән менге атлары да түгел. Юк, ул сәфәрдә күз төшәргә мөмкин нәрсә бөтенләй бүтән иде. Юл буе Чыңгызханның баш өстендә, аны кояштан күләгәләп, болыт йөзде. Ул кая – болыт та шунда. Зур тирмә чамасы ак болыт, нәкъ менә тере җан иясе сыман, аның артыннан калмый барды. Һәм аның илаһи ишарә булуы беркемнең дә башына килми иде, югарыда болыт кисәкләре азмыни, ә бит Дөньялар Әмиренә фатихасын Күк-Тәңре шул рәвешле белгертте. Чыңгызхан үзе, нәрсәдер сизенеп, теге болытны астыртын гына күзәтә башлады, аның, чыннан да, Күк-Тәңренең ихтыяр тамгасы булуына торган саен ныграк ышана барды.

Болытның пәйда буласын Чыңгызхан бервакыт үзенә якынлашырга рөхсәт иткән ниндидер сәйяр күрәзәче алдан әйткән иде. Чит туфрактан килгән ул адәмчек, алтын тирмәдәге тәхетендә тәкәббер генә утырган дала илбасарының дәһшәтле чыраена төкергән кебек, горур башын югары тотып, ханның аягын үпмәде, аңа бил бөкмәде, ялагайлык күрсәтмәде, яраклашып күрәзәлек итмәде. Чандыр, йолкыш, җилкәсенә кадәр төшкән гаҗәеп озын чәче белән нәкъ бөдрәләрен тузгыткан хатын-кызны хәтерләтә иде ул. Карашы кырыс, сакалы дәү, кара-кучкыл йөзе арык иде.

– Мин синең янга, хакан, шуны әйтергә килдем, – дип, уйгур-тылмач аша сүзен җиткерде ул, – Күк-Тәңре ихтыяры белән, сиңа югарыдан аерым ишарә-ым булачак.

Чыңгызхан көтелмәгән хәлдән бер мизгелгә һуштан язган кебек булды. Бу килмешәк үз акылындамы соң, әллә мондый тәкәллефсезлек өчен үзенә ни буласын аңламыймы?!

– Нинди ишарә, һәм сиңа ул кайдан билгеле? – дип, ярсуын көчкә тыеп, маңгаен җыерып кызыксынды чиктән тыш кодрәт иясе.

– Кайдан билгеле – анысын белгертергә ярамый. Ә ишарәгә килгәндә, яшерми әйтәм – синең баш очыңда ак болыт пәйда булачак һәм сиңа ияреп барачак.

– Болыт?! – Таң калуын тыя алмыйча кычкырып җибәрде Чыңгызхан, кашларын текә сикертеп.

Тирә-юнендәгеләрнең барысы да, хан ачуының шартлавын көтеп, ирексездән җәя җебе кебек тартылдылар. Куркудан тылмачның да иреннәре агарды. Җәза җиле аңа да кагылырга мөмкин иде бит.

– Әйе, болыт, – дип җаваплады гаиптән хәбәр китерүче. – Ул – синең җирдәге бик югары дәрәҗәдә булуыңа үз фатихасын бирүче Күк-Тәңренең таныгы. Ләкин син бу болытны сакларга тиешсең, әгәренки аны жуйсаң, шул мәлдә үк хакимиятеңне, кодрәтеңне югалтачаксың...

Алтын тирмәдә үле тынлык урнашты. Чыңгызханнан ул мизгелдә теләсә нәрсә көтәргә була иде, тик кинәт аның карашының ярсуы учактагы янып бетүче ут кебек басыла төште. Үч алырга кыргый омтылышын җиңеп, ул мосафир күрәзәченең сүзләрен ачу китергеч дорфа кыланмыш дип кабул итмәскә кирәклеген һәм бигрәк тә аны җәзаларга ярамаганлыгын, әгәр шулай итсә, үзенең ханлык дәрәҗәсен төшерәчәген аңлады. Һәм Чыңгызхан, мәкерле елмаюын җирәнрәк төстәге сыек мыеклары астына яшереп, сүзен дәвам итте:

– Фаразан, синең күңеленә бу хәбәрне Күк-Тәңре салды, ди. Ярар, мин дә моңа ышандым, ди. Тик син әйт әле, зирәкләрнең зирәге булган килмешәк, күктәге ирекле болытны мин ничек саклый алырмын соң? Ул болытны тотып

торсыннар дип, канатлы атка атландырып, куалап торучылар җибәрергә түгелме тагын? Алар, алай-болай югалмасын өчен, аны ияр күрмәгән ат кебек авызлыклап куярга тиешләрдер, бәлки, ә? Җил иркендәге болытны ничек үземә бәйләп куярга соң миңа?

– Ә анысы инде – синең кайгың, – дип, кыска гына җавап бирде мосафир. Һәм кабат барысы да катып калды, тагын үлем тынлыгы урнашты, тылмачның да иреннәре янә агарды, бу мәлдә алтын тирмәдә булганнардан берсе дә әллә ахмаклыгы аркасында, әллә аңлашылмый торган бүтән берәр сәбәбе булып, үзен котылгысыз һәлакәткә дучар иткән бичара күрәзәчегә күзләрен күтәреп карарга кыймады.

Чыңгызхан тонык тавыш белән әйтеп куйды:

– Берәр бүләк бирегез дә китсенсәнә. – Аның бу сүзләре күңелләргә кибеп коргаксыган туфракка тамган саран яңгыр тамчылары кебек коелды.

Ошбу сәер, мәгънәсез очрак тиздән онытылды. Дөньяның нинди генә мәхлуклары юк, анысы да хак. Гаиптән хәбәр китердем, дип масаеп тора менә берәү! Әмма ул килмешәк акылга җиңеләеп кенә үлем белән шаярган, дип әйтү гадел булмас иде. Үзенең нинди тәвәккәл адымга барганын аңлагандыр ул. Ханның кизүвылларына аны, шунда ук боргычлап алып, кыргый ат койрыгына бәйләп җибәрү – тәкәллефсезлеге һәм чиктән тыш оятсызлыгы өчен мәсхәрәле үлем кочагына ташлау берни тормый иде. Әмма шулай да ул кыю килмешәкне, бернидән дә өркеп тормыйча, чүлдәге арысланга тиң дәһшәтле һәм шәфкатьсез хаким каршысына килеп басарга нәрсәдер этәргән, нәрсәдер рухландырган бит. Акылсыз адәмнең сәер кыланмышы булдымы ул, әллә, чынлап та, бу – Күк-Тәңре шаяруы идеме?

Һәм инде узган көннәр агышында барысы да онытылгач, нәкъ төп-төгәл ике елдан күрәзәче бичаракай кабат Чыңгызханның исенә төште.

Хаканлыкта Кояш баешы сәфәренә әзерләнү өчен, чынлап та, тулы ике ел вакыт китте. Соңрак Чыңгызхан инанды, хаканлык чикләрен тыела алмыйча киңәйтүнең юлларын табып килә торган хакимиятенә бу ике ел бөтен дөньяны яулап алуга, зарыгып көтелгән максатына – җирләрне һәм төбәкләрне басып алуга таба барыр өчен җитәрлек көч-гайрәт һәм юллык ризык туплауның иң эшлекле дәвере булган икән, – аларны кулына төшергәннән соң, инде ул үзен хаклы рәвештә Дөньяның бөтен Дүрт Тарафы, җиңелмәс атлы чирүенең дәһшәтле дулкыны каплаган чикләргәчә бөтен ерак җирләр Хакиме дип саный алачак. Дала хакименең гаять рәхимсез асылы, аның тарихи миссиясе соңгы исәптә менә шушы саташулы идеягә, барчасы өстеннән хакимлек итү һәм котылгысыз рәвештә чиктән тыш кодрәтле булу сусынына кайтып кала иде. Һәм шуңа күрә мәмләкәтенең бөтен яшәеше – галәмәт зур Азия киңлекләрендә аның хакимлегендәге барча олысларның, бер каты кул астына тупланган төрле кабилә-нәселдән килүче халыкларның, калалардагы һәм күчмә тораклардагы бөтен бай вә гидайларның һәм соңгы исәптә һәр кешенең, ул кем булып, ни белән генә шөгыльләнмәсен, тулысынча бу мәңге туя алмас иблис вәсвәсәсенә – тагын, тагын да басып алуларга, яңадан-яңа җирләрне, халыкларны буйсындыруга йөз тота иде. Шуңа күрә һәммәсе дә баштанаяк бары тик аңа – Чыңгызханга хезмәт итү белән мәшгуль, барысы да бердәм ниятkә – аның хәрби куәтен туплау, үстерү, камилләштерүгә юнәлтелгән. Җир астыннан табып алынган һәм корал ясауга тотып булган бар нәрсә, тормыш өчен кирәкле бөтен төзү эшчәнлеге яу хаҗәтләренә тотылырга тиеш; Чыңгызханның Аурупага, аның әкияттәгедәй искиткеч бай калаларына көч

белән ыргылуына, ә анда кымыз елга булып агачак, һәр сугышчыны мул табыш көтә, анда – куе яшел урманнар, ат корсагына тигәнче үскән үләне белән кызыктыручы аланнар һәм болыннар; кыскасы, дөнья күкрәгенә ике ботың белән басып хакимлек итү куанычы Чыңгызханның авызыннан ялкын ургылдыручы аждаһалы һоруңнары астында яуга барган һәркемгә тиячәк, һәм аларның һәркайсы, үзенең куенында иң дәртле хатынны татыган кебек, җиңү ләззәтен кичерәчәк, имеш. Шуның өчен алга барырга, җиңәргә яңа җирләр яуларга боера бөек хакан, һәм ул әйткәнчә булып чыгар да...

Чыңгызхан исәпчел һәм алдан күрүчән, бөтен барлыгы белән эш (яу) турында гына кайгыртучы гамәл кешесе иде. Аурупага басып керү өчен әзерлек башланганда, ул вак-төягенә хәтле барысын да исәпләп карады, алдын-артын уйлады. Тугрылыклы шымчылары һәм аның тарафына качып чыгучылар, хаҗ кылучылар һәм сәйяр дәрвишләр аша, алыпсатарлар, төрле илләрдә эш йөртүче кытай-уйгурлар, гарәп-фарсыларның телен чиштереп, гаять зур хәрби көчләрнең хәрәкәте өчен белергә тиешле һәрнәрсәне – бөтен иң кыска юлларны, уңайлы кичүләрне белеште. Чирүе юнәләсе җирләрдә яшәүчеләрнең холык-фигыльләрен, гореф-гадәтләрен, диннәрен һәм шөгыльләрен исәпкә алды. Ул яза белми, шунлыктан аңа боларның барысын да, ягъни яу сәфәрендә үзен көтәргә мөмкин һәммә нәрсәнең файдасын – зыянын бизмәнгә салып чагыштырганнан соң, хәтер сандыгында сакларга туры килә иде. Эш барышында барысын да җайга салу, иң мөһиме, тайпылышсыз тимер тәртипкә ирешү бары тик шулай гына була ала. Чыңгызхан бернинди йомшаклык күрсәтүгә, дилбегәне бер мизгелгә дә бушатуга юл куймады, һичкем һәм һични аның төп максатына – Аурупаны басып алуына комачаулык итәргә тиеш түгел иде.

Нәкъ шул чакта, үзенең алга таба адымнарын уйлаганда, Чыңгызхан гасырларда күренмәгән эшкә – халык-чирүендә бала тудыруны тыюга барды. Хикмәт шунда ки, атлы яугирләрнең хатыннары һәм кечкенә балалары, гадәттә, гаилә олауларында, урыннан урынга күчә-күчә, чирү артыннан баралар иде. Бу гадәт күптәннән бирле яши, аңа кайчандыр тормыш ихтыяҗы мәҗбүр итте, чөнки, очы-кырые күренмәгән үзара ызгыш-талашлар вакытында, бер як еш кына икенче якның тирмәләрдә яклаучысыз калган хатыннарын һәм балаларын үтереп, бер-берсеннән үч ала иде. Өстәвенә, бу нәселнең тамырына ук балта чабар өчен, беренче нәүбәттә көмәнле хатыннарны үтерәләр. Әмма заманалар алышыну белән, тормыш агышы да үзгәрде. Элек бертуктаусыз дошманлашып яшәгән ыруглар Чыңгызхан чорында көннән-көн күбрәк үзара килешә һәм бөек дәүләт гөмбәзе астында берләшә башладылар.

Яшь чагында, әле үз исеме белән Темучин дип йөртелгәндә, Чыңгызхан да күрше кавемнәр белән аз сугышмады, ерткычларча кыланганына күрә җәфасын да татыды – меркитләр һөҗүм ясаганда, яраткан хатыны Бортэ, урланып, аларда берара кәнизәк булып алды. Хакимияткә ирешкәч, Чыңгызхан үзара сугышларны бик рәхимсез рәвештә бастырырга кереште. Ызгыш-талаш аңа идарә итәргә комачаулый, дәүләтнең көчен суыра иде.

Еллар узды, һәм гаилә тормышының иске рәвешенә хаҗәт тә әкренләп бетүгә таба барды. Ләкин иң зур бәла – олаудагы гаилә чирүгә йөк булып әверелде, зур орышлар, бигрәк тә һөҗүм вакытында һәм сулар кичкәндә, тиз хәрәкәт итәргә комачаулый башлады. Дала хакименең, чирү артыннан олау-олау булып баручы хатыннарга, Кояш баешына яу җиңү белән төгәлләнгәнче, бала табуны тыярга, дигән боерыгы да шул сәбәпле килеп чыкты. Ул әйтте:

– Башта Кояш баешы илләрен буйсындырыйк, өзәңгеләрдән төшик, атларны тугарыйк әле, менә ул чакта олаудагы хатыннар күпме телиләр, шулхәтле бала тапсыннар. Ә аңарчы төмәннәрдә бала табу хәбәрен минем колакларым ишетмәскә тиеш...

Дошманын җиңү хакына, табигатьнең үзеннән һәм Раббыдан мәсхәрәле көлеп, Чыңгызхан хәтта тормыш кануннарын да себереп түкте. Ул Раббыбызны да үзенә хезмәт иттермәкче булды бугай, чөнки балага узу – үзе үк Ходайдан вәхи-хәбәр бит.

Хәер, халык арасында да, чирүдә дә мондый башбаштаклыкка беркем ризасызлык белгертмәде һәм каршы торырга уйламады, ул вакытка инде Чыңгызхан хакимлеге шултикле күз күрмәгән көчкә ирешкән һәм дөньяның кендегенә әверелгән иде ки, әмер бирүченең бала тудыруны тыю турындагы моңарчы колак ишетмәгән боерыгына барысы да берсүзсез буйсынды, ә инде карышкан кешенең баш өстенә, билгеле ки, котылгысыз үлем балтасы эленеп куелган иде...

Кояш баешына таба сәфәренә чыкканнан бирле, бөек хакан менә инде ничәнче көн юл буенча үзгә, гадәттән тыш рух халәте кичерә. Тыштан ул, мондый дәрәҗәдәге затка тиеш булганча, тынычлыкка калып, йокымсырый төшкән лачын сыман, кырыс төскә кереп, бар дөньядан читләшкән бер кыяфәттә йөргән була. Ә югыйсә үзенең күңеле күктә, ара-тирә ул җырлап җибәрә, хәтта әле шигырьләр дә иҗат итә:

...Иң хәтәр мәлләрдә, яңгырлы төннәрдә,
төтенлеге белән киез тирмәм каплап,
төнге сакчыларым тора мине саклап,
тора һәм изрәтеп йокыга талдыра.
Бүген юлда сезгә рәхмәт әйтер идем,
дөнья күргән һәм инде чал кергән
сакчыларым:
мине сез бит,
бары тик сез
хан тәхетенә күтәрдегез!
Кышның кары, ап-ак буранны, ары,
калтыратып җанга сырганнары,
яңгырларның вагы, коен булып органнары,
һәм дә тагын болай гына яуганнары –
барысы-барысы
яуга баручы тирмәмнең бусагасы аша
үтә алмый торды, –
йөрәгем калканы шул сакчыларым булды!
Бүген юлда рәхмәт әйтер идем,
минем кару белмәс һәм
какшамас төнге сакчыларым:
Чыңгызханны бары тик сез күтәрдегез!..
Дошманның каен тузыннан ясалган ук савытын,
аның ишетелер-ишетелмәс кенә кыштырдавын сизеп алып,
сүндердегез фетнә утын
һәм сүттегез мәкер авын,
минем уяу төнге сакчыларым.
Бөтен гореф-гадәтләрне бозып,
сезгә рәхмәт әйтер идем мин бу көнне...
Өер башлыгына тугры бүреләр көтүе,
ай нурында ялларын торгызып,
күзгә күренмәслек бер түгәрәк сызып,
аны урап ала чыкканда ауга.

Кояш баешына таба ачкач яуны,
аерылмас чал яллы көтүем,
ак казык тешләре тәхетемнең,
беләм:
тоташтырып төнне көнгә,
ару-талусыз барасыз алга,
минем белән бергә һаман...
Шуңа сезгә рәхмәтемне җырга салам...

Бу шигырьнең, әгәр ул кеше ишетерлек итеп яңгыраса, Чыңгызхан авызыннан чыгуы һич урынсыз булыр иде, ярыймы соң инде аңа эчендәгесен тышка бушату! Әмма юлда, иртәдән кичкә кадәр ияр өстендә чагында, ул үзенә мондый рәхәт мизгелләрне генә булса да бүләк итә ала иде.

Күңел тантанасының төп сәбәпчесе – менә инде унҗиденче көн, иртән уянып чыгу белән кичен йокыга талганчы, Чыңгызханның баш өстендә ак болыт йөзеп баруы: ул кайсы тарафка гына юнәлсә дә, күктәге болыт аннан калышмый. Күрәзәченең алдан хәбәр бирүе чын булып чыкты. Кем уйлаган диген син аны! Ә бит ул әкәмәт җан иясен, ачу китергеч һәм акылга сыймаслык тәкәллефсезлеге, оятсызлыгы өчен, шул сәгатьтә үк үтереп ташлаган булсаң? Ярый әле, башы җитеп, мосафирның гөнаһсыз җанын кыймады. Күрәсең, язмышның әмере шулай булгандыр.

Яу сәфәренә чыккан беренче көнне үк, барча төмәннәр, олаулар һәм көтүләр, ташу вакытындагы кара-кучкыл елгалар төсле, күз күрер җирне, офыкларны иңләп, Кояш баешына таба юнәлгәндә, төш мәлендә арыган атын алыштырырга тукталгач, Чыңгызхан очраклы гына өскә карап алды, әмма салмак кына йөзүче кечкенә ак болытка, – ә ул, ихтимал, нәкъ аның баш очында катып калган булгандыр, – һичберсе игътибар итмәде, күк йөзендә аның кебек әзме болыт әрле-бирле йөри.

Ул, үз уйларына чумып, иярендә утырган көе, борчылып тирә-юнен күзәтте, тыңлаучан һәм тырыша-тырмаша дөньяны яуларга ашкынучы күпмеңле чирүенең хәрәкәтенә күз салгалап барды, алар аның шәхси ихтыярына шулкадәр буйсынган һәм аның ниятләрен тормышка ашыруга шултикле ихласлык белән бирелгәннәр ки, әйтерсең лә болар арасында берсе дә, күңеленнән генә булса да, аның кебек үк хакимлек итәргә теләүче кешеләр түгел, ә ат тезгенен аралаучы кул бармаклары иде, аз гына читтәрәк торып үзен озата баручы кизүвыллар һәм ясавыллар алдыннан юлын дәвам итте.

Яңадан күккә күтәрелеп карады, әмма үз өстендә әлеге дә баягы болытны күрсә дә, Чыңгызхан бу юлы шулай ук моны бернигә дә юрамады. Юк, ул, дөньяны яулап алу уе белән шашкан илбасар, өстәге болытның ни өчен астагы җайдак белән бер юнәлештә баруы турында уйлап та карамады. Хәер, алар арасында нинди бәйләнеш булырга мөмкин, ди?

Ул болыт сәфәр чыкканнарның берсенең дә күзенә ташланмады, һичкемнең анда эше юк, көпә-көндез таң калырлык могҗиза булыр, дип, һичберәүнең дә башына килмәде. Аяк астына карап барырга кирәк чакта, күзең белән иксез-чиксез күк йөзен айкау кемгә хаҗәт. Чирү, үзәннәр һәм калкулыклар аша, юллар һәм юлсыз җирләр буйлап, җир өстендәге галәмәт зур кара болыт сыман, тояклар һәм тәгәрмәчләр астыннан тузан күтәреп, узылган араларны бәлки мәңгегә кире кайтарып ала алмаслык итеп артында калдыра-калдыра, үз ибе белән алга атлый бирә. Һәм боларның барысы да ханның мавыгуларына, дуамал ихтыярына яраклашып, шуларга риза булып башкарыла, унар меңнәрчә

кеше аның – данга, канга, хакимлеккә, яңа җирләр яулауга сусаган иблиснең куалавына, үзенчә илһамландыруына әзер торып, ягъни камчысына буйсынып, прәннегенә ымсынып, көтү шикелле каядыр бара да бара.

Алар шулай юлда булдылар, менә инде көн дә кичкә таба авышты. Караңгы төшкән җирдә төнгелеккә туктыйсы бар, ә иртә таңнан тагын кузгаласы.

Хан һәм аның яраннары, аларга хезмәт күрсәтүче чербиләр (интендантлар) бу төнне кичәр өчен алдан ук сарай тирмәләрен корып куйдылар. Алар инде алда, ак гөмбәзләре белән ерактан күренеп-чакырып торалар иде. Төп тирмә янында хан һоруңы – ачык кызыл каймалы, уттай ефәк һәм алтын җепләр белән чигелгән, киң иңендәге авызыннан ялкын ургылдыручы аждаһалы кара әләм – җилдә җилферди. Юлдан күзләрен алмыйча, кизүвыллар – сайлап алынган төксе чырайлы пәһлеваннар – әмер бирүчене көтеп әзер торалар. Монда кичке мәҗлес – бергәләшеп ашап-эчеп алу булачак, тәгам кылгач, шунда ук, Чыңгызхан сәргаскәр-нойоннар белән, сәфәрнең беренче көне нәтиҗәләрен тикшерү һәм алдагы көнгә ниләр эшлисен киңәшер өчен, тәүге очрашуны үткәрергә җыена. Бөек ташкынның кузгалуы Чыңгызханны аралашу җаена таба тарта – бу кичтә ул нойоннар өчен күңел ачу мәҗлесе оештырырга да каршы түгел, исәбе – алар сөйләгәнне тыңларга һәм аларга үз боерыкларын җиткерергә; аның авызыннан чыккан акыллы сүзләр, аларның барысы да һәм һәркайсы аерым-аерым, өсте алынмаган сөт кебек, игътибар куерыгына әверелеп тыңланганда, Дөньяның Дүрт Тарафына әйтелгән шикелле булачак, тиздән җиһанның һәр тарафы һичбер карусыз аның авызына карап торачак, шуның өчен чирү белән бара да бит инде ул, үз сүзен сүз итәргә дип. Ә сүз – ул мәңгелек көч.

Әмма соңра Чыңгызхан мәҗлес үткәрү уеннан кире кайтты. Күңелендәге тынычсызлык аның япа-ялгызы гына калуын таләп итте. Һәм менә ни өчен...

Ялга тукталу урынына җитәрәк, Чыңгызхан кабат – инде өченче мәртәбә – баш очындагы таныш болытка игътибар итте. Һәм шул мәлдә аның йөрәге жу итеп китте. Акылга сыймаслык сизенүеннән хәйран калып, аның тәненә салкын йөгерде һәм күз күремендәге җир йөзеп киткәндәй булды, ул атының ялына көч-хәл белән ябышып өлгерде. Мондый хәлгә аның әле беркайчан тарыганы юк, чөнки кара күкрәкле Этуген Җирендә, җиһанның яшәү һәм хакимлек өчен Күк-Тәңре тарафыннан бүләк итеп бирелгән шул какшамас нигезендә, чынлыкта булган берни дә моңарчы аны шулкадәр, көтелмәгәнлектән аһ итәрлек хәлгә төшереп, аптырашта калдыра алмады, инде барысы да баштан кичерелгән, дөньядагы бер нәрсәнең дә аның үтә аек акылын хәйран итәргә, канлы эшләрдә күпне күргән күңелен сокландырырга яки кайгыга салырга көченнән килмәс кебек иде, һичкайчан, үзенең ханлык дәрәҗәсен төшереп, ниндидер хатын-кыз шикелле, ат ялына куркып ябышканы булмады. Мондый хәлнең булуы мөмкин түгел, һәм ул булырга тиеш тә түгел, чөнки күптән инде, яшь-яшел чагында, елгадан тоткан вак балык аркасында сүзгә килеп, ә чынлыкта иртә уянган бүре тоемы белән, аларга язмышның бер ияренде утырырга язмаганлыгын аңлап алганлыктан, карындаш үсмер энекәше Бектерне җәядән атып үтергәннән бирле, әйтергә мөмкин, шул вакытлардан ук тормышны коруның иң ышанычлы, хатасыз юлы – көч белән басу икәнлегенә төшенеп, көчкә буйсынмый калган, аның каршында тезләнми торган берни дә юклыгына, ташмы яки утмы, су, агач, ерткыч җанвар яки кошмы булсын, ә мескен адәм баласын искә төшереп торасы да юк, – барчасының да, тупас көч астында сүнеп-тоныкланып калуына, көлгә әйләнүенә инанган иде ул. Көч

көчне сындырганда, гаҗәп тоелган нәрсәләр дә бик кечкенә, ә гүзәллек исә кызганыч булып кала. Шуннан килеп чыккан нәтиҗә: таптап уза алган бөтен нәрсә дә тузан бөртегедәй вак, ә каршысында йөзтүбән сузылып ятканнарның һәммәсе, мәрхәмәтлек күрсәтергә теләгән кемсәнең талымына карап, беркадәр йомшаклыкка өмет итә ала. Дөньясы шуңа корылган...

Ләкин кайчагында, Һималайдан килүче сәйяр китапчылар аңлатуындагы Мәңгелек һәм Чиксезлек гәүдәләнеше булган Күк-Тәңре турында сүз барганда, анысы – бөтенләй башка нәрсә. Әйе, акыл белән иңләп-аңлап бетереп булмаслык Бөек Күк, бары тик ул гына аңа буйсынмый, аны үрелеп алу да, кулда тоту да мөмкин түгел. Күк-Тәңре хозурында хакан үзе дә – бер тузан бөртеге генә, аны куркытып та, аңа каршы баш күтәреп тә, яу белән барып та җиңә алмый. Җирдәге язмышлар һәм, Һималай китапчылары раслаганча, дөньялар хәрәкәте белән идарә итүче Күк-Тәңрегә табынырга, белгән догаларыңны укырга гына кала. Шуңа күрә, гомеренең соңгы көненнән котыла алмаган һәркем кебек, ихлас ышанулары һәм корбан чалулары белән, Күктән аны үз канаты астына алуын, аңа яхшы мөнәсәбәтен белдереп, кешеләр дөньясына ныклап хакимлек урнаштыруда ярдәм күрсәтүен һәм, сәйяр акыл ияләре раслаганча, Галәмдә мондый дөньялар исәпсез-хисапсыз икән, җир дөньясын аңа, Чыңгызханга, тулысынча, беркем белән дә бүлешмичә идарә итәр өчен бирсә ни була инде, дип, аны үз нәселенә, буыннан-буынга күчә барасы биләмә итеп билгеләвен ялынып-ялварып сорый, чөнки җир йөзендәге адәмнәр арасында аңардан да кодрәтлерәк һәм лаеклырак зат бар микән әле; гөманлавынча, Дөньяның бөтен Дүрт Тарафын тезләндерергә хәленнән килердәй, көче-куәте ягыннан аңардан өстенрәк торучы юк. Тирән, яшерен күңел төпкелен айкап, Чыңгызхан әлегә бүтән берәү дә Күк-Тәңредән сорарга җөрьәт итмәгән нәрсәне – илләр, халыклар өстеннән чиксез хакимияткә рөхсәт бирүен үтенергә үзгә хакы барлыгына торган саен ныграк ышана бара, чыннан да бит кемдер берәү әлеге тәхетне биләргә лаеклыдыр, бәс шулай икән, ул башкаларны көч белән буйсындыра алучы булырга тиеш! Чиксез рәхим-шәфкатьле Күк аның яулап алуларына, хакимлеген көчәйтүенә моңарчы комачаулык итмәде, һәм Күкнең аны аерым исәптә тотуына, аның кешеләргә күренмәс-беленмәс югары көчләре Чыңгызхан ягында булуына ышанычы торган саен ныгый барды. Аңа моңарчы ни кыланса да килеште, ә бит ул ут һәм кылыч белән узган бөтен төбәкләрдәге иңрәүчеләр авызыннан аның башына нинди генә ярсулы бәддогалар яумады, әмма бичара каргышларның берсе дә аның артканнан-арта баручы куәтенә, бөеклегенә, дөньяны тетрәткән шанына ат кылы калынлыгы да күләгә төшерә алмады. Киресенчә, үзен күбрәк каргаганнары саен, ул Күккә юнәлгән сыктау һәм ah-зарларны тагын да үҗәтләнебрәк санга сукмый башлады. Дөрес, юк-юк та, Күкнең ачуын китерүдән сагаеп, күкләр җәзасын татырга туры килмәгәе, дигән авыр шик күңеленә боз булып төшкән мизгелләр дә булмады түгел. Шундый чакларда бөек хан күпмедер вакытка өнсез калып, үзен йөгәнләп тора, кул астындагыларга җиңелчә сулыш алырга мөмкинлек биреп ала, Күкнең гадел шелтәсен кабул итәргә, хәтта тәүбә итәргә әзер була. Мәгәр Күк ачуланмый, үзенең канәгатьсезлеген берни белән дә белгертми, чиксез мәрхәмәтеннән мәхрүм итми иде. Һәм ул, Күк гаделлеге саналган нәрсәләрне таптап, комарлы уендагы сыман, тагын да тирәнрәк гөнаһка бата, Күкнең түземлеген сыный. Ә Күк түзә! Шуннан чыгып, ул үзенә ни кыланса да ярый, дигән нәтиҗә ясый. Еллар узган саен, аңарда Күкнең сайлап алган кешесе

нәкъ менә ул икәнлегенә, үзенең Күк Улы булуына ышанычы ныгыганнан-ныгый бара.

Әкиятләрдә генә ышанып була торган нәрсәләргә – зур бәйрәмнәр вакытында атка атланган җырчыларның, халык төркемнәре алдында йөренгәләп, аны Күк Тудырган дип җырлар чыгаруына һәм шул чакта меңләгән кулның шатланып Күккә күтәрелүенә ышанганга түгел, чөнки болар мескен-ялагай кешеләрнең тәлинкә тотуы гына икәнен аңлый дала хакиме, – бары тик тормыш тәжрибәсеннән чыгып, барча эш-гамәлләре Күк-Тәңренең уй-ниятләренә туры килгәненә күрә, Илаһи Күк аны яклый, дип, башкача әйткәндә, ул үзен Җир йөзендә Күк-Тәңренең ихтыярын тормышка ашыручы бердәнбер зат, дип фараз итә, Күк исә, аның кебек үк, бары тик тупас көчне, әлеге көчнең иясен һәм теләсә нинди максатка көч күрсәтеп кенә ирешеп булганын таный, дип уйлый, нәкъ менә ул гына, һичшиксез, шул таләпләргә тап килә дип саный иде...

Югыйсә вакыт-вакыт аның үзен дә гажәпкә калдырган хәлне – борын-борыннан аучылык һәм малчылык белән көн күргән, хәерчелеккә төшкән вак арат-киятлар ыругыннан булган ятим малайның, текә генә күккә күтәрелеп киткән лачындай, дәһшәтле дә, баш әйләндергеч тә дан биеклекләренә, дөнья белән идарә итү дәрәҗәсенә шундый тиз, ашкынулы менүен башкача ни дип аңлатырга мөмкин?! Тарихта күрелмәгән чиксез зур хакимияткә ирешү ничек була алды соң, ә бит аңа, иртәгәсе көнгә өмете өзелгән, шулай да әрсез-чая ятимгә, тормыш, иң яхшы дигәндә, курку белмәс йорт басучы яки ат карагы язмышын гына әзерләп куярга мөмкин иде, һәм башта ул шул юлга баскан да иде. Күрәзәлек итеп торасы юк: нибары сыңар арык аты гына булган Темучинны, Күк-Тәңре катнашыннан башка, авызыннан ут ургып торучы алтын аждаһалы һоруң-әләм көтмәгәндә генә урап алмас, беркайчан да аның Чыңгызхан дигән олы исеме булмас, Алтын тирмә гөмбәзе астында шулай вәкарь белән генә утырулар аның төшенә дә кермәс иде!..

Һәм менә барысы да шул сәбәпле икәнлеген, Азия хаканына Күкнең теләктәш мөнәсәбәтен раслап, һич кире каккысыз шаһәдәтлек, ачык дәлил булып күзгә күренеп тора! Карагыз: әнә ул – үзенең диваналыгы аркасында башын югалтудан чак кына котылып калган илгизәр күрәзәче алдан белеп әйткән гажәеп болыт. Ә бит аның сүзләре чынга ашты! Ак болыт – Күк-Тәңренең үз Улына хәбәр салуы, аның эш-гамәлләрен хуплавы һәм аңа фатиха бирүе, ул – алдагы бөек җиңүләр турында киләчәктән хәбәр билгесе.

Яу белән баручы күп меңләгән кешедән берсе дә үзләренә ияргән ак болытка игътибар итмәде, кайдан килеп чыккан ул, нинди максат белән – һичберәүнең боларда гаме юк иде, гомумән, мондый могҗиза булу ихтималы беркемнең дә башына килмәде. Ирекле болытлар агышын кемнең булса да күзәтеп торганы бармыни?.. Бары тик ул – дала чирүенең башында торган һәм аны дөньяны яулап алырга кузгаткан бөек хакан гына әлеге ак болытның илаһи мәгънәсен аңлый, берочтан үзенең гадәттән тыш сизгерлегенә хәйран кала, башка сыймастай мондый хәлнең булуына бер ышана, бер ышанмый да иде. Аны шулчак газаплы шик-шөбһәләр биләп ала: бу күзәтүләрен һәм фикерләрен кем белән булса да бүлешергәме, әллә бүлешеп торасы түгелме? Әгәр ул кемгәдер серен ачса, бәлки, болыт, тотар да, күз ачып йомган арада юкка чыгар? Кешеләр аны акылдан язган дип уйламасмы? Бераздан аның рухы яңадан ныгыган кебек була, ул кабат, ак болытның, мәгънәсез бер шаяру гына булмыйча, Күк тарафыннан җитди билге итеп җибәрелгәнен, кинәт гаип булмасын аңлый, шулчак аны шатлык, куәтле күңел күтәренкелеге биләп ала: үзенең зирәклегенә,

Кояш баешын яуларга дип сәфәр чыгуының хата түгеллегенә инану, зарыгып көткән максатына ирешү – кылыч һәм ут белән бөтен дөньяны тез чүктерү, мәңге какшамас зур мәмләкәт төзү нияте тагын да ныгый төшә. Ул шуның белән яши башлый. Аны күптәннән уянган дәрте – комсыз хакимияткә ашкыну теләге әйдәп бара. Күбрәк алган саен, нәфесе котыра гына...

Күзләре канлы орышларга сусаган яу, үткен хәнҗәр кебек, даланы тураклап, Кояш баешына таба котылгысыз сәфәрен дәвам итте.

Ә югарыдагы ак болыт... Ул, атаклы юргасы Хуба иярендә тәхеттәге сыман мәгърур гына оеп баручы Чыңгызханга ияреп, бер якка да тайпылмыйча, талгын гына йөзүен белде. Юрганың ялы ак, ә койрыгы кара, – ул бит тумыштан ук шундый иде, – белгәннәр әйтә, андый ат үзенә аерым йолдыз астында мең елга бер туа, дип. Ул чынлап та дөньяда тиңдәше юк коры җир көймәсе булып, чабышкы түгел, ә озын юлны йөзеп кенә, армый-талмый үтә торган мал иде. Менә Хуба, туктаусыз яуган коен кебек, дымлы-кайнар сулышы белән җирне сугарып, бер алынган киеренке тизлектә юргалап бара. Авызлыгы булмаса, мондый ат артыгын тырышып хәлдән таярга, явып арыган яңгырның соңгы тамчысыдай кибеп бетәргә әзер. Борын заманда бер акын әйткән, андый атка атланган кеше үзенең үлемсезлегенә ышана башлый, дигән...

Шул мәлдә Чыңгызхан үзен бик канәгать, бик бәхетле итеп тойды. Аңа күктән һәм җирдән илаһи көч иңде, әйтерсең лә ул да ару-талуны белмәс юргага әверелгән иде, максатына йөгерә-йөгерә бару сусынын басар өчен, чабып барган атның ярсулы кан әйләнешенә җаны-тәне белән тоташып, кичекмәстән хәрәкәт итәргә ашкынды.

Әйе, җайдак белән ат бер-берсенә тиң иде, берсен берсе дәртләндереп, бер көч икенчесенә куәт өстәде. Шунлыктан мал иясенең утыру рәвеше дә лачын торышын хәтерләтә иде. Бөтен булмышы белән ияргә сыланган киң җилкәле, базык гәүдәле, бакыр йөзле бу җайдак аяк табаннарын да, масаебрак һәм үз-үзенә нык ышанган кыяфәттә, ачу китергеч итеп өзәңгеләргә терәгән. Ат өстендә ул тәхеттәгедән дә болайрак булып, сынын катырып, башын югары тоткан хәлдә, кысык күзле калку яңагына, бөтен чыраена таш кебек кырыс, рухсыз төс чыгарып утыра. Аңардан дала йөзен кара болыт каплаган кебек иге-чиге күренмәгән галәмәт зур чирүне данга, җиңүләргә әйдәп баручы бөек хаким куәте һәм ихтыяр көче бөркелеп тора...

Билгеле, Чыңгызханның мондый күтәренке рухи халәтен аңлатырлык үзгә бер сәбәп бар, ул – йөрәгенә мөһер итеп басылган Күк-Тәңре тамгасы булып, аңа үзе юраган бөек вазифасының көмеш тажы сыман баш өстендә эленеп торган ак болыт. Һәм, шул якстан карасаң, барысының да үзара бәйләнештә икәнен күрергә мөмкин. Болыт... Күк... Алда, хәрәкәт юнәлешен билгеләп, байрак йөртүченең кулларындагы яу әләме – алтын аждаһалы кара һоруң җилферди, ул бер үк вакытта Чыңгызханның кай тирәдә икәнлеген дә күрсәтә. Һоруң янында алар өчәү иде – тәэсир көче белән теләсә кемне аяктан егарлык, үзләренә ышанып тапшырылган гадәттән тыш мактаулы вазифадан башлары әйләнеп, горурлыклары ташып ашкан өч байракчы. Өчесе дә сайлап алган кебек бертөсле чем-кара атка атланган. Уртада – байракның сабын тоткан пәһлеван, аның ике ягында – ялангач сөңгеләрен алга каратып аскан, аны озата баручылар. Хаканның юлын бизәп, ефәк һәм алтын белән чигелгән киң кара тукымадан гыйбарәт әләм җилдә җилферди, аңа төшерелгән, авызыннан якты ялкын ургытучы аждаһа да шуңа күрә җан кергәндәй булып бәргәләнә иде. Әнә ул аждаһа очып барган шәпкә дошманның өстенә сикерә, ә аның бөтенесен

күреп торган, ачудан дөянеке сыман бүлтәеп чыккан коточкыч күзләре, җилдә йолыккаланган әләм белән бергә, чыннан да тере кебек, як-якка тәгәри...

Ару-талуны белмәс хакан, иртә таңнан иярге менеп, чирүне алга әйдәкли. Үз хәбәрләрен җиткерү өчен, аңа төрле тарафтан атларын куалап, нойоннар килә дә, барган шәпкә генә күрсәтмәләр алгач, яныннан, чаптырып, кире үз урыннарына кайтып китәләр. Яуга төп киртә булачак бөек Идел ярларына кыш капкасындагы салкын яңгырлар, юл өзеклекләре башланганчы барып җитәр өчен ашыгырга кирәк иде, аннары инде боз катканны гына көтеп торасы һәм алга, хыялда йөрткән максатка – Кояш баешы җирләрен буйсындыруга таба юлны дәвам итәсе була.

Ул көнне төн караңгысына чумганчы диярлек иярдән төшмәделәр. Инде офыкка яткан кояш нурларында эңгер-меңгер алдындагы дала шундый иркен булып җәелде ки, бу җирләрнең шултиклем күз иңләмәслек икәнлеген, мөгаен, башка бер вакытта да болай ук күреп-аңлап булмас иде. Үзе яртылаш офык артына чумган хәлдә дә, алсу-кызгылт буяуларын кызганмыйча, киңлекләрне коендырган кояшның соңгы шәфәкъ нурларына, рәт-рәт булып, томан каплаган кара болакларны хәтерләтеп, ничәмә-ничә төмән, алардагы меңнәрчә җайдаклар кереп чума-кушыла бара.

Атларның талчыккан аркалары бары тик төн җиткәч, гаскәр йокы аланына туктагач кына, ияр һәм җайдаклардан бушап ял итә ала.

Әмма кичтән ялга тукталган урында, таң ату белән, гаскәрне яңадан яуга өндәп, добулбаслар – үгез тиресеннән ясалган искиткеч зур барабаннар дөпелди башлый. Дистә меңләгән кешене йокыдан аеру бик җиңел түгел. Шуңа уятучыларга шактый тир түгәргә туры килә – добулбасларның бертуктаусыз гөрселдәве тирә-юньдәге бөтен тирмә-чатырларга каты шау булып тарала.

Ул сәгатькә хакан инде аягына баскан. Беренчеләрдән булып диярлек уяна да, әле аяз, кояш сарысы гына саркылган көзге иртәләрдә сарай тирмәсе тирәсендә йөренгәләп, зиһенен бер ноктага туплап, төн узганчы башына килгән уй-фикерләрне кабат уеннан кичереп, ниндидер күрсәтмәләр бирә һәм шул арада чирүне ияр вә тәгәрмәчләр өстенә менәргә мәҗбүр итүче добулбаслар гүләвенә дикъкать белән колак сала. Чираттагы һәр көн шулай башлана, бераздан тавышлар ишәя, хәрәкәтләр ешая, төнгелеккә өзелеп торган сәфәр янә үз эзенә төшә.

Ә добулбаслар һаман гөрселди. Аларның иртәнге шавы, гөрелтесе, йокыдан торырга чакыру авазы гына түгел, ниндидер зуррак, бөегрәк максатны күздә тотучы чаң, таләпчән һәм беркемгә дә буйсынмас нык ихтыярлы әмирнең әлеге максатны исләренә төшерүе булып яңгырый. Шул рәвешле, Чыңгызхан, үзенә ияреп, бөек сәфәргә чыккан һәркемне куалый: барабаннар шавы белән тирмәләрнең төн кичәр өчен генә вакытлыча ябылып торган киез ишекләренә һәм уянып килүчеләрнең аңына үтеп керә, нинди генә акыллы фикер булмасын, әгәр аңардан чыкмаган икән, ул аны аяк астына салып таптый да үзенекен тага, чөнки адәм баласы йокы куенында чакта үзенең кемгәдер буйсынганлыгын онытып тора, имештер, ул – хөр, ирекле зат, шуңа күрә дә йокы – алама, заяга узган гомер, хыялый, әмма хәтәр азатлык мәле, андый башбаштаклыкны йокыдан айнуының беренче мизгелләрендә үк кешенең аңыннан, калебеннән бәреп чыгарырга, уянган һәркемне янә өнгә – бары тик хаканга гына берсүзсез буйсынуга, хезмәт итүгә, хәрәкәт эченә кайтарыр өчен, ике дә уйламыйча, «ирек» дигән ул чүп үләнен кырыс-усал кул белән һич кызганмый йолкып атарга кирәк.

Добулбасларның үгез үкерүенә охшаган шыксыз гөрселдәве һәр юлы

хәтта Чыңгызханның да тәненә салкын йөгертә, ул аның яшүсмер чагындагы күңел истәлегенә бәйле: берзаман якында гына ике үгез, кыргый тавышлар белән акырышып, тоякларыннан вакташ һәм тузан күтәреп котыра-котыра сөзешә башлаган иде, аларның үкерүеннән әсәрләнеп микән, ул, үзе дә аңлап бетермәстән, кайдандыр сугыш җәясен тартып чыгарганын һәм шул мәлдә йокымсырап яткан бертуган энекәше Бектернең күкрәген ук белән атып тишкәнен, – алар шуның алдыннан гына елгада икәү тоткан вак балык аркасында сүзгә килгәннәр иде, – төшендә күргән кебек кенә хәтерли. Бектер кыргый тавыш белән кычкырып җибәрде, сикереп торды һәм канга батып янә җиргә ауды, ә Темучин, – әйе, иртә үлгән Есугай-баһадирдан ятим калган Темучин гына иде әле ул, – куркуыннан, җилкәсенә тирмә янында яткан добулбасны асып, якындагы тауга йөгереп менде. Анда, тауга менгәч, эчпошыргыч бер тавыш белән туктаусыз барабан кагарга кереште, ә анасы Аголен аста үкереп елый, туганын үтергән мөртәтне каргап-каһәрләп, чәчләрен йолкый иде. Аннары тау янына башка кешеләр йөгереп килде, барысы да кулларын болгап аңа нәрсәдер кычкыралар, әмма ул берни дә ишетми, үҗәтләнеп, барабан кагуын белә. Ни өчендер һичкем аңа якын килмәде, добулбасын дөмбәсләп, ул таң атканчы шунда утырды...

Йөзләгән добулбасның колак ярып гөрселдәве, ярсып үкерүе хәзер исә хаканның сугышка өндәү ораны, батыр йөрәкле һәм кансыз булуы билгесе, үзе белән яуга чыкканнарга бөтен игътибарны туплап күтәрелергә, хәрәкәт итәргә, төп максатка – дөньяны яулауга таба юнәлергә чакыру авазы иде. Алар аның артыннан соң чиккәчә барачак, – офыкның да кайдадыр чиге бар ич, – һәм җирдә яшәгән һәммәсе – ишетү сәләте булган барча адәмчекләр башка җан ияләре, эчтән тетрәнеп, сугыш барабаннарына буйсыначак. Инде аның яшерен уйларының аерылмас шаһитына әверелеп килүче ак болыт та, хәтта ул да, читкә тайпылмыйча, иртәнге добулбас тавышларына колак салган кебек, баш өстендә салмак кына әйләнә. Кисәк исеп куйгалый торган җил җанлы булып тоелган ут ургытучы аждаһа чигелгән һоруңны кыштырдата. Менә-менә ул аждаһа әләмнән сикереп чыгар да, авызыннан якты ялкын бөркеп-бөркеп, җил уңаена йөгереп китәр төсле...

Бу араларда иртәләр әйбәт тора иде.

Кичләрен, йокы алдыннан, тирә-юньгә тагын бер күз салыр өчен, Чыңгызхан тирмә алдына чыгып баса. Һәркайда, буш киңлекләрдә учаклар яна, якын булса – аларның дөрләгәне, ерактарак икән – утларының җемелдәве күренә. Хәрби аланнардан һәм олау табырларыннан, ат көтүләрен куып баручыларның торак-тирмәләре тирәсеннән аксыл төтен җәелә; бу сәгатьтә кешеләр тирләп-пешеп шулпа эчә һәм туйганчы ит ашый. Галәмәт зур кисәкләре белән казаннардан алгач, пешкән ит исе ач дала җанварларын шул тирәгә чакырып китерә. Йә тегендә, йә монда мескен җан ияләренең шашынулы күзләре ялтыраганы күренә, колакка моңсу гына шыңшып-улап куйганнары ишетелә.

Ул арада халык, чалып ташланган кебек, бик тиз үле йокыга тала. Бары тик ялга туктаган гаскәрнең тынычлыгын саклаучы төнге күзәтчеләрнең генә бер-берсенә аваз салуы тәүлек буена тормышның ныклы тәртипкә корылган бер агымда дәвам итүен күрсәтеп тора. Ул шулай булырга да тиеш инде. Һәркемнең үз вазифасы бар, соңгы исәптә барысы да бердәм һәм иң югары максатка – Чыңгызханның дөньяны яулап алу идеясенә тайпылышсыз хезмәт итүгә дүндерелгән. Мондый минутларда, күңеле шатлыктан исереп, ул үзенең гайре табигый асылын – туймас нәфесен, бетмәс-төкәнмәс сусавын, җирләре никадәр киңәйгән саен, шашынып, тагын да чиксезрәк хакимлеккә омтылган

зат икәнлеген аңлый, һәм аңа әлеге хакимиятне арттыру максатына туры килгән нәрсәләр генә кирәк, ә шуңа җавап бирмәгәннәренең яшәүгә хакы юк, дигән котылгысыз бер нәтиҗә ясый иде.

Сарүзәктә җәзалап үтерү дә – күп заманнар үткәннән соң, Әбүталип Котлыбаев үз башына язып алган риваятьтә тасвирланган фаҗига – менә шунлыктан килеп чыккан каза иде...

«Төннәрнең чираттагысында баравылның (уң кулдагы төмәннең) атлы күзәтчеләре, һәрвакыттагыча уяулык күрсәтеп, хәрби аланнардан тыш, олаулар, көтү куып баручылар һәм төрле хезмәт күрсәтүчеләрнең тирмәләренә дә күз салгалыйлар иде. Бар җирдә дә тәртип. Кичүләр үтеп арган-талган кешеләр бөтен төштә – тирмәләрдә, чатырларда, ә күпләре ачык күк астында, янып бетүче учаклар янында тезелешеп йоклап ята. Тирә-юньдә тирән тынлык хөкем сөрә, барча тирмәләрдән дә караңгылык саркылып чыга. Күзәтчеләр инде бөтен җәйләүне әйләнеп бетерде дияргә була. Алар өчәү иде. Атларын тыя төшеп, үзара нәрсәдер сөйләшеп алдылар. Боларга өлкән итеп куелганы – йөзбашы бүреген кигән озын буйлы җайдак – ике иптәшенә әкрен генә боерды:

– Йә, булды. Барыгыз, егетләр, черем итеп алыгыз. Ә мин монда тагын бер караштырып килим әле.

Тегеләрнең икесе дә китеп барды. Монда калган йөзбашы исә иң элек күзләре белән бөтен тирә-юньне айкап алды, тынып калган дөньяга янә бер колак салган булды, аннары атыннан төште дә, аны тезгененнән тотып, олаулар, дирбия-каеш ясаучылар, тегүчеләр, корал осталары рәтеннән табырның иң аргы читендәге ялгыз тирмә ягына юл тотты. Ул, уйланып башын игән көе, төрле авазларга колагын торгызып барганда, күктән явып торган ай нурлары аның эре йөз сызыкларын һәм артыннан күндәм генә атлаган Акйолдызының ялтыраган зур күзләрен элем-чалым гына яктырта иде.

Йөзбашы Эрдене әлеге тирмәгә якынлашты, күрәсең, анда аны көтеп торырга тиешләр иде. Тирмәдән башына яулык бөркәнгән хатын чыкты һәм ишек төбендә аны каршы алды.

– Самбайну[1], – дип, тавышын басып кына, хатынны сәламләде ул. Борчылып сорады: – Йә, хәлләр ничек?

– Барысы да тәртиптә, Күк-Тәңрегә шөкер, бөтенесе әйбәт килеп чыкты. Хәзер инде борчылма, – дип пышылдады хатын. – Ул сине бик көтә. Ишетәсеңме, бик көтә.

– Мин үзем дә күңелем белән аңа таба ашкындым! – дип җаваплады йөзбашы. – Тик, үч иткәндәй, безнең нойон атларны кабат санарга булды. Өч көн буе шуннан котыла алмадым, ат көтүләре арасында югалып тордым.

– Йә, борчылмасана, Эрдене. Шундый хәл килеп чыккач, син ни кырган булыр идең? Монда кеше күзенә чалынып йөрүдән ни мәгънә? – Хатын аны тынычландырып башын чайкап алды һәм өстәп әйтте: – Иң мөһиме, шулай тыныч кына, җиңел генә тапты. Бер мәртәбә кычкырмады да, түзде. Ә иртән мин аны ябык олауга урнаштырдым. Берни дә булмаган кебек. Ул – синең менә дигәнең. Әй, нәрсә сөйләнеп торам соң әле! – дип, кинәт сүзен бүлде ул. Котлап: – Кулыңа кунган лачын һәрвакыт синең белән булсын! – диде. – Инде улыңа исем тап!

– Сүзләреңне Күк ишетсен иде, Алтун! Догулаң белән үлгәнче сиңа рәхмәтле булырбыз. – Йөзбашының тавышы калтырады. – Ә исемне уйларбыз, анысыннан гына тормас.

[1] Самбайну *(монгол.)* – исәнме.

Хатынга атның тезгенен тоттырды.

– Борчылма, һәрвакыттагыча, күпме кирәк, шултикле саклармын, – дип ышандырды Алтун. – Бар инде, бар, Догулаң сине зарыгып көтә.

Йөзбашы, кыюлыгын аяк табанына туплаган кебек, бераз таптанып торды, аннары тирмә авызына килеп, авыр тыгыз киез чаршауны аз гына ачты һәм, иелә төшеп, эчкә узды. Тирмә уртасында кечкенә генә учак янып тора, ә шул учакның көчсез, тонык яктысында ул аны – иңнәренә сусар тунын салып, эчтә үк утырган Догулаңын күрде. Аның каршысында – сырган юрган капланган бишек, хатын уң кулы белән бишекне җиңелчә генә тирбәтә иде.

– Эрдене! Мин монда, – дип, йөзбашының керүен сәламләгәндәй, әкрен генә эндәште Догулаң. Аннары: – Без монда, – дип, уңайсызланган кебек, елмая төшеп, үз-үзен төзәтте.

Йөзбашы тиз генә ук садагын, җәясен, кынытагы кылычын ычкындырды, коралларын ишек төбендә калдырып, кулларын сузып, хатын янына килде. Тезләнде, һәм алар йөзгә-йөз орындылар, иңнәренә башларын куеп кочаклаштылар һәм шул көе тынсыз тордылар. Дөньялары бер мәлгә шушы тирмә гөмбәзе астында йомылып калды. Бу тирмәнең тышындагы бар нәрсә әһәмиятен, кыйммәтен югалтты кебек. Бары тик алар икәве, аларны берләштергән бер-берсенә ашкыну хисе һәм өч көн элек дөньяга килеп, инде бишектә изрәп йоклаган йодрык хәтле җан иясе генә торып калды.

Эрдене беренче булып телен тибрәтте:

– Йә, хәлең ничек? – дип сорады ул, ешлаган сулышын көчкә тыеп. – Мин шулхәтле борчылдым.

– Инде барысы да артта калды, – дип җаваплады хатын, ярым караңгыда елмаеп. – Аларны уйлама. Аның турында – безнең улыбыз турында гына сораш. Ә ул шундый тере, нык булып чыкты. Имиемне шундый каты итеп суыра. Ул сиңа бик охшаган. Алтун да шулай ди.

– Миңа күрсәт аны, Догулаң. Бер күз салыймчы!

Догулаң читкәрәк тайпылды һәм, бишек өстендәге юрганны ачар алдыннан, иректән сагаеп, тыштагы авазларга колак салды. Тирә-юньдә тирән тынлык иде.

Йөзбашы йоклап ятучы нарасыйга, аның әлегә берни дә аңлатмый торган йөзендә үз чалымнарын табарга тырышып, озак карап торды. Тынын кысып яңа туган сабыена текәлгәндә, ул, бәлки тәүге тапкырдыр, мәңгелектән бер хәбәрбилге булып, дөньяга нәсел дәвамчысы килүенең илаһи асылына төшенгәндер. Мөгаен, шуңа да һәр сүзен бизмәнгә салып үлчәгән кебек әйтеп куйды:

– Менә мин хәзер һәрвакыт синең яныңда, Догулаң, хәтта минем белән ни генә булса да, һәрвакыт синең яныңда. Чөнки синдә – минем улым.

– Син минем белән? Шулай булсачы! – Хатын сагышлы көлемсерәде. – Будда тәгълиматындагы кебек, сабый – синең икенче чагылышың, дип әйтмәкче буласыңмы? Мин, аны имезгәндә, бу турыда уйладым. Әле өч көн элек булмаган җан иясен кулыма алып, күңелем белән сиңа эндәштем: әй Эрдене, бу бит – синең яңадан тууың! Үзең дә хәзер шулай дип уйладыңмы?

– Уйладым. Тик бөтенләй үк алай түгел. Мин үземне Будда белән чагыштыра алмыйм.

– Чагыштырмасаң да була. Син – Будда түгел, минем байрагымдагы аждаһа. Мин сине аждаһага охшатам. – Догулаң ягымлы итеп пышылдады: – Мин һоруңнарга аждаһалар чигәм. Аларның барысы да син икәнен берәү дә белми. Минем бөтен әләмнәремдә – син. Кайчак төшемдә дә күрәм, мин аждаһа сурәтен

чигәм, имеш, ә аңа җан керә, тик син көлмә генә, мин төшемдә аны кочаклыйм икән, без бергә кушылабыз да, аждаһа мине үзе белән алып китә, без очабыз, мин дә аның белән очам, һәм иң татлы мизгелдә ул аждаһа син булып чыгасың. Төшемдә син минем янымда – әле аждаһа, әле адәми зат. Уянгач, мин нигә дә юрарга белмим. Сиңа бит, Эрдене, элек тә әйтә идем, син – минем утлы аждаһам, дип. Юк, шаярып түгел. Ул шулай иде дә. Мин сине, синең аждаһадагы чагылышыңны байракларга чигәм. Инде менә мин аждаһадан бала таптым булып чыга.

– Үзеңә ничек ошый, шулай булсын. Тик, тыңла әле, Догулаң, минем нәрсә әйтәсем килә. – Йөзбашы тынып торды да аннары телгә килде: – Менә хәзер, балабыз тугач, безгә ни кылырга икәнен уйларга кирәк. Һәм хәзер шул турыда сөйләшик. Әмма минем баштан ук, син белеп торсын өчен әйтәсем килә, хәер, болай да беләсең, шулай да барыбер әйтәм: мин һәрвакыт сине сагынып яшәдем һәм һәрвакыт сине сагынып яшим. Ә иң курыкканым – сугышта башымны җую түгел, шул сагынуымны югалту, аннан аерылу. Мин һәрвакыт уйлый идем, гаскәрләр белән йә бер, йә икенче якка киткәндә, сагынуымны, ул минем белән бергә һәлак булмасын, ә синең белән яшәсен өчен, үземнән ничек аерып калдырырга, дип. Һәм берни дә уйлап таба алмый идем, шулай да ул йә кошка, йә, бәлки, җанварга, шундыйрак берәр җан иясенә әверелсен, мин аны синең кулларыңа бирер идем дә, мә, ал, бу – минем сагынуым, ул һәрвакыт синең белән бергә калсын, дияр идем. Ул чакта мин һәлак булсам да курыкмыйм. Менә хәзер аңлыйм инде: сине сагынуымнан улым туды. Ул хәзер һәрвакыт синең белән булыр.

– Тик без әле аңа исем кушмадык. Син улыбызга исем уйлап таптыңмы? – дип сорады хатын.

– Әйе, – диде йөзбашы. – Риза булсаң, аны яхшы исем белән атыйк – Кунан булсын!

– Кунан?!

– Әйе.

– Ә нишләп, бик яхшы. Кунан! Яшь чабыш аты.

– Шулай. Өч яшьлек ат. Көченең иң куерып килгән чагы. Ялы да давыл кебек, тояклары да кургаштай.

Догулаң сабый өстенә иелде:

– Тыңла, атаң сиңа исемеңне әйтер!

Һәм йөзбашы Эрдене әйтте:

– Исемең синең – Кунан. Ишетәсеңме, улым? Исемең синең Кунан булыр. Дөрестән дә шулай.

Бу мизгелнең кабатланмас әһәмиятен тоеп, алар тынып калдылар. Төн тыныч иде, бары тик күрше табырда бер эт болай гына өргән булып алды да ерактан озак итеп кешнәгән тавыш килде – мескен ат төн уртасында тауларын, йөгерек елгаларын, куе үләннәрен, башка атларның аркасында уйнаган кояш яктысын исенә төшергәндер, бәлки... Исемле булып алган нарасый тыныч кына йоклый, һәм сабыйлык язмышы да әлегә аның белән янәшә йоклап ята иде. Әмма озаккамы?

Йөзбашы Эрдене зур учы белән мыегын сыпырды, тынлыкны бозып, авыр сулап куйды.

– Мин балабызның исеме турында гына уйланмадым. Башкасын да уйладым, Догулаң. Үзең аңлыйсың, яңа туган сабый белән монда калырга ярамый сиңа. Тизрәк китәргә кирәк.

– Китәргә?

– Әйе, Догулаң, китәргә, һәм никадәр тизрәк булса, шулкадәр яхшырак.

– Мин дә уйладым, тик кая китәргә, ничек китәргә? Ә син нишләрсең?

– Хәзер әйтәм. Без бергә китәбез.

– Бергә? Бу бит мөмкин түгел, Эрдене!

– Бары тик бергә. Ә башкача була аламы?

– Тик син, баравыл йөзбашы, ни сөйләгәнеңне уйла!

– Мин инде уйладым, ныклап уйладым.

– Әмма син хакан кулыннан кая китәрсең икән, дөньяда андый урын юк! Эрдене, акылыңа кил!

– Мин инде барысын да уемнан кичердем. Мине тыныч кына тыңлап бетер. Хәтерлисеңдер, без башта, күп кешеле, базарлы һәм сукбайлы калаларда туктап торганда, качып-посып йөрмәдек. Мин сиңа ул көннәрдә болай гына әйтмәдем ич, Догулаң: килмешәкләр чүпрәк-чапрагына төреник тә, шулар арасында югалып, илдән илгә йөрербез, дип.

– Нинди илләрдә, Эрдене? – Чигү остасы ачынудан кычкырып җибәрде. – Кайда ул безгә үзең теләгәнчә яши торган җир? Хаканнан китүгә караганда, Ходайдан качу җиңелрәктер. Шуңа күрә без кыймадык та, үзең аңлыйсың. Гаскәрдән кем шундый адымга бара алыр икән?! Менә без курку һәм мәхәббәт арасында үзебезнең яшерен тормышыбыз белән калдык та, сиңа гаскәрдән китәргә ярамый, китсәң, башыңны җуясы идең, ә мин синнән китә алмадым, югыйсә бәхетемне югалткан булыр идем. Инде хәзер без ялгыз түгел. Улыбыз белән бергә...

Өсләренә ябырылып килгән, тау-ташлар ишелгәнгә тиң шомны күз алдына китерүдән, аңлаудан тирмәдә авыр тынлык урнашты. Шулчак йөзбашы әйтеп куйды:

– Кешеләр хурлыкка калудан, мәсхәрәләнүдән, хыянәт өчен җавап тотудан качалар; аларга бары тик газиз башларын гына саклап калырга кирәк, шулай еш булгалап тора. Безгә исә язмыш бала бәхете бүләк иткәнгә күрә качарга туры киләчәк, тик шундый ук корбаннар бәрабәренә. Рәхим-шәфкать көтәсе юк. Хакан үзенең боерыгыннан беркайчан кире чигенмәячәк. Әле соңга калганчы китәргә кирәк, Догулаң, бүтәнчә котылу юлы күренми. Башыңны чайкама. Бүтән чара юк. Бәхет белән бәхетсезлек бер тамырдан үсә. Бәхетле чакларыбыз булды, инде бәладән дә куркып калмабыз. Китәргә кирәк.

– Сине аңлыйм, Эрдене, – дип, хатын әкрен генә әйтеп куйды. – Хаклысың, әлбәттә. Тик мин менә уйлыйм, кайсысы яхшырак: үлүме, әллә зур корбаннар хисабына исән калумы? Сүзем ул турыда түгел. Синең белән шулхәтле бәхетле мин, үземә-үзем әйткәнем бар: кирәксә, үләм, тик синнән миңа килгәнне үтерә алмыйм. Диванамы мин, әллә акыллымы, әмма мондый җинаятькә кулым бармады...

– Үзеңне азаплама, кирәкми, яшәргәме яки яшәмәскәме, син болай өзгәләнергә тиеш түгел! Без әле тумаган җанны корбан итәргә теләмәдек. Хәзер ул туды. Инде без аның өчен яшәргә тиеш. Качарга һәм яшәргә! Без икебез дә улыбыз тууын теләгән идек ләбаса.

– Үзем димим. Мин – һаман башка нәрсә турында. Син әйтә аласыңмы, әгәр мине җәзаласалар, синең белән улыңны исән калдырырлармы?

– Алай ук кирәк түгел. Мине түбәнсетмә, Догулаң. Сүз ул хактамыни?! Иң яхшысы, син үз хәленне әйт: үзеңне ничек хис итәсең? Юлга чыга аласыңмы? Син арбада Алтун белән барырсың, ул безгә ярдәм кулын сузарга әзер. Мин, атка атланып, янәшәгездә булырмын, берәр хәл килеп чыкса, саклап калыр өчен...

– Ничек әйтәсең. – Чигү остасы бу юлы сүзне кыска тотты. – Тик синең белән! Бергә, янәшә булырга...

Бишек өстенә башларын иеп, алар янә тынып калдылар.

– Әйт әле, – дип, кабат сүз башлады Догулаң, – тиздән гаскәр Җаек ярларына чыга, диләр. Алтун кешеләрдән ишеткән.

– Ихтимал, ике көннән булыр, алай ерак калмады инде. Ә су баса торган урыннарга иртәгә үк барып җитәрбез. Анда әрәмәлекләр башланачак, куаклар да чытырманлыклар, алар артында – Җаек.

– Зур, тирән елгамы ул?

– Иделгә таба бару юлында иң зурысы...

– Тирән дәме?

– Теләсә нинди ат йөзеп чыга ала торган түгел, бигрәк тә каты агымлы төшләрендә. Култыкларында – саерак.

– Димәк, тирән инде, ә агымы салмакмы?

– Көзге кебек ялтырап ята, кызурак аккан урыннары да бар. Син беләсең бит, минем бала чагым Җаек далаларында узды, безнең нәсел шул яктан. Җыруларыбызның да бөтенесе Җаектан. Безнең җырулар айлы төннәрдә җырлана торган...

– Исемдә, – дип уйчан гына әйтеп куйды Догулаң. – Син, ничектер, миңа бер җыруыгызны җырлап күрсәткән идең, хәзергә хәтле оныта алмыйм, сөйгәненнән аерып алгач, Җаекта батып үлгән кыз турында иде ул.

– Бик борынгы җыру...

– Бер хыялым бар, Эрдене, ак ефәк тукымага шундый чигеш чигәсем килә: су тынган, җиңел дулкыннар гына аның өстен бераз шадраландырып тора, тирә-юньдә үсемлекләр, кошлар, күбәләкләр, әмма кыз инде юк, ул кайгысын күтәрә алмаган. Бу чигешне кем күрсә, шуңа сагышлы елга өстендәге хәсрәтле җыру ишетелсен иде.

– Бер көннән сиңа ул елганы күрү насыйп булыр. Мине дикъкать белән тыңла, Догулаң. Син иртәгәсе кичкә әзер торырга тиешсең. Алмаш атны иярләп, мин килеп җитүгә, теләсә кайсы сәгатьтә бишекне алып чыгуың кирәк булачак. Мыштырдарга ярамый. Озак кыймылдау хәтәр хәзер. Мин бүген, әле үк сезне теләсә кай якка алып китәр идем. Тик әйләнә-тирәбез – ачык дала, беркайда күмелеп, яшеренеп тора алмыйсың, бөтенесе уч төбендәге кебек, өстәвенә төннәре дә айлы бит әлегә. Ә арттан куа чыксалар, арба белән дала буйлап ерак китеп өлгерермен, димә. Менә алда, Җаекка табарак, куе әрәмәлекләр башлана, анда инде бөтенесе икенче төрле булачак...

Алар, бер кисәк кенә тынып калып, аннары яңадан үзләрен нинди билгесезлек, нинди язмыш көтәргә мөмкин икәнлеген тәфтишләп, – хәзер инде бу, яңа туган бала белән бергә, өчесенә уртак язмыш иде, – бик озак сөйләштеләр. Сабый да озак көттермәде, бу әңгәмәдә катнашасы килгән сыман, ыңгырашып, бишегендә кыштырдый башлады һәм, шыңшыган эт баласыдай чыелдап, бераздан елап җибәрде. Догулаң аны җәһәт кенә кулына алды һәм, әле ияләшмәгәнлектән уңайсызлана төшеп, ярым борылган хәлдә ими каптырды. Кайнар дәрт белән хисапсыз күп тапкыр үбелгән, ап-ак шома күкрәктән калкып чыккан имиләр йөзбашына шулхәтле таныш, якын, ул аларны, үзалдына гына, камыш арасына качып торучы үрдәкнең йомры аркасына охшата иде. Хәзер инде барысы да яшь ананың мәхәббәтеннән нур алып торачак. Йөзбашының күзләре гаҗәпләнүдән һәм сокланудан яктырып китте, нәрсәдер исенә төшеп, дәшми-тынмый гына башын боргалады, соңгы көннәрдә шулхәтле күп кичерешләр эчендә яшәде, һәм менә табигать билгеләгән мөддәт эчендә буласы эш барып чыкты: ул – ата, Догулаң – ана, аларның уллары бар, анасы әнә сабыена күкрәк сөтен имезә... Ул

баштан ук шулай булырга тиеш иде. Табигать кушуы белән, үләннән үлән ярала, җанвардан җанвар туа, кеше генә, үз талымына карап, шул табигый кануннарның юлына аркылы төшәргә мөмкин...

Сабый, иреннәрен чупылдатып, ими суыра, үзенең күңелен күргән «ак үрдәк»нең тәмен-татын тоеп кинәнә.

– Әй, кытыкланам, – дип, сөенеченнән көлеп җибәрде Догулаң. – Менә бит нинди җитез малай булып чыкты. Күрдеңме, ничек килеп ябышты, инде аерып алып булмый, – дип сөйләнде, үзенең бәхетле көлүеннән аклангандай. – Ә чынлап та ул, безнең Кунан, сиңа бик охшаган. Бәләкәй аждаһабыз, дәү аждаһаның улы! Менә күзләрен ачты! Кара инде, кара, Эрдене, күзләре дә синеке, борыны да шундый ук, иреннәре дә тач коеп куйган кебек...

– Охшаган, билгеле, бик охшаган, – дип рәхәтләнеп килеште йөзбашы. – Кемнедер таныйм мин анда, бик таныйм.

– Ничек кемнедер? – Догулаң, аптырап, аңа карады.

– Билгеле, үземне инде, үземне!

– Ә син менә аны кулыңа ал да бераз тотып тор. Нәкъ инде кечкенә тере йомгак. Шундый җиңел. Куян баласын тоткандай.

Йөзбашы баланы кыюсыз гына кабул итеп алды, ул мәлдә үз кулларының көче һәм саллылыгы артык, урынсыз булып чыкты, һәм, ни кылырга, көрәктәй зур учларына нарасыйның мамык кебек гәүдәсен ничек җайлап куярга белмичә, аны сак кына күкрәгенә кысты, дөресрәге, йөрәк тибешенә якынайтты һәм, моңарчы таныш булмаган наз тойгысын ни белән чагыштырып була икән, дип, шул мизгелдә биләп алган кичереш-тойгыларыннан бәхетле елмаеп, дулкынланган тавыш белән әйтте:

– Беләсеңме, Догулаң, бу – куян баласы түгел, кулларымда – минем йөрәгем.

Бәләкәч тиздән йоклап китте. Йөзбашына да инде гаскәрдәге үз урынына кайтырга кирәк иде.

Төн уртасында сөеклесенең тирмәсеннән чыгып, йөзбашы Эрдене көзге Сарүзәк өстендә сары май кебек балкыган айга карап алды һәм үзенең тома ялгызлыгын тойды. Аяклары китмәскә карышты, яңадан Догулаңга, улы янына әйләнеп керәсе килде. Төпсез дала төненең колакларны чыңлаткан серле авазлары йөзбашын сихерләгән кебек иде. Бүген бу тирмәдә акылга сыймаслык, шомлы хакыйкать ачылды: язмыш тарафыннан бөек хаканның гамәлләренә тартып кертелгәнгә, аның белән бергә Кояш баешына таба яуга чыкканга, аңа хезмәт иткәнгә күрә, үзләре үк куркыныч астында калдылар, теләсә кайсы мәлдә хаканның бала туган өчен котылгысыз җәзасы аларны бик зур кайгыга салырга мөмкин иде. Бәс, шулай булгач, аларны Дөньяның Дүрт Тарафына Әмер бирүче белән бәйләгән көч табигатькә каршы, моннан соң үз тормышлары белән сыешмый, берсен берсе юкка чыгара торган нәрсә икән, шул нәтиҗә генә сорала: китәргә, ирек алырга, баланың тормышын саклап калырга...

Тиздән ул хезмәтче хатынны эзләп тапты, бу вакыт дәвамында Алтун, сәфәр капчыгыннан бөртек белән сыйлап, аның атын саклап торган иде.

– Йә ничек, нәни улыңны күрдеңме? – дип каршы алды хатын.

– Әйе, рәхмәт, Алтун.

– Исем куштыңмы?

– Аның исеме – Кунан!

– Әйбәт исем. Кунан.

– Әйе. Күк ишетсен. Ә хәзер, Алтун, мин сиңа бер сүз әйтәм, аны башка вакытка калдырырга ярамый. Син миңа кыз туганым кебек, Алтун. Ә Догулаң

һәм аның баласы өчен язмыш тарафыннан җибәрелгән тугрылыклы ана. Син булмасаң, без аның белән бергә сәфәр чыга алмас идек, аерылу газабы кичереп яшәр идек. Һәм кем белә, бәлки, бүтән беркайчан да очраша алмас идек. Чөнки яу белән баручы сугышны икеләтә каршы ала... Мин сиңа рәхмәтле...

– Мин аңлыйм анысы, – дип сүз кыстырды Алтун. – Нәрсәнең нәрсәгә икәнен бик аңлыйм. Син дә бит, Эрдене, шундый колак ишетмәгән эшкә бардың! – Алтун башын боргалап алды һәм өстәп әйтте: – Ходай бирсә, барысы да яхшылык белән узып китсен... Мин аңлыйм анысы, – дип дәвам итте ул, – бу зур гаскәрдә син бүген йөзбашы, ә иртәгә меңбашы-нойон булуың да бар, бөтен гомереңә җитәрлек дәрәҗәле кеше. Ул чакта инде без хәзер серләшә торган нәрсәләр турында сөйләшмәс тә идек. Син – йөзбашы, ә мин кол. Шуның белән барысы да әйтелеп бетә. Ләкин син башка юлны сайладың – күңелең кушканны. Сиңа ярдәмем бит – атыңны тотып тору гына. Үзең беләсең, мин Догулаңыңа хезмәт итәргә, аңа эшендә булышырга билгеләнгән кеше. Шулай да аңа бөтен күңелем белән бәйле, чөнки ул, – миңа шулай тоела, – матурлык Алласының кызы. Әйе, әйе! Ул үзе дә чибәр, әлбәттә! Тик мин бу турыда гына түгел әле. Башка нәрсә турында. Догулаң кулында тылсымлы көч: җеп йомгаклары һәм тукыма кисәге теләсә кемдә булырга мөмкин, тик Догулаң чиккәнне берәү дә кабатлый алмас. Үземнән беләм. Аның аждаһалары, һоруңнар буйлап, тере кебек йөгереп йөриләр. Тукымасындагы йолдызлар да күктәге шикелле чекерәеп яна. Әйтәм бит, аның осталыгы Ходайдан килә. Мин дә аңардан аерылмас идем. Әгәр инде китәргә уйласагыз, мине дә үзегез белән алыгыз. Качып баргандагы сәфәрдә аңа үзенә генә кыен булачак, әле бит бала тапты гына.

– Сүзем дә шул турыда, Алтун. Иртәгә, төн уртасына таба, әзер булып торырга кирәк. Китәбез. Догулаң һәм бала белән син арбада булсаң, ә мин бер кырыйдан, атка атланып, алмаш атны иярләп барырмын. Җаек болынына китәрбез. Иң мөһиме, таң атканчы ераграк китеп яшеренергә, иртән иртүк куа чыксалар, эзгә басмасыннар, берүк. Ә аннары үз юлыбызда булырбыз.

Тынып калдылар. Иярге утырыр алдыннан йөзбашы Эрдене, башын иеп, Догулаң белән икесенә аның язмыш тарафыннан җибәрелгәнен аңлап, Алтунның – күп еллар элек Кытай якларында әсирлеккә төшкән, шул көннән алып картаеп беткәнче Чыңгызхан олауларында хезмәтче булып калган бу кечкенә буйлы хатынкайның – арык кына учын үпте. Әгәр уйлап карасаң, кем иде соң ул аңа – үзенең чоңгылына суырып алган Кояш баешына яу сәфәрендә очраган юлдаш кына бит. Әмма, асылда, гашыйкларның, алар өчен иң хәтәр вакытта, бердәнбер һәм тугрылыклы таянычы булды. Йөзбашы аңлый иде: дөньяда ул беркемгә дә, беркемгә дә түгел, бары тик аңа – хезмәтче Алтунга гына ышана алды! Бөек сәфәргә чыккан, дәһшәтле авазлар белән, корал чыңлатып сугышка ыргылган ун меңнәрчә коралдашлары арасында, бары тик ул, бердәнбер ул гына, картаеп баручы олау хезмәтчесе, аның ягына баса ала иде. Бары тик ул гына, бүтән берәү дә түгел. Соңыннан шулай булып чыкты да...

Мөдәррис ВӘЛИЕВ *тәрҗемәсе.*

Ахыры киләсе санда.



Әхәт
Гаффар

БЕЗ – АК БАРС

ПОЭМА

I

Гүргә иңү

Газиз милләтем җан биреп ятканлыгы күз алдында.
Ни кайгы, ни үкенеч! Ни хурлык һәм түбәнлек...
Инкыйраз дәһшәтеннән үзләрен коткарырга көчләр җитмәде,
кирпеч өстендә кирпеч калмады, өмет тәмам өзелде.
Ризаэддин Фәхреддинов

Казан зоопаркында ике ак барс ачтан үлде.
Матбугаттан. 1998 ел.

Тарих җәясенең угы идек,
Халыкның
Җаны,
Рухы,
Тугрысы,
Ак канатны җәеп,
Күккә аштык,
Без – татарның яшәү туграсы.
Сугарырга диеп киләчәкне
Яратылган безнең кайнар кан!
Биш гасырлык кисек канатыбыз
Биш гасырлык муенда аркан...
Калканыбыз – калкавычлар түгел, –
Ә иренебездәге авызлык.
Ыңгырчак түшлеген и өзәсе! –
Камыт бауларыбыз – явызлык.
Бәгырьләрне күпме өзгәләде,
Телгәләде игәп газабы,

Әхәт ГАФФАР (1949) – *язучы; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Ф.Хөсни исемендәге әдәби премия лауреаты. «Сызылып таңнар атканда», «Энә күзе», «Дәрья башы», дүрттомлык «Сайланма әсәрләр» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Ни җитмәде сезгә, и җегетләр,
Кайда безнең яшәү лабазы?
Базларны без күптән күмдек ләса,
Айдан йолдызларга сикереп,
Бармак каккан саен бетмәгез лә,
Болгар-татар, тәмам искереп!
Читлектәге без – иреклеләргә
Тимер ләхет әзерләгәнсез,
Ачтан үлгән шып-шыр сөякләрне
Юар өчен әзер
ләгән
сез!
«Мин – фәлән ул!» – дигән адәмнәр
Тимер Казык йолдызы түгел!
Икәү үлдек – ап-ак барслар,
Сезнең хакка яшәдек бит гел.
Түгелгән кан татар кавеменнән,
Мәнен суырганнар сөлектәй.
Без китәбез инде,
Гамебезне
гүргә иңдермәгез үлектәй...
Электән без – бер Тәңрегез идек,
Мәгез сезгә – ап-ак сөякләр!
Ә без инде... тугры тугра килеш
Мәңгелегегез өчен – өрәкләр.
Иягегез дерелдәмәдеме,
Безнең кабер юк ич, юк ич ул!
Татар халкы!
Ачтан үлгән барс –
Синең ачтан үлгән бер юлчың.
Юк соң, юк лабаса инде
Без фәкыйрьләр – ике ак барс.
Инде менә, үлемебездән соң да,
«Алга!» – диеп, җәннәткә барыш...

II

Ау

Идёт охота на волков, идёт охота –
На серых хищников – матёрых и щенков!
Кричат загонщики, и лают псы до рвоты,
Кровь на снегу – и пятна красные флажков.
В.Высоцкий

Ә мин – өченче ак барс –
Качтым таш койма ачып:
Туйдым, суверенитет, дип,
Казанда коймак ашап.
Казан каласы – таш кала,
Бар калага башкала,
Качсаң котылып каласың,
Качмаганнан баш кала.

Мин качтым, качтым, ирекле
Булсам да бер мизгеллек,
Татар зоопаркына
Кылмаммы, дип, изгелек.
Качканда президент та миннән
Бәхетле булмагандыр,
Сыер сауган чибәркәйнең
Чиләге тулмагандыр.
Мин качтым таш койма аша –
Иреккә күз камаша!
Читлектән котылганыма
Җаным дәрьядай таша.
Тамаша, давыл кузгалса,
Зилзиләләр кабынса,
Мин әзер идем якларга
Татар ялгыш атласа.
Мин әзер идем яшенне
Учымда кысар өчен,
Җаныма, бәгъремә җыйдым
Күк күкрәүләре көчен.
Туганнарым – тугларым
Арасында йөрәгем.
Казандагы коллыгыммы
Минем сезгә кирәгем?
Мин качтым, ардым, талчыктым
Сагынып үз тауларым,
Каян белим ирегемне
Татарларның ауларын?!
Яшен яшьни, күк күкри,
Күкрәк тулы пошу,
Миңа һичбер ярдәмче юк:
Ни Куян, Бүре, Поши.
Яшендә, күк ишелгәндәй,
Тишелгән җан уртасы,
Аттылар арттан – төз итеп,
Манчылсын, дип, картасы.
Мин аларга, имеш, ерткыч,
Өзгәнмен зынҗырымны,
Аттылар,
саттылар,
сыттылар
Минем иң соң җырымны.
Аллаһ куйнында шыткан мин, –
Читлектә үскән юаш;
Бу ау – миңа түгел иде, –
Гуаһы торды Кояш.
Урадылар, турадылар,
Яңгырдай яуды ядрә,
Елады Чулман, Итилләр,
Аттила иле – Әдрән!..
Күк тыныч, йолдызлар җем-җем,
Тулган иде якты Ай;

Шул төнне,
Мин – качкын барсны,
Атып, утка яктылар.

***

Мең елдан соң
Мин калдырган
Татар телен таптылар…

III

Үлемебез – хөррият

(Егерме елдан соң)

Казан зоопаркында соңгы ак барс үлгән. Теофани исемле барс инде августта ук җан тәслим кылса да, бу хакта хәзер генә билгеле булды.
Әле быелның февраль ахырында гына зоопаркта Тамерлан исемле барс үлгән иде. Аны 2005 елда Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев бүләк иткән. Хәзер менә Теофани да китте. Онкологиядән үлгән, диләр. Авыруданмы соң, әллә сагыштанмы? Республика символы булган, гербны бизәгән соңгы барсның да үлеп китүе күңелне шомландыра...

Татарстан матбугатыннан.
2017 ел, 15 декабрь.

Яшәү кыйбат! Бик офтанма!
Әйтмә:
«Ни кылсак та – барыбер үләргә».
Бөек очраклык – туу – үзе бәхет!
Юкка, димсең, кирәк аның хакын
Бөтен гомерең буе түләргә!
Хәтта
Үлемең белән...

Равил Фәйзуллин

Күпме үлмәк кирәк инде,
Яшәвеңне раслар өчен!
Раслаганны дәлилләргә
Каян килсен барс көче?
Безнең гомер – керфекләрнең
Бер кагуы ише генә.
Үткән юллар – бишегеңнән
Әлмисакның ишегенә
Атлап керү, дип язылган
Ләүхүл-Мәхфуз китабында,
Калганнары – максатында,
Аллаһ биргән аш-табында.
Ашаганда, эш кылганда,
Җилдәге җансыз кылгандай...
Кинәт шайтан өере куба,
Һәммә дәрья айкалгандай,

Чайкалгандай ялгыз көймә
Өем-өем дулкыннарда,
Җан дәрьясы ташып ага
Моң-саздагы соңгы кылдан.
Әле генә ни бар нигъмәт
Хикмәти Көч кушуынча,
Тук идек – сулды рухыбыз
Ком аккандай куш учыңнан.
Ике телле Юха елан
Татарның җанын чакты,
Мәңгелек умырткадагы
Җелек читләргә акты.
Шул чакта татар димәкли
Чаккан урынын кысып,
Җибәрделәр сүз дөньяга...
Кан катыш үтен косып,
Сосып үкенечебезне,
Барслар үрә калка:
«Бетте көч, сынды кылыч», – дип, –
Менә шул безнең калкан!
Саттылар, аттылар,
Сыттылар безнең җанны,
Ектылар, суктылар, сыктылар,
Сыктылар безнең канны.
Без – таулар, дәрья, үзәнне –
Бар җирне мәгърур гизеп,–
Ак барслар үткән идек,
Коллык чылбырын өзеп,–
Дигән мәлдә – без һәлакбез,
«Авырулардан», имеш,
Җәлладларның бүкәненә
Башларны имәс килеш.
Анысы да, монысы да бар
Җирдән кояшка чаклы,
Инде
менә,
сәждә кылып,
Тәңре-Аллаһны кочыйк.
«Очыйк бу денсез вә динсез
Калган Казан иленнән», –
Дип, менә без дә, ниһаять,
Үлеп кичтек «пленнан».
Инде хәзер шушы төштә
Чын бәеткә урын бар:
«Татарстан» дигән илдә
Барсларга урын тар.
«Яшим диеп яшәмәгәч,
Көям диеп көймәгәч,
Нигә яшәргә дөньяда
Сөям диеп сөймәгәч?» –
Дип алган идек түгелме
Татарга Җөмһүрият?..

Барсларда – нурлар хуры,
Үлемебез – хөррият!
Кайда безнең Аттилабыз.
Кайда Кубрат ханыбыз?!
Әйтмисезме, дәшмисезме? –
Туңды безнең каныбыз.

IV

Кан моңы

Без татарлар өчен мәңгелек –
Кояш сүнгәнчегә кадәр яшәү.
Безнең өчен мәңгелек – фәкать шул!
Индус Таһиров,
академик

Сират күперен күптән кичкәннәрдер
«Теофани» һәм дә «Тамерлан».
Күпме үлү тагын кирәк соң ул,
Татар!
– Яшим! – диеп, мәңге тамырлан!

Нигә алдыгыз Туграга
Без мәңгелек җаннарны?
Терсәгегезне тешләрсез
Дип:
– Аннары, аннары...
Агым сулар кире акмый,
Ә каннар – бигрәк тә.
Мөхәммәд пәйгамбәрле барс
Учта, җанда, йөрәктә.
Җырлый-җырлый шәһит киттек,
Җәсәдләрне күмгәндә,
Мөхәммәд белән Гайсә
Әлмисак күрмәгәндә.
Әлмисак – янәшәдә ул:
Безсез Сез яшәгәндә,
Барс рухлы татар сүзе
Һәр яшен яшьнәгәндә!

***

Без китәбез, сез каласыз, дип җырлармын,
Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.
Габдулла Тукай

Алда гомер бардыр-барын,
Сагындыра...
...узасың.
Күрерсез, шаһит булырсыз,
Без – барслар бузасын!
Гөлчәчәкләргә күмәрсез
Ак барслар нужасын,
Өмет итмәгез мәңгелек
Коръән-Кәрим тузасын.

Татар үз мәңгелегеннән
Ана телсез узасын.
Барс табар халык хакына
Тукай
белән
Мусасын.
Сизегез, белегез, кичегез
Безнең дөнья сусавын!
Әй лә яшәп күрсәттек соң,
Юлыбыз – Киек казлар,
Үлгәннәр – гүрләребездә,
Исәннәр азлар,
азлар...
Калганын Аллаһ назлар.
...Алда – моң сарган язлар.
Пәйгамбәребез сүрәсен,
Аятьләр алып иманга,
Без – барслар, суккан сөлге
Бәйләп барабыз алга.
Тик гел алга!
Ис китмәстән ялган-яманга, –
Әләмебез яшелгә манган,
Яшел яфрак саен кан тамган ла,
Тамчы-тамчы канда моң калган.
Каберебездә үсәрдер бер кылган…

Без барслар идек,
Ап-пакь барслар!
Фани белән бакыйлыктабызны
Җан сакчыбыз – туграбыз раслар.

Редакциядән:

Бу айда каләмдәшебез үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.

Айдар
Хәлим

КАРА ТӨННЕҢ КАРАСЫНДА

ХИКӘЯ

I

Минем сезгә моннан егерме-егерме биш еллар чамасы элек үзем белән булган вакыйганы сөйлисем килә.

Сентябрь башлары иде. Туган авылыма кайту уе белән Әкчиннән Миякәгә килеп төштем. Анда яшәп яткан ерак туганым Сабиржан белән киленем Рәгыйдә бик теләп үзләренең «Запарай»ларында Кәркәлетамакка ук илтеп куярга булдылар. Көзгә кереп килгәндә, уҗым арышы чәчкән чорда була торган вак күзле яңгырга да (аларны бездә спас яңгырлары диләр) карамыйча – озын-озак уйлап тормыйча, авылга каратып юлга да чыктык. Әнәч авылының аргы очында, «хәзер туктыйм-хәзер туктыйм» дип иренеп кенә типченеп яткан Миякә инешен үткәч, егерме елдан артык күрмәгән юл буйлап турыдан кайтасым килеп, машинабызны асфальттан кискен уңга каерып, җәйге ат юлына бордырып чыгарттым. Һәм без бая гына, санап кына, тамгалап азапланган вак тамчылардан оешып, эреләнә барып, кушылып, яфраклардан лычтырдап ташкын сулар ага башлады, шундый тиз арада җеби, сазланырга өлгергән җиргә күз дә салмыйча килгәндә – менә сиңа мә! – Сталин заманнарында колхоз межаларына утыртылган тирәклектә чөгендерчеләрдән калган чокырга кереп тә сеңдек. Бик ышанычлы рәвештә баттык. Әле генә шалтырап килгән ат юлы кинәт кенә ниндидер җеннәр могҗизасы белән тирән кара буразналарга әйләнде дә куйды. Яһү, бу нәрсә? Күз ачып йомганчы!.. Запарайның үзенең чыгарга дәрманы юк, ул көчәнә-көчәнә, безне коткарырга теләп, көпчәген әйләндергән арада, әкәм-төкәм кебек, мыштырдый, бездән читләшә, бата, күмелә бара, без исә аны, ничек кенә теләсәк тә, бу саздан этеп тә, күтәреп тә чыгара алмый идек. Шулай этә-төртә торгач, ләмдә коенып, тәмам шахтёр рәвешен алып, пычрандык. Җитмәсә, сентябрьнең алдагы атна-ун көнендә, әйткәнемчә, бары тик көзге спас яңгырлары башланган чорда гына төшә торган караңгылык сәтрәсе кинәт кенә куерып, күзләрне бәйләп тә өлгерде.

Айдар ХӘЛИМ (1942) – *шагыйрь, прозаик, публицист; «Өч аяклы ат», «Татар моңы», «Хунвейбин» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты. Чаллыда яши.*

Алга да, артка да барыр әмәл юк иде. Ә миңа, ике-өч кенә көнгә эшеннән сорап киткән мосафирга, юл бары тик алга, турыдан – үземнең урман кисеп, печән чабып үскән яланнарым-кырларым, урманнарым аша соңгы елларда ташландыкка әйләнгән иске ат юлы буйлап җәяү генә чыгарга калган иде. Мин теләгемне юлдашларыма чиштем.

– Адашмассыңмы? – булды аларның бар борчылганы. – Авылга бит моннан кимендә алты-җиде чакрым...

– Һи-и, тапкансыз адашыр кеше! – дидем, яңа куйдырган эре металл тешләрем белән һаваны уртлап. – Мин моннан бәйләнгән күз белән дә җырлап кына кайтам!.. Хлебороб юлына чыгам да Түгәрәк Имәнгә суктырам!.. Шалт, Мөхәммәтҗан!..

– Кара аны, Мөхәммәтҗан абзыкаем, – диде, киная белән кисәтеп энекәшем. – Башың әйләнеп, адаша күрмә. Көзге кара күзне яра, дигән әйтем бар. – Әйдәгез болай итик: сез кабинага кереп утырып торасыз. Мин, авылга барып, трактор алып киләм. Аннан асфальтка чыгып, авылга пешкән йомырка кебек теркелдәп кенә тәгәрәячәкбез...

Соңыннан ачыклануынча, килеп туган шартларда бу бик төпле киңәш булган. Әмма, мине, туган тугайларын үтә дә сагынган, аннан, алда үзен көткән сынауларны башына да китермәгән, сабырсызның «Күрмәгәннең ачасы, күргәннең качасы килә», – дигәненә ышанган хәлдә, могҗизага һәвәс затны тыю мөмкин дә түгел иде.

Без шулай иттек тә. Һәм мин, сумкамны иңемә асып, юлдашларым белән бераз гасабиланып җәһәт кенә хушлаштым да, тирә-якны чаштыр-чоштыр китереп, алга кузгалдым. Караңгы куера, яңгыр тагын да көчәя төшкән иде. Аның кай арада тукыма плащ аша костюмыма үтеп, эчке киememне чылата, авырайта, тәнемә ябешеп, пошлыктыра башлавыннан мин юлымның газаплы булачагын шунда ук сизендем. Кайчандыр Сталин бишьеллыклары заманында утыртылган, хәзер урманга әверелгән тирәкләр рәтен үткәч тә, аяк астындагы халәт тагын да катлауланды: элек, гадәтенчә, шалтырап яткан ат юлым чөгендерчеләр техникасы белән усал ермачланып, бер тәртипсез буразна хасил иткән юлым кара сазга әйләнде дә куйды, аяклар, потлы гер таккандай, авырайды. Гүя мин камыр баскан Геракл кебек шап-шоп килеп, үз артымнан Җир Шарын тартып киләм. Юл кешесе белә: яңгыр әле коры туфракның үзәгенә үтеп, аны эчтән изрәтеп, былчыратып, боламык ясап өлгермәгән, шул ук вакытта балчыкның изелеп, коры матдә булудан туктаган, табаннарга ябышып, ачуны китерер дәрәҗәдә өстерәлгән аякларга атларга бирми башлаган минутлары була. Мин нәкъ шундый мизгел корбаны идем. Бая гына чепек, вак күзле яңгыр, инде пыскаклап сибелүдән туктап, юнәлешен үзгәртте һәм уң тарафтан кыеклап, йөзгә бәреп ява торган эре тамчылы коенга әверелде. Дөресен әйтим, дөньяда илле ел яшәп, минем мондый көчле яңгыр күргәнем юк иде. Битем-ишарәтем буйлап аккан суларны сөртә-сөртә, «ә» дигәнче, үзе суга әйләнгән кулъяулыгымны сыккалап арыганнан соң, кесәмнән чыгарып та азапланмыйча, җиңем белән генә йөземне сыпыра башладым. Күз чокырларына тулыша барган тозлы тир яңгыр белән кушылып, авызга саркылып төшә һәм тозы телне әчетеп, ачлы-туклы балачак хатирәләрен уята. Бер яктан бу җанга рәхәтлек китерә, әлбәттә, мин моңа шат: тупас, әмма иркен табигатьнең нечкә дә, холыксыз да булган хозурында иркәләнә идем!.. Беркем комачауламый, үземдә булмаган чит акыл яктылыкларын эзләп көчләми, үземдә булган акылны да рәнҗетми – талатмыйча, мин, ниһаять, Әнәч межасы аша чыкканнан соң,

үземне инде ихластан да туган тарафларга кайткан кеше рәтендә тоеп, авыр балчык уралган аякларымны урман янәшәсеннән сузылган буразналардан өстерәп баруымны дәвам иттем.

Уф!.. Озак та үтми беренче тапкыр арый башлавымны тойдым.

Кая ди, миңа, әле юлының башына гына төшкән юлчыга, арырга-талчыгырга бик иртә иде!..

Үземне битәрләп тә алдым: бәй, баксаң, янәшәмдә генә, урман кырыенда, туган нигеземә кайту кызулыгы белән чирәм булырга тиешлеген дә онытып, мыш-мыш килеп, үзле балчык өстерәүне дәвам итәм икән! Күз бәйләнсә дә, дөнья әлегә кыенлык аша булса да таныла-күренә сыман, мин күпмедер вакыт чирәмнән атлаштырган булдым, әмма бу бәхет тә озакка тәтемәде: аяк астымдагы кайчандыр трактор ярган ызан, чокыр-чакыр, тәртипсез киселгән агач төпсәләре, ботак-санак, чытырман алга барырга бирми, чабылмый калып, урман кебек үрчегән кыргый үлән, кырлы курай, төлке койрыгы һәм башка шырлык аякка урала. Берничә тапкыр таеш басып, тәгәрәп тә киткәләдем. Туктап, берәр аваз, тавыш ишетелмәсме, дип колак салгалыйм. Чүгеп тә тыңлап карыйм. Юк, агымы таш тегермән куласасыннан гүләп аккан яңгыр тавышыннан башка берни дә ишетелми. Алдан барасы юлны күрү, үзеңне, уңны-сулны аешу мөмкинлеге юк, аның каравы, мине уратып алып биләгән караңгылыкның мәйданы чиксез иде. Бер яктан, урман үзе дә, чирәмнән читкә этәреп, кире килгән юлыма кысрыклап чыгара. Егылып, баш чүмечемне җимермәс өчен, мин, табаным белән тойган иске ызаныма төшәргә мәҗбүр идем...

Ә яңгыр туктау түгел, көчәйгәннән-көчәя барды. Алдымда, ниһаять, дивар кебек тоташ караңгылык хасил булды. Бу энә очы кадәр дә якты сизелмәслек кабер караңгысы иде. Мин үземдә моңа кадәр тоелмаган ялгызлыктан калтыранып куйдым. Йөрәгемне бер мизгелгә «Адашмаммы?!» дигән куркыныч уй парә-парә телеп үтте. Шушында?! «Комлык» башында?! Туган авылымның каш өстендә?!

Әткәмнең мине, туганымнан соң, күреп тә өлгермәс борын фронтка китеп югалганына быел җитмеш бер ел тулды. Җитмеш еллык кабер караңгылыгы, бәлки, шулай буладыр да инде...

Минем өчен хәзер уң да, сул да, ал да, арт та юк иде. «Караңгы дип килми калма, ай булмаса, йолдыз бар», дип җырлаган да бит халкыбыз. Әмма... Нишләргә? Биредә ае да, йолдызы да булмаган тома сукырлык халәте генә бар иде.

Караңгылыкның яктылык белән ничек, кайчан кушылганы-аерылганы тоемланмаган бу сынауда миңа хәзер туган җирне ярату гына аз, аны бары тик ис-хис, табаннарым белән тоеп белергә кирәк иде. Монда камил акыл да, камил тойгы да түгел, бары тик тәнемдәге биш тоем тойгысы – хәтер, сабый чак, үсмер чак ядкарьләре генә коткара алачак. Минем бурыч шушы егерме еллап күрмәгән алты-җиде чакрым араны күзләрем белән күреп түгел, ә бәлки, мөмкинендә, кулларым белән тотып, чамалап, борыным белән иснәп, телем белән тәмләп, күкрәгем белән сөреп, беренче чиратта, шушы җирне, шушы туфракны, аяк астымда леркелдәп, лырк-лырк килеп, лашпырдап яткан баткакны, буразналар белән ергаланып беткән чиксез материкны, аның үрен-тигезлеген, түбәнен-текәсен, чокырын-түбәнен хәтеремнән үткәреп, чагыштырып, аяк табаннарымның һәр төге, ноктасы белән танып, нигеземә кайтып егылу иде. Кыскасы, мин үкереп яуган яңгыр караңгысында үземә-

үзем әйдәп баручы штурман идем. Бу бурычны үтәү өчен, кайчандыр урман буендагы ат юлы булган, инде заман техникасы ерткалаган буразналардан уңга да, сулга да чыкмаска, табаннарымны ватерпас итеп шушы материкның баткак дәрьясын өстерәргә, Миякә урта мәктәбендә укыганда, өч ел буе йөргән юлым белән кушылган тәңгәлендә авылга таба кискен сулга борылырга, аннан «Комлык» юлы буйлап Түгәрәк Имәнгә килергә, аннан инде, үзем әйтмешли, «бәйләнгән күз» белән дә өч үр аша түбәнгә төшеп, авылга кайтырга тиешмен! «Түгәрәк Имән»гә җитсәм, мине беркем адаштыра да, югалта да, җиңә дә алмас, Алла боерса! Ул бит минем мәңге адаштырмас маягым!.. Бу яланнар минеке, алар мине аңлый һәм тыңлый; моңа үземне лаек дип саныйммы, әллә санамыймы, ничек кенә булмасын, аларның алыштыргысыз, газиз вә асыл баласы идем. Әлбәттә, һәркем үзен шундый итеп тоя ала һәм моңа хакы бар.

Шулай итеп, ориентир билгеле: ул минем күзләремә күренмәсә дә, биш тоемым белән тоелып, барлыгы уң тарафымда кара төн карасында чак-чак беленеп яткан урман. Димәк, үземнән ун-унбиш адымдагы урман буеннан сулга язлыкмыйча, бата-чума, шушы буразналардан алга, бары тик алга!

Мин киememне сыгып алырдай булып, энәсеннән җебенә кадәр чыланган, егыла-тора шакшы дуңгыз хәленә җитеп пычранган идем. Кинәт теземнән алата тирән ямга чумдым. Башта сул, аннан уң аягымны чыгарырга дип иелгәндәме, белмим, иңемдәге йөгем чокырга капланып төште һәм битемә салкын пычрак явын орды. Җиңем белән баткакны сөртәм дип аны битемә сылаганда чайкалып китеп, сул аягым катасын кулдан ычкындырдым. Күзеңә төрткән хәлдә дә күренмәс спаста югалган катамны баткак диңгезендә ничек кенә актарынсам да, таба алмадым. Бик табарга теләсәм, таң атканын көтәргә, ә бәлки, шушы мизгелдә, кулыма эскәк тотып, ләм диңгезендә төне буе буй салып йөзәргә тиеш идем. Эзләнүдән туктап, бер аягым оекчан килеш юлымны дәвам иттем. Бу мәхшәрдә бер аягың киемле, икенчесе шәрә килеш атлау мәрәкә күренеш, моның сихәте кышкы челләдә бер балаксыз чалбарда йөрү яки салкын мунча керү кебегрәк булганга, уң як катамны салып, кулыма элэктердем дә ике аягым да оекчан килеш атлый башладым. Табаннарымны очраклы пыяла-тимердән ярдыру, чөй-кадакка кадату куркынычын санамаганда, яланаяк бару миңа күпкә уңайлырак тоелды...

Шунысы кызык: бу коточкыч ялгызлыкта һич тә ялгыз буласым килмәде. Киресенчә, кичергән газапларымны урман эчләрендәге оя-өннәреннән барча җанварлар – бүре-аю, төлке-бурсык, ялан-басулардагы тишекләреннән әрләнйомран, тычкан халкы карап торуын тели идем. Имеш, шулай булырга тиеш!.. Алда бернинди үзгәреш тә, шылт иткән кузгалыш та, караңгылыкта кәтрә дә яктылык көтелмәгәнгә, берөзлексез буразналар буйлап чайкалганда, үземне мавыктырыр өчен күңелле уйлар уйларга, матур сәхифәләрне хәтергә төшерергә тырыштым. Гүя алар мине эчтән яктыртырга тиеш иде. Миңа юлымны кыскарту, үземне бу саңгырау ялгызлыктан чыгару өчен, бары тик уй, кыңгыраудай уята торган уй кирәк иде! Ләкин уйларның күңеллесе, хатирәләрнең матуры килергә ашыкмады. Шулчак колагыма баян моңы ишетелгәндәй булды. Чаллыдагы баянчы дустым Рифкать Муллин уйнагандай тоелды. Әйе, шул, нәкъ үзе!.. Юк, ул түгел, бу Зәкәрия!.. Үткән гасырның туксанынчы, милли күтәрелеш еллары башында Уфадан Чаллыга күченеп килгәч, мин, беренчеләрдән булып, оешып яткан татар гимназиясендә музыка укыткан педагог һәм виртуоз баянчы Зәкәрия Туллин белән таныштым. Мәктәп теплицасында яшәп азапланган бу моңзар-мәгърифәтче мине шулай бер тапкыр кунакка, дөресрәге, мәктәп

котельныенда пожарниклардан яшертен кораштырылган «саунага» – мунча керергә чакырды. «Нигә болай яшисең? Директорыгыз берәр бүлмә дә алып бирә алмыймыни бу йорт артыннан йорт сафка баскан мактаулы «КамАЗ»да?» дигән сорауга ул, көлемсерәп: «Директорыбыз югарыдагы оператив киңәшмәдә бездә фатирга мохтаҗ кешеләр юк, дип мактанган, – дип сөйләп китте. – Бер бүлмә сорап язган гаризам буенча ул мине чиратка да куймаган әле... Көнләшә, малай. Чөнки үзе дә музыкант – калай сыбызгыда уйный...» Мин аның баяннан чыгарган моңлы борылыш-бөгәлләренә шаклар каткан идем. Каяндыр, Урта Азия якларыннан кайткан бу табышмак-музыкант татар моңын, кем әйтмешли, «бөгеп кенә сала» иде. Ул шундый каршылыклы тоннарда уйный белә: елар урында көлеп елыйсың, көләр урында елап көләсең... Милләт баласы, көннәр буе балаларга моң өләшә: хорда һәм ялгыз җырлата, аларга гомумтөрки-татар моңының илаһи чыганакларын аңлата-аңлата арый, хәлдән тая, дәресләрдән соң, теплицасындагы шыгырдык диванында бераз хәл җыя да, яңадан баянын кулына алып, моң шахтасына төшә һәм кара күмердән ак моң чаба... Азмы иде алар, мондый моңзарлар, бездә, татарда?!

Шулай, ничектер, мин аңардан «Уел»ны уйнавын үтендем. «Бер тапкыр, Ташкентка килгәч, бу җырны җырлаганда, Илһам Шакировка «озатып баручы да булган» идем, – дип мактангандай итте ул, башкалар «аккомпанировать иттем», дип әйтәсе урында үзен «озата баручы», дип кенә атап. – «Уел» – татарның Казан алынганнан соң, хан, каласына керә алмыйча, каз кебек, бер аягында басып торган көннәре турындагы эпохаль опера ул. Аһ, вакландык, быр-рат!..»

Зәкәрия уйнаган җиреннән кинәт туктады. «Кара! – ди. – Шкаф астына кара!..» Ни күзем белән күрим, ниндидер зур күзле, бөдрә керфекләренә, иреннәренә, – бәлки, миңа шулай күренгәндер! – азгын хатыннар кебек, кычкыртып иннек-кершән буянгандай, комык безгә карап тора... «Бырыс!» – дип куркытырга теләде аны Зәкәрия, әмма комык кереп китәргә ашыкмады. «Ул берьялгызы түгел. Монысы разведчиклары гына. Калганнары сигнал көтә. Минем уйнавымны яраталар. Кайвакыт күмәкләп, аяк очларыма килеп утырып тыңлыйлар. Юк, миннән бигрәк, баян каешын ярата алар, – дип сөйләп китте шаян музыкант. – Баян каешына ниндидер татлы моң сеңә бугай. Комыклар әле дә үз өлешләре итеп кимерергә каеш көтә. Әмма мин гармуннарымның күрекләрен дә ашарлар дип, аларны кич белән күн капчыкларга салып, түшәмгә аса башладым. Түшәмгә сикерә алмыйлар, явызлар. Күрәсеңме, кереп тә киткән? Чөнки мин аларга өлеш чыгара алмыйм. Миңа ул өлешне директор бирергә тиеш. «Комыклар гармун каешларын ашады, яңа каеш алырга акча бүлегез әле», – дигән идем, – «үз акчаңа ал, комыклар мәктәп бюджетында тормый», – диде ул берчакны. Кеше, адәм баласы, комык аңлаганны да аңламый, дускаем».

II

Яңгыр туктады. Бу хәлне бераз гына уңай якка үзгәрткәндәй итсә дә, уптым-илаһи алганда, хәлне яхшыртмады, чөнки киемнәрем чылану гына түгел, гәүдәм, чамасыз күп көч куюдан токмач камыры кебек пешенеп, куна тактасына җәярлек булып изрәгән иде. Оекчан килеш лачтыр-лочтыр атлаган уңайга үземне көндезен, яктыда фараз итеп, чит кеше күзлегеннән күрергә тырыштым. Ниндирәк икән мин хәзер? Әнә, яңгыр белән тулышкан буразналар, бомбалардан калган буранкаларны хәтерләткән чокырлар аша

иңенә сумка аскан, бер кулына катасын эләктергән, икенче кулын, кинәт таеп китеп, йөзтүбән төшмәс өчен җиргә кадалырга әзер тоткан кара чутырдай бер албасты килә. Хәзер өстән, югарыдан карасак, бер назари нокта, такыр башлы микроб, нишләргә белмичә, уңга-сулга бәргәләнә, гүя ул, кая таба борылса, нәрсәгә тотынса да, электр шаукымы суккан калкавычны хәтерләтә. Ул – мин. Башына кигән кәпәче сынган кош канаты сыман янтаеп төшкән, йөзе дегеттәй кара, озын, өркәчле борыны исә авыр, кайнар тында җепшенеп, бүртенеп, бәрәңгегә әверелгән, кашларына учлап-учлап ләм ләпәшкән... Бу – мин. Килә... Кулында нәрсә? Ката!.. Аяк савыты!.. Туфли галиҗәнапләре! Икенчесе кая? Анысы баягынак кара упкын астында калды. Ул чакта нигә монысын күтәреп килә? Музей өченме? Тиле түгелме бу абзый? Мин гарьлегемнән генә түгел, ирлек ачуым белән кулымдагы катаның икенчесен болгап очырганымны сизми дә калдым. Кай тирәгәрәк барып төшкәндер?!

Кара төстәге аяк савытымның бернинди эз калдырмый, күзгә дә чалынмыйча юкка чыгуы, мине караңгылык белән яктылык янәшәлеге, аларның бердәм каршылыгы турындагы әллә-нинди тирәнтен уйларга кертеп җибәрде. Аннан, кая ашыгырга, перспектива – нуль, вакыт чиксез иде, дип әйттем бит инде. Уңга-сулга, алга-артка карамыйча, җирне бары тик аяк табаннарым, иңем янәшәсендәге урман исен, аның якындагы җисемен, йөрәкләребез арасын тыным, кулларым, гәүдәмнең һәр күзәнәге белән тоеп, иң мөһиме, урман кырыен зиһеннән ычкындырмыйча, бернинди адашу, эз югалтуларга юл калдырмыйча бардым да бардым. Кыскасы, мин хәзер Яктылык белән Караңгылык дигән ике бөек төшенчәнең, ике бөек тәгълиматның бербөтен булып оешкан матдәсе, колы – сынау һәм сыналу мәйданы идем...

Мин шушы караңгы төнгә кадәр караңгылыкның, җир һәм һава кебек җиде каттан торганлыгын, бер караңгылык эчендә икенче, өченче караңгылык булганлыгын, аларның бер-берсен яктыртып, эчтән сукырайтканын да белмәгәнмен. Яктылык караңгылыкны җиңә дип раслау өчен, бик беркатлы кеше булырга кирәк икән. Яктылык караңгылыкны җиңсен өчен, ул бары тик югарыдан гына төшәргә тиеш. Димәк, яктылык бары тик билгеле кануннан, канун кабул итүче система, түрәләрдән төшәме? Кешелекне, кешелектәге кечелек – яктылыкны Аллаһ яраткан бит. Без моны беләбез. Алайса караңгылыкны кем яраткан? Яктылыкка чыганак кирәк, ә караңгылыкка – кирәкми, ул караңгылыкны үзеннән-үзе җитештерә торып, чиксез караңгылыкка әверелдерә. Ул яктылыктан алданрак яратылган булганмы? Чынлап та, бар ителгән, яратылганга кадәр дөнья бары караңгылыктан торгандыр. Караңгылык яктылыктан картрак, өлкәнрәк. Миңа ишелгән караңгылык та миннән өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк менә.

Тукта, мондый караңгылык Аллаһының Фиргавен токымына һәм аның яраннарына җибәргән тугызынчы җәзасы түгелме?! Тәнемне чемердәтеп, куркыныч шаукым үтте. Коръән Кәрим сүрәләре раславынча, Аллаһы Тәгалә аларны динне кабул итмәгәннәре өчен һәм иманга килмәсләрме, дип, кодрәтлеләрдән кодрәтле ун җәза – корылык, кан, гөберле бака, чебен-черки, мал-туар үлеме, тән җәрәхәтләре, давыллы-утлы боз явымы, саранча афәте, гадәти булмаган караңгылык, сабыйлар үлеме кебек газаплар газабы белән сыный. Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында: «Аларга ачык дәлил итеп корылык, су басуын, саранча, бет, бакаларны һәм кан газабын җибәрдек. Бу дәлилләрне күргәннән соңра да алар тәкәбберләнеп, азгын кяфер кавеме булдылар», – ди. Әлеге караңгылык нәкъ шул чактагы динсезләр өстенә төшкән тугызынчы

газапның кабатланышы түгелдер лә, Илаһым?! Без кайчан иманга килербез? Без төзәләчәкбезме? Нәрсә көтәбез?

Караңгылыкта яңгыраган Беренчел Бөек Шартлау дөньяны бар итеп яктырткан. Шул рәвешле, яктылык караңгылыктан туган, шуннан бар булган, димәк. Без яктылыкны ничек кенә олыламыйк, бөек пәйгамбәрләрне сурәтләгәндә, аларның маңгаеннан чыккан илһам нурларын ничек кенә зурламыйк, аларның фикер яктысын ничек кенә алтын бөжралар белән данламыйк, безне бар иткән Аллаһ үзе дә шушы башлангыч караңгылыкның бер өлеше булып чыга түгелме? Шуңа күрә дә шайтан – кешенең зарури иярченеме? Армиядә хезмәт иткәндә, төнлә дә күрә торган яңа җайланма белән танк йөрткәннәрем хәтеремә килә. Кап-караңгыдагы юл нишләп безнең күзләргә ямь-яшел булып күренә иде икән? Шул җайланма белән елга төбеннән аша чыкканда да су төпләре ямь-яшел иде. Ә карадан туган яктының сыек яшел булуының сере нәрсәдә иде икән соң?

Кызык, яктыда түгел, кара төннең карасында, төн эчендәге төндә мин фикер иясенә әверелгән идем. Гүя караңгылыкның якты шартлары миннән философ ясарга җыена...

Дөнья буйлап миллион чакрым юллар үтеп, кем әйтмешли, алтыдан алтмышка җитеп, авылыма берничә чакрымда гына калган арада аңладым шушы чиксез гади хакыйкатьне. Яңгыр коя, аяклар астында гөрләвек булып айкала-чайкала иде. Мин күз нурларымны ук итеп, гүя күз кабакларымны җәядәй киереп, караңгыда нәрсәләрнедер күрергә тырыштым. Юк, караңгыдагы агачлар да, иген басуы да, кыргый үләннәр дә, хәтта артымнан «өстерәлеп барган» буразналар да күренми, ләкин – шунысы сәер! – «караңгыдагы караңгы» эчендә, бер аягымны суырып алганчы икенчесе ләмгә баткан, чаптыр-чоптыр килеп атлаган уңайда, ниндидер алтынчы тойгым, табан очларым, сихри көч аша шушы күренмәгән агач башларын каккан җилләр тавышыннан, урманның, яланның тын алышыннан чыгып, үземнең дөрес юнәлеш белән Хлебороб борылышына якынлашып килүемне чамалый идем! Бу чама дигән нәрсә, әлеге мизгелдә үзем матдәи сукыр булып, рухи күрүчәнлекнең балачактан сакланган Хәтер ядкаре иде!

Кинәт ерактан, бик ерактан, «Урман арты» дип аталган төштәге Ишле юлы тарафыннан нур көлтәсе балкып чыкты. Яңгыр шавы астында бернәрсә ишетмәстән, аның машина уты булуында шикләнмәдем. Прожекторның нуры очында караңгылык дигәннең очтыгы да юк иде. Караңгылыктан чыккан якты, инде прожектор түгел, гүя ялган прожекторга әверелеп, үзенең «ата-анасын» юк иткән, ашаган иде. Караңгы кайда булды? Яктылык мине, әле генә бернәрсә «күрмичә дә күрә алган» кешене, тәмам сукырайтты: алда нәрсә – чокырмы, упкынмы, әллә танк люгы, пароход карынымы? Мин яктылык белән караңгылыкның икенче бөек сыйфатын аңладым: арттан яктырткан ут сукырайтмый, алдыңдагы чокырны, упкынны күреп була, ә менә алдан яктырткан ут сукырайта, син яктыга әсир төшеп, хәзер теге караңгыдагы чокырга килеп чумасың! Мондый халәтне «күз чагылу», диләр. Күз чагылу – куркыныч нәрсә. Арттан яктырткан ут исә шунысы белән хәвефле: үзеңнән алдыңдагыларның аркаларын күрергә мәҗбүрсең. Кемнәр алар? Шик туа. Үтерергә килмиләрме? Арттан яктырткан яктыдан адәмзатта шөбһә, курку уяна, һәм ул саклана, кирәк икән сугыш та ача. Шул шик-шөбһәдән, куркудан кылыч-мылтыкка ябышып, кешелек гасырлар буена күпме кан койды? Күпме Робеспьер, Ленин, Сталиннар – һәркайсы үзенә хас гадел, үзенә хас ялган нур

белән сукырайтып, күпме халыкларны кырдылар? Әүвәлдән арттан, аннан алдан, аннан «уңлык», аннан «суллык»та гаепләп, аннан югарыдан торып кыруны «сәяси чисталык» хакына тормышка ашырмадыкмы? Безне алга – рухи яктылыкка илтер өчен, алдыбызга чыккан яңа пәйгамбәрләр аркасын күрмәс, артларыннан бармас өчен, без аларның башына җитмәдекме?! Мөхәммәд галәйһиссәлам яктысыннан котылу хакына аңардан алда килгән пәйгамбәрләрдән пот ясап, Көнбатыш Мөхәммәд өммәтенә каршы унике тәре явы оештырмадымы? Урта гасырларда Африка-Азиянең кара халкыннан таланган алтын, фил сөяге, энҗеләр исәбенә инде безнең заман – XXI гасыр башында, көне-төне Европага агылган кара мигрантларның кипкән телләрендә җавап булып, бүген кире кайтмыймы ул яулар?

Прожектор яктыртуын дәвам итте. Һавада көз торса да, ут ташкынының көлтәсен яңгырлы күбәләкләр сырып алган, алар, энҗе тамчылар, ниндидер сәер ноктаи фотоннар белән буталышып, туктаусыз кайныйлар һәм юкка чыгалар иде. Бу тамаша үз хәлем хәл икәнлекне оныттырды. Шушы балчык диңгезе минем өчен гүя дөньяны танып белү чарасы – бәхетем чыганагы иде. Шушы ачышларны ясарга нишләп элегрәк кайтмаганмын икән Түгәрәк Имәнемә?! Моның өчен тома караңгы кирәк булдымы? Яңгырларны үз гомеремдә аз кичердемме мин? Ә мондый яңгырны кичергәнем булдымы элек? Юк! Мең кабат юк! Мине – гамьсез кешене – җир ничек күтәреп йөрткән икән? Бу кадәр наданлыкта ничек яши алганмын? Шулчак яктылыкка алданып, канатларын яндырган күбәләк-бөҗәкләрдән көлеп куйдым. Әлеге мизгелдә аңыма килеп, чыраем чалшайган булгандыр: кара урманда, берьялгызым, үземнән-үзем көлдем – бәй, мин, бәндә, адәмзат, үзем дә шушы күбәләкләр кебек яктыга алданып, утка керәм, канатларымны көйдереп юкка чыгам икән бит! Мине бу күбәләкләрдән бары якты белән караңгы арасындагы чаманы бар иткән акылым – баш мием аера һәм коткара икән бит!.. Чөнки мин, бәндәчел кеше, үтә дә хәйләкәр: онытмагыз, мин әле, нурдан тайшанып, кара күзлек киеп, күзләремне саклый да беләм! Шулай итеп, артык яктыдан, күз чагылудан азат булам. Яктылыктан аңа караңгылыкны сатып котыла алам икән. Әмма күбәләкләр, сукырлар кебек, яктыдан сакланып, кара күзлек кими. Чөнки алар яктылык белән имгәнми, яктылык эчендә булып, караңгылыкта яши, җаныныңң галибанә таңы, рухының бөек яктылыгында бәрәкәт таба...

Кинәт мин, янә дә абынып, чак кына ләм диңгезенә капланып төшмәдем. Капшап карадым: урман читендә торып калган ялгыз төпсә икән. Кешеләр арасында да шундый абындыра торган «туң төпсәләр» бар. Кулларым белән сыйпаштырып, өстенә утырдым. Каен булырга тиеш. Каен бугай. Капшап карыйм: калын, картайган тузы кайрысына ябышкан. Ак булса да, караңгыда аклыгы танылмый. Иелә бирәп, алга укталам: андагы караңгыда ниндидер сүрәнлек шәйләнә. Юк, яктылык түгел. Шәй. Шәй шәйләнә. Урманны өстән айкаган прожектор яктысы кинәт юкка чыкты. Сүндеме? Сеңдеме? Киребә борылдымы? Ачыкларга хәлемнән килмәде. Утырган уңайдан сулга укталдым. Кызык бит: караңгылык эчендәге караңгыда урман юклыгы, анда бары тик урылган басу икәнлеге зәгыйфь кенә чалымлана. Анда чәчүлек җир – басу булганын сабый чагымнан ук беләм бит!..

Килгән юлым дөрес. Кинәт якында, гүя миннән кул сузымында гына, йөрәкне ярып, чыйнап өргән тавыш ишетелде. Тынсыз калдым. Бүреләр мәллә? Юк, бүре болай өрмәс. Ул улар гына. Этме? Чигәмдә нәрсәдер чүкеч белән сугып тибә. Аякларым тез буынымнан өзелде. Өнем качты, башымдагы

кәпәчем бер күтәрелде, бер төште. Шул чакта гомеремдә беренче тапкыр тойдым: куркып, котың качканда, өреккәндә, кешенең лепкәсе, баш чүмеченнән аерылгандай, аслы-өсле йөри башлый икән.

Эт икән!.. Ул, туктаусыз абалап, минем тирәдә чабуларга тотынды. Кайсы урынымнан өзеп алыр икән дип, бер йодрык булып йомарландым.

– Кто там?

Эндәшергә итәм, тавышым чыкмый. Йотылган. Курку өчен караңгы кирәк. Яктының очтыгы булса да, болай ук курыкмаган булыр идем.

– Барсук, ко мне!..

Җанга җылы керде. Кеше. Ат менгән. Эт, мине калдырып, хуҗасына таба китте.

– Лошадей не замечал, добрый человек?

– Не-е-т... – дим мин, кайткан зәгыйфь тавышым белән. – Нет, д-д-добрый человек...

Хлеборобның малларын югалткан ат караучысы, борын астыннан нәрсәдер мыгырданып, минем кебек үк, караңгыда билгесез кеше белән мөгамәләгә кереп тормады, атының тоякларын үзле балчыкта шомбыртап, үз юлыннан китеп тә барды...

Кеше белән дөм караңгыда да, яктыдагы кебек, күрми-күрешмичә аңлашып, дөнья көтеп була икән. Күңелең изгедә булса. Моннан йөз ел чамасы элек Украинадан китертеп, бабаларыбыз нәселен сыеклату максатында туган җирләребезгә утыртылган һәм биредә дустанә тамырланып киткән кахуллар токымы белән үзара шулай матур яшәвебезгә куанып бетә алмадым. Ә менә уең явызлыкта булса, бер сүз дә кушмыйча, шәрран яра яктыда да дошманлашырга, хәтта дөнья белән хушлашырга да мөмкинсең.

Яңгыр тагын тынгандай итте. Моңа артык үкенмәдем дә, куанмадым да, гүя минем өчен яңгырның туктау-туктамавының инде бернинди мәгънәсе калмаган иде. Миңа караңгылыкның хет кечтеки булса да эчтән күзәнәкләнеп яктыруы, дөньяның аз гына күренә башлавы зарур иде. Шырпым да, электрик утым да булмау сәбәпле, кулымдагы сәгатьтән вакытны да белә алмыйм, ичмасам!.. Юлга чыкканыма ике сәгать чамасыдыр. Кара исәп белән кичке уннар булырга тиеш. Ару-талчыгуымның чигенә җитеп, бишек сиртмәсе кебек бөгелә-сыгыла, баткак диңгезен издем. Хәзер инде «чаманы чамалап» хәрәкәт итәргә кирәк. Агяһ (уяу – *ред*.) бул, дим мин үземә, караңгыда, кызулык белән Хлебороб юлын узып китеп, дөрес юнәлештән чыга күрмә – синең юлың «Кысык»тан соң икенче юл белән кушыла да кискен уңга борыла!.. Аяк табаннарыңа яңа көч-куәт, сизем җибәр!.. Их бу якты җитешмәүләр! Их бу караңгыда бәргәләнүләр! Ходай Тәгаләм, нишләп син миңа, тугры колыңа, бераз гына булса да эңгер яктылыгы җибәрмисең?! Нинди гөнаһларым өчен син мине эңгерләрнең сабыр яктысыннан да мәхрүм итәсең?

Һәм миндә, соңлаган юлчыда, янә дә фикер иясе уяна: кешелекнең күпчелеге өчен иң таман, иң идеаль якты – ул шәхсән яктылык үзе дә, аның капма-каршысы – караңгылык та түгел, ә уртакул булып әлҗе-мөлҗе килгән ярым-якты эңгер икән! Кешелек ашар ашын, язар сүзен нәкъ шушы эңгердә эзләп таба, чөнки ул үзе дә шул эңгер-меңгердә яши. Әмма барлык кешелек түгел, әйткәнемчә, күпчелек. Болардан тыш, караңгылыкта да күрә ала торган сирәкләрдән-сирәк затлар бар. Алар яктыда күргәнне караңгыда да күрәләр. Андыйлар кешелек эңгерендә башкалар күрмәгән идеалны казып чыгаралар.

Яктылыктан башка тормыш мөмкин түгел, ансыз – дөнья сансыз. Хак сүзләр!

Әлбәттә! Әмма аңа табынмаска, аны тулысынча үзеңә хезмәткә куярга кирәк! Хлеборобтан килгән «Кысык» урманы борылышында миңа караңгылык белән яктылык кушылган чикне таба алмыйча, газапланып, түбән ганимәт, ясалма, русча әйткәндә, «серость» тудырган соргылт байлыклар турында уйланырга туры килде. Алар җәмгыятьне бертөрлелеккә, сәләтсезлеккә, хаксызлыкка батыра торган иң куркыныч көчләр икән. Бәгырьсезлек белән туңйөрәклелек шунда яратыла икән. Соргылт төс яктылыктан да, караңгылыктан да бердәй курка. Аларның икесен дә алыштырырга тырышып, киләчәкне тоткарлап тора. Ул икесенең дә җиңүеннән өркә...

Юк, караңгылык кимемәде дә, сүлпәнәймәде дә. Каршыма ярсу җил исүен тойдым. Бу шатлыклы фал иде. Табаннарым белән җирне капшадым. Туган туфрак, кулга караганда, күбрәк аяк табаннары аша сиземләнә, таныла һәм табыла. Мин җирнең сиздермичә генә уйсудан бераз текәгә тарта баруын, кулларымның җил-яңгырда җилсенгән сырты белән урманның тын алуын, колакларымның йомшагы белән авазлар тирбәлешен тойдым. Уң тарафта, ниһаять, «Кысык»тан ургып чыккан урман юлы иде! Бу юллардан кышын, җәен, язын, көзен өч ел буе җәяү йөреп, Кыргыз урта мәктәбендә мәгърифәт эстәгән идем. Шулчак тагын яңгыр коя башлады. Күкнең төбе тишелгән иде, билләһи!.. Кискен вә гайрәт белән туксан градус сулга тарттым. Мин йөз процентлы караңгыда йөз процентлы кара нокта булып авылыма юл сапкан идем! Алга, инде «Комлык» үренә!

– Әссәламегаләйкем, якташлар! – дип ыңгыраштым, шатлыгымны кая куярга белмичә. – Әссәламегаләйкем, кан-кардәшләрем!

III

Кинәт колакларыма «Ah!» дигән нечкә хатын-кыз авазы ишетелгәндәй итте. Кем тавышы булыр? Бер генәме? Кемнәрнеке, диген!.. Бу бит заманында тузан да төшермәгән олы юл иде. Авылыбызны Әкчин тимер юл станцасы, район үзәге белән тоташтырган борынгы «Кыргыз» юлы, кая басма, әнә шул үзәк өзгеч «ah»лар белән түшәлгән. Сугышларның гаделенә дә, гаделсезенә дә якташларым биредән киткәннәр. Андый сугышларның һәркайсында да халык кырылган. Һәлак булу хакына җиңү «гадел» сугыш буламы? Исәннәре шушыннан әйләнеп тә кайтканнар. ГПУлар да шушы юлдан алып киткән «сыйнфый дошманнарны». Атлар кешнәгән. Ләкин халык сугыш һәм ГПУ мәнфәгатьләре белән генә чикләнеп калмаган. Ул яшәгән: туйлар ясап, кызлар биреп, килен төшергән, биредә, әнә теге караңгыда йөзгән каен төпләрендә, кода-кодагыйларны ачы бал белән сыйлап, биегән-җырлаган.

Авазның хуҗасы Гөлзәйнәп зуринәм кебек тоелды. Безнең яклар теле белән әйткәндә, Гөлдәйнәп дүринәй. «Зур инәй», ягъни әтиемнең бертуган агасының хатыны. «Ah» дигән аваз аныкы, бары тик аныкы гына булырга тиеш. Мин аны эчемнән «Көмеш дүринәй» дип атый идем. Тумышы белән Башкорт Аетының Сабиржан хәзрәт гаиләсеннән иде ул. Башкорт булса да, мин аның башкортча сөйләшкәнен хәтерләмим. Атасы кайчандыр гражданнар сугышында Зәки Вәлиди армиясендә полк мулласы булып хезмәт иткән. Ул моның белән горурлана иде. Мулла даирәсендә тәрбия алып, татлы телле, башка хатыннар балаларын бары тик тупас сүз, каты мөгамәлә, талчыбык белән өшкергәндә, үзенекеләрне мактап кына сөйләгән «дүринәмнән» гел көмеш кенә коелып тора иде. Шушы юлдан алып киткәннәр аны Бәләбәй төрмәсенә. 1944-1947 елларда өч ел утырып кайткан ике пот бодай өчен. Тоткыннар

арасында фронт өчен баш бармаклы бияләйләр тегүдә беренче урынга чыга мулла кызы! Планнан тыш тегелгән башбармаклар аңа көненә йөз грамм ипи китергән. Шул ук башбармак хакына аны бер айга алдан азат та итәләр. Нәкъ менә шушы урында, «Кысык» авызында, милиция сагы астында авылдан алып чыккач, артларыннан тотам да калмыйча, «Инәйне кайтарыгыз!» дип елап йөгергән өлкән улы Әмин белән соңгы тапкыр «Ah!» дип хушлаша ул. Дөресен әйткәндә, өтермәгә Әмин улы утырырга тиеш була. Әмма бер ел чамасы элек ире Әхмәтвәли дүрәтәй сугышта һәлак булгач, иң өлкән уллары Әзһәм дә – фронтта, калган балаларыннан Әмингә ундүрт, Раузага унбер, Зөфәргә җиде, Хәләфкә ике генә яшь бит әле, хөкем органнары гаиләдән утыртырлык кеше калмаганга, әниләре – Гөлдәйнәп дүринәйдә туктыйлар. Һәм атасыз да калган балаларны утыртудан «кызганып», инәләрен алып киттеләр. Безнең закуннар «кешелексез» дип кем әйтә алыр? Аяк астымдагы җир «Ah!» итеп куйды. Бу дүринәй сыкрануы иде. Җирнең биле сынар чиккә җитеп сыгылды. Бу дүринәй сыгылуы иде. Әминнең инәсенә сүз тишмичә, гыйнвар суыгында бәләкәй чана тартып, туң җиргә чалкан ятып, колхоз келәтенең идәнен бораулап, капчыгына ике пот чамасы иген агызып алуына да шул кahәр суккан ачлык һәм атасыз-атсыз калу сәбәпче иде бит инде. Аны, чанасын Өязенең яшь бозы өстеннән өстерәп, үз капкасына керәм дигәндә генә, төнге уникедә идарәдән кайтып килгән колхоз рәисе эләктереп ала. Җир-Ана тагын «Ah!» итте.

Әмин абзыйның миңа үзенең сөйләгәне хәтердә: бишенче сыйныф укучысы, ул, атасының үлем хәбәрен почтальон биреп киткән похоронкадан мин менә хәзер юнәлеш тоткан Түгәрәк Имән басуында, урак урган чакта белә. Бу кадәр авыр хәбәрне инәсенә ничек җиткерергә дип аптырап елый башлый. Имәнгә асылган бишегендә йокыдан уянган энесе Хәләф тә кычкырып еларга тотына...

Чиләкләп койган яңгыр янә дә тына төште. Аяк асларымда ком катысы тоеп, сыек баткактан чыга, «Комлык үре»нә күтәрелә баруымны абайладым. Ат җигеп, мин моннан канатлы арбаларымда текердәп кенә үтә идем, биллəhи!.. Инде Түгәрәк Имәнгә күп дигәндә ярты чакрым ара калгандыр. «Яраткан саен максат, идеал ерагая, Түгәрәк Имән генә ерагаймаса ярар иде, – дип уйлап алдым. – Тирә-як караңгы булса да, шөкер, түккән тирем якты». Шулай дип уйлап өлгермәдем, «Караңгы ничек шулкадәр тома караңгы була ала ул?» – дигән ачулы уй килде башыма. Күземә ак-кара күренмәгән килеш туган ояма кайтып җитеп килсәм дә, чур, нәрсә бу: шатлыктан башка монда берәр үкенеч тә юкмы? Нишләп һаваны биләп алган, үзем ачкан җиде кат караңгының бер генә каты булса да миңа ачылмаска тиеш?! Бу табигать кануннарын инкарь итү түгелме? Мин аяк табаннарымдагы яшерен ватерпасларым белән рельефны танысам, «укый» алсам да, күземдәге җиде кат яктының берсе белән булса да Түгәрәк Имәнемне чамаларга тиешмен!.. Тагын да шул чама. Нишләмәк кирәк, тормыш үзе – чама. Дүрт-биш сәгать буе капшанып килеп, Җир шарының шушы бер тар даирәсеннән генә чыгып караганда да, кимендә өч йөз яшьтә булып, кешелеккә маяк сыйфатында хезмәт иткән һәм үзем дә шуның ябалдашы астында үскән Түгәрәк Имәнне эзләп табу – минем өчен хәзер бәрәңге ашау кебек гади нәрсә һәм, шул ук вакытта, килеп туган шартлардан чыгып, эскерттә энә табуга тиң катлаулы бурыч иде!

«Кыргыз юлы» басуының авылдан күтәрелгәндә өченче, соңгы үрендә бар дөньяга яктырып торган Түгәрәк Имәнемне тапмыйча, аның белән күрешмичә ярамый! Аңа кайту – авылыңа кайту. Аннан ерагаю – авылыңнан

ерагаю. Имәннең һәр нәрсәгә үз исәбе бар. Өтермәгә китеп барган Гөлдәйнәп дүринәйне сакчылар, ул инәлеп үтенсә дә, имән янында туктатып, шушыннан озатып калган иренең рухына дога кылдырып маташмаганнар. Шул ук Әмин абзый раславынча, дүринәй Түгәрәк Имән каршыннан үткәндә, эчтән генә укынып, егерме тиенлек көмешен ыргыта:

– Күрешергә насыйп ит, Түгәрәк Имән!.. Балаларымны сакла!.. Телсез итмә!..

Насыйп итте Түгәрәк Имән. Барча халык тәрбияләде дүрт ятимне. Дүринәйнең үзенә дә исән-сау кайтып, балаларын аякка бастырырга насыйп итте. Шулчак мин инде бу караңгыда ничә сәгатьләр тома сукыр хәлдә килеп, беренче тапкыр караңгылыкның кап-кара карынныннан, кайдадыр бик тирәннән карадан да кара сәер шәүләне абайлагандай булдым. Гүя бер караңгы үзеннән икенче бер караңгыны бүлеп чыгара иде. Мөмкинме бу? Күзләремә яшь тыгылды! Юк, бу һава яктыра төшкән икән дә, күрә башлаганмын икән, дигән сүз түгел иде әле. Ышанасызмы, артта, меңләгән яфраклары, кытай иероглифларын хәтерләткән ботаклары белән һаваны ботарлап утырган ниндидер зур кара йодрык тоемлана иде... Мондый күрешү дүринәмнең Түгәрәк Имән төбенә ыргыткан көмеш тиененнән миңа әйләнеп кайткан садакасы иде кебек!..

Кискен сулга борылып, шәүләгә таба юнәлдем. Аяк асларымда игене җыештырылып алынган камыл. Миңа җылы, бу сәяхәттә беренче тапкыр шулай рәхәт иде. Куанычымнан барлык Җир Шарын өстерәгәндәй мышнап, үзенә чакырган кара иероглифларга киләм... киләм... киләм һәм имәнем ябалдашының иң астагы ботакларына килеп төртеләм...

Башымны иеп, кәүсәне кочам, аның таш кебек йомшак кайрысын кат-кат капшыйм, ләззәтләнеп, кулларым белән сыйпыйм... Һәм шатлыгымнан, күңел ярсуымнан, караңгылыктан чыккан караңгылык яктысыннан сихәт алып, үксим:

– Исәнме, Түгәрәк Имәнем! Мин, ниһаять, синең канатларың астында! Мин, ниһаять, өйдә!..

– Әйе, син өйдә, – дип пышылдый имән шыбырдап яуган яңгыр астында. – Инде сиңа авылыбызга төшәсе генә калды...

Бу инде Ватан үзе иде.

Мин аны караңгы төн карасында табаннарым сиземе белән эзләп таптым.

Кайтып җитү шатлыгыннан яңа дәрман алып, инде аяк астымдагы бәлаләрдән шикләнми-курыкмый батырая төшеп, беренче үрдән сыдыра-атлый түбәнгә өстерәләм. Галәм корабын кирәкле биеклеккә чыгарганда, ракетасының беренче баскычын ыргытып калдырган космонавт үзен шулай бәхетле тойгандыр, дип уйлыйм мин. Үземне адәмзат итеп тоя башлаганнан соң, унҗиде яшькә кадәр шушы туфракта иген иккән, шушы болыннарда печән чапкан, шушы урманнарда бүрәнәләр аударган үсмер буларак, мин, адашу дигән нәрсәне күз алдыма да китермичә, икенче үрне дә төшеп җитәм. Яңгыр туктый. Чокырдагы авылдан ут әсәрәсе дә күренми. Нишләп? Электрлары кая? Мин мондый газаптан соң, төн уртасында бертуган абзамны борчырга теләмичә, авыл очындагы беренче йортта яшәгән туганымнан туган Риф абзыйларда кунарга һәм туган нигеземә иртән генә кайтырга карар итәм. Камыллы басудан чирәмгә күчкән уңайдан, иркенгә чыккан туп кебек инде соңгы, өченче үрдән дә аска таба тәгәрим һәм каршымда челтерәп яткан Кырлыган инешенә килеп керәм. Үземнеке!.. Барысы да үземнеке!.. Ah, рәхәтлекләр! Сәгатьләр буена

яуган яңгырда салкыная төшсә дә, су ничектер иркә, сагынычлы, җылымса иде. Агымсу, оекларым аша үтеп, арыган аякларыма, каты кантарларга бәргәләнә-сыргалана, шактый авырта башлаган табаннарымны сылый, дәвалый, массаж ясый иде...

Менә, ниһаять, Риф абзыйның ишеген шакыйм.

– Ыхту тамы?

Бу инде теге Хлебороб кахулы түгел, Рафига түти. Дарига җиңгинең әнисе. Сиксән дүрт яшьлек әбекәй. Гөлдәйнәп дүринәйнең ахирәте, сугыш ятимәсе.

– Рифләр кая? – дим мин, кем икәнлегемне әйтеп тә тормыйча. Ул колакка катырак, миннән сорашып та азапланмый.

– Нету, – ди шикләнеп караңгы төндә, урысча гына. – Раевка пошёл. Газплитә алырга...

Раевка. Авылдан җитмеш-сиксән чакрымда бар шундый станца. Тукта, нинди газплитә тагын? Сорашып өлгерә алмыйм, карчык шакылдатып келәсен төшерә.

Болай булгач, өйгә кайтмый булмый. Күрәсең, юлны башлагач, язмыш аның азагын да күрсәтергә җыена. Капкадан чыгу белән, урамга борылам дигәндә, ниндидер көтелмәгән тирән чокырга килеп төшәм. Тукта, нинди чокыр?! Монда бернинди дә чокыр-чакыр юк иде бит элек!.. Туры килсә, килә бит!.. Кулларым белән балчык өемнәрендә капшанып, аннан шуышып чыгам. Алга юл да, атларлык форсат та табалмыйм: уңда, сулда, алда, артта – һәркайда балчык өемнәре. Таеп китеп, кире чокырга төшәм. Чокыр авыл буйлап сузылып алга таба барган кебек. Тукта, бу бернинди чокыр түгел, траншея түгелме? Миңа, инде хәзер бер дөм караңгыдан икенче дөм караңгыга төшергән чокыр-траншея буйлап барудан башка чара юк. Шулчак алдагы ихаталардан чыра-шәм уты кебек зәгыйфь якты күренгәләштерә. Бу көчсез, соргылт якты, өмет өстәп, мине сукырайтты да кебек. Җан ачуы белән алга ыргылдым һәм чокырда печән күбәсе кебек таза бәдәнле берәү белән маңгайга-маңгай чәкештем. Күзләрдән утлар күренде. Бик әшәке сүгенү яңгырады. Мыгырдануына караганда, ул чокырга тәгәрәп төшкән исерек һәм шактый каты исерек иде. Аһәңеннән, караеп бөтәшкән төндә, җитмәсә чокырда, бу кешенең авылныкымы-түгелме икәнлеген чамаларга мөмкин түгел иде. Артыма ут капкандай, сикереп чыктым. Алла сакласын! Хәзер, кем кемне белгән?! Әмма ул монда минем өчен кечкенә булса да хәбәр алырлык бердәнбер адәмзат иде!..

– Нәрсә бу? – дип кычкырдым мин, онытылып. – Бу ниткән чокыр?!

– Авылга газ керт-тәб-без, әм-мит-ке. Газ-офицаровать ит-тәбез! – дип мыгырданды ир кеше кыршылган тимер тавышы белән. Ул чокыр эченнән кулын сузды, аннан сасы аракы исе бөркелде. – А-а-бзый!.. Т-тартып ч-чыгар!..

Чыгардым. Газ кертүченең гәүдәсе «тонна ярым» иде. Мин аңардан тизрәк котылырга тырыштым. Бәйләнә күрмәсен. Шулай да:

– Электрыгыз кая? – дип сорарга булдым.

– Газ к-керткәнче... м-мишайт итмәсен, дип, э-электрны к-кисеп ыргыттык, – диде ул, горурланып... Абзый, с-салырга юкмы?

– Юк.

«Сукыр булса да, кыз яхшы, урау булса да, юл яхшы», дигәннәре хак икән. Мин, урам буйлап кайтырга мөмкин булмагач, ике дә уйламастан, кире үз чокырыма төшәм. Кинәт баш миләрем яктырып китә:

Газ! Авылга, ниһаять, газ кертәләр икән бит!

Җир катламнарында – гасырлар буена, кем әйтмешли, үземнең астымда

Аллаһ тарафыннан миңа атап кына яратылган зәңгәр дәһшәт бүген үзебезгә кайта!..

Риф кардәшем хатыны белән бергә менә нинди «плитә» алырга Раевкага киткән! Һәм мин туган якларда нефть – җир мае чыкканнан соң, илле-алтмыш ел узганнан соң, моңа кадәр һаман чыра-утында яшәгән авылыма, ниһаять, шул җир маеның яктысы киләчәгенә, аның авылдашларымны җылытачагына куанып бетә алмыйча елмаям һәм үземне шушы көзге яңгырларда, караңгыда калып, газ үткәрүдә катнашкан бер инсан итеп тоеп, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләр укыйм. Әгәр мин бүген кичләтеп, Әнәч борылышыннан авылга кайтырга чыкмаган булсам, бу шатлыкны кичерә алыр идемме?!

Газ керткән көннәрдә авыл халкын, гадәттәгечә, икенче өзеклеккә кертеп, электрдан мәхрүм итеп торганнар, күрәсең. Миңа хәзер җир йөзендә авылымның шәмдәл утларыннан яктырак утлар юк. Траншеядан казып чыгарылган туфрак өемнәре буйлап пластунча шуышканчы, миңа туры чокыр буйлап юл кыскарту җиңелрәк иде...

Мин караңгыдан яктыга таба барам. Әйе, авылымның ошбу тычкан утлары, яландагы прожектордан да көчлерәк булып, мине туган йортыма алып кайттылар.

– Мунча суынмагандыр әле, – диде Миннур җиңги, тупсадан үткәч тә. – Кереп чыкмыйсыңмы?

– Керми диме?!

– Җир сөреп килдең мәллә? – Ак түшәктән ак күлмәге изүеннән томырылып чыккан абзам, онытылып, мине танымый торды. – Син... Донбасс шахтасыннан түгелдер бит?

– Әйе, – дидем. – Сезләрне газ белән җылытыр өчен, Донбасслардан җир чокып кайттым...

Мин караңгыдан яктыга таба бардым. Әйе, авылымның ошбу тычкан утлары, яландагы прожектордан да көчлерәк булып, мине туган йортыма алып кайттылар. Әйе, теге җырда җырланганча, «караңгы дип килми калмадым». Ай юк дип тә, йолдыз юк дип тә тормадым. Шулай да, мондый да дөм караңгыда нәрсә алып кайтты икән мине илемә? Кем әйтә ала? Бу ниткән табышмак?

Элек авылда ак мунча юк диярлек, барысы да кара иде. Хәзер барысы ак, каралары юк. Минем абзамның мунчасы – кара. Шуңа күрә, үзе кебек, мунчасы да сирәк. Мунчаны керә башлаганда, сәгать төнге бер иде. Мин аннан, кара штурманга әверелгән мосафирдан, бодай бөртеге кебек яктырып чыктым. «Минем әсәрләрем дә кешеләрне караңгыдан яктылыкка алып барса иде, – дип уйладым шунда. – Алар бу нигъмәтләрнең никадәр кадерле булуын тизрәк аңларлар иде».

Караңгылыктагы яктылык, газ ялкынындагы утын, инде тарихка әйләнгән кара мунча белән менә шулай күрешеп хушлаштым.

Булат
Ибраһим

ТАТАР БУЛЫП ГОМЕР ИТҮ КИРӘК...

Кыш бабайга хат

Син язасың аңа...
Син көтәсең,
Өмет дигәннәре яндыра!
Ә бер көнне,
Хат ташучы апа,
Килеп сиңа, бер хат тоттыра.
Яңа елга ерак әле ара...
Хатка мөһер суккан
«Кайтарырга кире!»
Каһәр суккан иле...
Кыш бабайга дигән хат кайткан...
Ә мин аңа айлар буе яздым,
Кыска булды, диеп, озынайттым,
Озын булды, диеп, кыскарттым,
Кыш бабайга дигән хат... кайтты.
Әллә берәр хата киткән микән,
Берәр хәреф төшеп калганмы?
«Әллә ниләр яза, юләр», – диеп,
Укымаска диеп тапканмы?
Ә югыйсә, елдагыча яздым,
Имин көннәр, бәхет сорадым,
Илләр тыныч булсын,
Кешеләрдә
Кешелеклек хисе сулмасын.
Ә югыйсә елдагыча яздым...
Елдагыча, туган телемдә!
Нигә диеп хатым кире кайткан?
Нигә кайткан хатым, белмим дә.
Ә югыйсә елдагыча яздым:
Котыпка, дип, Кыш бабайга, диеп...

Булат ИБРАһИМ (1990) – *шагыйрь; «Йолдызлы билет» халыкара әдәби премия лауреаты. «Балык теле», «Шагыйрь – Поэт», «Безнең эзләр – Наши следы» китаплары авторы. Казанда яши.*

Ә асылда,
Минем язган хатым
Барып җитмәгән дә бабайга.
Хатлар җибәрүче аңламаган:
«Нинди Кышка икән алай да?
Нинди Котып?
Ни яза бу тиле,
Нинди телдә бу?» – дип,
Хатка мөһер суккан:
«Кайтарырга кире!»

Ә югыйсә елдагыча яздым...

Татар булып

Яулар купса, атлар кирәк булган,
Җайдакларын көткән яу атлары.
Һәрбер заман үзе тарих яза,
Һәрбер чорның үзенең татарлары.
Безнең тарих тирән,
Тамырларын эзләп табыйм, дисәң,
Җире каты.
Кайчакларда бер арбада кайта
Батыр даны белән яманаты.

Шанлы тарих, чәнечкеле гөлдәй,
Чәнчеп ала үтеп йөрәкләргә.
Татар дигән кызу канлык гүя
Тумыштан ук безнең күкрәкләрдә.
Тумыштан ук тынгысызлык бездә,
Тумыштан ук бездә ярсу йөрәк.
Мөһим түгел нинди чорда туу,
Татар булып гомер итү кирәк!

***

Тинчурин бакчасында узачак Хәтер көненә чакыру килде. Хатның ахырында Казан шәһәр хакимиятеннән рөхсәт бар, дип тә өстәгәннәр. Ниһаять, безгә дә хәтерләргә рөхсәт иткәннәр, дип елмаеп куйдым.

Хәтерсезлек чире бар гавамны
Агулатып яткан бер чорда,
Рөхсәт сорый-сорый түрәләрдән,
Төшеп барыш төпсез чокырга.

Хәтерләргә рөхсәт итәсезме?
Хәтер күндәм безнең, әйтсәң, күнә.
Ханбикәсен саткан милләт бит без,
Татар барда, хәтәр булмас, димә.

Хәтерләргә рөхсәт бирәсезме?
Нинди тарих яза яңа заман?
Бу җирләргә патшалар килгәнче,
Каһан булган, –
Хан юртасы торган...

Хәтерләргә рөхсәт бирәсезме,
Үткәннәрдә калган шанлы чакны?
Тузан кунган тарих күмелерме
Заман аны җирдән юачакмы?..

Хәтерсезлек чире бар гавамны
Агулатып яткан бер чорда,
Рөхсәт сорый-сорый түрәләрдән,
Ярларыннан тарих убыла,
Җирдән безнең тарих юыла.

Беләсеңме, Тукай...

Бүген менә
Синең һәйкәлеңә
Чәчәк өябез без,
Чәчәк!

Беләсеңме, Тукай,
Безнең милләт –
Өчпочмак та чәкчәк
Һәм түбәтәй бугай кайчак.

Дөньяларга тарих язган халык
Телен тешләп тора бер чатта.
Үзебез үк кискән утын белән
Милләт яна утсыз учакта.

Заманында яулар чапкан халык
Сабантуйлы калды нибары.
Атсыз милләт кемгә кирәк булсын,
Атсыз халык бик тиз югалыр.

Без үзебез салган мәчетләрдә
Ятим булып калып барабыз.
…Һәр ел саен сиңа киләбез без,
Ерагая гына арабыз.

Бүген менә синең һәйкәләңә
Чәчәк өябез без,
Чәчәк!
Беләсеңме, Тукай,
Бар да үтә.
Бар да үтә,
Һәм бу...
Үтәчәк.

***

Йа Раббым,
Бу ничәнче гасыр?
Бу ничәнче буын алышына?
Әле кичә генә туган сабый
Тормыш дигән олуг ярышына
Мүкәләргә әзер.
Әле кичә генә туган сабый
Сафлык дигән самимилек белән,
«Әннә», диеп телен ачкан иде,
Күзен ачып дөнья ачкан иде.

Бу ничәнче буын алышына?
Заман тавышына,
Бу ничәнче буын,
Азан агышына кулын селтәп
Кайный бирә үзенең сагышында?

Әле кичә генә туган сабый,
Төнге айны азгын икән, диеп,
Йолдызларны монафыйк, дип үртәп,
Күктән эзли гаеп.

Йа Раббым,
Син Җир шарын зур намазлык иттең.

Әле кичә генә туган сабый
Синнән ярдәм сорый, сәҗдә төшә,
Тик кыйбласы берәү түгел аның,
Әллә ничә...

Йа Раббым,
Бу ничәнче гасыр?
Бу ничәнче буын алышына?..

***

Бу заман шулкадәр тизләнде,
Үзгәрде яшәүнең мәгънәсе.
Әйдәле, шушында тукталыйк,
Тукталыйк һәм бераз көч алыйк.

Каядыр ашыгу, ашкыну,
Нигә соң? Кайда соң? Белгән юк,
Күрәсең, без инде күптәннән,
Ихластан шатланып көлгән юк.

Югыйсә, дөньясы бер көлке,
Көлеп ят мәгънәсез сүзләрдән.
Күрешәбез кебек тә үзебез,
Сөйләшкән генә юк күптәннән.

Югыйсә, сөйләшер әйберләр
Бихисап бу салкын шәһәрдә.

Тик нигә?
Нигә соң әле дә:
«Иртәгә, әйдәле, иртәгә...»

Әйдәле, барысын ташлыйк та
Сикерик туктамас арбадан.
Нилеккә бу синең шөһрәтең?
Нилеккә сиңа бу ялган дан?

Нигә бу якалы күлмәкләр,
Нигә бу ялтыравык савытлар?
Шул арба көпчәге астында
Тузанга күмелеп җан бирә
Кабатлап булмаслык вакытлар.

Утырып сөйләшик әле бер,
Утырып сөйләшик...

Сугыш бетте, бабай...

Кемдер яу кырында калды, берәүләр җиңү бәхетен татыды, кайберәүләр төрмәләрдә әсир булды, кемнәрдер бүген дә исән. Бу шигырем бабайлар рухына дога булып барсын иде.

Нинди төшләр күрәсең син, бабай,
Күзләреңә йокы керәме?
Офык һаман кызгылт төсе белән
Сугыш исен күккә түгәме?

Нинди төшләр керә сиңа, бабай,
Тынмас туплар һаман шартлыймы?
Бер кайтырбыз, дигән иптәшләрең
Әле һаман кире кайтмыймы?

Өн белән төш күперләре буйлап –
«Сугыш бетте» дигән кайтаваз...

Һаман әсирлектәме син, бабай,
Кайда йөри килми калган яз?

Нинди төшләр керә сиңа, бабай,
Нинди төстә җиңү бәхете,
Җилфердиме канлы кызыл байрак,
Шанлы үткәннәрнең шаһиты?

Уян, бабай, чәй кайнады, әйдә,
Ниләр күрдең, төшләр кайда йөртте?
Сугыш бетте, илбасарлар бетте,
Сез җиңдегез!..
Сугыш бетте, бабай,
Бетте...

БУЛАТ ИБРАҺИМ ШИГЫРЬЛӘРЕ

Бүгенге татар поэзиясендә XX йөз башы милли шигърияте белән аваздашлык, интертекстуаль бәйләнешләр, һәр шагыйрь иҗатында диярлек, мотивларда, образларда, алымнарда – күзгә ташланып тора. Әмма бу яссылыктан караганда, яшь шагыйрь Булат Ибраһим иҗаты аерымрак урында. «Балык теле» (2014) дип аталган беренче җыентыгы, бигрәк тә, модернизмның бер юнәлеше булган сюрреализм традицияләрен үстереп язылган текстлары белән гажәпләндерде. Аның иҗатында сюрреализм – идеяләр белдерү өчен хезмәт итә торган иҗат алымы булып, тормышка, вакыйгаларга, әйберләргә, кичерешләргә гадәти булмаган караш ташлау төсен ала. Модернизм эстетикасына хас «озын» яки гадәти шигырьләрдән, җыентыктагы «Балык теле», «Тукай килә», «Йөрәк», «Казан алынган», «Бишенче фасыл», «Туган тел», һ.б. сюр-сурәтнең классик картинасын үзгәртү юлы белән язылган.

Әмма сүзебез алар турында түгел. *(Әлеге җыентыктагы шигырьләргә анализ белән Д.Ф.Заһидуллинаның «Татарская поэзия рубежа XX-XXI вв.» (2017) китабын укып (169-178 бб.) танышырга мөмкин.)* Бу очракта без журналга тәкъдим ителгән текстлар турында сүз алып барырбыз.

Шигырьләр «Татар булып гомер итү кирәк...» дигән мәгънәле баш астына туплап бирелгән. Бу исем аларны бүгенге татар җәмгыятен борчыган төрледән-төрле мәсьәләләргә багышланган итеп аңларга юл күрсәтә. Хәтта беренче карашка татар тормышы белән бәйле булмаган «Кыш бабайга хат» шигыре дә контекстта милли эчтәлек ала. Шуннан башлыйк.

Озын шигырь, элегрәк иҗат ителгән «Балык теле» кебек үк, тулысынча сюрреализм агымында. Өметләр һәм аларның өзелүе турында. Шагыйрь эчтәлекне сюр-формага төрә: Кыш бабайга хат язу һәм аның, адресатка тапшырылмыйча, кире кайтуы рәвешендә формалаштыра. Әмма хат – нәни баланың бүләк соравы түгел. Ул һәр олы кешенең күңелендәге теләкләрне *(«Имин көннәр, бәхет сорадым, / Илләр тыныч булсын, / Кешеләрдә / Кешелеклек хисе сулмасын»)* кабатлый, аларның тормышка ашмавы – хатның кире кайтуы иң олы борчу, чарасызлыкка әйләнә. Сиздерми генә шагыйрь укучыга моның сәбәбен күрсәтә: *«Хатка мөһер суккан / «Кайтарырга кире!» / **Каһәр суккан иле...**»*. Лирик геройның, шушы белдерүдән соң, сәбәп эзләве, «Ә югыйсә, елдагыча яздым» тезмәсенең кабатлануы аны – бәхетсез илдә яшәүче беркатлы кеше буларак күз алдына китереп бастыра. Шигырь ахырындагы «Елдагыча, туган телемдә!» һәм «Нинди телдә бу?» дигән ике үзара бәйләнештәге тезмәләр бу илдә лирик геройның туган телен аңламыйлар дигән яңа эчтәлеккә алып чыга.

Шулай итеп, шигырь эчтәлеге ягыннан кызыклы, сәяси-гражданлык лирикасы әсәре булып чыккан. Сюр-форма аның эмоциональлеген, тәэсир көчен арттыра, кабатлаулар моны тагын да ассызыклый.

Эчтәлеген хуплаган хәлдә, форма турында берничә сүз. Сюр-форма, абстракт яки абсурд форма булсын – барыбер эчке гармония сакланырга тиеш. Шигырь 10/9 үлчәмен уйнатып, ирекле рәвешкә китереп язылган. Әйтик, беренче зур строфа болай урнаша: 6+4(10)/9,4+6(10)/9/9, аннары 6/6/6/9. Сәнгать законнары буенча, аннан соңгы икенче зур строфа шуны кабатларга тиеш. Әмма Б.Ибраһим бу тәртипне боза: 10/10/9/9; аннары 10/9/10/9; 10/9/10/9; 10/9/10/9; 10/10/10/9; 10/9/10/6; 6/6/10.

10/9 чикләреннән чыкмаганга, дисгармония артык күзгә ташланмаса да, вәзен тәртипле булмау үзен сиздерә. Бу очракта, беренче зур строфа тәртибен кабатлап бару шигырьнең формасын камиллеккә китерер иде. Гомумән алганда, мондый күзәтүне циклдагы күпчелек текстларга карата кабатларга мөмкин. Шунысын да әйтергә кирәк: беренче шигырь җыентыгы белән чагыштырганда, бу бәйләмдә эчке аһәңне саклау омтылышы көчлерәк.

«Татар булып» – традицион классик шигырь, гражданлык лирикасы үрнәге. Текстта *«Безнең тарих тирән, / Тамырларын эзләп табыйм дисәң, / **Җире каты**»* кебек үзенчәлекле, фәлсәфи тирән образлар бар. Ул Б.Ибраһимның классик романтик шигырьләрне дә үзенчә иҗат итә алу сәләте турында сөйли.

Исемсез, «хәтер» сүзен уйнатып язылган шигырь турында да шуны ук кабатларга мөмкин.

Модернизм юнәлешендә иҗат ителгән киләсе шигырь – «Беләсеңме, Тукай...» Тукай туган көнне язылган булып аңлашыла. Сюр-поэтикасы алымнарда, беренче карашка уңай күренеш булган, бөек шагыйребезне искә алуны милләтнең фаҗигасе дәрәҗәсенә күтәрә. Ахыр чиктә, һәйкәл булып баскан шагыйрь белән сөйләшү – милләт яшәешендәге барлык горурланырлык күренешләрнең үткәндә, тарихта калганын искәртә. Аның урынына – символлар гына торып калды дигән сызлануга алып килә. Асылда, шигырь сызлану (экзистенциализм) фәлсәфәсе кысаларында язылган, әмма аның тулысынча риторик эндәш формасында корылуы һәм образлылык – сюр-поэтикасы чикләрендә.

Үзенчәлекле образлар, берсен-берсе көчәйтеп, милләт дигән зур образ булып җыйнала торган тулы бер галерея хасил итә. Бу вакытта безгә таныш детальләргә мөрәҗәгать ителә: *«Безнең милләт – / Өчпочмак та чәкчәк, / Һәм түбәтәй бугай кайчак»; «Дөньяларга тарих язган халык / Телен тешләп тора бер чатта»; «Үзебез үк кискән утын белән / Милләт яна утсыз учакта»; «Заманында яулар чапкан халык / Сабантуйлы калды нибары»; «Без үзебез салган мәчетләрдә / Ятим булып калып барабыз»; «Һәр ел саен сиңа киләбез без, / Ерагая гына арабыз»*.

Шушы образлар ярдәмендә тудырылган милләт сурәте тагын да көчлерәк бер абсурд образ белән йомгаклана: *«Беләсеңме, Тукай, / Бар да үтә. / Бар да үтә, / Һәм бу... / Үтәчәк»*. Сөләйман пәйгамбәр йөзегендәге, шәркый әдәбиятлар өчен лейтмотив булган фикернең нинди контекстта әйтелүе аңлашылмый. Моның да үтүе – ул яхшымы, әллә начармы? Әлеге сорауга җавап юк: шигырьнең уйландыру сәләте менә шунда. Дөнья сурәтенең бертөрле җавапка яки гармониягә китерелмәве – модернизм билгесе, Б.Ибраһим иҗатының да көчле ягы булып чыга.

Кайчакта сюр-сурәт сиздерми генә таныла торган образ яки билге кертү аша хасил була. Бу да шагыйрьнең осталыгы турында сөйли. Әйтик, «...Йа Раббым...» шигырендәге: *«Әле кичә генә туган сабый, / Төнге айны азгын икән, диеп, / Йолдызларны монафыйк, дип үртәп, / Күктән эзли гаеп»* юлларында Такташ шигъриятенә ишарә ясала, шуның аша кешелек тарихына совет чорының динсез дәверләре урнаштырыла. Шигырь ахырындагы *«Йа Раббым, / Син Җир шарын зур намазлык иттең. / Әле кичә генә туган сабый, / Сиңнән ярдәм сорый, сәҗдә төшә, / Тик кыйбласы берәү түгел аның, / Әллә ничә...»* дигән юллардагы сурәт кеше фәлсәфәсенә әйләнә, яшәештә кешенең үз урынын таба алмавын төрле кыйбланаларга табынуы белән аңлата.

Тагын бер үзенчәлекле, экзистенциаль шигырь – «Сугыш бетте, бабай...» Текст тирән фәлсәфи фикергә нигезләнә: сугыш чорын үткәннәрнең, ул тәмамланганнан соң да, шуның белән яшәүләрен ассызыклый. Асылда, текстны төгәлләп куя торган тезмә конкрет кешегә – лирик геройның бабасына, эпиграф белән бәйләнештә – шушы чорны кичкән тулы бер буынга, димәк, илгә карата да әйтелгән булып аңлашыла: *«Уян, бабай, чәй кайнады, әйдә, / Ниләр күрдең, төшләр кайда йөрттте? / Сугыш бетте, илбасарлар бетте, / Сез җиңдегез!.. / Сугыш бетте, бабай, / Бетте...»*. Болай гомумиләштерә алу – шигырьнең югары сәнгатьлелеге билгесе.

Шулай итеп, Б.Ибраһимның эзләнүләр, тәҗрибәләр уздырырга яраткан татар шигърияте өчен дә шактый чит тоелган текстлары – асылда, тирән фәлсәфә белән сугарылган, уйландыра, тормыш-яшәешкә һәм кешегә, гомумиләштереп, шактый катгый бәя бирә торган сәнгать әсәрләре алар. И.Бродский, Г.Сапгир, Г.Айги иҗатындагы сюрреалистик сурәтлелекне хәтерләтеп, әлеге шигырьләр татар поэзиясенең бу сукмакны да салу мөмкинлеген күрсәтә.

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,
академик, филология фәннәре докторы

Гөлнур Әхмәдуллина-Архипова 1959 елда Чүпрәле районы Яңа Кәкерле авылында туа. 1977 елда Иске Чүпрәле урта мәктәбен, 1982 елда Казан дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультетын тәмамлый.

Утыз елдан артык Балык Бистәсе районында яши. Балык Бистәсе районы Каз-Чаллы сигезьеллык мәктәбенә 1982 елда рус теле укытучысы булып кайта, ә инде шушы районның Яңа Арыш урта мәктәбендә 1985 елдан алып 1990 елга кадәр рус теле һәм татар теле укыта, Шумково урта мәктәбендә 1990-2001 елларда, авыл тарихында беренче булып, татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укыта башлый. Ә инде 2001 елдан соң Балык Бистәсе район мәгариф бүлегендә милли мәгариф буенча урынбасар, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетында өлкән референт һәм киңәшче булып эшли. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы аны «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкли.

«Син киткәч...» һәм «Син бар...», «Ялгышу», «Сыңар алка», «Бәхеткә бер адым калгач» һ.б. китаплары басылып чыга. Шулай ук Гөлнур Әхмәдуллина-Архипова – тәрҗемәче дә. 2017 елда Татарстан китап нәшриятында аның тәрҗемәсендә Фирүзә Җамалетдинова хикәяләре «Рассказы» исеме астында рус телендә дөнья күрә.

Гөлнур
Әхмәдуллина-Архипова

ТАШЛАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНӘМ МИН...

Болгарда

Меңьяшәр наратлар шаулаша.
Карагай, каеннар кушыла –
Моң таша.
Хәтта таш күңелләр
Аклыкка, сафлыкка төренә.
Чал тарих авазы
Урнаша йөрәкләр түренә...

Нур коела

Гүзәл идем. Язларымны
Көткән идем яратырга,
Ачылмаган хисләремне
Җилгә сиптем таратырга,
Бар җиһанга, йолдызларга,
Туар айга, бар галәмгә...

...Сөю һәм наз моңы булып,
Нур коела кулымдагы
Кәгазем белән каләмгә.

Йөрәк чыдый

Минем йөрәгем урынында,
Гөлләр нишләр иде? –
Бәлки, шиңәрләр иде.
Сулар – кибәрләр иде.
Утлары да сүнәр иде,
Күк тә ярылыр иде,
Май аенда үләннәргә
Сары сарылыр иде...
...Йодрык кадәр йөрәк чыдый.

Алтын көздә

Алтын көздә офыклар да
Алтын булып уяна.
Көз көз инде, агачлар да
Моңлы төскә буяна.
Алтын көздә ялгызларга
Яз җылылары кирәк.
...Ярый әле, язлар саен
Ямь-яшел була тирәк.
Сары сагышлар илендә
Еламасана, йөрәк!

Ташлар телен өйрәнәм

Ташлар телен өйрәнәм мин,
Нигә кирәк, димәгез,
Үткәннәр шавында ялгыз
Таштай яшим, тимәгез.

Ташлар телен өйрәнәм...

Тынлык авазы

Тынлык...
Тавышыңны ишетәм,
Җан авазыңны синең.
Бәлки, сагыш-моң гынадыр
Дәшмәвеңдә бүген?
Тып-тын... ефәк йомшаклыгы
Тәнемә кагыла.
Тик миңа авыр һәм моңсу.
Әйтерсең лә җаныма
Мең энә кадала.

Ә минем килә кочагында
Синең коенасым,
Җаныңа җаным белән сыенасым,
Балавыздай эреп җылынасым...
Ераклашасың...
Юлларың киртәле, таулы-сикәлтәле,
Пышылдыйсың тынлык авазында:
«Көт мине, көт, тагын бераз гына,
Иркәм, көт әле...»
Күзләр сөйләшүе диңгез шавында
Юкка чыга.
Язмыш ярында торам ялгызым.
...Йөрәгемне тагын кузгатты
Ерактагы тынлык авазы.

***

Мәхәббәт ул – «Син гаепле» түгел,
Бәлки – «Гафу ит мине».
«Син кайда йөрисең?» түгел,
«Мин монда, – диген, – бүген».
Мәхәббәт ул – «Йә, син ничек?»,
«Мин аңлыйм, көтә беләм».
«Рәхмәтлемен син барга,
Җаным гел синең белән!»
Мәхәббәт ул – «Аңладым...
Кичер мине, телефоннан
Шалтырата алмадым...»
Ярату ул – бары рәхмәт
Кояшка, җиргә, айга.
...Бүген дә әрнеп еладым,
Дәва тапмый ярага,
Инде ничек ияләним
Синсез калган дөньяга?..

***

Яфрак кояшта кызынды,
Кошлар җырын тыңлады,
Яңгыр тамчысында коенды,
Һавада очты,
Җиргә сыенды.
Һәм... биеклеккә карап,
Үзенең агачын күрде.
...Кем булуын шунда гына
Белде.

Таң җиле

Таң алдыннан туктады җил,
Яфрак коеп арды.
Үкендерде, юксындырды –
Җанны салкын сарды.

Тын сукмакка сагыш җәйде,
Айны юлдаш итте.
Утта көйгән йөрәгемне
Ымсындырып китте.
...Арабыздан үтте.

Булчы терәк...

Минем өчен син бүген бик кирәк...
Еллар ава бугай өстемә,
Булчы, зинһар, терәк!
Фасыллары алмашамы –
Дер-дер килә йөрәк...
Калмады ла, ахрысы, егәре.
Сорауларыма минем
Бирче җавап,
Бармы икән халкыма
Минем бүген кирәгем?!
Булыш миңа күз карашың белән,
Җылы сүзең белән иркәлә.
Ара ерак, беләм, иркәм, беләм...
Тик... уятчы өмет иртәгә...

***

– Сау бул! – дидең, –
Дөнья хәлен кем белгән,
Бәлки күрешмәбез дә.
Серләрне уртага салып,
Әллә бүлешмәбез дә.
– Исән йөр! – дидем, –
Язмыш юллары урау.
Бәлки әле. Бәлки әле...
Әйтеп бетералмадым –
Җаныма төште кырау.
Кадерен белдек микән
Бүгенгенең, хәзернең?!
Йөрәгемә яшем тамды,
Эретеп бозын хәтернең...

***

Вакыт – бур ул. Сине урлады,
Алып качты миннән,
Чалт кояшлы көннәремнән,
Шау йолдызлы төннән.
Югалтулар-табышларым
Күбәйде көзендә.
Шул Вакытны куа чыктым
Еллар белән үзем дә...

***

Яратудан куркам! – дидем,
Моны бит мин әйттем!
Кайтавазлар кушылды да
Сүзләремне меңәйтте.
Белсәң иде авырлыгын,
Куркуны җиңалмадым.
Ялгызлыкның диңгезендә
Тагын берүзем калдым.
Яратудан куркам, диеп,
Берүк әйтә күрмәгез.
Ятим, ялгыз көймә белән
Тирән суга кермәгез.
Ә мин менә парсыз ишкәк
Белән дәрьяга чыктым.
Арыдым да талчыктым.
...Яратудан курыктым. Их...

Гөлфәгыйзә
Юлышева

БӘХЕТ

ДОКУМЕНТАЛЬ ХИКӘЯ

Абыем истәлегенә багышлыйм.

1

Район үзәгенә китүдән аның улы өйгә әйләнеп кайтмады. Мөнҗия апаның йөрәгенә сагыш кына түгел, бала кайгысыннан бәгыренә ачу ташы укмашты. Ил буйлап эзләп китәр иде, акча юклык җелекне корыта. Колхозда бушлай эшлиләр, хезмәт көне бары «таяк» белән генә билгеләнә. Ул таяк дигәнең таянып йөрергә дә ярамый, идарәдә саналып, кәгазьдә генә бара шул.

Районнан авыл җирлеге рәисенә шалтыратып, Миржанның тәрәзәдән сикереп качуын һәм аңа чара күрүне таләп иткәннәр. «Уттай эш вакытында аны эзләп йөрмәдем инде, йә тагы утыртып куярлар дип тә уйладым. Бик бетеренмә, кай тарафка китсә дә, исән генә йөрсен. Туганнарыгыз кайларда, сорашырга кирәк. Мин эш йөртсәм, малайны куркытырбыз гына», – дип юатты үз чиратында рәис Мөнҗияне.

Шулай да түзмәде, улын эзләп, Мөнҗия апа Сарапул ягына юл тотты. Көнозын әйләнеп-тулганып, сәләмә киенгән кешеләрне күзәтте ул. Вокзалда йөреп, арып, төн уздырды, хәле китте. Бермәлне ананың күзе вокзалның урта баганасына таянып торган егеткә төште. Тик бу егет ару гына бишмәт-чалбардан иде, шикле кеше кебек як-ягына да каранмый. Кайгыдан йөзенә сары яфрак төсе кергән анага әлеге егет гел аның улына охшап, Миржан булып күренде. Адәм баласын иң күп алдаучы – ул аның үз хисләре. Менә Мөнҗия апа да хискә бирелеп торгач түзмәде, урыныннан кузгалып егеткә дәште. «Улым, Миржан, син түгелме соң, балакаем?» – дип, сак кына егетнең беләгенә кагылып алды. Ә егет исә, ихтирам белән: «Юк, апа, мин Миржан түгел, мин – Тәфкил Бикетов. Моннан ерак булмаган Краснокама районы Андреевка авылыннан. Әнә, иптәшем автобуска билет алырга тора», – диде.

Мөнҗия апа, һаман бу егетнең буй-сынында үзенең улын күрү теләгенә ышандырган-ымсындырган ялган хисләргә бирелеп, егетнең башыннан кепкасын салдырып алды. Аналарча иркәләп, йомшак кына, Тәфкилнең чәченнән сыйпады да авыр итеп көрсенеп куйды. Күз яшьләренә ирек бирмәскә тырышса да, аның йөрәге елый, сыкрый иде. Егет тә моны сизде һәм ананы юатырга тырышты. Ни булганын белергә теләп, сүз башларга өлгермәде, янына иптәше килеп: «Әйдә, менә – билет кулда», – дигәч, уйлары бүленде. Ул: «Апа

мине үз улына охшаткан икән, шул турыда аңлаша идек әле... Әһә, билет булгач, киттек алайса авылга», – дип кузгалды да, кире борылып, – «апа, кепканы бирәсеңме соң?» – диде. Әле һаман да уйларыннан арына алмаган Мөнҗиягә ягымлы елмаеп, күзләрен тутырып бер карады да, кепкасын башына киеп, китеп тә барды. Мөнҗия апа, үзенең хыялый хисләренә алдануына нәүмиз булып, вокзал уртасында басып тора бирде. Шул минутта теге егет, янә килеп, аңа: «Апа! Мә, ал әле менә бу бәләкәй күмәчне, без хәзер автобуска утырабыз, ә син безгә хәерле юл теләрсең, бар да яхшы булыр, хуш, апа», – дип, иптәше артыннан йөгерде.

Мөнҗия апа почмактагы агач диванга утырды да егет биргән күмәчне, рәхмәт укый-укый, күз яшьләренә чылатып, тәмләп ашап куйды. Аннан, авылга кайту хәстәрен күрүне уйлап, вокзал ишегенә юнәлде. Ишек төбендә су тутырылган мичкә һәм аңа бәйләп куелган алюмин кружканы күреп алды. Сусаудан иреннәре көйгән ана йотлыгып су эчте дә вокзалдан чыгып китте.

Авылга кайтуга, җирлек башлыгы аңа улы Миржанның исән-сау икәнлеген җиткерде. «Чегән почтасы улыңнан хәбәр китерде, бик бетеренмә, кайгырма, – диде ул, Мөнҗия апаны юатып. – Әйттем бит мин сиңа, Донбасс тикле җирдән исән-имин кайткан бала монда, үзебезнең якта, югаламы соң инде? Ул вербовщикка бару кирәкмәс иде шул. Алар бит закончылар. Миржан өчен миңа эләкте инде анысы. Чара күрмәгәнсең, дип шелтә чәпәделәр. Миңа бит, Мөнҗия апа, авыл халкы, сезнең белән эшлисе, яшисе, авылым кешеләренең мәнфәгатен якламасам, ышанычыгызны акламасам, кем булам соң мин?» – дип, сүзен бетерде рәис.

2

Сугыш вакытында һәм сугыштан соң иген игеп, ипекәй белән шәһәр халкын туендырган, олаулап фронтка икмәк озаткан яшүсмерләрне 1947-1948 елларда исеме җисеменә якын да килмәгән ФЗӨ мәктәбенә җибәрү башланган иде.

Авылында бик яхшы билгеләргә генә җиде сыйныфны тәмамлаган Миржанны да, районнан унсигез үсмер малай белән бергә шушы мәктәпкә озаттылар. Монда бернинди белем бирү, һөнәргә өйрәтү юк иде. Аларны Донбасс шахтасында зурлар янәшәсендә күмер чабу, вагоннарга кулдан күмер төяү хезмәтендә эшләттеләр. Укуын дәвам итәргә теләгән Миржан Сәяповның бөтен хыяллары челпәрәмә килде. Уналты яшьлек егет – табигатьнең әле иң бәхетле җаны – чын оптимист булган Миржан беренче гаделсезлек белән шушы ФЗӨ мәктәбендә очрашты. Мондый ризасызлыктан, сагынудан, эш, тормыш хафаларына җаны өзелүдән соң чиккә җиткән Миржан белән бергә тагын биш малай качарга хәл кылдылар.

Миржан өенә кайткач, әнисе янында бары бер генә төн кунды. Районнан милиция машинасы килеп алды да, аны бер елга ирегеннән мәхрүм итеп, Архангельски төрмәсенә илтеп яптылар. Менә монысы инде бөгелмәгән таякны шартлатып сындыру белән бер иде. Ләкин Миржан ярты юлда туктап кала торганнардан түгел, үз дигәненә – максатына ирешүчән кеше ул; бу сыйфатлар ата-анасыннан, үз авылы халкыннан күчкән: якты күңелле, татулыкның, дуслыкның кадерен белә, монда да үзен гел яхшы якстан гына күрсәтте, һәм аны алты айдан соң, кулына белешмә биреп, иреккә чыгардылар. Төрмә башлыгы, үз итеп: «Бу белешмә сине кайда да яклаячак, шуның белән паспорт та алырсың» – дигәч, Миржан сөенеп тә куйган иде.

3

Миржан, авылына кайтуга, укуын дәвам итәргә дигән карарга килде. Кеше булыйм дисәң, алга барыр юлыңны абайлау кирәк, ә әлеге юл сине кая алып бара, уңышлы булырмы? Вакытында сөрлеккән кеше зерә егылып китми. Димәк, ул үз юлында. Татарстанның кечерәк берәр шәһәренә барып, эшкә урнашып, укуын дәвам итү өчен хокукы бар лабаса аның. Тик менә акча ягына килгәндә, хыялында адашасың шул... Районга торф эшенә язучы килгәнлеген ишетеп алды да, уйлый торгач, шул вербовщикка барып ялынырга булды егет. Җәяүләп район үзәгенә юнәлде. Апрель азагы – табигатьнең иң җанлы, ямьле чагы. Туасы җан ияләре туган, тереләселәре терелгән – бар да шатланып тереклек итә, яши. Кояш нурлары күбәләкләрне дә җанландырган, җылыткан. Алар иркенләп, куанып очалар. Миржан, табигатьнең сәер көчкә ия булуына аптырап, сокланып, сары тасмадай боргаланып яткан юлдан уйлар өермәсендә атлады. Аның күңеле, йөрәге туган як кырларын шулчаклы сагынган ки, күзләрен нурлы күккә төбәп, күк йөзенең ачык, көләч мәленә сокланып, юл читенә утырып ял да итеп алды. Яхшы уйлар белән атлый торгач, район үзәгенә килеп җиткәнен сизми дә калды. Кирәкле йортны табып, ишеген шакыды. Җәйге эссе көн булганга, бүлмә ишеген ачып куйганнар. Керүгә, Миржан бер абзый кеше белән исәнләште. Аңа утырырга урын тәкъдим итүче вербовщик теләр-теләмәс кенә хәйләкәр текәлеп караганда, яңак сөякләре ачулы кешенеке шикелле калкып чыкты.

Миржан аңа үз гозерен белдерде. «Абый, торф эшенә мине дә языгыз әле, зинһар. Минем бик тә укыйсым килә, авылдан бер чыгып китсәм, үз юлымны карар идем әле», – диде. Бу киң җилкәле, гөмбәз авызлы, җирән чәчле, хәйләкәр майлы күзле абзыйны урыныннан кыймылдату өчен, Миржанның кулындагы кош теле кебек кәгазь генә җитми тора икән. «Абый, абый, карагыз әле! Минем белешмәм дә бар», – дип, егет үзенең белешмәсен сузарга да өлгермәде, абзый кеше, урыныннан сикереп торып, бүлмә ишеген бикләп үк алды да телефонга үрелде. Нәкъ шушы минутта Миржанның йөрәге ачы ләгънәт белән тулып, күкрәгеннән чыгардай булып ярсып кага башлады. Кыргый мәче тизлегендә ачык тәрәзәгә ыргылды һәм җәһәт кенә җиргә сикерде. Йортның беренче каты гына булгач, алай артык авыртынмады: котылуына һәм белешмәсе үзендә калуга чиксез шатланды. Бер ишегалдына кереп, байтак кына посып утырды. Ярсуы басыла төшкәч, берни булмагандай атлап китте. Авыл башында урманга баручы атчыга очрап, шуңа утырды да, урман юлында төшеп калды. Аңа агачларны ера-ера атлау читен иде, әмма бу үзеңә юл яру, моның үзенә күрә ләззәте дә бар!

Менә инде икенче көн Миржан уйларын, серләрен урман белән бүлешә, тик агачлар гына берни дәшми. Әллә аның күшеккән күңелен алар да аңларга теләми... Төн караңгылыгы куркыта, тирә-як тын, ләкин урман шаулый. Дала да, урман да җанлы, ахры. Урман – колак, дала – күз, димәсләр иде югыйсә. Әйе, урман шаулый, шулчакта күңел түрендә куркуны, ачлыкны җиңәргә тырышып, тынычлык хисе баш калкыта. Ул бит төнлә абага чәчәген күрү өчен түгел, ә максатына ирешергә дип урман юлын сайлады. Урман да, дала да аңа бик нык ярдәм итте. Кузгалак, кыр суганы, кукы белән тукланды. Хәтта божыр – урман тавыгы оясына да тап булды. Үтереп ашыйсы килде, андагы йомыркаларга үрелергә теләде, ләкин ояга кагылмады. Әнкәсенең: «Урманга кердеңме, үзеңне тәртипле тот», – дигән сүзләре Миржанның колак төбендә агачлар шаулавы булып ишетелде. Ә кош оясына кагылырга ярамаганны ул балачагыннан ук белә. Бәлки, божыр үзе оясыннан ерак түгелдер, Миржан, аны куркытканмындыр дип уйлап, бу урманнан әкрен генә атлап чыгып китү ягын карады.

Менә инде ул икенче көн, ач булса да, авылга кайтмый йөри. Моның сәбәбе бар иде. Бөтен теләге – милиция кулына кабат эләкмәү. Уналты яшендә бер тапкыр татыды бит ул ирексезлекне. Барыр юлны сайлар өчен, артка да борылып карарга кирәклеген белсә дә, Мирҗан һаман алга бара, бар көчен җыеп алга атлый. Әнә, чабаталары да мыек җибәргән, ә ул бара да бара. Чөнки вербовщик аңа: «Мин сине каядыр укырга урнаштырырга түгел, бу белешмәң белән утырган җиреңә генә кире озата алам», – диде бит.

Хәйран инде дөнья дигәннәре. Кемдер комсызлыгы аркасында рәхәт яши. Мирҗан исә авыл читләрендә, ферма буйларында ачка интегеп йөри... Тик ул максатына ирешүдән өмет өзми, бу гаделсез тормышта үз урынын табарга тырыша иде. Төнлә күккә карап: «Әнә, хәтта күктәге һәр йолдызның үз урыны бар, җирдә дә һәр кешенең үз урыны булырга тиеш бит», – дип, үзенең шәхси билгесезлек халәтеннән чыгу юлын эзләп уйлана иде.

Авыл саен бер күлем-өч күлемгә[1] ялланып эшләп, Мирҗан Тымытык кырларына якынлашты. Баек авылыннан үткәндә, өлкән яшьтәге бер апа аңа сугышта үлеп калган улының кирза итеген бирде. Егетнең яраланып беткән аякларын күргәч, үзенең алъяпкычын ерткалап, чолгау ясап кидерде, хәленнән килгәнчә ашатып та чыгарды. «Улым, кеше максатына ирешү өчен барын да эшли, йөрәге, табигате белән ничек тә түбәнлеккә төшмәскә, соңгы чиккә җитмәскә тырыша. Син дә, улым, тырыш, дөньяда яшәү үзе бәхет, яшәүдән беркайчан өмет өзмә», – дип озатты ул Мирҗанны.

Тымытыкны узгач, балкып янган факел утларын күреп сөенде. Төнлә урманда йоклау куркыныч, ә факел янында тыныч та, җылы да булыр дип, шул тирәгә җайлап утырды да татлы уйга чумды. Кешегә бәхет бәхетсезлек аша килә дип әйтә иде бит әнкәсе; бүген исән-сау икәнсең, тамагың тук, туңмыйсың-өшемисең икән, димәк, бу бәхет... Гүя ул бәхет тавы итәгендә кояшта кызынып ял итә: изрәп татлы йокыга талды. Төшендә әнисен күреп: «Әнием, кайгырма, юлны кояш чыгышына карап атларга кирәк дигән киңәшеңне онытмадым һәм онытмам да», – дип, әнисен юатып, уянып китте.

Факел ялкыны янында төн уздыргач, Мирҗанның күңеле күтәрелә төште. Әнкәсе әйткәндәй, «көрчинәсе түгәрәк, күңелдәге борчуларны җилләр алды бүлгәләп», дип, аңа озак кинәнергә туры килмәде. Чиләкләп булмаса да, иләкләп яңгыр коя башлады. Аның җылыдан соң һич кенә дә чыланасы килми иде, һәм ул сыерлар җәйләвенә йөгерде. Савым җиһазлары куя торган куышка ышыкланды. Көндезге савым алдыннан яңгыр туктады һәм сыер савучылар килә башлады. Аларның барысы да яшь кызлар иде, Мирҗан шыпырт кына куыш артыннан карап торуын белде. Ә кызлар аны бөтенләй күрмиләр дә. «Күрсәләр соң...» дип уйлады егет. Бу елларда кем нинди кием белән йөрми һәм җан саклар өчен кем генә хәер сорашмый икән дип, кызларга сүз кушарга батырчылык итте Мирҗан. «Кызлар, кызлар, ни хәлләр сез? Ә менә минем хәл шушылайрак, зинһар, курыкмагыз, – диде ул, башын иеп, түбәнчелек белән кулын күкрәгенә куеп. – Мин бур да түгел, караклыкта да йөрмим», – дип, тәфсилләп үзенең хәлен сөйләргә уйлаган иде дә, ләкин флягасына сөт салып торучы хатынның тутырып үзенә каравыннан куркып туктап калды. Тик юкка курыккан икән. Апа кызларның иң кечкенәсенә эндәште. «Алып бир әле, кызым, чүмечеңне», – дип, чүмеч сорап алды. Аннан алагаем сөткә батырып, тулы чүмечне Мирҗанга сузды. «Мә, эч! Хәл керер үзеңә. Әй, балакай, кем газизе соң син? Безнең тирәдән түгелсең бугай», – дип, егеткә бер-бер артлы

[1] Күлем *(диал.)* – төшке аш. Бу урында – өч төшке ашка яллану.

сорауларын яудырды. Бу хатын яшь кызларга караганда шактый олырак күренә иде. Миржан: «Кыяфәтемә карап, сез мине әшәке кешегә санамагыз, бик авыр хәлдә калдым мин», – диде һәм үз хәлен сөйләп бирде. «Апа, авылда әнием һәм ике сеңлем бар, әтием сугышта һәлак булды. Минем исәнлекне әнием белсен иде. Моны ышанычлы кеше аша белдерсәгез, бик рәхмәтле булыр идем. Әлбәттә, булдыра алсагыз, зинһар, апа, үтенәм сездән», – диде ул, сөтне тәмләп кенә, ашыкмый гына эчкәч.

Чүмеч алып биргән унөч-ундүрт яшь тирәсендәге кызчыкның бу минутта үзенә дикъкать белән карап торганын сизеп, оялып та куйды. Кыз зәп-зәңгәр чагыр күзле иде. Миржан аның бит очында берничә сипкелен дә күрергә өлгерде, кычкырып рәхмәт әйтте дә буш чүмечне үзенә карап торган кызга бирде. Миржанның бу кызчыкка, эчтән генә пышылдап, күңел тавышы белән генә, ниндидер җылы сүз әйтәсе килә иде. Аларның күз карашы гына түгел, күз нурлары да очрашты.

4

Миржан яшәгән районыннан ераграк киткән саен, үзен иркенрәк сизә иде. Азнакай белән Әлмәт арасында машиналар күренгәли, ә менә җәяүлеләр бөтенләй очрамый диярлек. Ачыгудан хәле китүен, тез буыннарының тотмавын тойды. Төнгә чаклы берәр машина булуына өметләнеп, юл читенә утырды. Ул әтисенең хатта язган сүзләрен исенә төшерде. «Әгәр дә тез астыңа суксалар, улым, уң ягыңа егылырга тырыш», – дип язган иде ул. Шулай булгач, Миржанның әле җебеп төшәргә хакы юк. Бары ачлыктан гына аяклары тыңламый... Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына – янына эшчеләр йөртүче вахта машинасы килеп туктады, Миржан куркып кына урыныннан торып басты. Шофёр, кул изәп, аны үзенә чакырды. «Курыкканга куш, койрыгы белән биш», дигәндәй, шофёр янында утырган кеше, машинадан төшеп, Миржанга таба килә башлагач, әллә аны милиционерга охшаттымы, әллә ачлыктан тәкате төкәнгән егетнең күзенә шулай күрендеме – куркып, урманга ыргылмакчы булды, ләкин аяклары тыңламады, ул абынды, җиргә чүмәште. Миржан: «Бетте баш», – дип уйларга да өлгермәде, яшел фуражкалы кеше: «Курыкма, әйдә, утыр», – дип, аңа җирдән торырга булышты һәм кузов өстендә басып торучы егетләргә: «Принимайте, хлопцы!» – дип кычкырды. Өстәге ирләр Миржанны үзләре янына күтәреп диярлек алдылар. Бу минутларда ул әллә куркудан, әллә куанычтан, үзе дә аңламыйча, кузов идәнендә йөзтүбән ятып тавышсыз гына үкси иде.

Шофёр, Елховойга җитәрәк, нәкъ скважиналар янына килеп туктады һәм бригадирга: «Кара, сиңа эшче көч китердем. Ул ач, аны иң беренче ашатыгыз!» – дип кычкырды. Ә үзе Миржанны, якын итеп: «Башта су эч, улым, берьюлы күп ашама, – дип кисәтте һәм аркасыннан сөеп куйды. – Без әле синең белән күрешербез». Шофёр, кайтасы эшчеләрне машинасына утыртып, кузгалып китте.

Бригадир Нариман исемле икән. Миржан төрмәдән биреп чыгарган, күз карасыдай саклаган белешмәсен аңа күрсәтте дә үз хәлен һич яшермәи сөйләп алды. Баксаң, бригадир үзе дә, эшчеләре дә искиткеч мәрхәмәтле кешеләр икән. Миржанның хәзер тамагы тук, өсте бөтен иде. Җәй көне булганга, ул әлегә вагонда яши, ярдәмче эшче булып бик тырышып эшли, ни кушсалар да, риясыз теләп башкара. Аның сөенече зур хәзер. Егетләр ярдәмендә әнкәсенә үзенең хәлен белдерде. «Эшләр бара уңайга, моңайма, егет, моңайма», дип көйләп тә җибәрә.

Бер ай үтүгә, Нариман абыйсы Миржанга кыштырдап торган өр-яңа паспорт алып килеп бирде. Миржан, кечкенә малай кебек, шатлыгыннан мәтәлчек атып җиргә сузылып ятты. Теге вакытта кузов идәнендә яткандай аркасы туктаусыз

селкенүдән аның үксүен аңласалар да, иптәшләре күрмәмешкә салышты. Бөтен коллектив аның белән бергә сөенә иде.

Иртәгесен бригадир Миржанны Әлмәткә эшкә урнаштырырга алып барырга булды. Моны ишетүгә, Миржанның түбәсе күккә тиде. Коллектив, аны порукага алу турында сорап, имзаларын куеп, гариза да әзерләгән икән. Миржан бу коллективка елмаеп-көлеп килеп кермәсә дә, кешеләргә йөрәген ачты, саф күңел белән аларның ышанычын акларга тырышты. «Алар миңа ышаналар, мине бәхетле итеп күрәселәре килә икән, мин моны берсүзсез аклармын», – дип, үз-үзенә максат куйды егет.

5

Бригадир Нариман Вәлиев Миржанны Әлмәт промыселына буровойда эшләүче итеп урнаштыргач, ул үзен яхшы якта гына күрсәтте, чын-чынлап нефтьче һөнәрен бик теләп үзләштерә башлады. Менә скважинадан нефть вулканы атарга тотына. Бар да сөенешеп, кара алтын белән битләрен юа, ә Миржанның бу әле беренче табышы гына. Ул биленә чаклы чишенә дә башыннан ук нефтькә коена һәм, нык сөенеп: «Шушы көннән мин эшче – нефтьче. Ишетәсезме, абыйлар, рәхмәт сезгә!» – дип, күз яшьләреннән дә оялмыйча кабатлый. Әле кайчан гына Миржан оясыннан егылып төшкән кош баласы кебек иде бит, ул төптән күтәрелгән кеше, үсмер чакта бер сөрлекте, ләкин кире төпкә батмады.

1952 елның көзендә коллектив Миржанны армиягә озатты. Өч ел хезмәт иткәч, үзенең җанына якын игелекле абыйлары янына кайтты, тик әлегә аның урыны буш түгел иде. Нариман абыйсы, аны икенче бригадага тәкъдим итеп: «Онытма, эшче маркасын югары тот, син миңа үз улым кебек үк якын, частьтан килгән рәхмәт хатларыңны авылыңа да җибәрдек, алар да горурлансын, дидек. Бүген-иртәгә Әлхәт абыеңны пенсиягә озатабыз, якын арада үземә алырмын», – диде.

Миржан монда да бик тиз үз кеше булып китте. Югарыдан карар килгәч, зур бер коллективка тупланып, киңәйтелгән комплекс оештырып җибәрделәр. Беренчеләре нефтьне тапса, икенчеләре скважиналарны ремонтлый, аларны урнаштыра. Һәр очракта, нефть фонтаны ургыганда, аның иң беренче мәртәбә кара алтынга коенуын үзе генә түгел, бөтен коллектив сагынып искә төшерә иде. Миржан Сәяпов үзе дә, нефть кебек, җирдән тартып-суырып алган кеше, диләр. Миржан исә коллективны бәяләп бетергесез ярдәмчел затлар – бәхеткә юл күрсәтүчеләр дип саный.

6

Миржан паспорт алып эшкә урнашуга, әнисе янына авылына кайтырга ашыкты. Сеңелләрен дә сагынган иде. Әнисе аның төшенә еш керә, моңсу күзләре нидер әйтергә теләгәндәй текәлә, шуңа да егетнең күңеле тыныч түгел иде. Бик сагына ул әнисен, бик сагына. Күчтәнәчләр алып кайтып, аның күңелен күреп гафу үтенсә, йөрәк ярсуы басылыр кебек.

Районга кадәр машина очрады, аннан җәяү атлады. Бу кырларны, юлны ул теге чакта ач-ялангач үтсә, бүген исә җаны май кояшына сөенгән күбәләктәй очына. Менә ул басу капкасына якынлаша, әнә аларның урамы күренә. Әй, күңелле дә соң син, авылым, дип кычкырасы килә Миржанның. Кешегә туган җиреннән кадерлерәк, гүзәлрәк бер җир дә юктыр. Әнкәсенә, тиздән кайтасын белдереп, хат та язган иде инде. Менә ул, һич курыкмый, авыл җирлеге бинасы

яныннан уза, монда аңа бар да үз, бар да якын. Сагынуын тоеп, һәр йортка сокланып карый-карый атлый. Менә аларның капка алды, әнә сеңелләре – чәчбиләре йөгереп чыкты. Ә газиз әнкәсе баскычтан төшеп килә. Миржан аны күтәреп диярлек кочагына алды. Менә ул бәхетле мизгел, ике ягында аңа сыенган сеңелләре, кочагында иң кадерле кешесе – әнкәсе – күз яшьләре аша елмая. Миржанның төшләренә кереп йөдәткән моңсу күзләре шатлыктан балкыган йөзен бизәп нур чәчеп тора.

7

Миржан Сәяпов үзенә ярдәм кулы сузган кешеләргә иң мөкатдәс хисләр белән җавап бирергә тырышты. Ул аларның хәлен белүне бурычы итеп санады.

Авылына кайткан саен, юл өсте булмаса да, Баек авылындагы әбинең дә хәлен белеп, күчтәнәчләр биреп чыга торган булды. Даригөл әби үз чиратында, аңа рәхмәт әйтеп, дога кыла, хәерле гомер тели.

Миржан җәйләүдә сөт эчертеп сыйлаган апаны да эзләп тапты. Тау белән тау гына очрашмый, кешеләрне кавыштыра икән язмыш. Шул җәйләүдә күзләре очрашкан туташ әлеге апаның кызы булып чыкты. Кечкенә бала гына иде ул чакта, инде җиткән кыз булган, элек тә матур күзләрендә хәзер уй катнаш акыл пәрдәсе аша тирә-якка нур сибелә... Миржан өчен бу мәхәббәт сандугачлы серле алсу таңда тумаса да, яшьлегенең авыр, давыллы иртәсендә кабынган, сыналган мәхәббәт бөтен коллектив һәм туганнарны җыеп, туйлап өйләнү белән тәмамланды.

Миржан гаиләсендә дә, кеше арасында да якты күңелле, риясыз, йомшак холыклы, итагатьле булганга, аны барысы да ихтирам итә иде. Үз гомерендә эшләү дәверендә югары белем дә алды, җәмәгать эшләрендә дә теләп катнашты. Сикәлтәле юллардан соң аның беренче баскычы – бригадир, кырык яшендә КРС[2] җитәкчесе дәрәҗәсенә күтәрелде. Сәяповның сурәте шәһәр дан галереясенә куелды. Ул бу урынны лаеклы бизәп тора.

8

Миржан Сәяповка «Атказанган нефтьче» исеме биреп, күкрәгенә Хезмәт Кызыл Байрагы орденын элгәч, ул, залдагы кешеләргә – хезмәттәшләренә рәхмәтен җиткергәндә, сүзләрен өзек-өзек, бик дулкынланып кына әйтә алды. Тамагына утырган төерне йота алмый интекте. Бераз тынычлангач: «Кызганыч, миңа кешелеккә олы юл күрсәткән Нариман Нуриевич арабызда юк, иң изге рәхмәтләрем аңа дога булып барсын. Шулай ук гомер буена җитәрлек балалык рәхмәтем – газиз әнкәемә. Коллективыма, җитәкчелеккә зур рәхмәт. Алар миңа шушы дәрәҗәгә күтәрелергә ярдәм иттеләр, – дип, сүзен дәвам итте. – Кеше өчен олы бәхет менә шушыдыр, җәмәгать. Мин бит авылымнан чабата киеп, җәяүләп чыгып киттем, җилләрдә җилфердәп килә торгач, чабаталарым тузып, яланаяк килеп кердем бу коллективка. Ә бүген?! Менә моннан да зур хөрмәт, зур бәхет булуы мөмкинме эшче кешегә?! Иптәшләр! Һәрбер кеше – җир тәгәрмәченең бер төене, мин дә сезнең ярдәмегез белән төптән күтәрелгән – бәхеткә тиенгән бер төен. Рәхмәт сезгә, рәхмәт», – диде. Зал аны котлап, шаулатып кул чабып, сәхнәдән озатты.

Миржан төче сүз әйтмәде, алдамады, ул чыннан да бәхетле иде.

Пермь крае Барда авылы

[2] КРС – скважиналарны капиталь төзекләндерү.

Зәбир
Гыймаев

ЗИЛЗИЛӘДӘН СОҢ

ХИКӘЯ

1

Тукталышта Сөббух күренми иде.

«Тагын соңга кала! Әйткән җиргә вакытында килсә, Сөббух буламыни ул?! Хатыны кочагыннан чыгалмый ятадыр әле!.. Өйләнүенә икенче ел китте, һаман ширбәт аендагыдай кыланалар! Һ-и-и, әйтер идем!..»

Раббанинының дустына әйтәсе тәнкыйть сүзләре әле бер олау иде – чаттан, җиңел-җитез атлап, Сөббух күренде.

Куллар кысышып, кыскача гына хәл-әхвәл сораштылар.

– Соңга калып йөрисең, – дип, ризасызлыгын белдерде Раббани.

– Мин вакытында йөрим, дустым, – диде тегесе, сәгатенә күз ташлап. – Син иртәләгәнсең.

Сүзсез калдылар. Бу җаваплы мероприятие («чара» дип кенә әйтәсе килми) алдыннан юк-бар сүзгә вакыт юк иде.

Автобусны көтеп алдылар. Кереп утырдылар. Кондуктор: «Молодые люди, заплатите за проезд!» – диде. Раббани кондукторның кулына ике кешелек чакыру билеты тоттырды. Кондукторның күңеле булды, бүтән бәйләнмәде. Соңгы тукталыштан соң ике чакрым җәяү барасы. Җәмгысе буладыр – егерме чакрым. Бәлки, чак кына артыграктыр.

Автобустан төшкәч тә сизелде: шәһәрдә җылырак булган икән, ачык кырда салкын иде. Җитмәсә, үч иткәндәй, җил каршы исә.

– Халык җыелган микән инде? – диде Раббани.

– Җыелмыйча! Шту син! – дип кабынып китте Сөббух. Ул оптимист иде.

– Җилләп тора бит, – диде пессимист Раббани.

– Йөгердекме? Соңга калмыйк тагын! – дип җилкенде озын дистанциягә йөгерү буенча икенче разрядлы Сөббух.

– Салмак кына атласак та, вакытында барып җитәбез, – диде, спортзалга керсә, тимер-томыр күтәреп мәш килергә яратучы Раббани.

Үзәк нефтьүткәргечкә кадәр ике чакрым юл. Яшь кеше өчен арамыни ул?! Җиңел-җитез атлап киттеләр. Көне салкынчарак булса да, җилләбрәк торса да – кояшлы. Болай да күтәренке кәефләр күкнең җиденче катына ашты. Ничек ашмасын?!

Дөнья матур! Дөнья киң! Каршыларында, ап-ак дала кояш нурларында балкып, җәйрәп ята. Юл читендә ап-ак бәскә төрәнгән шайтан таякларына кадәр күзне иркәли. Дөнья гел ак төсләрдән генә тора! Галәмнең үзәгендә – син! Күкрәктә көч ташый! Уйлар чиксез биеклеккә омтыла! Син – хөр күңелле табигать баласы!

– Бу мероприятиедән читтә калмый дөрес эшләдек, иеме, Раббани дустым? – диде Сөббух, хискә бирелеп.

– Сүз дә юк! – диде Раббани дусты, ике уйларга урын калдырмыйча.

– Уйлап карасаң, ис-акылың китәрлек бит! Менә шушы җирдән күпме нефть тапканнар!

Моңарчы бу хакта уйлаганы юк иде, Сөббух, шаккатып, хәтта барган җиреннән туктап калды. Шулай да, фикерен йомгаклый алды:

– Галәмәт! – диде.

– Өч миллиард тонна! – диде Раббани, дустының «галәмәт» сүзенә ачыклык кертеп.

Сөббух һаман гаҗәпләнде:

– Илле ел буена суыртканнар да суыртканнар! Ничек бетмидер ул?! Нефть диңгезе өстендә утырабыз икән!

– Беренче нефть фонтаны 1943 елда Шөгердә бәргән! – диде Шөгер егете Раббани.

– Елына 100 миллион тонна нефть тапкан заманнар булган! – Сөббухның тагын нидер әйтәсе килгән иде, нык дулкынланудан фикер җебен чуалтты.

– Угу! – дип, мәче башлы ябалакка охшатыбрак ухылдап куйды Раббани.

– Себердә әле нефть тапмыйлар. Төптәнрәк уйлап карасаң, Татарстан нефте ул заманда ил бюджетының арка терәге булган бит! – диде Сөббух, фикер җебен тәртипкә салып.

– Себер нефтен үзләштерүдә дә безнекеләр башлап йөргән инде, – диде Раббани. – Әле дә йөриләр, вахта ысулы белән. Ярты Себердә татар-башкорт анда!

– Юк, син әйт: бүгенге көндә дөньяның кайсы иле Татарстан белән бил алыша ала?! Бармы андый ил?! – дип, ярты сүздә дустын бүлдерде Сөббух.

– Кувейт «отдыхает!» – диде Раббани, ни өчендер русчалап.

– Сөгуд Гарәбстаны «ял итә»! – диде Сөббух.

Тагын берничә илне элеп алып, селтәп ташладылар – Татарстан гел беренче урында калды.

– Шул байлыкның күпмесе генә үзебездә калган һәм кала бирә? – Сөббух кыза башлады. Аның кайчак кызып китә торган начар гадәте бар иде.

– Пүчтәк, – дип гүләде Раббани.

– Дөресме бу?! – Бәхәскә урын юк, сорау кабыргасы белән куелды.

– Хы! – диде Раббани, шушы ике авазда үзенең чиктән тыш ризасызлыгын белдереп.

– Бу мероприятиедән читтә калмый дөрес эшләдек, – дип кабатлады Сөббух нык итеп. Раббани җавап бирмәде. Раббани җырлап җибәрде.

Ком бураны, ком бураны,
Оренбурның урамы;
Илдә көрәш барган чакта
Өйдә торып буламы?

Әлбәттә, кар баскан бу далада ком бураны юк, булуы мөмкин дә түгел, әмма җырның рухи халәткә туры килеп торуын әйт син!

Менә шушы урында хөрмәтле укучымны геройларыбыз белән тулырак таныштырып китү кирәктер.

Раббани белән Сөббух – аерылмас дуслар, Әлмәт театрының яшь һәм өметле артистлары. Икесе дә Казан театр училищесын тәмамлап эшкә килделәр. Озакка сузмый өйләнеп җибәрделәр. Матур гына, күркәм генә итеп яшиләр. Икесе дә, баш-аяк белән дигәндәй, иҗатка чумдылар. Шуннан да зуррак бәхетнең булуы мөмкинме соң?! Әмма, тормыш булгач, гел чумып кына яшәп тә булмый, калкып чыксалар – дөнья кайный! Баш күтәрми эшләүдән гайрене белмәгән татар аяк

терәп мөстәкыйльлек даулый, Мәскәү – Татарстан арасында килешү төзелеп ята икән.

Шул уңайдан, кичә шәһәрдә митинг булды, сәнгать халыктан аерылмаска тиеш! Бу фикерне театр училищесында сеңдергәннәр иде. Ике дус митингка барды. Сөббух чыгыш ясарга да кыҗрап караган иде дә – чират җитмәде. Сөйләүчеләр болай да күп булып чыкты.

Митинг бертавыштан резолюция кабул итте: раз без мөстәкыйль дәүләт икәнбез, раз Мәскәү белән ике арада килешү бар икән – рәхим итегез, килешү нигезендә нефтьне баррелен фәлән тәңкәдән сатып алыгыз! Ә без бәяне куя белербез! Әйтеп-әйтеп тә, безнең сүзне колагыгызга элмисез икән – иртәгәдән краннарны ябабыз да куябыз!

Сөббух кичә бер нәрсәне аңлады: әлбәттә, митингта зәһәреңне чәчеп, эчеңне бушату да кирәк шөгыль – моның өчен сине атмыйлар да, асмыйлар да... Үзеңнең дә кәефең күтәрелеп китә: галәмәт зур эш кыргандай, өеңә кайтасың, сөтле чәеңне эчеп, кухняда тагын бер дулап аласың... Сүз сөйләүчеләр күп, реаль эш кирәк. Менә нәрсә җитми дөньяда! Сөббух бу фикерен дустына да әйтте. Раббани хуплады.

Һәм менә алар, кояш белән бергә торып, ашкынып-җилкенеп, үзәк нефтьүткәргечкә баралар.

– Кранны үзем ябам! – дип кыҗрады Сөббух.

– Мин дә булышырмын инде, – диде Раббани, дустының чандыр гәүдәсенә күз ташлап.

– Ярый, булышырсың, – дип, олы җанлылык күрсәтте Сөббух.

Нефтьүткәргеч күренде.

– Хал-ы-ы-к! – диде Раббани, куанып.

– Сабан туендагы кебек! – дип, дустының сүзенә куәт өстәде Сөббух.

Кызыл кирпечтән салынган бина янында йөзгә якын кеше җыелган иде. «Кеше азрак җыелган түгелме соң?» дип, дусларның кәефен төшермик, күп кенә авылларда йөз кеше җыелып та бик күркәм, бик матур итеп Сабан туйларын бәйрәм итәләр ич!..

– О-о, артистлар килгән!

– Әйдәгез, егетләр, түрдән узыгыз!

– Сәнгать безнең белән!

– Болай булгач, эш пешә!

Килеп кулларын кыстылар. Шап-шоп итеп иңбашларына суккаладылар. «Туңмадыгызмы әле?» – дип сораган булдылар. Сүз дә юк, дулкынландырgыч мизгелләр!.. Халык аларны таный, халык аларны белә икән. Менә шуннан соң «әлмәтләләр театр яратмый» дип әйтеп кара син! Нурислам хәзрәт тә монда икән. Хәзрәт белән үзләре барып күреште.

Краннарны инде япканнар, Сөббухка эш калмаган булып чыкты. Сөббухның моңа бераз кәефе кырылды, әмма озакка түгел.

Вакыйгалар аны тиз арада үз эченә бөтереп алды. Алтабан нишлибез? Сүз шул хакта бара икән. Фикерләр уртак: ахыргача торырга! Кемдер: «Отступать некуда! За нами Москва!» – дип кычкырды. Аны: «За нами Әлмәт!» – дип төзәттеләр.

Көне кояшлы булса да, кыш үзенекен итә: битләрне чеметтереп, җылы куртка эченә керергә чамалый иде. Аяклар да җир салкынын сизә башлады. Берничә җирдә учак ягып җибәрделәр. Берәү дә буш кул белән килмәгән: кемдер чәй, кофе кайнатып алды. Чыбык очына элеп утта кыздырылган сосиска, тавык ботларыннан тирә-юньгә тәмле ис таралды. Дөньялар ямьләнеп, күңелләр хушланып китте. Бер абзый, тальянын алып, «Сарман» көен уйнап җибәрде. Кемдер, тальянга кушылып,

җыр башлады... Сөббухның янә чак кына кәефе кырылды: татар татарлыгын итә шул. Шундый җаваплы көндә авыз күтәреп «Сарман»ны җырлап тормасалар соң! Хәер, бераздан тынычланды. Булсын!.. «Сарман»ы да булсын!..

Ул арада автобус күренде, юлдан төшеп, ачык кырда чайкала-чайкала, җыелган халыкка таба килә башлады. Тальян, адашкан каз бәбкәсенә охшатып, соңгы нотаны алды да тынды... Егерме-егерме биш адым кала автобус туктады. Ишек ачылды. Автобустан зәңгәр курткалы, аркасына «Татнефть» дип язылган урта яшьләрдәге ир-ат; кыш булуга карамастан, башына текә түбәле фуражка кигән офицер төштеләр. Офицер каты тавыш белән боерды:

– Выходи, стройся!

Автобустан, кыска көпшәле автоматын җилкәсенә аскан, күзгә ят, чуар киемле ОМОН сугышчысы сикереп төште. Җайсызрак сикерде ахры, авыртудан йөзен чытып сүгенеп куйды.

– Чү, балам, ипләбрәк! – диде Сөббух янәшәсендә басып торган карт.

Егет, аксаклап булса да, сафка басты. Аның артыннан башкалар коелышты.

– Йә, нәрсә карап торасың? Кранны ач! – дип боерды офицер зәңгәр курткалы ир-атка. Ир-ат, кыюсыз гына, нефтьүткәргечкә таба китте.

Моңарчы боларны кино карагандай тамаша кылган халык кузгалышып куйды. Кара бөдрә чәчләрен һәм мыегын ап-ак бәс сарган егет, зәңгәр курткалының юлына аркылы төште.

– Син кая, агай-эне? – дип сорады егет.

– Ничек кая? Кранны ачарга, – диде зәңгәр курткалы, кыюсыз гына.

– Йөрмә! – диде егет, нык итеп.

– Мәҗбүр итәләр бит, – диде зәңгәр курткалы.

Сүзгә бүтәннәр кушылды:

– Кем рөхсәт итте?

– Ачмыйсың!

– Син, агай-эне, бу тирәдә чуалма! – диделәр.

– Мин кушканны үтәүче генә... Кызмагыз әле сез, – диде зәңгәр курткалы.

Аңа бүтән игътибар итүче булмады. Зәңгәр курткалы, бераз таптанып торганнан соң, борылып, офицер янына китте. Офицер саф алдына чыкты. Һәр сүзен чатнатып әйткән каты тавышы салкын һаваны ярды:

– Граждане! Самовольно закрыть краны в нефтепроводе – это диверсия! Диверсия, понимаете?! Виновные будут отвечать перед законом! А сейчас, расходитесь по домам!

Моңарчы таралыбрак йөргән кешеләр бер тирәгәрәк туплана төште. Офицер сөйләп бетерүгә, усал сүзләр ишетелде:

– Куркытма!

– Куркытылган инде без!

– Кранны ачмыйбыз – и всё!

– Ычкыныгыз моннан!

– Юлыгызга ак җәймә!

– Таптылар савым сыерын!

– Үзебез кайчан кешечә яши башлыйбыз?!

– Без хәзер мөстәкыйль дәүләт!

– Һәм шулай булып калачакбыз да!

Кемдер ачы итеп сызгырып җибәрде. Офицерның чырае бозылды. Власть белән килешенмәгән митингны куып тарату, сугышкан яшьләрне тукмап ташлау берни түгел. Монда хәлләр икенчерәк булырга охшаган... Болар сүз сөйләп кенә калмаган, болар сүздән эшкә күчкән – кранарны ябып куйганнар! Ә бу – диверсия! Кешеләрнең куркып калмавы офицерның ачуын кабартты.

«Раз диверсия, нужно действовать как в Чечне!» – дип ярсып уйлады ул. Күкрәгенә салкын һава алып, янә бер кычкырды:

– Расходитесь по домам!

Төркем туктаусыз хәрәкәт итә иде: артта басып калганнар алгарак үтәргә тырышты, тегеләре исә артта калу белән ризалашмый янә алга үттеләр... Ике ара котылгысыз рәвештә якыная барды... Йөрәккә шом салып, аяк астында кар шыгырдады... Офицер аркасына салкын тир бәреп чыгуын сизде. Нишләргә? Менә хәзер ул нишләргә тиеш?! Боларны резин күсәкләр белән генә куып тарату мөмкин түгел. Болар үзләре сине, сугышчыларың-ниең белән, бөтереп алачак. Бик күбесе гәүдәле, таза-таза ир-атлар. Бу аңлашыла да: нефть эше – җелегеңне суыра торган авыр эш. Сыек буынлылар монда эшли алмый. Нәрсә белә соң ул бу кешеләр турында? Түрә кабинетында чакта ул гел сораштырды: кемнәр каршысына барачагын ул белергә тиеш иде. Түрә тынычландырды: «Да ты не беспокойся, подполковник. Уголовников среди них нет. Там в основном нефтяники. Вполне законопослушные граждане...»

Соңгы җөмләсен төзәтте: «Были законопослушными гражданами». Чыгып киткәндә, кисәтүне кирәк тапты: «Ты смотри там, дров не наломай!»

Әйе, түрә хаклыдыр. Тик менә шушы секундта ул нишләргә тиеш? Киңәш сорап югарыга шалтыратыргамы? Ни мәгънә?! Җавабын алдан ук белә: «Действуйте по сложившейся ситуации!» – диячәкләр. Һәркем җаваплылыктан кача шул. Кан коелса?! Гаеплене эзли башлаячаклар. Әлбәттә, ул, гаепле булып калачак.

Шулай да, кан коелса?!

– Готовься!

Отряд, бер кеше булып, автоматларын иңбашларына терәде. Яшен чытырдавыдай затворлар чыкылдап алды.

Ул бары тик аларны куркытырга теләде.

Үзенә төбәлгән автомат көпшәсен күрүгә, адәм баласы икеләнеп кала, ихтыяры какшый. Затвор тавышыннан аяк буыннары тотрыксызланып, күңелен шом баса. Ә йөрәгенә курку оялаган кеше белән эш йөртү күпкә җиңел.

Төркем өстеннән өермә узгандай булды. Әмма кешеләр тере, усал карашларын аңа текәп, баскан урыннарында калдылар. Киеренке тынлык урнашты.

Кинәт бу тынлыкны автомат тырылдавы бозды. Пулялар, үлем эзләп, кешеләрнең баш очыннан бушлыкка очып үтте...

Әйе, автобустан беренче сикереп төшкән сугышчы атты. Ул бик җайсыз сикергән иде. Тубык турысыннан үтереп аягы сызлый башлады. Ул моңарчы түзде. Тешен кысып булса да түзде. Ахырда бу каршы тору аңа гомер буе бетмәс кебек тоелды. «Баш очларыннан «чират» бирсәң – сарыклар кебек куркып качачаклар! Ә җиңүчене хөкем итмиләр!» Шушы уй аңа тынгылык бирмәде. Тора-бара ышанычка әйләнде. Түземлеге төкәнгәч, автоматын чак күтәрә төшеп, тәтегә басты...

Ату тавышы кешеләрне ярсытып кына җибәрде. Кешеләр кычкыра башлады. Кайчандыр аларның ерак бабалары өчен изге булып та, хәзер кимсетелүгә дучар ителгән сүзләр, җан авазы булып, тышка – менә шушы кар баскан киң далага бәреп чыкты.

Моңарчы каршы торуны тыныч юл белән хәл итү мөмкин кебек иде. Ату тавышы соңгы өметне сүндерде. Офицер, чарасызлыктан, ачы итеп сүгенде.

Зиһенен хәвефле уй телеп узды: «бәрелеш котылгысызмы?!» Чигәсендә кан тамыры сулкылдап типте: котылгысыз... котылгысыз... Кулы, каударланып, кобурасын капшады, пистолетының кытыршы сабын кысты. Корал ышаныч уятты. «Сволочи! Меня так просто не возьмёте!» – дип уйлады.

Көтмәгәндә аның күзе Нурислам хәзрәткә төште. Хәзрәт бу хәлләргә битараф кеше сыман, башын иеп, бер читтәрәк басып тора иде.

– Эй, мулла, подойди сюда! – дип кычкырды офицер. Эчке бер тоемлау белән, ул халыкны тынычландырса бары тик мулла гына тынычландыра алачагына төшенде. Хәзрәт, шулкадәр тупас эндәшүгә гаҗәпсенеп, аңа күтәрелеп карады. Шулай да килде.

– Успокой народ, мулла! Успокой народ! Иначе!.. Никому от этого лучше не будет! Ну?!

Җәя керешедәй киерелгән, моңарчы офицерның күңелен нык тоткан кыл шартлап өзелде... Соңгы өметен җуярга теләмичә, ул хәзрәтнең изүенә ябышты, инәлеп гыжлады: «Прошу тебя!..»

Хәзрәт тыныч кына аның кулларын изүеннән алды. Мулла гына димәссең, кулы каты, көчле иде. Халыкка борылып: «Җәмәгать!» – дип эндәште...

Ату тавышы безнең геройларыбызга ничек тәэсир итте соң?

Ату тавышын ишетүгә, икесе дә җиргә чүкте. Раббани үзен кулга тиз алды. «Слушай мою команду! Короткими перебежками вперёд!» – дип кычкырды ул, урынныннан купкан күзләре белән Сөббухка карап. «Короткими перебежками» дигәне, сикереп торып, 20-25 адым бик каты йөгерәсе дә тагын җиргә капланасы икән. Берничә тапкыр шулай эшләделәр. Раббани армиядә булып кайткан егет шул, эш тәртибен белә. Ерагая төшкәч, җиргә капланмый гына элдерттеләр. Гаҗәеп дәрәҗәдә тиз һәм җиңел йөгерелә иде.

Тукталыш күренде. Автобус юк иде.

– Әллә килә, әллә юк! – дип кычкырып узды Раббани.

– Куып җитсә, утыртыр әле! – дип, кул селтәп үтте Сөббух. Йөгерү буенча разряды булмаса да, Раббани дустын әллә никадәр артта калдырды. Йөгерү рәвеше бик сәер: тигез генә юыртып барган җиреннән, башын кырыйга ташлый да, чыгымчы ат шикелле арт санын сикертеп-сикертеп чабарга тотына – һич куып җитәрмен димә. Үзе исә, чын спортчыларча, тигез сулап, көчен бик сарыф итмәскә тырышып йөгерде.

Шәһәргә кергәндә, өйләрдә ут ала башлаганнар иде. Урамда кешеләр: кемдер эштән кайта, кайсы кибеткә бара, кышкы матур кичтә саф һава суларга чыгучылар да юк түгел. Әнә, көлешә-көлешә кызлар үтеп китте. Ничек?! Тормыш һаман үз агымы белән агамы?! Дөньяда бернинди дә үзгәреш булмадымыни?! Булды бит! Булды! Дөнья элеккечә түгел! Дөнья үзгәрде!..

Көлешә-көлешә үтеп киткән кызлар сәбәпче булдымы, дуслар азмы-күпме тынычлана төште. Сөббух бүреген салды – башыннан пар бөркелде. Раббани куртка төймәләрен ычкындырды – шул ук хәл.

– Шәһәргә кадәр бертуктамый йөгереп кайттыкмыни без? – диде Сөббух, шаккатып. – Марафон дистанциясе бит бу!

– Полумарафон, – диде төгәллек яратучы Раббани.

Бу халәттә өйгә, сөекле хатыннар янына кайтып булмый иде. Сораштырып теңкәгә тиячәкләр. Әүвәл тынычланырга, фикерләрне тупларга кирәк иде.

– Бүген театрда Фоат абый дежур тора, – диде Сөббух.

– Мужик хәлен мужик аңлар. Киттек! – диде Раббани.

Кесәләрне кармалап, бер акбашлык җыйдылар. Бүген ансыз булмый иде. Беренчедән, тынычланырга кирәк; икенчедән, хатынның бетмәс-төкәнмәс сорауларыннан котыласың. Аракы исен сизүгә хатын: «Тагын кайда эчеп йөрдең, хайван?» – дип, бер генә сорау бирәчәк. Калган сораулар үзләреннән-үзләре төшеп калачак.

«Мужик хәлен мужик аңлады» – театрдан соң гына чыктылар. Кәефләр дә күтәрелеп киткән кебек булды.

– Бер пуля минем колак төбеннән генә сызгырып узды! – диде Сөббух мактанган сыман.

– Шул тирәләрне тагын бер әйләнеп кайтырмын! – диде Раббани, кыдрачланып.

– Йөрмә! – диде Сөббух нык итеп.

Сүзсез калдылар.

– Ни булып беткәндер анда? – диде Сөббух, иреке здән көрсенеп.

– Бүтән атмадылар бугай... Юк, атмадылар...Точно! – диде Раббани.

– Артка да борылып карамадык бит, – диде Сөббух, һаман ышанып җитмичә.

Куллар кысышмый гына аерылыштылар. Икесе дә сәер халәт кичерә: үзләрен яу кырын ташлап киткән солдатлар кебек хис итәләр иде...

...Бу гадәттән тыш вакыйга ничек булып бетте соң?

«Җәмәгать!» – дип кабатлады Нурислам хәзрәт. Башын күтәреп, кешеләргә карады. Сабыр гына шау-шуның басыла төшкәнен көтте.

Хәзрәтнең тавышы көчле түгел, әмма күңелгә үтеп керә иде. Берәү дә хәзрәтне бүлдерергә кыймады. Ул сөйләде дә сөйләде. «Сабырлык, тагын бер кат сабыр итү кирәк, җәмәгать!» – диде. Сабырлыкның адәм баласын бизи торган күркәм сыйфат икәнен кат-кат искәртеп, хәдисләрдән өзекләр китерде.

– Әйтер сүзең беттеме, хәзрәт?! – ачулы ир-ат тавышы даланы сискәндерде. Ул арада тавыш иясе үзе – якасын утыртып кыска тун кигән, имән кискәседәй нык бәдәнле ир-ат, урыныннан кубып, Нурислам хәзрәт янына килде.

– Әйтер сүзең беттеме, хәзрәт? – дип кабатлады ул.

– Сабыр иткән булсаң, әле сүзем бар иде, – диде хәзрәт, тыныч кына.

– Синең динең сабыр итәргә генә өйрәтә! – диде ир-ат.

– Ул синең динең дә!.. – диде хәзрәт, ачулана төшеп.

– Ул буйсынырга гына өйрәтә! – диде ир-ат, сүзен бирергә теләмичә.

– Бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә!.. – диде Нурислам хәзрәт, нык итеп.

Сүзсез калдылар.

– Таралышыйк, дисеңме, хәзрәт? – диде ир-ат, киңәш сорагандай.

– Әйе. – Нурислам хәзрәт, башын иеп, янә үз уйларына чумды.

Кешеләр таралыша башлады. Башлар иелде. Иңбашларга авыр йөк ятты. Аяк астында, ак кар булып, өметләр тапталды. Юк икән бу дөньяда гаделлек! Рәнҗү хисе, ризасызлык тойгысы, ачуташ булып, күңел төпкеленә төшеп ятты.

Зәңгәр курткалы барып краннарны ачты. ОМОН автобуска төялеп китеп барды. Кышкы көн кыска: караңгы төште.

Кешеләр киттеләр... Далада сүнеп баручы учаклар калды. Учаклар, җил исеп куйганда, утлы күмерләрен җемелдәтеп, янә дөрләп янып китәргә талпыналар кебек иде.

Учаклар сүнүгә, күктә йолдызлар кабынды...

II

Олы юлдан кар бураны туздырып чапкан җиңел машина борылышка җитәрәк туктады. Машинадан спай гына гәүдәле, җитү чәчләренә мул булып чал төшкән ир-ат чыкты.

Далада җәяүле буран себерә, салкын иде.

Ир-ат, җиленә-салкынына игътибар итми, басып торуында булды. Карашы халык телендә «качалка»лар дип йөртелгән нефть суырту җайланмаларына юнәлгән иде аның. «Ничә еллар буе көне-төне эшләп торалар. Бер дә ватылмыйлар микәнни соң? – дип уйлады. Уеның самимилегенә үзе үк көлемсерәп куйды. – Нәкъ минем халкым кебек». Чагыштыру көтмәгәндә килде.

«Нәкъ минем халкым кебек!» – дип кабатлады ир-ат.

Нигә килде ул монда? Үзе дә аңлап бетермәгән нинди сәер теләк тартып китерде аны бу салкын, буш далага?

Тукта... Ашыкма... Уйларыңны тәртипкә сал.

Шәһәр Татарстанда кара алтын чыгара башлауның 75 еллыгын бәйрәм итәргә җыена. Зурдан кубып тотындылар. Олуг юбилей шаукымы театрны да читләтеп узмады: менә аңа бик тә мәртәбәле исем – «Халык артисты» исеме бирелде. Нигә яшереп торырга, көтә иде ул халык артисты булуын, чак кына каушап, дулкынланып көтә иде.

Шулай да... нигә япа-ялгыз дала уртасында басып тора соң әле ул? Менә дивана баш! Ник килгәнеңне үзең дә белми аптырап тор инде!.. Юк, белә... Әй, искән җилдәй үтә дә китә гомер дигәнең... Ул вакыйгага да чирек гасыр гомер узган диген...

Кисәк кенә күз алдына, аермачык булып, аларның салкында кызарган усал (әмма явыз түгел!) йөзләре килде; колагында турыдан бәреп, кистереп әйткән сүзләре яңгырагандай булды.

Хәтер, бер дә карышмыйча, башын аска иеп, үз уйларына чумган Нурислам хәзрәтне, автобустан җайсыз сикереп, аягын авырттырган ОМОН сугышчысын кызганып: «Чү, балам, ипләп!» – дип әйтеп куйган ак сакаллы картны, аның кулын шытырдатып кысып (кул атна-ун көн авыртып йөрде): «Сәнгать безнең белән! Болай булгач, эш пешә!» – дип, балаларча куанган пәһлеван гәүдәле егетне күз алдына китереп бастырды... Күзаллау шулкадәр көчле иде, ир-ат хәтта сискәнеп куйды.

Шулай да...Кайсы сорау җанына тынгылык бирми соң аның?

Юк, ул артист язмышына зарлана алмый. Ул уйнаган рольләр, саный китсәң, йөзгә туладыр. Ниһаять, бу мәртәбәле исем...

Нинди образлар ижат итте соң ул? Әлбәттә, төрлесе булды. Ә менә АЛАР – күкрәкләренә мылтык төбәгәндә дә кыйбласын ачык белдереп, сүзен кистереп әйтә алган куш йөрәкле КЕШЕЛӘР булдымы аның геройлары арасында?!

«Юк» диясе килми иде...

Хөрмәтле укучы бу чал чәчле ир-атның безнең күптәнге танышыбыз: ул чакта яшь артист, хәзер Татарстан Республикасының халык артисты Сөббух Биккол икәнен, шәт, аңлагандыр.

Икенче танышыбыз кайда соң? Раббани Максудов бизнеска китте. Сүз уңаеннан әйтеп узыйк: эше гөрләп бара. Тик менә вакыт ягы... Сезнең белән тагын бер очраштырасым килгән иде дә... ярый соң, үпкәләмик. Ике дус күрешеп торалармы? Әлбәттә, күрешеп торалар. Кунакка да йөрешәләр. Раббани кунакка килсә, яшь чакларын, үзе уйнаган рольләрне сагынып искә ала. Күзләрендә – сагыш...

Сөббух кунакта булса: «Их, бу дөньяларда Раббани кебек бай яшәсәң иде ул!» – дип, дустының тормышына көнләшеп кайта. Әлбәттә, ак көнләшү белән. Дуслар ич... Шулай да, сәер бу дөнья!..

Ябалак-ябалак кар төшә башлады. Җилгә шул гына кирәк тә, кар бөртекләрен бөтереп алып, алар белән әйләп-бәйләп уйнарга тотынды. Салкын, колакларны чеметтереп, аяк киеменең юкарак булуын сиздерде.

Машина эчендә җылы иде. Термосын алды. Зиләсе чәйне, нәкъ ул яратканча, таман гына шикәрен салып, лимон белән ясаган иде. Чәй эчкәч, эченә җылы йөгерде. Салкынга инде чыгасы килми, ян тәрәзәне чак кына ачып, тәмәке кабызды. Янган шырпысына карап торды. Ут, бармакларын пешереп, соңгы тапкыр талпынып алды да сүнде. «Ул чакта соңгы талпыну булды микән?» – дип уйлады. Бу күңелсез уйны үзеннән тизрәк куасы килде...

Җил көчәйде. Буран күтәрелде. Болай юлда калуың да бар. Кузгалырга вакыт. Зиләсе дә: «Бәлеш салам, озак йөрмә!» – дип әйтеп калды. Соңламаска иде. Таба ризыгы мичтән төшүгә аеруча тәмле була.

Җиңел машина җай гына кузгалып китте дә, кызулый барып, ак кар пәрдәсендә югалды...

Түбән Кама шәһәре

Язучы, галим Җәвад Тәрҗеманов.



«Скульптор» Әмир (Буа егете) шагыйрь Роберт Әхмәтҗановны пьедесталга менгерә. 1995 ел.



«Идел» журналы редколлегиясе утырышыннан. Сулдан уңга: баш редактор Рашат Низами, рәссам Фәридә Хәсьянова, язучылар Рәфикъ Юныс, Нәбирә Гыйматдинова, Ләис Зөлкарнәй. 1997 ел.

Рашат НИЗАМИ әзерләде.



Әхәт Гаффар
әнисе Бибигайшә
Хөснетдин кызы белән.

Язучыларның секция утырышы. Флёра Тарханова, Дания Заһидуллина, Вакыйф Нуриев, Камил Кәримов, Газинур Морат, Әхәт Гаффар, Рабит Батулла, Әнәс Хәсәнов. 2016 ел.

Марсель Галиев, Әхәт Гаффар, Ләбиб Лерон, Әзһәр Шакиров. 2013 ел.

Әхәт ГАФФАР әзерләде.

КЕРЕШ СҮЗ УРЫНЫНА

Хәзерге татар шигъриятенә нигез салучыларның берсе, драматург, прозаик һәм публицист Һади Такташның (1900-1931) тормыш юлына һәм иҗатына караган аерым мәсьәләләрне актив өйрәнү соңгы елларда бу өлкәдә кала килгән күп кенә ак тапларны бетерергә ярдәм итте[1].

Һади Такташның Урта Азия, төгәлрәк әйткәндә, Бохара һәм Ташкент белән танышуы 1914-1918 һәм 1922-1923 елларга туры килә. Гаиләсенең матди хәле авыр булу сәбәпле, ул шушы якларга юл тота.

Хәзерге Үзбәкстан җирләренә татарлар XVIII гасыр ахыры – XIX йөз башында күпләп килеп төпләнә башлый: татар яшьләре Бохара һәм Сәмәрканд мәдрәсәләренә укырга керергә омтыла. Капиталистик мөнәсәбәтләр үсү һәм сәүдә-сәнәгать даирәләрендә яңа базарларны үз ихтыяҗларында файдалану теләге көчәю белән бәйле, күченү тагын да активлаша. Бу чорда җирле татарлар үзләштермәгән һөнәрне атап күрсәтү мөмкин дә түгел. Әмма иң күренекле төркемне сәүдәгәрләр тәшкил итә.

XIX гасырның соңгы унъеллыклары һәм XX йөз башында татарлар Төркестанда, җирле халыкның телен файдаланып, мәгърифәтчелек эшен җәелдереп җибәрә, газеталар чыгара, нәшриятлар, гарәп шрифты өчен җиһазлар кайтарта, уннарча җәдит мәктәбе ача. Татар зыялыларының мәгариф, театр, әдәбият, рәсем сәнгате һ.б. үсешенә йогынтысы зур була.

Татарларның Урта Азиядәге җирле халык белән якынаеп, дус яшәвендә дин уртаклыгы, биредә яшәүчеләрнең телләрен аңлавы, гореф-гадәтләрне, көнкүрешне, тормыш тәртибен белүе зур роль уйный.

Татарлар Төркестан халыкларының инкыйлаби хәрәкәтендә актив катнаша. 1917 ел вакыйгаларыннан соң да Урта Азиядә татар мәдәнияте шактый йогынтылы булып кала. Әлеге һәм соңгырак елларда Ташкентта татар телендә берничә газета-журнал нәшер ителә, милли китапханәләр, профессиональ театрлар, татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерли торган татар мәгарифе институты эшли.

Һади Такташ бу чорда яшь бохаралыларның җәдитчелек хәрәкәтендә, хәйрия фонды эшендә катнаша. Ташкентта чыга торган «Олуг Төркестан»[2] газетасында 1917 елның 21 гыйнварында аның беренче әсәрләреннән булган «Төркестан сахраларында» басыла. 1921-1922 елларда ул төбәкнең мөселман халкы: үзбәк, казакъ, таҗик, төрекмән, уйгур, татар, дүнгәннәр һ.б. өчен кадрлар әзерләү үзәге саналган Төркестан эшче-диһкан коммунистлар университетында укыта.

Бу язманың авторына, фәнни эзләнүләр нәтиҗәсендә, үзбәк газетасы «Кызыл байрак»ның[3] 1922 ел 22 февраль санында Һади Такташның зур булмаган «Скрипкә егълайдыр» дигән, җәмәгатьчелеккә билгесез лиро-эпик әсәрен табу насыйп булды. Гарәп графикасында язылып, ул шагыйрь Урта Азиядә яшәгән вакытта дөнья күрә.

Һ.Такташның «Скрипкә егълайдыр» әсәре зыялы, күп укыган, заманча автор белән очрашу тәэсире уята. Такташның теле гасыр башы мәгърифәтчеләре Бехбуди, Фитрәт, Айниның үзбәк теленә якын, әмма анда татар «акценты» да сизелә. Гарәп графикасының үзенчәлеге дә шунда: текст, төрки яки фарсы сүзләренең әйтелеш үзенчәлекләрен яшереп, аларның укылыш кыяфәтен-асылын тергезә. Шул рәвешчә, язмадагы үзбәк тексты кайчакта, әйтелештәгегә караганда, аңлаешлырак килеп чыга.

1920-1930 елларда Татарстан башкаласына Үзбәкстаннан язучылар делегацияләре

---

[1] Гайнетдинов М. Такташ һәм такташлык турында // Казан утлары. – 1991. – №1; Кудрецкая Э. И крылья свои опустил он устало // Идель. – 1996. – №9-10; Галиуллин Т. Егерменче еллар татар шигърияте // Мирас. – 1997. – №5; Хабутдинова М. Проблема личности в творчестве Х.Такташа: Автореф. дисс… – Казань, 1998 и др.

[2] «Олуг Төркестан» – милли, сәяси һәм әдәби газета. Төркестан төбәге татар җәмгыятьләре бюросы басмасы. Редакторы – Кәбир Бәкер. Ташкентта 25.04.1917 дән 26.11.1918 гә кадәр нәшер ителә.

[3] Бу газетаның исеме үзгәрешләр кичерә. Октябрь революциясеннән соң «Олуг Төркестан» базасында «Йштрокиюн» (1918-1920) газетасы оеша, аннары ул «Кызыл байрак» (1920-1922) исеме белән чыга. Баш редакторлар вазифасын бер-бер артлы күренекле татар иҗтимагый һәм сәяси эшлеклеләре Гариф Кләүлиев һәм Әхмәт Донской башкара. 1922 елдан газета яңача атала – «Төркестан» (1922-1924) һ.б.

килә. Иҗади көчләрнең очрашулары вакытында татар коллегалары белән тәжрибә алмашу күзәтелә. Мәсәлән, 1928 елда Казанда Гафур Гүләм, Хәмид Алимҗан, Зия Саид кебек язучылар һәм шагыйрьләрдән торган делегация булып китә. Татар вакытлы матбугаты битләрендә тугандаш республика тормышына багышланган язмалар, шулай ук килгән кунакларның шигырьләре, хикәяләре, очерклары, әдәби тәнкыйть мәкаләләре дөнья күрә. Соңрак, бу көннәрне искә төшереп, Г.Гүләм болай дип яза: «Безне бик кадерле, көтеп алынган дуслар кебек каршы алдылар. Газеталарда безнең укучылар, Татарстан хезмәтчәннәре белән очрашуларыбыз хакында отчётлар даими басылып торды. Мин иске дустым Һади Такташны очраттым (…). Ул миңа Казанны, аның тарихи урыннарын – Кремль, Сөембикә манарасы, «Печән базары», Г.Тукай әсәрләрендә исеме еш очрый торган «Болгар» кунакханәсен күрсәтте. Һади Такташ безне татар язучылары Гадел Кутуй, Демьян Фәтхи, Шамил Усманов, Афзал Шамов һәм Кави Нәҗми, шулай ук, «татар әдәбияты аңа бик зур өметләр баглый», дип, яшь шагыйрь Муса Җәлил белән таныштырды[4].

Үзбәкстанда Һ.Такташ иҗатына игътибар алга таба да сүрелми. Мәсәлән, 1932 елны Ташкентта, латин графикасында, үзбәк теленә Гафур Гүләм тәрҗемә иткән «Һ.Такташ шигырьләре» җыентыгы[5] нәшер ителә.

Үзбәкстанның мәдәни тормышында Такташның улы – академик, сәнгать белгече, рәссам һәм шагыйрь Рафаил Һадиевич (1926-2008) та якты эз калдыра. Ул озак еллар дәвамында Ташкентта яши, әтисенең истәлеген саклау өчен, бик күпне эшли, аның җир тормышына шушында нокта куела.

Йомгаклап, Һади Такташның фикер-идеяләрен, шигъри һәм чәчмә әсәрләр язу осталыгын өйрәнү, аңларга һәм бәяләргә омтылу – күренекле татар шагыйренә ихтирам билгесе ул.

Ринат ШИҺАБДИНОВ,
Үзбәкстан Республикасы Фәннәр академиясе
Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре

Һади
Такташ

СКРИПКӘ ЕГЪЛАЙДЫР

НӘСЕР

Скрипкә егълайдыр... ләкин Адәм балалары аның телен аңламайлар, алар аның егълау тавышына шадлана-шадлана уйнайлар. Ah, кызганычлар! Егълашдан, күз яшьдән – көлешкә, шадланышка үгрәнгән тупас күңелле Адәм балалары!

Скрипкә егълайдыр... Аның белән бергә минем йөрәгем һәм егълайдыр. Әйт, әйт, йөрәгем, нимә өчен син скрипкәнең моңлы кыллары белән бергә егълайсың?.. Яхуд скрипкәнең сабырсыз кыллары синең тамырларга барып тоташканмы?.. Яхуд скрипкәнең серле қыллары сиңа ачеллардагы күз яшьне, андагы газиз кардәшләреңнең бер бурда нанга тилмереп җан биргәндәге кебинге ah-зарларын искәртәләрме? Сүзләйләрме?..

Һа, һа, әнә адәм башларыннан өелгән тагълар... Ыржаеп торган сөякләрдән өелеп, канлар белән бизәлгән тәхет өстендә күз яшьләре мәрҗәнләре белән канлы бер таҗ киеп, «Ач үлем» утырадыр... Әнә ул үзенең кулындагы утлы зынҗырлары белән хөр илнең бahадир угылларын бөгеп үтерергә тырышадыр...

Әнә аек угыллары, «Ач үлем»нең мөдһиш тырнаклары астыдан котылышка телән,

[4] Гулям Г. Литературно-критические статьи (на узб.яз.). – Ташкент, 1971. – С.283-284.
[5] Н.Тақтош шеъерлари (Г.Гулом таржимаси) тўпламинин гмуқоваси. – Тошкент-Самарканд, 1932.

кибенке көчләре белән тартышадырлар. Алар, үзләренең аһ-зарларын бөтен дөнья халкына ишетдерергә теләп, бар көчләре белән кычкыралар... Алар «Күмәккә!» дигән байракларын, гарешләргәчә күтәреп, бөтен дөнья халкына күрсәтмәкче буладырлар.

Ләкин тупас күңелләр аларны күрмәйләр, алар йоклайдырлар...

Скрипкә! Өйрәт син миңа үзеңнең шомлы телеңне! Мин илгә тәмуг көйләре көйләен(м). Мин ачык хакыйкатьләр сүзләп, йоклаганнарны йокыларындан куркытып уятаен(м)!..

Кояш! Бир син үзеңнең нурыңны, бир ялгыз бер генә көнгә! Мин ил өстендәге күз яшьне, канны күрсәтәен(м) бөтен җиргә.

ӘСӘРГӘ КАРАШ

Һади Такташның беренче чор иҗатына караган «Скрипкә егълайдыр» нәсере шагыйрь лиро-эпикасындагы тәэсирле, җитлеккән әсәрләрнең берсе буларак игътибарга лаек. Шул ук вакытта текст инкыйлабтан соңгы чор татар әдәбиятындагы үзгәрешләрнең көзгесе, дия алабыз. Әсәрдә лирик герой күңелендәге хисләр палитрасы үз чорының тарихи вакыйгалары белән бәйле: **ачлык** *(«тәхет өстендә күз яшьләре мәрҗәнләре белән канлы бер таҗ киеп, «Ач үлем» утырадыр...»)*, **яңа тормыш төзү** *(«Күмәккә!» дигән байракларын гарешләргәчә күтәреп...»)* – аның күңелен кузгаткан сәбәпләрдән. Ул шуларга мөнәсәбәт белдерә, текстның соңгы абзацындагы кояшка мөрәҗәгать бу мотивларның шагыйрь тарафыннан иң мөһим, иҗатта җырланырга тиеш дип саналуы турында сөйли.

Шунысы да бар: 1920-1930 еллар әдәбиятында Һ.Такташ, Ф.Әмирхан, Г.Рәхим, Г.Кутуй, Н.Исәнбәт, К.Тинчурин кебек талантлар, иң беренче чиратта, милли сүз сәнгатенең иң уңышлы традицияләрен саклап калучылар кебек кабул ителә. Бу да алдыбыздагы нәсер мисалында раслана.

1916-1922 елларда Һ.Такташ символик-романтик әсәрләр – эчтәлеге белән легендаларга нигезләнгән һәм мифологик, символик образлар аша кешенең рухи хөрлеген данлаган, аны буып торган явыз көчләргә, гаделсезлеккә каршы ярсулы көрәш, гыйсъянчылык идеясен алга сөргән күп кенә әсәрләрен иҗат итә. Шуларны күзәтеп, Г.Рәхим Такташны «аермачык күзгә бәрелеп торган бер индивидуалист, «үземче», дип атый, татар әдәбиятына «өр-яңа бер нәрсә» – үзенчәлекле лирик герой алып килде, дип яза. «Ул көрәшә, ул җиһад игълан кыла – әмма иҗтимагый тигезсезлеккә генә, мәгълүм бер сыйныфка каршы түгел: ул бөтен инсаният галәме, моңарчы табынып килгән кодсияткә, күкләргә, Аллаларга, кануннарга, әхлакка, золымга, вәхшәт вә сугышка, тагын әллә ниләргә, әлхасыйль, инсанның шәхсиятен, аның шәхси иреген изүче никадәр көчләр бар, шуларның барысына бердән сугыш ача, протест ясый, «нәләтләр» яудыра. Менә шул ягы белән ул башка яңа татар шагыйрьләренең һәммәсеннән аерыла, үзенә башка бер «фронт» тәшкил итә»[1]. Шул рәвешле, үз чорында ук Такташның гыйсъянчы лирик герое – әдәбиятка алып килгән яңалыгы буларак бәяләнә.

XX гасыр башы татар әдәбиятында агым булып формалашкан гыйсъянчылык фәлсәфәсе кешене галәм язмышын һәм үз язмышын, башкалар язмышын хәл итәрдәй, үз кулына алыр дәрәҗәдәге көчле, гадәттән тыш итеп күргә теләү белән аерылып тора. Әсәрләрнең нигезендә яткан «мин – яшәеш» каршылыгында «мин» Аллага тигезләштерелә, «яшәеш» исә җир тормышын да, күк тормышын да берләштерә. Шушы юнәлештә иҗат ителгән «Газраилләр»ендә (1916) Һ.Такташ, дини мифологиядәге кешенең җанын алучы үлем символы Газраил һәм яхшылык теләүче, аклык-сафлык символы булган фәрештә образларын каршы куеп, яшәешне ике чиккә аера: вәхшәт, явызлык һәм җәннәт, гөлбакча. Шагыйрьнең гыйсъянчы герое җирдән матурлык һәм мәхәббәт сакчысы фәрештәне качарга чакыра: *«Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт, / Монда үлем, монда патша – газраилләр»*.

Бу герой – ниндидер билгесез золымга каршы чыгучы түгел, бәлки максаты ачык билгеләнә торган шәхес. Шигырьнең исеме астына шагыйрь «1914 елгы Европа сугышына каршы» дигән аңлатма бирә. Шушы ачыклау «сугыш – Газраил» янәшәлеге тудыра, Такташның гыйсъянчысы үлем алып килүче сугышка каршы чыга, кешеләрнең, бер-берсен үтерер өчен сугыш ачып, җир йөзен тәмугка әйләндерүен иң олы явызлык дип бәяли. Җирдәге золымга капма-каршы гүзәл урын – җәннәт хакындагы күзаллау китерелә, ул лирик герой омтылган хыял, идеал булып аңлашыла.

[1] Рәхим Г. Нәләтләр шагыйре // Безнең юл. – 1923. – №10-11. – 49 б.

Һ.Такташның «Күктән сөрелгәннәр» (1918) әсәрендә исә Газраил образы – күк Алласына каршы бунт күтәрүче, – җирдәге сугыш афәтенә түзә алмыйча, «Бетсен җирдә коллык, күз-яшь һәм кан!» дигән өчен күктән сөрелгән, зинданга ябылган шәфкатьле фәрештәне яклаучы, күк дөньясына каршы сугыш ачучы гыйсъянчы сурәтендә тәкъдим ителә. Лирик геройның җирдәге явызлыкка, кешеләрнең бер-берсенә каршы корал күтәрүенә нәфрәте шулкадәр зур, бу нәфрәтне сурәтләү өчен, шагыйрь явызлык һәм үлем символын Аллага каршы күтәрелергә мәҗбүр итә. Җирдәге золымга түзә алмаган фәрештә, күктә яклау табудан өмет өзгән лирик герой белән янәшә, әлеге гаделсезлектән гыйсъян күтәрүче Газраилнең соңгы сүзләре заман таләбенә ярашлы яңгырый: *«Китәм хәзер канлы үлем кырларына! / Сөйлим хаклык мәзлүм адәм улларына! / Биреп канлы кызыл байрак кулларына, / Ачам сугыш, салам киртә юлларына!»*

Такташ явызлыктан котылу юлы итеп инкыйлабны күрсәтә. «Мәзлум адәм уллары», «кызыл байрак» гыйбарәләре моңа дәлил булып килә. Шул ук елны иҗат ителгән «Үтерелгән пәйгамбәр» шигырендә Такташ инкыйлаби идеяләрне үзендә йөрткән кешене «пәйгамбәр» дип атый. Инкыйлабны тормышны камилләштерү максатыннан ялгыш кануннарга каршы чыккан азатлык өчен көрәш белән тиңләштерә.

«Скрипкә егълайдыр» нәсерендә дә шушы, тирә-яктагы кешеләрдән – «йоклай» торган «тупас күңелләр»дән – аерылып торган, скрипкә тавышында дөнья кайгысын тоя-аңлый, шуны үз күңеле аша уздырырга сәләтле үзенчәлекле кеше образы тудырыла. Ул адәмнәрне үлемгә хөкем итеп, аларның канлы мәрҗән күз яшьләреннән таҗ кигән «Ач үлем»гә каршы гыйсъян күтәрә, бу хис шулкадәр көчле: ул, хәтта, кояшка мөрәҗәгать итә. Әгәр инкыйлабка кадәр язылган әсәрләрдә татар гыйсъянчы геройлары өчен иң бөек мөрәҗәгать объекты – Аллаһы Тәгалә булса, бу әсәрдә аның Кояш белән алмашынуы – яңалыкларга дәлил.

Текст, нәсер таләпләренә буйсынып, берничә өлешкә бүленә. Башланып китүе Г.Тукайның «Милли моңнар» (1909) шигыре белән аваздаш: *«Ишеттем мин кичә: берәү җырлый / Чын безнеңчә матур, милли көй…»* Тукай лирик герое кебек үк, Такташ нәсеренең героен да скрипкә тавышы сискәндерә, Адәм балаларының аның тавышын аңлый алмавы сызланырга мәҗбүр итә. Бу интертекстуальлек Такташ текстын милли проблематика яссылыгына күчерә, андагы шартлы символик Адәм балалары образын – милләт вәкилләре кебек аңлау вариантын калкуландыра.

Икенче кисәктә лирик герой үзенең йөрәгенә мөрәҗәгать итә. Бу өлештә лирик геройның – нечкә күңелле, скрипкә моңын аңларлык булуы ачыклана. Шуның белән бергә геройны борчыган, аны кайгырырга һәм сагышланырга, скрипкә кебек моңланырга мәҗбүр иткән сәбәп бар: ул – ачлык, шул ачлыкта кардәшләрне югалту!

Шуның артыннан килгән өченче төп өлештә үзәк каршылык ачыклана: кеше белән ачлык арасында ул. Ачлыкның сурәтләнеше традицион, XX гасыр башы нәсерләрендәге, кешегә каршы явыз көчне тасвирлауга охшаш. Бу урында М.Хәнәфинең 1913 елда «Аң» журналында басылган «Мин төш күрдем» нәсерен искә алырга мөмкин. Адәм башларыннан өелгән тау, сөякләр, кан – барлык мәдәниятләрдә үлем символының детальләре. Канлы таҗның күз яше мәрҗәннәреннән ясалуы, кулындагы утлы чылбыр – Такташның шәхси табышы. Болар үлем символикасының эмоциональ көчен тагын да арттыра. Моннан тыш, күз яшенең XX йөз башы әдәбиятында хакыйкатькә төшенү билгесе икәнлеген[2] дә искәртергә кирәк. Бу сурәт, шулай ук, текстның XX йөз башы әдәбияты белән интертекстуаль бәйләнештә булуы турында сөйли.

Үлем белән тартышкан «хөр» илнең «баһадир» уллары «Күмәккә!» дигән байрак күтәргәннәр. Бу сурәттә советлар иленең яңа тормыш төзү символикасы күренә. Нәтиҗәдә, гыйсъянчы геройның иң зур теләге – җир өстендәге үлемгә, ачлыкка, гаделсезлеккә каршы чыгу белән янәшә, бөтенләй үзгә мотив пәйда була: «хөр» илнең «баһадир» уллары көрәше хакында дөньяга хәбәр итү омтылышы ул. Әлеге контекстта Такташ герое – яңа тормыш төзү җырчысы булып аңлашыла башлый. Шул рәвешле, иҗатның да, гыйсъянның да максаты үзгәрә: традицион эчтәлек яңа эчтәлек белән тоташа.

Әлеге күренеш Такташның шигырьләре мисалында да күзгә ташлана. Мәсәлән, 1921 елны шагыйрьнең иҗат кредосын билгеләүче «...Җил сөйли, үкерә миңа...» шигырендә гыйсъянчы лирик герой дөньяның явызлыгын кире кагуның да, аңа каршы

[2] Заһидуллина Д. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. – 87 б.

күтәрелүнең дә бернинди нәтиҗәгә китермәвен тасвирлый, әмма җирне һәм күкне үзгәртерлек иң олы көч итеп шагыйрь иҗатны күтәрә, дөньяны үз артыннан ияртер пәйгамбәр-шагыйрь, көрәшче-шагыйрь образы тудыра.

Инде «Нәләт» (1922) шигырендә илдәге янгын, золым, вәхшәт, аннан барлык фәрештәләрнең качып бетүе, үлекләр һәм кан тулы тормыш картинасы тудырыла. Шуның белән бергә, шагыйрь өр-яңа сурәт иҗат итә: *«Тау башында күп халык һәм канлы дар, / Нинди корбан? Кемне китергән алар? / Кем елый?.. Кем яшь түгә? Кем?.. / Эшче ул...»* Шагыйрь эшченең халык бәхете өчен үзен корбан иткән «яңа заман пәйгамбәре» булуы хакындагы фикерне ныгыта. «Бакчачылар» (1922) шигырендә гыйсъянчы герой үзгәрешләрне яңа тормыш төзүчеләр – бакчачылар белән бәйли. Боларның гади кешеләр булмыйча, яңа яшәеш коручы – Аллага тиң булачагын «бакчачылар» гыйбарәсе ныгыта. Язу стилендә үзгәрешләрне шагыйрь үзе «Такташ үлде» (1923) шигыре белән билгеләп куя.

Шулай итеп, образлар бирелеше ярдәмендә текстта инкыйлаби үзгәрешләр, яңа тормыш төзелешен иске тормышка каршы кую калкулана. Заман картинасын тергезү өчен, шагыйрь күп кенә символик образлар иҗат итә: Ач үлем, Адәм уллары, скрипкә – шундыйлардан. Такташта имажинистик, катлы-катлы сурәт тышкы дөньяныкы булып чыга, һәм ул гыйсъянчы лирик геройга каршы куела. XX йөз башы татар әдәбиятындагы лейтмотивка аваздаш «әкият»-миф тудырыла: гадел булмаган тормышны үзгәртү, Адәм балаларын бәхеткә илтү юлын шагыйрь алар күңеленә, акылына хакыйкатьне җиткерүдә таба. Текст шушы фикер белән төгәлләнә.

Башта ул, ярдәм сорап, иҗат символы булган скрипкәгә мөрәҗәгать итә: *«Скрипкә! Өйрәт син миңа үзеңнең шомлы телеңне! Мин илгә тәмуг көйләре көйләен(м). Мин, ачык хакыйкатьләр сүзләп, йоклаганнарны йокыларындан куркытып уятаен(м)!..»*

Бу мөрәҗәгатьтә текст буенча кабатланып килгән йокы мотивы бик мөһим. Йокы мотивы XX гасыр башы татар әдәбиятында тотрыклы, ул поэзиядә дә, прозада да төп мотивлардан санала. Татар иҗатчылары милли җәмгыятьнең хәлен – йокы халәте, үзләренең максаты – аны уяту, дип саныйлар. Лирикага әлеге мотивны гомум билгеле шигыре белән Г.Тукай («Йокы», 1908), лиро-эпикага – Ф.Әмирханның «Аң» журналының 1912 елгы беренче санында басылган «Шәрык йоклый» нәсере алып керә. Ул һәр шагыйрь яки язучы әсәрләрендә кабатлана, лейтмотивка әйләнә.

Лирик геройның кояшка дәшүе: *«Кояш! Бир син үзеңнең нурыңны, бир ялгыз бер генә көнгә! Мин ил өстендәге күз яшьне, канны күрсәтәен(м) бөтен җиргә»* – аның чарасызлыгын күрсәтә. Текст шушы ноктада төгәлләнә. Мондый күренеш Такташның бу чорда иҗат ителгән «Урамда» (1923) кебек шигырьләрендә күзәтелә. Әмма «Янар таулар»да (1923) инде шигырьнең герое – ялгызак бунтарь түгел. Ул – күмәк көрәшкә күтәрелүчеләрнең берсе: кояшка омтылучыларга, «бөек үч» белән кайнаучыларга дан җырлаучы лирик герой үз гыйсъяны турында түгел, бәлки меңнәр-миллионнар гыйсъяны турында сөйли.

Шулай итеп, Һ.Такташның чор идеологиясенә аваздаш шигырьләрендә дә тормышның традицион символик картинасы тудырылу, катлаулы сурәтләр, ритм хасил итүче кабатлаулар аларны, гомумән, 1920-1930 еллар татар шигъриятендәге примитивлыктан, лозунглар белән сөйләүдән, агитация рухыннан коткара. Инкыйлаби көрәш, тема буларак, шигырьләрнең үзәгенә куелганда да, Такташ романтик дөнья сурәте тудыра. Бу күренешкә игътибар итеп, Гали Халит билгеләгәнчә, революцион-тарихи перспективаны идеаллаштыру шул рухта чорның образлы ниндидер бер синтезын тудыру омтылышына китерә[3]. Әлеге күренеш без анализлый торган нәсер текстында дәлилләнә. Алга таба иҗат ителгән зур әсәрләрендә дә Такташ шушы табылган стильгә тугрылыклы кала.

Инде әсәрнең жанрына килик. Нәсер (гарәпчәдән: чәчү, тарату; чәчмә әсәр, проза) – татар әдәбиятында XX гасыр башында формалашкан үзенчәлекле лиро-эпик жанр. Асыл сыйфатлары ягыннан шигъри прозага якын тора.

Мондый формалар төрки-татар әдәбиятларында бик күптәннән яшәп килә. Күлтәгин ташъязмалары, һуннарның язма истәлекләре үк синкретик характерлы

[3] Халит Г. Шагыйрь. Чор. Герой. (Һади Такташ иҗатын өйрәнү тәжрибәсеннән). – Казан: Татар.кит.нәшр., 1971. – 31 б.

була. Татар халык авыз иҗатындагы каргыш яки теләкнамә жанры да форма ягыннан билгеле бер тотрыклы сыйфатларга ия. Ислам дине кабул ителгәч, безнең җирлектә гарәп югары прозасының бер төре – сәҗегъ (гарәпчә «күгәрчен гөрләве» дигән сүз), ритмик яктан камил чәчмә сөйләм популярлаша. Соңрак ул гарәп-фарсы, төрки әдәбиятларында сәҗегъ алымы, ягъни рифма һәм ритмга ия сөйләм тудыру, сәҗегъне кабатлау ярдәмендә хәрәкәт һәм халәт белдерү кебек сакланып кала. Сәҗегъ алымын кулланып язылган чәчмә әсәрне исә сәҗегълы нәсер, дип атыйлар.

Гомумән алганда, лирик проза күпчелек шәрык халыкларында матур әдәбият формалашкан дәвердә мәйданга чыга. Мәсәлән, Кытай әдәбиятындагы фу, япон әдәбиятындагы дзиюси жанрлары нәсергә охшаш, соңрак алар алым кебек тә кулланыла.

Татарларда «нәсер» сүзе XIX-XX гасырлар чигендә «чәчмә» мәгънәсендә йөри. Гасыр башы милли-мәдәни күтәрелеше вакытлы матбугатның кинәт үсеп китүенә китерә, газета-журнал битләрендә бик күп әдәби әсәрләр басыла. Ритмлы әсәрләренең тезмәдә (нәзым) түгеллеген искәртер өчен, авторлар исем астына «нәсер», ягъни чәчмә әсәр, дип ачыклык кертәләр. Нәтиҗәдә, «нәсер» сүзе жанр атамасына әверелә.

Мөстәкыйль жанр булып калыплашу өчен, яңа форма сәҗегъ алымына мөрәҗәгать итә, моннан тыш, Европа һәм рус әдәбиятларындагы «стихотворения в прозе» сыйфатларына, эссе һәм очерк (бигрәк тә лирик-фәлсәфи очерк) традицияләренә таяна.

Нәсердә төп эчтәлек хис-кичереш, мөнәсәбәт, күзаллау үзгәрү кебек тәкъдим ителә. Үзәккә лирик герой статусындагы субъектив образ куела. Форма ягыннан, кабатлаулар, инверсия, өзү, күпнокталар белән билгеләнгән пауза ритм тудыра. Кайчак рефрен булып кабатланучы гыйбарә текстны өлешләргә аера. Риторик эндәш, символларга еш мөрәҗәгать ителә.

Татар әдәбиятында нәсернең бик тә актив чоры – XX гасыр башы. Иң кызыклы авторлар буларак, Ф.Әмирханны («Татар кызы», «Шәрык йоклый…(Рәсемгә даир)», «Фәрештәләр җуатсыннар сине»), Ш.Әхмәдиевне («Шагыйрь моңая», «Кеше», «Сагыш»), М.Гафурины («Бу кемнең кабере?», «Тәэссорат (Җәй көненең төнге ай яктысында)»), Ә.Тангатаровны («Анама»,«Ни ул?») һ.б. атарга мөмкин.

1920-1930 елларда нәсерләрдә публицистик башлангыч көчәя. С.Җәлал («Егет һаман күренми иде», «Яз»), М.Максуд («Сагынам, сөям сине, туган илем!», «Изге көрәшкә!»), Ф.Әсгать («Без чәчәкләрдән сүзләр…», «Таш кала», «Бәхет») кебек авторлар иҗаты жанрны иҗтимагый эчтәлек белән баета.

Һ.Такташның «Скрипкә егълайдыр»нәсере нәкъ менә XX йөз башында формалашкан жанрлык хасиятләрен дәвам итүе белән үзенчәлекле. Шунысын да әйтергә кирәк: жанр төсендә нәсерне беренче тапкыр тулы тикшерү Һ.Такташ иҗаты мисалында, Г.Рәхимнең «Нәләтләр шагыйре» (1923) мәкаләсендә башкарыла. Монда галим «сәҗегъле (мөсәҗҗәгъ) нәсер» яки «аһәңле нәсер» жанрына хас сыйфатларны барлый: «анда бер билгеле әсәрнең башыннан ахырына кадәр үзгәрмичә яки мәгълүм бер тәртиптә тезелеп, нәүбәтләшеп бара торган вәзен булмый; бәгъдән вәзенлелек эзләре дә күренеп-күренеп китәргә мөмкин, ләкин ул мондый әсәрләр өчен лязем булган бер әйбер түгел, җөмлә төзелешендәге «аһәң», ягъни сүзләрнең бер-берсенә туры килеп, гармонияле бер агым тәшкил итүе, кайбер вакытта шуның өстенә тагы юл ахырларының кафияле (сәҗегъле») булуы аларда вәзен урынына тора»[4].

Һ.Такташ нәсерендә бу сыйфатлар тотрыклы. Әсәр күпсанлы һәм күптөрле кабатлаулар ярдәмендә тәэсирлелекне арттырырлык итеп язылган. Риторик эндәшләр аның эчтәлегендәге яңа мәгънәләрне ныгытып бара. Шәхсиләшү янәшәсендә символик, шартлы образларга мөрәҗәгать итү, кешене тормыш-яшәешкә каршы кую сурәтнең тирән, колачлы килеп чыгуына китерә. Әлеге нәсерне без Һ.Такташның XX йөз башы татар әдәбияты традицияләрен заманча эчтәлек белән кушу омтылышы ясалган иң матур әсәрләреннән дип бәяли алабыз.

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,
академик, филология фәннәре докторы

[4] Рәхим Г. Нәләтләр шагыйре // Безнең юл. – 1923. – №10-11. – 62-82 бб.

Фатих Кәрим (1909-1945) безнең күңелләрдә шинельле, автоматын кулдан төшермәгән, Ватанга тугры изге зат – олуг шагыйрь булып яши. Аның:

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла.
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була,

– дигән юлларын кем генә хәтерләми икән?!

Татар поэзиясенә, Х.Туфан, Һ.Такташларның чордашы булып, 1927-1928 елларда ук килеп керсә дә, утызынчы елларда «Җиденче мич», «Яшен яктысы», «Илле егет» кебек шигырьләре белән үк шигъриятта үз урынын алса да, ул безгә сугыш чоры иҗаты белән аеруча якын. 1945 елның 19 февраленә, ягъни батырларча һәлак булганчыга кадәр аның солдат булып та, шагыйрь булып та Ватанга багышланган гомере меңьяшәр шигъриятендә дәвам итә. Ул сугышчан батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены, Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

Фатих Кәрим 1937-1941 елларда, «халык дошманы» тамгасы сугылып, төрмәләрдә интегә, 1942 елда сугышка китә. Сугыш чорында, өч ел эчендә 150ләп шигырь, 8 поэма, 2 повесть, драма әсәре яза. Аларда халкыбызның күпсанлы образлары гәүдәләнә.

Без, шагыйрьнең 110 еллыгы уңаеннан, аның сугышта иҗат иткән шигырьләрен укучыларыбызның хәтерендә кабат яңартырга булдык...

Фатих Кәрим

ИЛЕҢ ТУРЫНДА УЙЛА...

***

Сөйләр сүзләр бик күп алар,
Иренмичә сөйләсәң;
Озын сүзнең кыскасы шул:
Күп яшәргә теләсәң,

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла,
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

Сибәли дә сибәли

Төнге җилдә көзге яңгыр
Сибәли дә сибәли;
Янымдагы иптәш кенә
Миңа берни сөйләми;

Уема да кертмәдем мин
Аның бу төн үләсен,
Разведкадан кайткан чакта
Тиде немец пулясы.

Өс-баш юеш. Көрәкләргә
Үзле балчык сылаша;
Кабер казыйбыз тынлыкта,
Җил генә ыңгыраша.

Кайгыдан каралып торган
Япь-яшь нарат төбенә
Япь-яшь иптәшне күмгәнне
Күрә бары төн генә.

Япь-яшь иптәшне күмәбез,
Беркем берни сөйләми,
Көзге төндә яңгыр гына
Сибәли дә сибәли.

Окоп

Көзнең күк томанлы таңында
Мин фронтка килдем тагын да.

Мылтык яңа, дуслар да яңа,
Окоп иске, таныш мин аңа.

Сержант та дус булып өлгерде,
Консервы һәм граната бирде:

«Консервысын үзең ашарсың,
Бусын... немецларга ташларсың».

Кидем башка корыч каскамны,
Гранатамны билгә асканмын.

Мылтык яңа, дуслар да яңа,
Окоп иске, таныш мин аңа.

Җиңү җыры

Без яшенле давыл кебек
Айкап киләбез.
Илгә бәхет, шатлык даулап,
Утка керәбез.

Кичәбез киң дәрьяларны,
Урман, тауларны.
Давыл кебек туздырабыз
Дошман яуларын.

Без ант иттек, куроклардан
Кулны алмабыз.
Бөтен дошман берләшсә дә,
Җиңми калмабыз.

Бу җиңүнең онтылмаслык
Данлы булуын
Иң матур җыр итеп җырлар
Киләчәк буын.

Син еракта

Кадриягә

Син ерак миннән ерагын,
Ераклыкка карамый,
Яраласа мине дошман,
Ул сине дә яралый.

Ялгышмыйк без, ерак түгел
Сугышта безнең ара,
Мәхәббәтең минем белән
Атакаларга бара.

Кahәрле дошманга төзәп
Мин мылтык аткан чакта,
Гүя син патроннар салып
Торасың минем катта.

Ә шулай да... син еракта,
Мин тик хатыңны күрәм,
Хатка язган сүзләреңне
Күзләрең итеп үбәм...

Ил язмышын даулаганда
Аерылышкан кешеләр,
Зур кайгыга төшсәләр дә,
Караңгыга төшмиләр.

Кайгырма син

Яңгырый яз: кыр казлары кайта,
Кар сулары гөрли басуда;
Атыш тынган ара җай китереп,
Кулъяулыгы юам бу суда.

Ак кулъяулык элеп куям җилгә,
Җил тирбәтеп аны киптерә;
Сизәм-сизәм, язның дәртле җиле
Синнән миңа сәлам китерә.

Сагындыңмы, бәхет күгәрченем?
Мин дә менә урман буенда,
Талгын гына йомып күзләремне,
Җанландырам сине уемда.

Гүя хәзер безнең һөҗүмнәрне
Сөембикә манарасыннан,
Чәчең җилфердәтеп язгы җилдә,
Бәгърем, карап торасың сыман.

Ерагаясың дип кайгырма син,
Без дошманны куып барабыз;
Никадәрле ерак куа алсак,
Шулкадәрле якын арабыз.

Эчәр өчен салкын кар сулары,
Әй, чылтырап ага басуда;
Кар суында кулъяулыгы юам,
Мин кайгымны юам бу суда.

«МАЛАЙКА»

ОЧЕРК

Йокысыз төн

Аны нужа бик яшьли куып йөртте. Тормыш тегеләй дә, болай да сынады...

Гали ишле гаиләдә үсте. Сугыштан соңгы ачлык еллары, авылларда михнәт чигүләр аның да җанын күп тапкырлар тетрәндерде. Ничарадан бичара хәлендә калган яшүсмер Галинең күңелен, тора-бара, фәкать бер уй биләде: алга таба ничек көн күрергә, ничек ачлыктан исән-сау яшәп калырга?..

Әйе, инде сугышлар бетсә дә, илленче елларда аның әти-әнисенә ишле гаиләне туйдыру ифрат та авыр иде. Шул михнәтләрне күреп яши торгач, ахыр чиктә, ул да түзмәде, алтынчы сыйныфны тәмамлагач, теләсә-теләмәсә дә, туган авылы Баландыш белән озакка хушлашты...

Шушы фикергә килү болайрак та булды: бер көнне ул төнлә, йокы аралаш, әтисе белән әнисенең сөйләшкән тавышларын ишетеп калды:

– Балаларны таптык та таптык табуын, – диде әтисе Мәгъсүм, аптырап. – Хәерчеләр генә арттырдык… Инде хәзер шул балаларны ничек туйдырырга белгән юк. Өстәл артында тезелешеп утыралар да, тәмам артык кашык кебек, нәүмизләнеп, күзгә карап торалар…

– Нишлисең бит, – диде әнисе Гөлшаһидә, бу сөйләшүне авыр кичереп. – Дөньяга килгәч, аларның да яшисе бар… Юкса, мин аларны сыныкка туймасыннар өчен таптыммыни? Якты киләчәккә өметләндереп: өндәделәр, таладылар, сөрделәр…

Алар икесе дә, шулай сөйләшә-сөйләшә, иртәгесе көнгә өмет баглый-баглый, йокыга талды. Тик Гали генә йокыга китә алмады. Әтисе авызыннан ишетеп калган «артык кашык» гыйбарәсе аның бәгырен телгәләде… Әйтерсең, бу аның үзенә генә атап әйтелде. Һәм ул, борсаланды, күңелендә сорау арты сорау туды: миңа нишләргә, кая барырга? Әллә берәр училищега укырга китәргәме? Әнә, Казанның 7 нче һөнәр училищесында укыган авылдашы Сәлим ничек кенә киенеп кайтмаган?! Өстендәге курсант формасы үзенә килешеп, сыланып тора. Сокланып туймассың! Аякларында ялтыравыклы ботинкалары… Безнеке кебек тишек галуш түгел инде…

Икенче көнне ул мәктәпкә укырга да бармады, уйлашырга дип, шыр ятим үскән авылдашы Госман янына китте.

– Госман! – диде ул, зур яңалык әйтергә җыенгандай. – Әйдә, без дә, Сәлим укыган училищега барып карыйк әле?

– Казангамы?

– Әйе, шунда берәр һөнәргә дә өйрәнербез.

Гали җиденче сыйныфка укырга бармады. Укытучы Саимә апасы: «Җиденче классны тәмамласаң, син безнең мәктәптә дә эшли аласың, – дип тә үгетләде, – җыр дәресен булса да укытырсың. Гармуныңда уйнап, «Сарман» көйләрен бер сыздырып җибәрерсең. Тавышың, моңың бар…»

Укытучы апасы белән килешмәде ул, «китәм тек китәм…» янәсе, «артык кашык булып яшәгәнче...»

Әйе, аңа инде авылы Баландыш мәктәбендә «Сарман» көйләрен уйнарга, җырларга туры килмәде. Үҗәтлеге җиңде, аны ерак юлга чакырды…

...Алар, Госман белән икесе, Казанга юл алдылар. Калага килеп җиткәч,

җиденче училищены да эзләп таптылар, Сәлимнең үзен дә күрделәр. Аннары ул авылдашларының директор кабинетыннан чыкканын да көтәргә булды.

Егетләр, кыюсыз гына кергәч, директорның ишек төбендә туктап калдылар.

– Тыңлыйм сезне? – диде аларга кызыл галстук таккан урта яшьләрдәге ир, егетләрне баштанаяк күзәтеп. Һәм ни әйтерләрен көтте.

– Безне училищега укырга алыгыз әле, – диде чаярак Гали, кыюлана төшеп.

Директор, авыл егетләре күңелен аңлаган хәлдә, җавапны бераз көттерде, аннан үз карарына килеп кырт кисте:

– Набор бетте, алмыйбыз… – диде.

– Кайда алырлар икән? – диде Гали.

Директор бу юлы иңбашларын гына сикертте:

– Белмим… Бәлки, «Соцгород»тагы 16 нчы училищега барып карарсыз. Анда слесарьлыкка укыталар…

Казанның «Соцгород» шәһәрчегендәге уналтынчы училищесын да эзләп таптылар. Биредә училище директоры хатын-кыз иде. Кыяфәтенә караганда, шактый ук горур да күренә, кабарынкы соргылт чәчләре һәм күкрәкләре мин-минлеген дә сиздереп тора кебек. Ул, егетләргә ачык чырай күрсәтергә ашыкмый гына сорап куйды:

– Кайсы районнан килдегез?

– Сабадан.

– Кайсы авылдан?

– Баландыш авылыннан.

– Белемегез?

Егетләр бер-берсенә карашып алды. Гали, колхоздан китәргә бернинди рөхсәт юклыгын аңлап, җавапны үзе тотты.

– Алтынчы классны тәмамладык…

– Яхшы, – диде директор, ризалашып һәм егетләрнең исем-фамилияләрен журналына язып та куйды. – Җиденче группада укырга тиеш буласыз. Сидоров Геннадий Петрович группасында. Хәзер аны күрерсез, ул нишләргә кирәген үзе аңлатыр…

Егетләрнең, директор бүлмәсеннән чыкканда, башлары күккә тигән иде!

Җиденче группа җитәкчесе Сидоров егетләргә күрсәтмәләрен бирде:

– Хәзер тулай торакка урнашыгыз, комендантка шушы записканы бирегез. Ул бүлмә мәсьәләсен хәл итәр. Аннары мунча керерсез, формалар алырсыз…

Егетләр барысын да группа җитәкчесе кушканча эшләде. Күңел дигәннәре шатланып туймады. Шәһәр мунчасында юынулар үзенә бер рәхәт ич. Формаларны кигәч, куанычлары эчләренә сыймас дәрәҗәдә булган иде дә... Ләкин...

Менә алар икенче көнне төркемдәшләре белән сафка да чыгып бастылар. Бераздан Геннадий Петровичның командирларча әмере яңгырады:

– Сафин Гали, Кашапов Госман, выходите из строя!..

Аннары Геннадий Петровичның икенче әмере яңгырады:

– Хәзер үк директор кабинетына, Ольга Николаевнага кереп чыгыгыз. Ул сезне үзендә көтә.

Чыннан да, Ольга Николаевна аларны көтеп тора иде.

– Керегез! – диде, егетләрне ярым ачык калган ишектән күреп алып.

Көтелмәгән бу хәлдән алар, директор кабинеты ишеге төбендә тукталып калды. Авыр тынлыкны директор үзе бүлде:

– Менә нәрсә, егетләр, без сезне училищега кабул итә алмыйбыз. Сезнең белемегез җитеп бетми, гәрчә алтынчы сыйныфны тәмамласагыз да… Так что не получается… – Һәм ул як-якка кулларын гына җәйде.

Егетләр бу хәлгә ышанырга теләмәде. Ничек болай була инде? Группада алтынчы сыйныфны тәмамлаган укучылар да бар бит? Ни чарадан бичара хәленә төшкән Гали, директор каршына ук килеп тезләнде дә, аның аякларын кочып алып:

– Апай! Зинһар, калдырыгыз безне училищеда?.. – диде һәм болай дип тә өстәргә мәҗбүр булды: – Безнең әти-әниләребез дә юк… – Аннары ул елап ук җибәрде.

Ханымның бу кадәресенә дә исе китмәде, кабарынкы чәчен кулы белән тарагандай сыпырды да кырыс тавыш белән кырт кисте:

– Что это такое? Вставайте сейчас же…

Гали, теләр-теләмәс кенә, аягына басты һәм чигенә-чигенә китәргә мәҗбүр булды…

Сөмсере коелган үсмерләр, директор кабинетыннан, ризасыз гына, башларын иеп чыгып киттеләр. Аннары, формаларын салып, иске киемнәрен табып киярга мәҗбүр булдылар. Егетләр әлеге хәлнең серенә төшенеп бетмәделәр шул... Чынлыкта балаларын урнаштырырга дип, кәттәрәк кешеләр килеп чыккан иде... Алар директорны кызыксындыра белгәннәр. Инде шул вакытта ук ришвәт дигән нәрсә тамыр җәйгән булган. Егетләргә әле гаделлек төшенчәләренә төшенергә, «син – миңа, мин – сиңа!» принцибын аңлап җиткерергә иртәрәк иде шул…

Инде хәзер нишләргә? Шушы сорау урамда калган егетләрне бер-берсенә каратты. Аларның, барыбер дә авылга кире кайтасылары килмәде. Аеруча Галинең, әтисе авызыннан ычкынган «артык кашык» дигән сүзләр, янә дә исенә төшеп, күңелен тынгысызлап тора иде. Шулай аптырап, шәһәр урамнарында каңгырап «адашып» йөргәч, ахырдан алар Ульяновск шәһәре ягына бара торган бер поездга утырып киттеләр. Анда да училищелар бар дип ишеткәннәр иде. Кем белә, бәлки, берәр җае чыгып куяр әле.

Поезд Арзамас станциясенә кадәр алып килде. Тукталышта торган арада, егетләр, тамак ялгап алырга дип, вагоннан төшкәннәр генә иде, сакчы милиционерлар, «бу нинди «беспризорниклар тагы», дип, аларны эләктереп тә алды. Ярый әле җавап тотканда, үзләренең каян икәнлекләрен яшерә белделәр, юкса туган якларына кире җибәрәчәкләр иде. Аннары, «беспризорниклар» буларак, Лукаянов шәһәрендәге детдомга озаттылар… Ахырдан алар моңа да бик сөенделәр. Аеруча ятим Госман куанды.

Детдомга эләккәч, тамакка да ярыйсы гына тиенелде. Һөнәр эшенә өйрәтергә керештеләр, ФЗӨ дә укыдылар. Гали бик тырышты, бар эшкә дә теләп алынды. Һөнәрсез бер эш тә кырып булмаслыгын яхшы аңлады ул. Мастерскойда тимерен дә игәде, гайка, болтларын да борды. Техникага хирыслыгы артканнан арта барды. Ул инде, агач арбаларны җитәрлек тарткан кеше, хәзер исә, азмы-күпме сызымнарга да төшенә башлады.

Бер көнне, дәрестән кайтып барганда, урамда аны таныш булмаган бер ир туктатты:

– Әй, егет, син кайдан?

Гали, чит-ятлар «кармагына» эләгүдән сагаепмы, әйтергәме, әйтмәскәме дип, аптырабрак калды. Аннары, бу ирнең зыянлы кешегә охшамаганлыгын сизенгәч, әйтеп куйды.

– Татарстаннан…

Аның «Татарстаннан» дигәнен ишеткәч, ир кешенең йөзе ачыла төште һәм ул икенче соравын бирде.

– Исемең ничек, малайка?

– Гали.

– Ә мин «дядя Володя» булам. – Ул егеткә кулын сузды. – Таныш булыйк…

Ул, ихтыярсыздан, үзен «Малайка» дип яратып кына дәшкән «дядя Володя» артыннан иярде. Һәм ялгышмады. Оста куллы, тәжрибәле ир, кара чәчле, тут йөзле авыл егетенең күзләрендә эшкә дәртләнеп, янып торуын да сизemли алды. Соңрак аның һәрнәрсәне отып, тиз аңлап алу сәләтен дә чамалады һәм алар бер-беренә тиз ияләшеп киттеләр, төрле-төрле эшләргә дә җигелделәр: түбә дә яптылар, бетон да койдылар. Инде аралаша торгач, «дядя Володя»ның комбайнчылар әзерли торган һөнәри-техник училище мастерскоенда практика дәресләрен алып барганлыгы да ачыкланды. Шушы танышлык аңа, бер елдан соң, комбайнчылар әзерләү курсында укып чыгарга ярдәм итте…

Яшь комбайнчы Гали, Горький өлкәсенең Лукосовский районына эшкә җибәрелде. Ул шундагы бер колхозда «Сталинец-6» комбайнында урып-җыю эшләренә кереште. Беренче елны ук, яшь белгечләр арасында беренче урынны яулады. Ә икенче елны аны, үз теләге белән, чирәм җиргә – Казакъстан далаларында үскән игенне урып-җыярга

җибәрделәр. Тракторын да, комбайнын да йөртә белмәгән чакта, күп нәрсәләргә өйрәткән, тормыш сабакларына төшендергән «дядя Володя» үз «Малайка»сын озатырга килде, хәерле юллар теләп калды… Мең рәхмәт аңа!

Икмәктә – хикмәт...

Бер поездда чирәм җиргә баручы утыз ике кешедән торган механизаторлар төркеме, ниһаять, Казакъстанның Актүбә шәһәренә килеп тә җитте. Төрле-төрле җирләрдән җыелган кешеләрне башта шунда тупладылар. Аннары, кайсын кая, төркем-төркем итеп, район хуҗалыкларына озаттылар. Гали Биргизск районының зур гына ундүрт бригададан торган Тжабас совхозына килеп эләкте һәм шунда төпләнеп эшли башлады.

Инде моңарчы да шактый тәҗрибә туплап өлгергән тырыш егет, Казакъстан далаларында гөрләп үскән иген басуларына килеп кергәндә, үзе дә шул иген басуларыдай дулкынланды. Ул, әле кайчан гына бик тә тансык булган, гәрәбәдәй эре бодай бөртекләрен уч төпләрендә дә уып-уып ашады. Яшьтән үк күңеленә сеңеп калган шул бөртекләр аңа бүген дә бик кадерле. Күңеле янә дә бер кат шуңа инанды: барысы да ашауга, тамакка бәйле… Аңа да, туган иленнән бер чыгып киткәч, үз көнен үзе күрергә калды...

Ул көннән-көн уңышлары белән куанды да куанды, үзе иярләгән «С-4» комбайны оста хуҗасын «тыңлаучан» булып чыкты. Чөнки Гали катлаулы техниканың һәр механизмын җаны белән тоеп эшләтте, аны вакытында җайлый, көйли белде.

Тырышып эшли торгач, аның техника серләренә яхшы төшенүен дә, әзерлеген дә бик тиз күреп алдылар. Совхозның баш инженеры Кунубаев, кайсы комбайн чыгымлап, эшләми башласа, Гали янына тиз генә килә торган иде. Килә дә, бераз кысынкырак күзләрен ача-йома төшеп:

– Гали агазан! – дип, казакъчалап кына сүзен башлый. – Анда өченче бригадада эшләүче Курлабәкнең комбайны туктап калды. Әйдә, тиз генә шунда барып килик әле, нәрсәдә икән хикмәте?

Гали тыңлады, карышмады, чакыргач барды, комбайнның хикмәтле серләренә казакъча да аңлатып, төшендереп бирде. Ул инде аларча сөйләшергә дә өйрәнгән иде.

Шулай, беркөнне, Галине совхоз директоры Теләү Асамбаев үзенә чакыртып алды. Ул, хуҗасына кергәнче, «нәрсәгә чакыра икән?» дип, бераз борчылган иде. Кабинет ишегеннән узгач, хуҗа, кояшта каралган тут йөзенә яктылык сирпеп эндәште:

– Килдеңме, егет, әйдә, уз, утыр. Эшләрең барамы?

– Бара болай… – диде Гали, аннары кыюлана төшеп өстәде: – Тырышабыз инде, кирәк бит…

– Тырыш, тырыш… Үкенмәссең. Безгә синең кебек кадрлар бик кирәк. – Директор иркен сулап куйды да дәвам итте: – Алдынгылар рәтендәсең, молодец...

Әңгәмә барышында Гали кылт итеп башына килгән уен да әйтеп салды:

– Тагын да югарырак күрсәткечләргә ирешеп булыр иде дә, – диде ул, бераз уфтанып, – ерактагы кырларга барырга-кайтырга вакыт күп китә. Транспорт мәсьәләсе катлаулырак, гел дә вакытында гына килеп тә җитмиләр йә соңаралар...

Директор хикмәтнең нәрсәдә икәнлегенә тиз төшенде:

– Иптәш Сафин, син велосипедта йөри беләсеңме?

– Беләм, – диде Гали, йөрергә өйрәнүне кыенга санамый. – Ул велосипедны каян аласың бит?

– Мин сиңа үзем велосипед алдыртып бирәм, теләгәнчә йөрерсең. Нәрсә, килештекме?

Гали куанычыннан елмайды гына. Аннары директор сүзен дәвам итте:

– Менә нәрсә, энем, миңа кичә военкоматтан чыктылар. Синдәй призывник яшендәгеләрдән кемнәрне армиягә алырга, кемнәрне калдырырга, дип. Мин сиңа ике ел «отсрочка» бирдерттем. Тора-бара тагын күз күрер. Бездә эшләрсең, кышын, язын техника паркында төзәтү эшләре белән шөгыльләнерсең. Килештекме?

Гали, ризалыгын белдереп, баш какты. Аннары, Асамбаев, калын иреннәрен җәя төшеп, елмайды да болай дип өстәде:

– Әгәр дә өйләнәм дисәң, без сиңа матур гына бер казакъ кызын табып бирә алабыз. Әнә, безнең бухгалтериядә эшләүче Дәрзәнәй дигән кыз менә дигән… Ошаса, бик теләгең булса, диюем…

Гали көтелмәгән тәкъдимнән бераз сагаеп калды:

– Миңа өйләнү турында уйларга иртәрәк әле. Әти-әниләргә булышмый булмый… Әпәйгә дә туймый ач утыралар…

Шушы минутта Асамбаев иң мөһим сүзен исенә төшерде дә:

– Без сиңа, энем, – диде ул, күтәренке рух белән, – эшләгән хезмәт хакыңны, тәртип буенча, икмәкләтә дә түләрбез. Өч центнер икмәк сиңа премияләтә тиеш, тагын, сезон нормасын үтәгәнгә, гектарыннан чыгып күпмедер бар… Эшләгән икмәгеңне әти-әниеңә хет бүген-иртәгә җибәртә аласың.

Шушы минутта Галинең тулып ташыган куанычы йөзенә үк бәреп чыкты! Аннары аңа, озак та тормый, әти-әнисенең адресын күрсәтеп, бер тоннага якын икмәккә тиешле кәгазь-документларны тутырып, аларны Саба районының Шәмәрдән станциясенә юлларга туры килде. Әти-әнисе икмәкне шуннан барып алырга тиеш булды.

Гали директор Асамбаев кабинетыннан канат ярып чыккан көннән эшкә велосипедта йөри башлады...

Ә беркөнне аңа туган авылыннан хат килеп төште. Хатны, әти-әнисе кушуы буенча, Гомәр абыйсы язган. «Улым! Без сиңа бик рәхмәтле. Көтмәгәндә безгә, игелекләр кылып, җибәрттергән бер тонна икмәгеңне үзебезнең Шәмәрдән станциясеннән барып алдык. Бик куандык. Ачлыктан да йолып калгандай булдың... Шатлыктан күңелләребез тулып еладык та… Бу хәлгә авыл халкы да шаклар катты. Кемнәрдер уйлавынча, «качкынлыкта, зимагурлыкта» йөрмәгәнлегеңә дә ышандылар, мактап-мактап телгә алдылар. Хатларыңны өзмә, сиңа барчабыздан күптин-күп сәламнәр юллыйбыз, исәнлек-саулык теләп калабыз.

Әтиең, әниең. 10 октябрь,1954 ел».

Сәфәргали әти-әниләреннән килгән хатны кат-кат укыды, аны кесәсендә шактый вакыт саклап та йөртте.

***

Ә беркөнне Сәфәргалине янә үзен хөрмәт иткән совхоз директоры Теләү Асамбаев дәштерде. Аның янында озын гына гәүдәле военком да мыекларын тырпайтып утырып тора иде. Ул шунда ук уйлап алды: «Димәк, мине, ике ел вакыт узгач, армиягә алырга җыеналардыр инде…»

Иң элек совхоз директоры, сүз башлап, военкомга мөрәҗәгать итте:

– Иптәш майор! Без бу Сафинны армиядән калдырып торырга дип, ике елга отсрочка бирдерткән идек бит...

– Анысын беләм, беләм… – диде майор, кашларын җыерып.

– Бу егетне тагын ике елга калдырасы иде.

– Армиягә дә кешеләр кирәк ич.

– Кирәген кирәктер дә… Бу егет бүген совхозда тагын да кирәгрәк кеше бит. Ансыз безнең эшләр бармый. Ул берүзе ун казакъ егетенә торырлык! Армия сафларын казакъ егетләре белән тулыландыра төшсәгез безнең өчен әйбәтрәк булыр иде.

Майор, нишләргә соң дигәндәй, аптырап, башын кашып алды. Совхоз директоры сүзен дәвам итте:

– Без быелгы эш күрсәткечләре буенча комбайнчы Сафинга «Хезмәттәге уңышлары өчен» дигән медаль бирергә әзерләндек. Инде документлар да тутырылган. Шул медален алсын инде. Егет аңа бик лаек…

– Ярар, бу мәсьәләне утырып уйлашырбыз… – диде майор, үз-үзенә нәтиҗә ясагандай.

Шуннан соң Гали, китәргә дип, ишеккә юнәлде. Ул урамга чыккач та, бу сөйләшүдән канәгать калган иде. Хезмәтен дәрәҗәләп, медаль биреләчәгенә янә дә куанып сөенде.

Ниһаять, көтеп алынган көннәр килеп тә җитте. Аны тагын ике елга армиядән

калдырырга отсрочка бирелде. Вәгъдә ителгән медальне совхозның алдынгыларны котлау җыелышында тантаналы рәвештә зурлап тапшырдылар. Аның башы янә күккә тигәндәй булды һәм ул бу җыелыштан үзе яшәгән йортка канатланып кайтып керде. Хуҗабикә Гөләндәм апасы белән дә ачылып кына исәнләште. Аннары Гөләндәм ханым күңеле күтәренке Галигә:

– Сиңа авылыгыздан хат бар, өстәлең өстенә куйдым… – диде.

Хат Гомәр абыйсыннан килгән иде. Ачып укый башлагач, Галинең йөзе кинәт торып-торып үзгәрде, уйларга да салды, күңелен җилкендерде. Ул хаттагы юлларга кабат-кабат игътибар итте: «…Энем! Кайт инде, җитәр… Болай читтә йөрүләреңкүпкә китте. Синең өчен әти-әни бик тынгысызлана. Саулыклары да таманга гына калып бара. Интегүләре җиткән. Алар безнең ярдәмгә дә мохтаҗ. Сиңа механизатор, комбайнчы эшләре монда да булыр әле. Тәвәккәллә дә кайт…»

Хаттагы юллар аңа, укыган саен, нык тәэсир итә барды. Шулвакыт йөрәге әллә ничек кенә кузгалып, дулкынланып китте һәм ул, шушы минутта, үз карарына килеп: «Кайтам!..» – диде.

***

Чирәм җирләрне урап, исән-сау авылына кайтып төште Гали. Шөкер, әти-әниләре исән-сау, бер көе «тормыш арбасын» тартып яшәп яталар иде. Ул кайтып керүгә, һәммәсенең сөенечләре хәттин ашты, көтелмәгән күчтәнәч-бүләкләре дә куандырды. Күр, уллары ничек баеп кайткан!.. Һөнәрле дә булган: комбайнчы да, тракторист та. Бу хәл авылдашларының да игътибарын җәлеп итми калмады. «Булган егет икән…» дип сөйләделәр.

Булган егет Гали гел эш мәшәкатьләре артыннан йөгерде. Беркөнне ул Казакъстанда бирелгән паспортын, хезмәт кенәгәләрен алып, район хәрби комиссариатына учётка басарга дип килде. Аны майор Ливадный каршылады. Кайсы авылдан икәнлеген, туган елын сорады һәм, гаҗәпкә калып, кашларын җыерды.

– Кайда йөрдең син моңарчы? – диде ул. – Армиядән качып, дезертирлык кылыпмы? Где жульничал? Моның өчен сине трибунал белән судить итәргә кирәк…

Түзеп тыңлап торган Гали үзенә әйтелгән мондый сүзләрне кабул итә алмыйча кыюланды.

– Иптәш майор! Мине судить итәргә ашыкмагыз әле. Мин…

Майор, аны тыңлап та торасы килмичә, сүзен бүлде.

– Нәрсә, дүрт ел буе армиядән качып йөргән өчен синең башыңнан сыйпаргамы?

– Сыйпамагыз, – диде Гали, тернәкләнеп, – нишләгән мин? Сезнеңчә зимагурлыкта йөргәнме? Юк… – Ул, кесәсеннән документларын чыгарып, майор өстәленә китереп салды. – Монда барысы да язылган…

Соры чәчле майор, бераз тынып, аның хезмәт кенәгәсендә актарынды, паспортын да чагыштыра-чагыштыра карады. Кашларын җыера-җыера, чыраен да сытты, аннары егетнең «Хезмәттәге уңышлары өчен» дип бирелгән медале турында язылган катыргыга да карап-карап алды һәм армиядән азат итәргә бирелгән «отсрочка» карарына күз текәп торды-торды да секретарь кызны дәшеп алды, янә ризасызлык белдергәндәй:

– Выпишите ему военный билет!.. – диде.

Ни генә булмасын, Галинең, ни гаҗәп, эшкә дәрте сүрелмәде, ташып кына торды. Ул шул ук елны, үзенә бик тә таныш «Сталинец-6» комбайны белән Баландыш кырларын иңләде. Ә инде ел ахыры нәтиҗәләре буенча комбайнчылар арасында беренче урынга чыкты. Бу аның, туган авылына кайткач, тәүге уңышы иде.

Шулай кызу эш көнендә аның капкасын Питрәчтән килгән комбайнчы Илья Максимов шакыды. Эзләп тапкан бит, кайчандыр ул районның Ленин исемендәге совхозында эшләп киткән иде. Чыгышы белән Янсуар авылыннан. Гозерен болай дип белдерде:

– Гидросистема отказать итте. Жатканы күтәрми, үзе эшли. Зинһар өчен, булыш, машина капка төбендә, алып китәм, китереп куям.

– Ашыкма әле, Илья, – диде Гали, – йә, башта сөйләп кенә күрсәт.

Ул, Ильяны тыңлап бетергәч, үз киңәшләрен бирде: «Шул төшләрен, бу төшләрен

тикшер, – диде, деталь, узел исемнәрен атап. – Гидробак белән насоска тикле. Арада калган һаваны чыгар. Фәлән номерлы клапаннарны тикшер, чүп тыгылмаганмы? Аннары да эшләмәсә, килерсең, барам».

Илья бүтән килмәде. Димәк, сәбәбен ул, Гали сөйләгәннәрдән чыгып, үзе эзләп тапкан. Аңа шулай киңәш сорап килүчеләр бер Илья гына да булмады...

Ул инде комбайннарның төрле-төрле маркаларына да утырып эшли башлады, аларның серләренә тиз төшенде. Елдан-ел Социалистик хезмәт ярышларында югары күрсәткечләргә дә ирешә барды. Исеме гәҗит битләрендә мактанды. Ул хәзер ВДНХның көмеш, бронза медальләренә дә, аннары «Хезмәт кызыл байрагы ордены»на да (1972), «Ленин ордены»на да (1976), «Татарстанның атказанган механизаторы» исеменә дә лаек булды (1982). Болар һәммәсе дә аның хезмәт җимешләре тудырган чын хакыйкать.

Дәгъвалы машина

Тынгысыз холыклы Гали тормыш сабакларын үз җилкәсендә күп татыды. Аның һаман да «мин булдырам, мин тиеш…» дип омтылулары, тора-бара, кайберәүләргә бик ошап та җитмәде, хөсетлек, көндәшлек чирләре, күзгә бәреп әйтмәсәләр дә, үзләрен сиздерде. Кешеләр үзара сөйләшкәндә әйтеп куялар:

«Район җыелышларын уздырганда, гел шул Галине генә президиумга ук менгереп утырталар».

«Премияләрен дә, бүләкләрен дә берүзе генә чүпләп торган көне…»

«Каян килгән?.. Барысын да шул «Тумран» Галиенә бирергә димәгәндер инде…»

Ничек кенә сөйләмәсеннәр, күрсәткечләр, шөкер, Гали Сафинныкы һәрвакыт өстен чыкты. Ул, соңгы биш ел дәвамында, беренчеләрдән булып яңа төр «Дон» комбайнында да алдынгылыкны бирмәде. Кырык бер ел тузан йотып, 270 мең центнерга якын икмәк суктыру күктән төшкән җиңү түгелдер.

1990 елда, районның тантаналы рәвештә алдынгыларны бүләкләү, котлау җыелышында, 450 кеше каршында, аңа, куллар чабып, «Москвич» машинасы бирергә карар кылынды. Әмма ул машина бик тә дәгъвалы булып чыкты.

Гали «Москвич» машинасы кайтыр-кайтыр дип бер ел көтә, икенче ел көтә, ә машина юк та юк. Бу ни хәл? Аптырагач, аның какшаган нервылары түзмәде, китте Саба райкомына. Бер барды, ике. Икенче, өченче секретарьны да күрде. Җаваплары шул булды: «Белешербез, көт бераз…»

Капчыктагы «без» озак көттермәде, ниһаять, тишелеп чыкты. Хәлләр ачыклангач, ул үҗәтлеген дә күрсәтеп, шул машина артыннан ныгытып ук йөри башлады. Райкомның беренче секретаре Маннур Харисовичка ук барып керде, сүзен төгәл сораудан башлады:

– Министрлыкка киткән карарны кем шулай үзгәртеп тутырды? – диде ул. – Анда юлланган эш күрсәткечләрем ел саен шул килеш кала бирә, аны үзгәртә алмыйлар бит.

Бу катгый таләпкә райком секретаре болай дип җавап бирде:

– Мин моны, шәхсән, үзем тикшертермен… Сиңа «Москвич» машинасы бирелергә тиешлеген яхшы хәтерлим. Монда кемнең кулы шулай уйнагандыр, ачыкларбыз… Көт, сиңа тиеш – сиңа булыр…

Маннур Харисович сүзендә торды, дәгъвалы машина, барыбер, аның ишегалдына кайтып кунаклады… Хәзер дә ул үз көенә йөреп тора. Әле шул машинага комбайнчы малае Рушан белән утырып, Оренбург шәһәренә, «чирәм җир»нең 50 еллык бәйрәменә барып кайттылар. Анда 750 кеше чакырылган иде. Бу тантанада Гали Татарстаннан берүзе катнашты. Ул рәеш киемнәрен киде, орден-медальләре тагылган костюмын чыгаргач, тукталып, бер тын аларга карый-карый, хатирәләргә дә бирелде.

Оренбург шәһәрендә зурлап уздырылган бәйрәм аңа бик тә ошады. Дүрт көн буе кунак булдылар. Авылга кайткач, «ничек булды бәйрәмнәр?» дип сораучыларга ул:

– Дүрт көн буе «җәннәттә» булып кайттык… – дип кенә җавап бирде.

***

Төшке аш алдыннан Гали, гадәтенчә, көчеген ияртеп, авыл урамнарын әйләнеп кайтырга дип чыга. Көн аяз. Яз кояшы юмарт елмая. Мәчет турына җиткәч, ул туктап калды да манарада балкып торган айга күзләрен кыса-кыса карады. Йөзендә сөенеч: «Без дә яңа мәчеткә тиендек! Үзе калку урында, нәкъ Баландыш уртасында бөтен авылга ямь биреп тора. Мин эшләгән тәрәзәләре дә нурлар сибеп балкый, ялык-йолык…»

Кайчандыр мәчетнең манарасын кисеп, рухыбызны кимсетеләр, өметебезне өзгәннәр иде. Бүгенге хуҗаларга рәхмәт, материалларын кызганмадылар, тәки оештырып чыктылар... Мәчетне ачкан көнне халык бик күп җыелган иде. Ул сөенүләрен күрсәң… Әй, гомерләр, киләчәктә дә мәчетле көннәребез, үз рухыбыз, үз иманыбыз белән яшәргә язсын. Әти мәрхүм әйтмешли, тәмугка тиң сугышларны, ачлыкларны күрмичә генә, Ярабби…

Ул шулай йөри-йөри, янә дә төрле-төрле хатирәләргә бирелде. Аннары кайту ягына чыккач, көчеген орышып та алды:

– Өрмә әле, синнән башка да миңа монда «өрүчеләр» күп булды... «Эт – өрә, бүре – йөри…» диләр. Бүреләр дә йөри шул, кайсыдыр ки сарыкны тотып ашаганчы. Нишлисең, ашыйлар да, кыйбласын югалткан кайбер «бүре»ләр, синнән, миннән дә сорап тормыйлар… Заманалар үзгәргән саен, көрәше дә үзенчә үзгәрә бара икән. Яхшыга гына булсын иде…

Урам чатыннан борылгач, Гали сәгатенә карап алды да:

– Намаз вакыты җитеп килә икән, – дип, өенә таба кызулады.

Нурислам ХӘСӘНОВ

Игътибар!

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең филиалы
«Казан утлары» журналы редакциясе»
ТАССРның 100 еллыгына багышлап
иң яхшы әдәби очеркка конкурс игълан итте.

Ул **2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 15 декабренә кадәр** үткәрелә. Татар телендә язылган, моңарчы беркайда басылмаган очерклар гына кабул ителә. Аларның күләме А4 форматында 15 биттән артмаска тиеш.

Конкурста катнашучылар үзләренең эшләрен электрон почта аша җибәрергә яки «Казан утлары» журналы редакциясенә электрон вариантын китерергә тиеш.

Җиңүчеләр жюри тарафыннан **2019 елның 20 декабрендә** игълан ителә. Премияләр:

I урын – 15 000 сум (бер премия).

II урын – 10 000 сум (бер премия).

III урын – 7 000 сум (бер премия).

Кызыксындыру премияләре – 3 000 сум (өч премия).

БОГАУЛАРДАН АРЫНУ

ӘХӘТ ГАФФАРГА 70 ЯШЬ

Татар әдәбияты тарихында әлегәчә иҗатлары тиешенчә үк өйрәнелмәгән язучылар катламы бар. Сүзебез инде бүген җитмеш яшьләрен тутырып килүче, әдәбиятта, бигрәк тә аның проза һәм публицистика дип йөртелгән мәйданында заманында яхшы ук ат уйнаткан, чыннан да ир-ат әдипләребез турында, бигрәк тә шуларның берсенең – аерым алганда, Әхәт Гаффарның иҗаты турында барыр. Әлеге әдәби төркемнең вәкилләре, сугыш афәтләре узгач, 1948-1954 елларда бу якты дөньяга килгәннәр. Ир-атларны гына аерып алып карасаң да, шактый зур исемлек килеп чыгар: мәсәлән: Шаһинур Мостафин, Рашат Низамиев, Солтан Шәмси, Тәлгат Нәҗмиев, Алмаз Хәмзин, Равил Рахмани, Факил Сафин, Марсель Галиев, Ринат Мөхәммәдиев, Камил Кәримов, Вахит Имамов һәм Әхәт Гаффар үзе... Әлбәттә, бирегә кайбер башка исемнәрне дә өстәп булыр иде. Бигрәк тә гүзәл затларыбыз – хатын-кыз авторларыбыз иҗатлары турында махсус һәм әтрафлы сөйләшү булыр дип башка вакытка калдырырга булдык. Зинһар, моны ниндидер кимсетү яисә дискриминация дип аңламасыннар иде. Ни әйтсәң дә, барыбер ул әдәбиятның үз йөзе, үзенчәлекләре һәм спецификасы бар. Ул махсус өйрәнүне сорый. Ә мин исә әлегә моңа әзер түгел кебек.

Узган гасырның җитмешенче-сиксәненче елларында әдәбиятка килгән әлеге буын баштарак иң мәшһүр классикларыбыз мисалында каләм тибрәтте һәм... шуларның күләгәләрендә калып, бигүк танылып һәм бәяләнеп җитмәде, чөнки әдәби җәмәгатьчелек тә, тәнкыйтьчеләр дә теге мәшһүрләр белән генә мәшгуль иде. Әмма акрынлап тормыш барыбер үзенекен итте: ни кызганыч, иң бөекләребез – чын классиклар гасырлар чигенең аргы ягында калды. Ә чикне әлегә иҗатлары аз өйрәнелгән, үз вакытында һәм хәзер дә әлегәчә тиешле бәясен алып җиткермәгән төркем атлап чыкты – исемнәре аталган «яшьрәкләр» янына кушып, без сугыш алды һәм сугыш чоры балаларыннан Рабит Батулла, Марат Әмирханов, Тәлгат Галиуллин, Айдар Хәлим, Нурислам Хәсәнов, Госман Гомәр, Рәфкать Кәрами, Хәнәфи Бәдигый кебекләрне дә истә тотабыз, һәм менә бүген нәкъ шундыйлар изге миссия – татар прозасы җебен өзмичә, туачак чорларга китереп ялгау бурычын башкара.

Әлеге мәкаләдә төп сүзебез Әхәт Гаффар иҗаты турында. Ул Көнбатыш Европа әдәбияты үрнәкләреннән һич кайтышсыз булган «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» (1979-1984), «Богау» (1998), «Олы юлның тузаны» (1986-1988) исемле романнарын, күпсанлы повестьлар һәм хикәяләр иҗат итте. Язучы әдәбият бусагаларын атлап кергәндә, Хемингуэй, Фицджеральд, Сэлинджер, Андре Моруа кебек әдипләрнең әсәрләрен йотылып укыганлыгын яшерми.

Әлбәттә, үзебезнең «бөекләребезнең» дә һәркайсын гел Көнбатыш әдәбияты тарафдарлары дип санау бигүк дөрес булып бетмәс иде. Аларның һәркайсы – без әле генә искә алганнардан бишесе дә татар классик әдәбияты рухында тәрбияләнеп һәм совет җирлегендә үсеп өлгергән шәхесләр. Аннан килеп, аларның иҗат очышларының нәкъ менә ил тормышындагы котылгысыз борылыш чорына – XX гасырның сиксәненче-туксанынчы елларына туры килүенә игътибар итегез. Аларның иҗатындагы колачлы алымнар, зур адымнар халыкның милли һәм иҗтимагый аңындагы күтәрелеш елларына

туры килүе һич тә очраклы түгел иде. Бу хәл Әхәт Гаффарның «Олы юлның тузаны», Камил Кәримовның «Ком сәгате», Ринат Мөхәммәдиевнең «Кенәри – читлек кошы» кебек тормыш проблемаларын яңача һәм кыю күтәргән әсәрләрендә үзенең лаеклы чагылышын тапты. Шушы әдипләребез үз карашларын үткәргәндә прозаның образлы һәм лирик чаралары белән генә чикләнмичә, публицистиканың проблемаларны турыдан-туры куя торган кыю алымнарын да эшкә җиктеләр. Мин бу урында Марсель Галиевнең «Догалы еллар», «Рух» әсәрләрен, Ринат Мөхәммәдиевнең «Утлы таба өстендә» исемле романын, Камил Кәримов, Солтан Шәмси, Әхәт Гаффар һәм Фәүзия Бәйрәмованың ялкынлы чыгышларын, публицистик мәкаләләрен һәм тарихи романнарын күздә тотам.

Шушы әдәби төркемнең бер вәкиле – бу көннәрдә үзенең 70 яшьлегенә килеп җиткән Әхәт Гаффар романнарының берсен «Богау» дип атаган. Нәкъ менә әлеге атама минем үземә бу авторның тик ул гына тапкан ижат юнәлешен төшендерердәй, аның гражданлык позициясен һәм әдәби-эстетик үзенчәлекләрен ачарга ярдәм итәрдәй ачкыч ролен уйный торган фактор яисә татар әдәбиятында кабатланмас бер күренеш булып тоелды. Бу хәл, бәлки, күпләрне гаҗәпләндерер дә, чөнки заманында, ягъни әсәр дөньяга чыккан көннәрдә ул укучыларга артык катлаулы, буталчыграк сюжетлы һәм әдипнең ничек тә каләм ияләренең бүтәннәренә охшамаска тырышып, оригиналь булып кылануы рәвешендәрәк күренгәндер. Бер әйбер бәхәссез – әсәр әдипнең бөтен ижатын сугарган төп идея – кешенең хөр, азат яшәүгә хокукы, һәртөрле рухи коллык богауларыннан азат булырга тиешлеге хакыйкатен яклау идеясе аеруча нык чагылган роман.

Символлар, күп мәгънәле метафорик алымнар тарафдары Ә.Гаффарның үз ижат җимешенә аңлаешлы, шомлы исем куеп, укучы алдына чыгуы сискәндереп җибәрә – кешенең тәненә, кулына, аягына кигертелгән богаулар бик ачык, конкрет халәтендә күз алдына килә: гүя ул богаулар безнең үзебезне, һәркайсыбызны буып, чикләп, кысып тора – аларны тизрәк өзәсе, котыласы килә. Берәүләр аларны киң социаль яссылыкта – тоталитар режимның халыкларны рәнҗетүе, интектерүе һәм шуңа каршы көрәш дип аңласа, икенчеләр эстетик җирлектә – элеккеге катып калган постулатлардан котылу кирәклеге дип уйласа, безнеңчә, язучы әлеге төшенчәгә тагын да тирәнрәк мәгънә сала: кешенең хөрлегенә, азатлыгына, үзенчә яшәвенә, тормышны аңлавына, олы Тәңре хөкеменнән башка һичнинди киртәләр булмаска тиеш дип саный һәм шушы хакыйкать аның бөтен ижаты белән раслана. Ә.Гаффар ижатын иңләгән яктылык гүзәллеге әнә шуннан килә дә инде.

Мәгълүм ки, замандашларыбыз тормышының һәр тарафыннан ямь, тирән мәгънә табып, алларына ачык максатлар куеп, проблемаларның чишәсен чишеп, алдагысына өметле карап яшиләр. Андыйларга тормыш юлларының барысы да ачык – яшәргә дә яшәргә генә кала. Әдәбият-сәнгать чын тормышның бер чагылышы дип саналганга күрә, галимнәрнең дә моңа карата фикерләре, җаваплары бик ачык: әдип реалистик сәнгать кысаларыннан аз гына читкә авышса, алар яңа алымнар, яңа күренешләрнең кайсын сюрреализм, кайсын модернизм яисә постмодернизм шүрлекләренә урнаштырып куя һәм... шуның белән мәсьәлә хәл ителде, чишелде дип уйлый. Инде безгә барысы да мәгълүм кебек, чөнки күренешкә яисә әсәргә үзенә тиешле мөһерен сугарга өлгердек, алга таба бу ижатны җентекләп өйрәнмәскә дә була – нәрсә икәнлеген әйттек бит инде. Әмма, дөресендә исә, мондый классификация әлегә исем кушудан гайре бернәрсә дә түгел: бу – әтрафлы анализга чакыру гына әле.

Әнә шундый уйлар минем башыма Әхәт Гаффарның Татарстан китап нәшрияты тарафыннан 2016 елда чыгарылган дүрт томлык «Сайланма әсәрләр»е белән танышканда килде. Әлеге танышу барышында байтак фикерләрем үзгәрде, яңарды, кайберләре юкка да чыкты. Юкка чыкканы – бу әдипнең ижатын яхшы беләм дип йөрүем икән. Күз алдымда өр-яңа әдәбият хәзинәләре коесы, хәтта дәрьялары ачылды.

Авторның ижат диапазонының киңлеге игътибарга лаек: прозаның кайсы гына тармагына мөрәҗәгать итмә, алдарак телгә алынган романнары, «Язлар моңы»

(1972), «Яра» (1973), «Гозер» (1975), «Кашан җыры» (1977), «Бабай чишмәсе», «Су астындагы чишмә» (1983), «Бишек» (1985), «Яшиселәр алда иде» (1985), «Дәрья башы» (1995) һ.б. повестьлары, якты, ачык сурәтләрдән эшләнгән йөзләп хикәясе җәлеп итә. Аларның һәркайсында нәкъ шушы авторга гына хас иҗат билгеләре, чалымнары, төсмерләре бар. Әгәр боларның берсе дә булмаган очракта да, автор үзенең «Иртәгә улың булам», «Язлар моңы», «Җиләк вакыты бер генә» кебек лирик пьесалары, тарихи шәхесләр – М.Җәлил, М.Вахитов, Г.Тукай турындагы «Хөкем», «Сызылып таңнар атканда», «Соңгы сәгать» драмалары белән генә дә әдәбиятыбыз һәм театр тарихында үзенә лаеклы урынын алыр иде. Бу әсәрләр төрле татар театрлары сәхнәләрендә зур уңыш белән барды, күпсанлы тамашачыларның олы ихтирамын казанды. Әлеге зур иҗат ташкыны дәрьясы артында нинди зур шигърият – саф лирика, поэмалар дөньясы да ята бит әле! Боларның барысы янына әдипнең фәкать балалар, сабыйлар укысын дип кенә язылган төрле парчаларын, әкиятләр, хикәяләр, пьесалар, шигырьләрен дә өстәсәк, диапазон дигән төшенчә тагын да тулылана төшәр.

Әле без Ә.Гаффарның гаять көчле коралы – публицистикасы турында бер сүз дә әйтмәдек; ә бит анысын аның саф әдәбият дип саный башлагандагы пар иҗат канатларының икенчесе дип әйтергә, ул гына да түгел, авторны чын гражданин һәм олы художник иткән төп фактор дип атап була. Иң әүвәл әдипнең һәртөрле гаделсезлекләргә карата килешмәүчән актив мөнәсәбәте күзгә ташлана. Мондый мөнәсәбәтне аның төп тормыш позициясе дип тә, сәяси хәлләргә карата үзенең бәясе рәвешендә дә аңларга кирәк. Бу бигрәк тә тарих битләренә гаделсез сугыш чагылышы рәвешендә кереп калган әфган сугышы мисалында ачык күренә. Үз вакытында язучының бик күп әсәрләрендә әнә шул сугышның аяныч нәтиҗәләре, бигрәк тә, шуларны аңлатканда, массакүләм мәгълүмат чараларының ялганы, ә соңыннан шул гаделсез сугышта физик һәм рухи яктан имгәнеп кайткан асыл егетләребезнең җәмгыятьтә үзләренең лаеклы урыннарын һәм кылган эш-гамәлләрен хак-дөрес бәяләүне таба алмый интегүләре публицистик әсәрләрдән тыш («Билгесез сугыш», «771 аршын җир», «Ил фажигасе», «Хәтер тактасы»), «Яшиселәр алда иде» (1985) повестенда, «Олы юлның тузаны» (1986-1988) романында, «Күзләремне тутырып» драмасында, «Утын» исемле һ.б. хикәяләрендә дә чагылды. Әгәр дә Әхәт Гаффарның нигездә якты кояш нурларында коендырылгандай үтә оптимистик иҗатына вакыты-вакыты белән шактый ук шомлы бизәкләр һәм сурәтләр (зират күренешләре, каберләр, гүрләр, ачылган табутлар, каркылдап утыручы козгыннар һ.б.) килеп керә икән, кайчагында моны тормыштагы әнә шул гаделсезлекләрне төзәтә алмау чарасызлыгыннан килгән гажизлектән дип тә аңлатып була торгандыр. Әмма әдипнең реалистик иҗатны ара-тирә бик табигый рәвештә экзистенциаль чаралар белән аралаштырып бару сәләте бик көчле икәнлеген белсәк, барысы да аңлашыла төшәр. Гомумән, Әхәт Гаффар – ул яшәеш, тормыш агышы, галәм, табигать халәте турында бик тирәннән һәм җентекләп уйланучы фәлсәфи сүз рәссамы. Бу философия аның үзенең җир кешесе, галәмнең, табигатьнең бер күзәнәге буларак, туган ягыннан, шулай ук дуслары, каләмдәшләре тирәлегеннән аерыла алмый, һич тә шуннан читкә китә алмый торган газиз баласы итеп тоюыннан килә булса кирәк.

Шәхсән мине аеруча сокландырганы: авторның һәртөрле әдәби алымнар, сурәтләр, хәтта иҗат юнәлешләрендәге махсус чаралар белән үтә дә иркен, бик кыю эш итүе – дөресен әйткәндә, монысы да аның шул хөрлеккә омтылуы, үз-үзен чикләмичә, безнең барыбызны да тышаулап торучы гадәтилек стандартларыннан, ягъни богауларыннан ычкыну омтылышы. Әлбәттә, мондый халәтнең отышсызрак яклары да булырга мөмкин – әмма монысы да авторның гаебе яисә кимчелеге түгел, – тик барыбер аның үзенә уңайсызрак, чөнки хәзерлексез һәм талымсызрак укучылар әлеге алымнар катнашмасында адашып калырга, бигрәк тә әһәмиятле булган яисә шулар янындагы икенче, өченче рәтләргә куелган ваграк нәрсәләрне үзара буташтырырга да мөмкин. Кайберәүләргә авторның шартлы алымнар белән мавыгып, иҗат фантазиясенең бик

ерак югарылыкларга очышы аңлашылып җитмәве дә бик табигый, тик монысы өчен хөрмәтле укучыбыз үзен-үзе шелтәләсен. Ошбу язучы күп очракларда хәзерлекле, үзен аңлардайларны күздә тотып иҗат итә һәм ялгышмый. Бу фикерне раслау өчен, мисалга фәкать берничә вариантта язылган «Язлар моңы» повестеның бәхетле язмышын гына искә төшерик. Аның шартлы да, гаять тормышчан да алымнарга корылган сәхнә варианты татар театрлары сәхнәләрендә зур уңыш белән барды. Шулай ук зиһенне кузгатырдай ачык, якты, ассоциатив, яңача метафорик сурәтләргә нигезләнгән «Әҗәт», «Кояшның салкын чагы», «Ак каен дегете», «Акчураның җир үбүе», «Бабай чишмәсе» кебек хикәяләре дөнья халыкларының уналты теленә тәрҗемә ителеп танылды. Бу фактлар Әхәт Гаффарның үз укучылары һәм тамашачылары күп икәнлеге турында сөйли.

Ошбу әдип нинди генә темага алынмасын, теләсә кайсы жанрда ул аны югары сыйфатлы итеп һәм үзе теләгәнчә башкарып чыгарга сәләтле. Чыннан да, бу очракта без сәнгать кешесе өчен ифрат та кирәкле сыйфатларның күбесен үзенә туплаган киң эрудицияле шәхес белән очрашабыз. Иң әһәмиятлесе: ул туган ягы, туган халкы, сөекле шагыйрьләре, каләмдәшләре янында гына үзенең кадере, дәрәҗәсе барлыгы хакыйкатен һәрдаим төшенеп, аңлап яши: *«...әдәбиятка мен, тик тәгәрәмә, шатланган чагыңда кемнеңдер борчулы икәнлеген һәрчак истә тот. Кайгың барында исә синекенә караганда күп мәртәбә зуррак кайгылы кешеләр барлыгын онытма. Яшәү мәгънәсе шушында ятар. Тормыш шулай – ике яклы. Өченче ягы бар – битарафлык. Әмма битараф кешеләр ахыр чиктә кайгылы кешеләрдән дә бәхетсезрәк. Кояштай көлә, болыттай елый белүчеләр генә бәхетле...»*

Әхәт Гаффар үзен язучылардан иң бәхетлеләренең берсе дип саный: *«Безгә дөнья әдәбиятының гүзәл үрнәкләре белән таныша башлау, алар акылын, фәлсәфәсен, идея-эстетик кыйммәтен аңлау җиңел бирелде. Халык көйләренә җитәкләп диярлек керткән аналарыбыз кебек итеп, безне ул гүзәл үрнәкләргә Габдулла Тукай, Муса Җәлил шигърияте алып менде... Бөек Тукайның теле, шигыре киң тугай икән ләбаса!.. Инде менә үсә төшеп, үзебезнең балачак тугайлары уч төбе хәтле генә булып күренә башлаганда, дәреслекләрдә Җәлил белән очраштык. Ул әлеге тугай буендагы биек тау булды да безне югарыга, каһарманлык һәм моң тантанасы биеклегенә ирештерде, тугайларны тагын да җәелдереп җибәрде – аны туган як, Ватан иттерде.*

Муса Җәлил – көрәш биеклегенең иң югары ноктасына менгән, богауланган, тик бирешмәгән Прометей. Дошман аның кулына богау салса салды, ләкин бернинди дошманның да кешенең йөрәк хисен, йөрәк ялкынын богауларлык зынҗыр ясый алганы юк әле!

Чөнки аның йөрәге тугайларыбыз шикелле киң...

Тугайларга богау салып булмый...»

Әлеге юлларда әдипнең төп мәнфәгате, иҗат кредосы ярылып ята. Икенчедән, бу юллар белән танышканда, язучының кайберәүләргә чишә алмаслык табышмактай яисә әһәмиятсез тоелган нәрсәләр, әмма дөресендә зур иҗат табышлары да ныграк аңлашыла төшәчәк дип уйлыйбыз.

Алдагы иҗат адымнарын ясаганда, ул һәрвакыт, һәр очракта үзе табынган бөекләргә карый, үзен шуларның тырыш, карусыз шәкертләренең берсе итеп тоя. Без бу очракта Тукай, Җәлилләрдән тыш Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Хәсән Туфан, Мостай Кәрим, Нурихан Фәттах, Гариф Ахунов, Әбрар Кәримуллин кебек шәхесләрне күздә тотабыз; дөресен әйткәндә, Әхәт Гаффарның барлык иҗаты дәвамында әнә шундыйларның иҗтимагый һәм сәяси карашлары, гомумән, кешелек һәм иҗади позицияләре файдаланыла, алар яңа шартларда Әхәт Гаффарның үзе генә белгән һәм тапкан өр-яңа шартлы әдәби алымнар ярдәмендә үстерелә, хәзерге укучыга тәкъдим ителә. Олы фикердәше академик Әбрар Кәримуллин турындагы «Хакыйкатькә сусау» исемле мәкаләсендә ул болай дип язды: *«Корылыкта яңгырның һәр тамчысы кадерле. «Теге» корылык заманында һәркем иркен фикер йөртү*

хокукына сусап яшәде. Әбрар Кәримуллинның без татарларның кемлеге хакындагы, безнең кемлегебез, кем булырга тиешлегебез хакындагы һәр китабы озын-озак тышауда тотылган хыялларыбызны иркенгә – табигый җәйләүгә җибәрүгә тиң булды. Аның гыйльми фикерләве сөреп тырмаланган җир тасмасы, чәнечкеле тимерчыбык, таш дивар кебек шартлы чикләрне белмәде. Хакыйкатьне белер, таныр, аны тирән коедан суырып чыгарыр өчен, ул, кан тамырлары чылбырын мәңге өзелмәслек итеп көрнәгән хәлдә, бәгъзе томаналарга (укымышлы сыйфатта күкрәк киергәннәргә) каршы затлы кынындагы күгәрмәс хәнҗәрен ялтыратып күрсәтте. Тик үз дошманнарын юк итәр өчен түгел, ә бәлки аның хакыйкать кояшы нурларында ялтыравы белән халыкка рухи ләззәт бирү өчен. Һичнинди тетрәүләр дә селкетмәслек гаделлек телисең икән, иң элек тормышның һәммә хәшәрәт ялганына бармагың белән төртеп күрсәтә бел.

Ул, Әбрар Кәримуллин, белде... Кирәкле хакыйкатьне тапты, халкыбызны инандырырлык хакыйкатькә тап булды».

Әгәр дә укучы классиклар, замандаш каләмдәшләре, зыялы артистлар, театр һәм музыка әһелләре турындагы мәгълүматларны белергә тели икән, ул аларны Әхәт Гаффарның «Сайланма әсәрләр»енең дүртенче томыннан таба ала. Әлеге томны язучының метафорик, беркадәр ироник фикерләү сәләтен, урыны-урыны белән шактый зәһәр сарказм аша сугарылган мәкаләләренең бер энциклопедик җыелмасы дип тә санап булыр иде.

Әхәт Гаффар үтә сыгылмалы, кинаяле, бай татар телебезнең мөмкинлекләреннән киң файдалана. Бүген газиз телебезне чикләп, гаять кыен шартларга куеп кысрыклаган бер заманда аның матурлыгын, сафлыгын, куәтен халкыбызга, укучыларыбызга күрсәтү үзе генә дә зур игътибарга лаек. Әдип үзенең язмаларында гел шуңа басым ясый, текстта чит-ят сүзләрне кулланмыйча, туган телебездә ижат итә. Мәшһүр Тукаебыз кебек, аныңча кыю рәвештә, милләт улларының, иң беренче нәүбәттә каләм ияләренең мөшкел хәлләренә ачынып, аларга ярдәм кулын сузарга өнди: *«Бүген татар каләм ияләре зарланып йөрүгә калды. Башны кая куярга белгән юк. Бу замана иң әүвәл язучы башына кадак булып кадалды... Каләмнәре очыннан саркып чыккан барча диярлек иман нурының, әүлияныкыдай мәсләкләренең заты да калмады дигәнемә ышанмасагыз, базарларга барып чыгыгыз, китап кибетләренә кереп карагыз: татар әдипләренең китаплары һәммә шүрлекләрдән гаип кебек. Кемнәрнеңдер теләкләре рас чыкты: әхлак һәм язучыларның мәңгелектән өйрәнеп, мәңгелеккә исәпләп әйткәннәре зил-зиләбә килеп бетте...*

Әмма хәзер илһам толпарын фәлүәт тә итми үз мәнфәгатьләренә җикмәк кылган түрәләр аң булсыннар: бүген каләм ияләрен үз кысаларына көчләп кертмәк әмәлләре киләчәктә тәртәгә шундый бер китереп тибәр ки, соң мәлдә, иреннәренә дымлы каурый тидерердәй, Гаффарга ялварулары кызган таба ялаудан да хәтәррәк булыр». Мондый кисәтүләр әдипнең башка язмаларында да кабатлана – болар барысы да аның чын милләт кайгыманы икәнлеген раслаучы сурәтләр.

Кайбер очракларда Әхәт Гаффар Н.В.Гоголь әсәрләрендәгеләрен хәтерләтерлек башка сурәтләргә дә күчә. Мондый хәл бигрәк тә «Богау» романы битләрендә күренеп тора. Бу әсәрне аның кызыклы эксперименты яисә яңа тәҗрибәләр мәйданы дип тә санап булыр иде. Чыннан да, һәртөрле фантасмагорик һәм мистик элементларны мул кулланып, бүгенге тормыш агышын сурәтләгән, яшәешебезнең күпләрне борчыган җитди мәсьәләләрен күтәрергә яисә хәл итәргә тырышу үрнәкләре милли әдәбиятыбыз тарихында алай еш очрамый. Тик заманында бөек рус классигы, аеруча бер кыюлык белән шул юлга басып, гүзәл ижат үрнәкләре тудырган бит! («Вий», «Диканька хуторы янындагы кичләр», «Коточкыч үч алу» һ.б.) Татар әдибе дә бүгенге реаль тормыш хәлләре янына, шуның янәшәсенә әкияти, фантастик дөнья галәмәтләрен китереп куя һәм шуның шартлы җирлегендә җәмгыятебезнең һәртөрле догмаларга, кешелексез, мантыйксыз тәртипләргә бирелеп, мәгънәсезлек упкынына тәгәрәп төшүебезне искәртә. Моны аңлау өчен, янәшәгә Тукаебыз заманнарыннан

ук укучыбызга якын һәм таныш шүрәлеләр дөньясы тәкъдим ителә. Нәкъ әнә шул шүрәлеләр гавамы янында адәми затларның үз-үзләренең нинди богаулар тоткынлыгында көн итүләре, шул тоткынлыкка дучар булулары бик ачык күренә. «Богау» әсәре ахырында кешеләрнең ялгышларын төзәтердәй өстен көчләрнең барлыгына да ишарә ителә: *«Шүрәле гавамын Адәми затларга күренмәс хәлдә тоткан көзгеләр ачылып киткән сыман булды. Күктән иңгәндәй рәвешле, Шүрәле Олуг Хәким Алтын Мөгезнең тавышы ишетелде: «Асыл Рух ярдәм итсен, Ибрай, бар, күтәрел, оч, төш. Син – Адәми зат. Адәми зат булып кал. Онытма: син күрмәгәнеңне күрдең, белмәгәнеңне белдең. Күргәнең күзеңне ачты, белгәнең богавыңнан азат итте. Хәзер синең юлың Тәңрең юлында инде».*

Бүгенге татар авылының гап-гади кешесе Ибрай Зәкуановның реаль тормыш белән аралаштырылган, әмма әкияти язмышы аша әдип байтак күп фәлсәфи фикерләр әйтергә тели – моны үзенә күрә мәшһүр «Фауст»ка охшатып, шуның сюжетына беркадәр янәшә эшләнгән фәлсәфи притча дисәң дә ярый торгандыр – биредә адәми зат үзенең гомере буена ниндидер котылгысыз чикләр, нормаларга кысылып яшәргә мәҗбүр ителә, шулардан арыну омтылышы белән яши, әмма тулы азатлыкка аның җаны Тәңре карамагына киткәч кенә ирешә икән. Бәлки, әсәрдәге катлаулы сурәт-бизәкләр һәм сюжет борылышларын әнә шулай аңларга да мөмкиндер, тик минем үземә калса, мәсьәләнең икенче ягы әһәмиятлерәк: автор үзенең барлык иҗаты дәвамында гел иркенлеккә сусап, шуңа омтылып яши: һәртөрле әдәби клише, штампларны санламыйча, тышауларыннан котылган, йөгәне салдырылган аргамак кебек, иҗат болыннарында үзенчә гизә. Мондый шәхесләр өчен тормышта богаулар була алмый.

Әхәт Гаффар – бәхетле иҗади язмышка ирешкән әдип, чөнки ул үз халкына кирәкле сүзен өздереп, кистереп әйтә белде, үз укучысын, тамашачысын, әдәби шәкертләрен тапты, хәзер дә ул туган якларының, Олы Әшнәк болыннарына, чишмәләренә сокланып, аның матурлыгын тоеп, андагы һәр җан иясенең – сандугачларының җырын тыңлап, күкеләренең моңын аңлап яши. Болар барысы да аның йөрәк хисләре белән аралашып, фәлсәфи фикерләү, лирик хисләр, юмористик бизәкләр нурында коендырылган әсәрләре аша үз укучыларына барып җитә.

Әхәт Гаффар феномены дип аталырлык нәтиҗәле күренешкә юбилярыбыз үзенең ярты гасыр чамасына сузылган иҗат дәверендә иреште. Аның өчен зур бәхет дөнья һәм милли мәдәниятләренең байлыкларын үзләштерү, шулардан файдаланып, хәзерге олы иҗат казанында кайнауда, иҗат итүдә дә иде. Яраткан язучысы Эрнст Хемингуэй каһарманнарының берсе авыр мизгелдә «кеше ялгызы калса, берни дә булдыра алмый ул» дигән сүзләрне ычкындыра. Әхәт Гаффар ялгыз калмады: авыр югалтулары булса да, ул һәрдаим туганнары, якыннары, каләмдәшләренең ярдәмен тоеп яши. Аның гаилә терәге – кызлары Ләйлә, Сөмбел һәм инде бакыйлыкка күчкән хәләл җефете Фәридә дә – иҗат кешеләре. Туганнары – җәмгыятебезнең асыл егетләре Ренат һәм Рәкыйп Гаффарлар – аның иң ышанычлы гомер юлдашлары. Шушындый мохиттә Әхәт Гаффарның үзенә дә бер генә юл – һич туктаусыз армый-талмый язарга да язарга гына кала. Мондый юлда һичнинди чикләүләр, киртәләр, богаулар була алмый.

Рифат СВЕРИГИН

ЗАМАН СУЛЫШЫН ТОЕП...

КИМ МИҢНУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Узган гасырның утызынчы елларында ук Казанда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында нигез салынган фольклор мәктәбенең бәрәкәтле туфрагында үсеп чыккан күренекле галимнәрнең берсе – Ким Мөгаллим улы Миңнуллин. Төрки дөньяда һәм Россия фәне күләмендә татар фольклорын танытуга, милли фольклористикабызны югары дәрәҗәгә күтәрүгә әлеге мәктәпнең Хәмит Ярми, Нәкый Исәнбәт, Илбарис Надиров, Фатих Урманчеев, Флора Әхмәтова-Урманче, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Марсель Бакиров, Нурмөхәммәт Хисамов, Рәшит Ягъфәров, Ленар Җамалетдинов, Айсылу Садекова кебек санаулы шәхесләре биниһая зур өлеш керткән булса, Ким Миңнуллинның бу җәһәттән тоткан урыны аерым бер игътибарга лаек. Ким Мөгаллим улының фәннәр арасында нәкъ менә фольклористиканы үз итүе, татар халык ижаты өлкәсендә ут уйнатучы күренекле затлар белән якыннан аралашып, фольклорчы галим булып формалашуы татар фольклор мәктәбенең хәлиткеч чоры өчен бик зур әһәмияткә ия. Татар фольклор фәне XXI гасырга аяк атлаганда, белемле, зирәк, көчле бу шәхеснең дилбегәне үз кулына алуы гаять кирәкле гамәл иде, шөкер, язмыш фәннең халыкка иң якын торган милли рухлы әлеге өлкәсенә карата һәм, гомумән, фәнгә мөнәсәбәттә хәерхаһ булды.

Галим Ким Миңнуллинның татар фольклорын күтәрүдәге эшчәнлегенә күз салсак, аның күпкырлылыгына игътибар итми мөмкин түгел. Беренчедән, фольклор ул – киң һәм тирән дәрья булуы өстенә, әдәбиятның да чишмә башы; фольклорчы галимнең халык авыз ижаты һәм язма мәдәният кисешкән ноктаны барлавы аның әдәбият галиме булуын да раслый. Икенчедән, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә эшкә чакырылып, башта премьер-министрның баш референты, аннан Министрлар Кабинеты каршындагы Телләр комитеты секретаре, 1999 елдан Татарстан Хөкүмәте структурасында телләрне саклау һәм үстерү буенча төзелгән махсус бүлекнең җитәкчесе булып эшләгән чорыннан Ким Мөгаллим улы тел сәясәте мәсьәләләрендә дә әзерлекле белгеч һәм зирәк, тынгысыз җанлы оештыручы булып танылды.

Ким Миңнуллин – әнә шундый сирәк белгечләрдән, фәнни эш юнәлеше, хезмәтләре буенча да аны һәм фольклор, һәм әдәбият галиме буларак беләләр. Галимнең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык ижаты бүлегендә әзерләнгән «Сүз сәнгате буларак җыр» дигән темага докторлык диссертациясенең 2001 елда ике белгечлек – «фольклористика» һәм «Россия Федерациясе халыклары әдәбияты (татар әдәбияты)» белгечлекләре буенча якланыуы үзе үк Ким Миңнуллинның киң колачлы галим булуына ишарә итә. Аның фәнни тикшеренүендә татар халык җырларының барлыкка килүе, жанр үсешенең төп юнәлешләре ачыклана, җырларның жанрлык сыйфаты билгеләнә. Галимнең диссертациясендә өч меңгә якын профессиональ җырны эченә алган мәгълүмати база булдырылган, татар җырларында образлар системасы киң планда һәм фәнни нигездә тасвирланган, җыр текстлары стиленең композицион төзелешенә, җырларның лексик составына зур әһәмият бирелгән.

Галимнең фәнни эзләнүләр нәтиҗәсе буларак дөнья күргән «Шигърият һәм җыр» (1998), «Җырларның шигъри табигате» (1999), «Басма сүз һәм татар җырлары» (2000), «Һәр чорның үз җыры» (2003), «Песенное творчество татарского народа» (2006)

исемле һ.б. монографияләре дә җыр жанрына гына хас нечкә хасиятләрне төрле яклап өйрәнүгә багышланган. Аларда җыр шигъриятенә, профессиональ җырларның туу һәм яшәү үзенчәлекләренә, төрле елларда төрледән-төрле җыентыкларда һәм көндәлек матбугатта басылган җырларга күзәтү ясала, җыр текстлары, төркемнәргә бүлеп, фольклор әсәре буларак һәм әдәби күзлектән системалы анализлана.

Татар халкының җыр мирасы – төсле бизәкләрдән тукылган моңлы, шигъри бер дөнья ул. Җырның хискә, мәгънәгә бай нәфис сүзләре, гамьгә, дәрткә бай тылсымлы музыкасы халыкның рухи бөтенлеген һәм тиңдәшсез талант иясе булуын раслый. Җыр хәзинәсендә чал тарих авазлары да, бүгенге көннәр аһәңе дә тирәннән килә. Ким Миңнуллинның халык җырларын шигъри хәзинә буларак тикшерүгә багышланган барлык хезмәтләре татар традицион җыр мирасына кагылышлы бүген дә гаять актуаль бик күп мәсьәләләрне кузгатуы белән кыйммәт. Татар халык авыз иҗатының җыр жанрын өйрәнүгә багышланган монографияләреннән тыш, галим бу өлкәне Татарстан, Россия, һәм чит илләрдә чыга торган фәнни матбугатта дөнья күргән мәкаләләрендә, халыкара форумнарда даими яктырта.

Ким Мөгаллим улына фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлекне милли фольклорга тыгыз бәйле педагоглык белән үреп алып бару да хас. Әйтик, татар халык иҗатының иң гүзәл үрнәкләрен туплаган, мәктәпләр өчен уку ярдәмлеге сыйфатында «Энҗе чәчтем – энҗе җыям» сериясендә 2000 елдан «Мәгариф» нәшриятында басылган унга якын җыентыкларны Ким Миңнуллинның фольклор өлкәсендәге эшчәнлеге нәтиҗәсе дип бәяләү хаклы булыр. Әле Ким Миңнуллин ТР Министрлар Кабинетында ТР телләрен үстерү һәм мәдәният бүлеге җитәкчесе вазифаларын башкарган чорда ук Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән берлектә хәзерләнгән бу җыентыкларда төрле жанр фольклор әсәрләре урын алган. Болардан тыш профессор Фатих Урманчеев белән берлектә югары уку йортлары студентлары өчен төзеп бастырылган «Татар халык иҗаты» курсыннан хрестоматия дә галимнең фән һәм уку-укыту өлкәләрендә фольклорны актуальләштерүе буларак кабул ителә. Галим – Татар дәүләт гуманитар институтында, Казан дәүләт педагогика университетында, Казан (Идел буе) федераль университетында студентлар белән озак еллар тыгыз аралашып, аларга «Татар җыр шигърияте», «Күпмилләтле дәүләт шартларында телләр сәясәте» кебек темалар буенча махсус курслардан белем бирүче, студентларны фольклор белән кызыксындырып, яшь буынны татар фольклор мәктәбенә тартучы профессор, дәүләт имтиханнарын кабул итүче таләпчән рәис тә.

Бүгенге көндә татар фольклор мәктәбендә буыннар алмашы мәсьәләсендә фәннең башка тармаклары белән чагыштырганда хәлнең уңайрак булуы – һичшиксез, галимнең әлеге мәсьәләнең бик әһәмиятле бурыч икәнен аңлап эш йөртүе нәтиҗәсе. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры булып эшли башлавыннан алып, бүгенге көнгә кадәр Институтның халык иҗаты бүлегендә докторлык, кандидатлык диссертацияләре яклаган әзерлекле кадрларның уңышлы эшләве, бүлектә яшьләрнең артуы, шул исәптән бүлек мөдире Ким Мөгаллимовичның шәкертә Илмир Ямалтдиновның яшь галимнәр сафын тулыландыручы вәкилләрнең берсе булуы, яшьрәк буын фән докторларының бер-бер артлы яңадан-яңа фундаменталь монографияләре дөнья күреп торуы, аларның, Россия күләмендә һәм чит илләрдә фәнни чараларда катнашып, уңышлы чыгыш ясаулары, Россия фәнни фонды, Татарстан Фәннәр академиясе грантларына ия булулары, бүлектә халык иҗаты буенча татар һәм рус телендә академик томнар әзерләнү, яңа килгән аспирантлар белән эш алып бару һ.б. – болар бар да галимнең фольклористиканың бүгенгесен һәм киләчәген алдан кайгыртуы, фольклорга булган җылы мөнәсәбәте йогынтысында барлыкка килгән уңай нәтиҗәләр.

Фольклористика фәненең ике канатлы булуы һәркемгә мәгълүмдер: аның берсе моңа кадәр тупланган авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү белән бәйле зур юнәлешне тәшкил иткән канат икән, икенчесе халыктан фольклор үрнәкләрен җыю-туплау белән бәйле. Татарлар яши торган төрле төбәкләргә махсус чыгып, җирле халыкның рухи һәм матди мирасын барлау – фольклористиканың гына түгел, гомумән, Институтыбыз эшчәнлегенең дә зур бер тармагы. Ким Мөгаллим улы – бу юнәлешнең үсешен дә

бик нык тәэмин итүче оештыручы-галим. Институт оешканнан алып, сиксән елга якын вакыт дәвамында уздырылган экспедицияләр, мәгълүм сәбәпләр аркасында, XX йөзнең 80 нче елларыннан берара тукталып торган иде, 2007 елда Институтны җитәкләгән Ким Миңнуллинның әлеге эшне кабат җанландырып җибәрүе зур хуплауга лаек гамәл булды. Шушы чордан башлап Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында төрле төбәкләргә фәнни экспедицияләр үткәрү комплексы төс алды һәм бүгенге көндә ел саен берьюлы бишәр-алтышар юнәлештә алып барыла.

Фәнни экспедицияләрне оештыру халыкныкын халыкка кире кайтару максаты белән тыгыз бәйле. Җыелган мирасның үз вакытында тарихка кертелүе, теркәлгән материаллар нигезендә өр-яңа фәнни хезмәтләр язылу, бер яктан, фән өчен зур казаныш булса, икенче яктан, шушы тере хәзинәнең, басма сүзгә әверелеп, китап булып чыгуы халыкның үзе өчен гаять тансык. Татарларның китапка хөрмәт белән каравы уку-язуга мөкиббән, китапка хирыс халык булуларыннан килә, шуңа да язуга теркәлгән сүзнең теге йә бу төбәк татарының үз авызыннан чыккан булуын күрүе, үзенә турыдан-туры кагылышлы китапны кулына алуы – зур вакыйга. Соңгы елларда халыктан тупланган байлыкны фәнни-популяр әйләнешкә кертүнең үтә оптималь ысулы булдырылу – шулай ук Ким Мөгаллим улы җитәкчелегендә башкарылган күркәм гамәлләрнең берсе. Институт оештырган комплексы фәнни экспедиция нәтиҗәләре 2010 елдан башлап «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» исемле аерым серия булып дөнья күрә килә. Бу – фән алгарышы өчен дә, шушы эшнең башында торган Институт өчен дә, галимнәр белән әңгәмәдә катнашып, фактик материал тупланыга үзенең зур өлешен керткән информантлар өчен дә көтелгән күренеш. «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә аерым төбәкләргә багышлап китаплар чыгару идеясенең тормышка ашырылып, җиде-сигез ел эчендә шундый 16 китапның дөнья күрүендә сериянең баш мөхәррире Ким Мөгаллим улы Миңнуллинның роле бик зур һәм, әйтергә кирәк, хәлиткеч. Россия буйлап сибелеп яшәүче татарларның мәдәни мирасын туплап, беренчел эшкәртеп, фәнни әйләнешкә кертеп җибәрү ысулы буларак та, Институтта төрле юнәлештә эшләүче галимнәрнең халык белән турыдан-туры аралашуга нигезләнгән күзәтүләрен киң даирәгә җиткерү җәһәтеннән дә әлеге сериядә чыга килгән китапларның әһәмияте әйтеп бетергесез. Татарстанның Актаныш, Апас, Кукмара, Чүпрәле, Мамадыш, Арча, Россия төбәкләреннән Түбән Новгород, Марий Эл, Удмуртия, Омск, Самара, Әстерхан, Оренбург, Томск, Чиләбе өлкәләрендә, Пермь краенда, Башкортстанда яшәүче милләттәшләребезгә, хәтта чит илдәге – Казакъстанның Семипалат татарларына багышланган китапларның дөнья күрүе, әлеге төбәкләрнең үзләренә кабат барып, китап чыгу шатлыгын җирле халык белән уртаклашып, басманы тәкъдим итү кичәләре уздыру да – һәр эшне җиренә җиткереп эшләргә гадәтләнгән Ким Миңнуллинның сыналган тәжрибә җимеше.

Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры профессор Ким Мөгаллим улы – галимлекне җитәкчелек белән оста үргән абруйлы шәхес. Фольклорчы галимнең фән юлы да, җитәкчелек карьерасы да заманча: текә, иркен, якты. Кемдер сокланып, кемдер көнләшеп карыйдыр мондый уңышлы язмышка. Татарда бер әйтем бар: «Холкың күркәм булса, тереклегең хуш булыр, холкың явыз булса, тереклегең буш булыр». Чыннан да, кешенең хөрмәтлелеге үз кулында. Ким Мөгаллим улы холкы белән дә, эше белән дә ил-көн өчен ипле, затлы кеше; аның һәрвакыт төптән уйлап гамәл кылуы төзекләндерү, җайлау, яхшырту, булдыру, үстерү сыйфатына ия. Зур галим, оста җитәкче булуы өстенә кеше буларак та олы ихтирамга лаек зат ул. Эшләгән эшләре бинаһая Ким Миңнуллинның, яуланачак үрләрен үтәли күреп, ышанычлы һәм ныклы адымнар белән максатына туры барачагына шик юк!

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,
Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре,
филология фәннәре докторы

«КИЛДЕ-КИТТЕ КЕШЕ ТҮГЕЛ БЕЗ!»

Яшәү рәвеше белән дә Тукайны кабатлаганнар татар каләм ияләре арасында җитәрлек. Шуларның берсе, һичшиксез – Нияз Акмал, ягъни Нияз Рәшит улы Акмалов (1954-2007) – заманыбызның танылган шагыйре, талантлы һәм алга таба тагын да ачылуы көтелгән прозаигы, төгәл телле тәржемәчесе, заман проблемаларын төпле ачкан публицисты, халык һаман онытмаган күпсанлы, үтә үзенчәлекле җырлар авторы.

Нияз Акмал төрле өлкәләрдән белемле кеше иде. Бу табигый, чөнки ул Сарман районы Каташ-Каран авылында укытучылар гаиләсендә туган, тәрбияләнгән. Әтисе Рәшит абый аны төгәл фәннәрдән үстерсә, әнисе Хәлимә апа баласына татар теле һәм әдәбияты серләрен төшендергән. Кечкенә Ниязның каләм тибрәтә башлавында аларның роле, бәхәссез, зур. Ул укымышлылар гаиләсендә тууы белән бик бәхетле: иҗатын бәяләүчеләр, каләменә дөрес юл күрсәтүчеләре бар. Нияз Акмал үзен алтмышынчы елларда ук матбугат аша каләме өметле үсмер буларак таныта, кайбер әсәрләрен яшьләр тупланмаларында бастырып өлгерә.

Талант бар икән, кешедә ул яшьтән үк күренә, киңкырлы була. Тукай шәхесе һәм аның кабатланмас иҗаты – моның ачык дәлиледер. Нияз Акмал да мәктәп елларында һәм студентлык чорында үзен төрле жанрларда сыный. Язган һәр уңышлы әсәре вакытлы матбугатта чыга тора. Башкалада яшәгәннәрнең иҗатчы буларак үсү, танылу мөмкинлекләре зуррак. Диплом алганнан соң, хезмәт юлын район җирендә башласа да, Тукай кебек, зур өметләр белән, Нияз Акмал да Казанга килә. 1977 елның көзеннән аның алдагы гомере башкалабыз белән бәйле.

Шул хакта уйланып утырам: балачактан ук яхшы язса да, әсәрләре еш басылса да, талантын студентлык чорында ук күреп алсалар да, Нияз абый беренче китабын басмаханәгә илтергә дә, Татарстан Язучылар берлегенә керергә дә ашыкмаган. Ул бүгенге яшьләребезгә бөтенләй охшамаган. Үзеннән элгәреләргә һәм соңгыларга тартым. Ул да – кемнеңдер укучысы, ә безнең буынның бер остазы.

Нияз Акмал Үзгәртеп кору чорынача киләчәккә бәйле без белмәгән өметләр белән яшәгәндер, үзен икенчерәк, җитдирәк сыйфатта күрсәтерлек шартлар көткәндер кебек. Югыйсә нәкъ менә сиксәненче еллар ахырында бөтенләй башка югарылыктагы, тирәнлектәге әсәрләр иҗат итә башлар идемени?! Шунысы да игътибарга алырлык бер күренеш: Нияз Акмалның тәүге китабы – лирик-публицистик шигырьләр тупланмасы булган «Учак» – татар телен яшәтү өчен көрәш җәелә башлагач, 1986 елда басылып чыга.

Мөхәррирлек теләсә кемнең каләмен бик нык камилләштерә. Тукай белән дә шулай булган. Аның күп вакыты чит эшләргә китә, дисәк тә, бу хезмәт аны рухи дә нык үстергән. Мөхәррирлек кайчак хәтта аңарчы язу теләге тамчы да булмаганнарны да үзгәртә һәм кулларына каләм тоттыра, ә үзен әдәбиятта инде сынаганнарда башкаларны узып иҗат итү теләге уята.

Әлбәттә, Нияз Акмал гажәеп нечкә тоемлы, башкалар өчен каләмен кызганмаган редактор иде. Бүгенге көннең кайбер танылган каләм ияләре аның үзләренә кылган яхшылыклары өчен эчтән генә булса да рәхмәтледер дип ышанасы килә. Әйе, ул, вакыты белән, үз мәнфәгатьләрен дә бер читкә куеп торып, кеше әсәрләрен камилләштерүне, кемнедер иҗат мәйданына китерүне нык кайгыртты. Без үзләре дә камил язганлыкларын белүебезгә карамастан, Н.Акмал өлешенең М.Мәһдиев, Ә.Еники кебек корифейлар иҗатында да барлыгын күпләр белә.

Тукай кебек үк, прозаик та, публицист та булуына карамастан, Н.Акмал халыкка, беренче чиратта, шагыйрь сыйфатында танылды. Аның оста композиторлар тарафыннан көй язылган «Тәрәзәңдә утың бар», «Күзләремнең төсе үзгәрмәде», «Соңгы кар» һәм башка әсәрләре бүген төссезләнгән, мәгънәсезләнгән эстрада әсәрләренә бер омтылыш биеклеге булып торырга тиешле. Шулар арасыннан күңел

кылларымны иң нык чиерткәне – «Тәрәзәңдә утың бар». Аның төп мотивы торып-торып тел очында әйләнә: *«Әле ярый, әле ярый / Тәрәзәңдә утың бар»*.

Классик формада иҗат итә алмаган каләм иясен чын шагыйрь дип санау кыен. Кануни сәнгатьтә йомшаклар еш кына җиңел юлдан китә һәм үзен башка, яңа, күктән төшкән бер зат итеп күрсәтергә тели, расларга тырыша. Талантка талант икәнлеген расларга кирәкми. Нияз Акмалның һәр жанрда язганы шуны ачык күрсәтте. Ул мәктәптә укыган еллар шигъриятта мөгез чыгарулар чоры булса да, Нияз абый Муса Җәлилне, Фатих Кәримне үз итә. Берара, аларга ияреп, поэмалар да яза, әмма соңыннан күбрәк Тукайны укырга тотына.

«Үзем турында үзем» язмасында Нияз Акмал болай ди: «Ә Такташка, Тукайга (аңа мин соңрак килдем), Җәлилгә, Фатих Кәримгә мәхәббәтне миндә кечкенәдән үк әнкәй тәрбияләде. Әнкәй аларны яттан белә иде. Ул аларны ятламый, әмма яттан белә иде. Аның бу гадәте (бәлки сыйфатыдыр?) миңа да күчте. Әнкәй өчен Тукай, Такташ, Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Алиш – имән баганалар иде». Шулай да иҗатчы Кәрим белән Җәлилдән Тукайга күчкән икән, әлбәттә, аның ниндидер башка сәбәбе дә бар, аларның иҗаты, һичшиксез, кайдадыр керешергә тиеш. Мин әлеге кисешү ноктасын үзем өчен таптым: өч шагыйрь дә – көрәшче. Бу аларның яшәү рәвешендә, уйларында һәм әсәрләрендә ачык чагыла.

Шагыйрь миссиясе турында уйланулар Нияз Акмал иҗатында билгеле бер урын алып тора. Ул моны Тукай образы аша да ача һәм аны милләтенә авыр чакта юл күрсәтүче дип саный. «Тукай» исемле шигырен Нияз Акмал болай дип башлый: *«Кешеләрне шул бер сорау борчый: / Тереклеккә тере су кайда? / Йөз яшәгән картка килгән кебек, / Килә кеше яп-яшь Тукайга»*.

Әйе, зур шагыйрь мирасында, хәтта бик яшьли арабыздан киткәндә дә, халык акылы һәм тәҗрибәсе туплана, милли үзаң чагыла. Әнә шуңа күрә Нияз Акмал килер буын каләм ияләренең генә түгел, теләсә кайсы кешенең, тулы бер милләтнең Тукайга килүе турында уйлана, аның сәбәп һәм шартларын ача. Ул боларны халкыбызның Тукай иҗатын тормыш дәреслеге итеп каравында, әдипнең исә халык язмышын йөрәге аша уздыруында, тормыш проблемаларын халыкка хас аңлавында, аларның асылына төшә алуында күрә.

Нияз Акмалның үзенең дә Тукайга талант буларак табынуы, олуг шәхесне рухи бөеклек үрнәге санавы ачык күренә. «Тукай. Казан. 1913 ел» шигырендә ул бу хакта: *«Мәгънә эзли, / мәгънә эзли шагыйрь / Сезнең яшәү мәгънәсендә»*, – ди. Шигъри иҗек камиллеге, язганнарына үтә таләпчәнлек, яңалыкка, башкаларча язмауга омтылыш, талантның киңкырлылыгы да Нияз Акмал исемле яшьли арабыздан киткән зур каләм иясен бөек талант Тукайга бик якын итә.

Нияз абый иҗатында талантка мөнәсәбәтле шигырьләрдән истә калырлык юллар юк түгел. Шул төшенчәне ачкан сатирик рухтагы бер әсәрендә ул болай дип язды: *«Бик күпләрнең кайгысын ул бүлеште, / Бик күпләрнең җан хәсрәтен тараттты. / Үз кайгысын сөйләмәде... / Әйттеләр: / «Кайгысы юк, шуңа күрә талантлы...»*

Нияз абый белән бик якыннан, гаилә коргач – икенче курста укыганда аралашып киттем. Бервакыт ул безгә будильник тотып килгән. Күчтәнәчем, ди. Ләис колагыма, иртәгә үзе белән алып китә дә яңадан алып килә ул аны, дип пышылдады. Өеннән чыгып киткәндә алырга өлгергән бердәнбер әйбере шул, имеш. Ирем әйткәнчә булды да. Нияз абый кич тагын эшеннән туры безгә кайткан. Алдагы көндә бик тәмле пилмән пешергән идем. Кемнеңдер юбилеен хәзерләүгә пешерүче эзлиләр, синең исемне әйтәсе булыр, дигәч, и беркатлы авыл кызы, мин ышандым. Тагын башка ризыкларыңны да ашап карарга кирәк әле, дип тә өстәгәч, икенче килешен мантыймы, башка бер нәрсәме пешереп көттем. Хушлашканда, «күчтәнәч» будильнигын бик кадерләп кесәсенә тыкты. Алга таба да ашларымны тикшерергә вәгъдә бирде. Хәзер менә үземнән көлеп, юксынып утырам. Мин инде – чын хуҗабикә, тагын да тәмлерәк ашлар пешерәм, сыйланырга көн дә йөрсә дә, ачуым килмәс иде.

Яшәгәндә кешенең кадерен белмибез. Талантларныкын бигрәк тә. Үз-үзен тотышы өчен сүгәбез, язганнары өчен көнлибез, аныңча була алмаганга үч итеп, гайбәтен таратабыз, ә эчтән генә… Эчтән генә, аның кебек була алсак, яши алсак иде, дибез. Үзебез теләгәнчә, намусыбыз кушканча, бернинди киртәләрне санга сукмыйча, «бөек»ләргә тәлинкә тотмыйча. Нияз Акмал әнә шундый иде. Ул Тукай тудырган милләт баласы иде.

Рифә РАХМАН

ДАМИР ГЫЙСМЕТДИНГӘ 70 ЯШЬ

Язучы, журналист Дамир Гыйсметдин (Дамир Минсәгыйр улы Гыйсметдинов) 1949 елның 25 гыйнварында Чувашстан Республикасының Батыр районы Татар Тимәше авылында укытучы гаиләсендә туа. 1966 елда шул ук районның Тойси урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, бер ел туган авылында, аннары Мәскәү тирәсендәге төрле төзелешләрдә эшли, 1969-1970 елларда армиядә хезмәт итә. Хәрби хезмәттән соң Казанга килеп, 1971-1976 елларда университетның журналистика факультетында югары белем ала. Университетны тәмамлагач, ун елдан артык (1975-1986) «Чаян» журналы редакциясендә хәбәрче, бүлек мөхәррире, бүлек мөдире булып эшли. Шул елларда ул үзенең сатирик каләмен чарлый, «Чаян» журналы һәм башка көндәлек матбугат битләрендә юмор-сатира жанрындагы күп кенә хикәяләрен, усал эчтәлекле фельетоннарын бастырып, укучыларның киң даирәсенә исемен таныта. Узган гасырның сиксәненче елларында аның кайбер юмор-сатира әсәрләре Мәскәү басмаларына да урнаштырыла.

1986-1990 елларда Д.Гыйсметдин КПССның Татарстан өлкә комитетында халыкара мәсьәләләр буенча консультант һәм бүлек инструкторы булып эшли. Туксанынчы елларда халыкара «Ватан» җәмгыятенең әүвәл рәис урынбасары, аннары рәисе вазифаларын башкара, Бөтендөнья Татар конгрессының идарә әгъзасы буларак, чит илләрдәге татар диаспорасы белән багланышларны ныгыту юнәлешендәге эшләргә җитәкчелек итә. Туксанынчы елларның урталарыннан башлап Дамир Гыйсметдин Татарстан Республикасының чит ил компанияләре белән уртак предприятиеләре идарәләрендә җаваплы җитәкче урыннарда эшли.

Дамир Гыйсметдин – юмор-сатира әсәрләре тупланган өч китап авторы («Өметсез шайтан», 1990; «Әйтсәм әйтим», 1999; «Атта да, тәртәдә дә...», 2007). Ул шулай ук аерым күмәк җыентыклардагы («Таныш булыгыз, Ломжа» – «Знакомтесь, Ломжа», 1989; «Йөртә безне язмышлар», 1992) очерклары, көйгә салынган популяр җыр текстлары (унлап җыры 1999-2000 елларда чыккан «Сез яраткан җырлар» китабына кертелә) һәм төрекчәдән тәрҗемә китаплары авторы буларак та укучыларга таныш. Аерым алганда, Ф.Бичури белән берлектә ул Төркиядә үз вакытында киң танылган милләтпәрвәр татар эшкуары-кәсепчесе Ибраһим Мәңгәр турында кызы язган истәлек китабын (Сафия Имре. «Әтием», Казан, 1994) төрекчәдән татарчага тәрҗемә итә.

Д.Гыйсметдин – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Ул – 2002 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

---

* Сәхифә «Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек» (төзүчеләре: Р.Даутов, Р.Рахмани. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2009) китабы нигезендә әзерләнде.

Кайтаваз

АЧЫК ХАТ

Әссәламегаләйкем, Айдар хаҗи!

Былтыргы күчтәнәчеңне быел алдым. Рәхмәт! «Шушы кырлар, шушы тугайларда» дигән китабың өчен. Прозаик Айдар Хәлим белән шагыйрь Айдар Хәлим ярыша-ярыша иҗат итәләр. Афәрин!

Гадәттә, тәнкыйтьчеләр шагыйрь иҗатына бәя биргәндә, автор күтәргән темаларны санап чыгалар. Туган халкы, туган җир, мәхәббәт... Мин тәнкыйтьче түгел. Ритм-рифмаларга, эпитетларга тукталып тормыйм. Әйтик, чәчәкнең исен сүзләр белән бирепбуламыни?! Чәчәкнең үзен күрергә, аны иснәп кararга кирәк. Татар тотмый ышанмый ич. Шуңа күрә шигырьне дә тотып кararга, ягъни укып кararга кирәк.

Мин дә укып чыктым китабыңны. Һәм бер мәртәбә генә дә түгел. Гадәтем шундый. Ошаган әйберләрне кайта-кайта, кат-кат укыйм, шулай ләззәтле минутлар кичерәм.

Автор нәрсә турында яза? Урыста «Каков ты велик, человек; каков ты низок, человек!» дигән афоризм бар. Син менә нәкъ шул турыда язасың. Аннары шигырьне шигырь иткән метафораларың... Без бит, гадәттә, халык иҗатындагы, классик шагыйрьләр иҗатындагы метафораларга күнеккәнбез. Алар безгә таныш, нык аңлашыла. Ә менә синең метафораларыңның күбесе – үзеңнекеләр, яңалар. Шуңа да алар укучыны сискәндерә, хәтта кайберләре аңлашылып та җитми. Монда инде укучыга зиһенен эшләтергә туры килә. Кеше чәйнәп каптырганга караганда, үзең чәйнәп йотуга ни җитә!

Әйткәч әйтим инде. Шигырьләрең генә түгел, проза әсәрләрең дә, гомумән, бар иҗатың бездәге бөтен премияләргә лаек, димәк, син халык әдибе исеменә лаексың.

Сиңа сәламәтлек телим. Язасыларың күп әле…

Уфадан каләмдәшең **Фәрит ГАБДЕРӘХИМ**

Бер фото тарихы

«1965 елда Пермь краеның Барда районы тарихында беренче тапкыр Татарстаннан язучылар һәм композиторлар төркеме булып китә. Язучы-шагыйрьләрдән Нури Арсланов, Галимҗан Латыйп, Әдип Маликов, Рәдиф Гаташ, журналист Зоммер Гыйләҗев, композитор Зәһид Хәбибуллин составындагы делегацияне язучы Габдрахман Әпсәләмов җитәкли. Әлеге шәхесләр 14 очрашу оештыра. Фотода Габдрахман Әпсәләмов минем әни – районыбызның беренче галимә хатын-кызы, филология фәннәре кандидаты, Урал татарлары теле үзенчәлекләрен өйрәнүгә гомерен багышлаган Дания Сарманаева һәм аның укучылары белән».

Алсу МӘҮЛИКАЕВА.
Пермь крае, Барда

Галиәсгар Камал
(1879-1933)

Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов 1879 елның 6 гыйнварында Казанда һөнәрче гаиләсендә туа. Сабый вакытын бабасында – әнисенең туган авылы Түбән Масрада (хәзер Арча районына керә) уздыра, алты яшендә авыл мәдрәсәсенә йөри башлый. Аннары, Казанга кайтып, «Госмания», «Халидия» мәдрәсәләрендә укый. 1893-1900 елларда заманының алдынгы карашлы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә, шул ук вакытта өч класслы рус мәктәбендә башлангыч белем ала.

Мәдрәсәдә укыган чакта ук әдәбият, театр сәнгате белән мавыга, рус спектакльләренә йөри. 1898 елда «Бәхетсез егет» (I вариант) исемле тәүге драмасын яза, төрек язучысы Н.Кәмалның «Кызганыч бала» драмасын татарчалаштыра, «Өч бәдбәхет» исемле пьесасы да дөнья күрә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлап, Г.Камал 1901 елда «Мәгариф көтепханәсе» оештыра һәм китап басу, тарату эше белән шөгыльләнә башлый. 1905 елдан татар журналистикасын булдыру-үстерү эшенә алына, газета-журналлар чыгаруны оештыра. Һ.Максуди чыгара торган «Йолдыз» газетасына эшкә килә, биредә 1917 елның октябренә кадәр эшли. Шулай ук 1908-1909 елларда Г.Тукай белән берлектә татар телендә беренче сатирик журнал – «Яшен»не чыгара. «Яшен» ябылгач, «Ялт-йолт» көлке журналында да эшен шул юнәлештә дәвам итә.

Г.Камал – татар милли театрын үстерү эшенә зур көч куйган шәхес. Ул, театр репертуарын драма әсәрләре белән баетудан тыш, «Сәйяр» труппасында артист һәм режиссёр булып та эшли. 1906 елның 22 декабрендә Казанда Яңа клуб бинасында беренче рәсми спектакль – Г.Камалның тәрҗемә әсәре «Кызганыч бала» сәхнәләштерелә.

Профессиональ театр туу Г.Камалны иҗатка рухландыра. 1907-1912 еллар аралыгында үзенең иң көчле, сәнгатьчә иң камил әсәрләрен яза. Нигездә, ул драматургиянең ике жанрында иҗат итә. «Бәхетсез егет» (1907, икенче варианты), «Уйнаш» (1910, «Өч бәдбәхет»нең үзгәртелгән варианты), «Дәҗҗал», «Каениш», «Көндәш», «Өйләнәм – ник өйләндем?» кебек драмаларында җәмгыятьтәге әхлакый түбәнлек, кешелексезлек проблемалары яктыртыла. «Беренче театр» (1907), «Бүләк өчен» (1908), «Банкрот» (1911), «Безнең шәһәрнең серләре» (1912) комедияләре үз чорының актуаль мәсьәләсен, тормышчан вакыйгаларны сәхнәгә күтәрү белән аерылып тора. Г.Камал үзен комик ситуация, сатирик тип тудыру остасы итеп таныта.

Октябрь революциясеннән соң Г.Камал «Эш», «Эшче», «Кызыл көрәшче» газеталарында чор таләпләренә буйсынып язылган күпсанлы сәяси, сатирик шигырьләр-декламацияләр бастыра. Егерменче елларда һәм утызынчы еллар башында «Тәкый гаҗәб, яки Ахыры заман», «Могҗиза», «Ысул кадимче», «Җантаһир белән Җанзөһрә» исемле сатирик комедияләр, «Хафизәләм-иркәм» (1921-1922), «Күзсез мастерлар» (1930), «Өч тормыш» (1930) исемле драмалар, кечкенә күләмле эстрада әсәрләре яза. 1923 елда Г.Камалга – «Хезмәт Батыры», ә 1926 елда «Татарстанның халык драматургы» дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Галиәсгар Камал 1933 елның 16 июнендә вафат була.

---

* Сәхифә «Татар драматурглары: биобиблиогр. белешмәлек» (төзүчеләре: Ф.Ганиева, Р.Яруллина, А.Саттарова. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2007) китабы нигезендә әзерләнде.

Сатирик әсәрләр

ШАЯН ПАРЧАЛАР

Су юлы

Күп еллар үтсә дә, армиядә булган хәлләрне еш искә алам. Әйтергә кирәк, ни өчендер гел акыллы чакларымны гына хәтерлим...

Учениеләр бара. Мин авыл егете булгач, командир елга аша үтәрлек, ун метрлы басма салырга әмер бирде. Бу хәрби учение барышында бик әһәмиятле корылма, дип кисәтте.

Бригада җыйдым, шуларның берсе төзелеш техникумын тәмамлаган егет иде. Ул, бик җитди уйлар белән, булачак күпернең сызымын да эшләп куйды. Субайларны судан күпкә күтәрергә ярамый, чөнки ныклыгы булмас, диде. Нәтиҗәдә, бер метр киңлектәге басма барлыкка килде.

Икенче көнне карыйбыз, басмабыз юкка чыккан. Баксаң, төнлә көчле яңгыр яуган да, елга күтәрелгән, кичү дигәнебез баткан, якын килгәч кенә күренә икән. Бераздан солдатлар, бер-бер артлы тезелеп, елга аркылы чыга башлады. Шуларны күзәтеп торган авыл халкы, гаҗәпләнеп, аптырап калды, ә әбиләр исә: «Смотрите, они по воде ходят!» – дип чукынырга ук тотындылар.

Комбат миңа, ни өчен басманы суга салдың, дигәч, дошманнар күрмәсен өчен шулай иттек, дидем. Задание уңышлы үтәлгән өчен, соңыннан бүләккә тәкъдим ителдем.

Көлке түгел

Беркөнне мине эштән машина килеп алырга тиеш иде, биш минуттан булабыз, дип шалтыраттылар. Урамга чыксам, инде машина килеп туктаган. Җайлап кына кереп утырдым да, «поехали!» дидем шофёрга. Тик ул нигәдер кузгалып китәсе урынга, машинадан чыкты да чапты.

Баксаң, мин машинаны бутаганмын икән, ә шофёрга, бервакыт шулай, бандит кереп утырганы булган. Шуңа ул табан ялтыраткан да инде. Аңлашкач, бик озак көлештек!

Таныклыклы танышлар

Кичә бер кызыклы хәл булды бит әле. Автобуска кердем, кондукторы танышым булып чыкты. Җайлап утырдым да, язып барырмын, дип, кулны блокнот алырга кесәгә тыккан идем, шунда ук кондуктор, кирәкми, таныдым сине, күрсәтеп торма таныклыгыңны, диде. Китте инде бу, дип, кулымны кесәмә тагын тыктым, тик ул, күреп, кабат алып куярга ишарәләде. Ераграк киткәнен көтеп торып, блокнотымны алдым, ниһаять, тик ул вакытта язарга теләгән уйларымны оныткан идем инде!

Ах, оятсыз...

Бервакыт мине, «на переподготовку» дип, өч айга армиягә алдылар. Мәскәүдә безнең ишеләрдән команда җыеп, Алтай якларына җибәрделәр. Мине озын буйлы, юан бер тәкәббер майорга беркеттеләр, ул хәзер – начальнигың, ни әйтсә, шуны эшлә, диделәр. Поездда бик озын, ялыктыргыч юлны кем ничек кыскарта бит: кемдер газеталар, калын китаплар укый, күбесе исерткеч белән күңел ача. Минем дә начальнигым миңа күрсәтмичә генә эчеп бара. Тукталышларның берсендә безнең янга

утыз яшьләр тирәсендәге бер чибәр кыз керде. Кызу көннәр бит, бик жиңелчә киенгән бу, ә теге майор аңа гел текәлеп карап тора. Мескен кызый бик уңайсызлана, үзен кая куярга да белми. Миңа әллә ниләр әйтә башлады майор, юктан гына кимсетә, ачулана, гел үзенең өстенлеген күрсәтә. Әлбәттә, ачуым килә, тик нишлисең – буйсынырга приказ бирделәр бит. Шулай бара торгач, тоннельгә кереп киттек, кап-караңгы, төн диярсең. Капылт кына бер уй килде башыма... Тиз генә кызның күкрәгенә орындым! Кулны яшен тизлегендә алып куюым булды, ишетәм: чалт – майорның яңагына... Тынычлык, поезд яктылыкка чыга. Минем начальник, кыз үзенә карап барганны яратмады, шуның өчен эләкте, дип уйлады, ахрысы, бик игътибар белән тәрәзәгә текәлде. Бераздан тагын караңгылыкка кереп киттек, мин «чалт» итеп, кулларымны бер-берсенә суктым. Теге мескен, тагын эләгә, дип уйлаган булса кирәк, чыкканда ике кулы белән башын каплаган иде! Без өч ай диярлек бергә булдык. Бервакыт бу майор суга бата язды, өстерәп чыгардым. Ну мине бик мактады инде, гафу ит теге чакны поездда кыланганга, диде. Мин аңа ничек булганын сөйләп биргәч, көлә-көлә, суга бата язганын да онытты теге.

Хәрби сер

Бервакыт армиядә бергә хезмәт иткән танышымны очраттым. Әлбәттә, бергә кичергән кызыклы вакыйгаларны искә алдык. Мин, ни өчендер, взводта иң соңгы булып киенүче идем. Күпме генә тырышсам да, ике-өч секундка артта калам. Уйлый торгач, җаен таптым бит, жиңдәге төймәләрне күчереп тактым... Шул көннән иң житез солдатка әверелдем: фокусник сыман, тиз генә киенәм, кулны банкага тыккандай итәм дә, төймәләрне дә эләктергән рәвеш чыгарам. Аптырап беттеләр, тик ничек икәне хәрби сер булып калды.

Ашыктырма

Автобуста эшкә барышым. Больницада ята торган дустыма телефоннан, ашыкмыйча гына, кичә язган хикәямне сөйлим. Уртасына житәм дигәндә, бер хатын: «Чем заканчивается? Мне уже надо выходить?!» – дип, ачу белән әйтеп куйды. Гажәпләнүемнән, үзем дә сизмәстән, тиз генә хикәямнең ахырын әйтеп бирдем. Теге хатын автобустан: «Уффф!..» – дип чыгып китте.

Адәм күрке – чүпрәк...

Минем дустыма кырык яшь тирәсе. Ул интернетта бер татар кызы белән танышкан. Шулай, ике ел буе көне-төне сөйләшә торгач, тормыш корабыз, дип, Казанда очрашырга булган болар. Егет кунак йортында ике урынлы бүлмә дә алып куйган. Бик озак сөйләшкәннәр, көн төнгә авышкан, кыз юыну бүлмәсенә кереп киткән. Дустым тумбочкага караса, анда парик, ясалма тешләр, керфекләр, ди... Хәзер ваннадан нинди әби чыгар, дип куркып утыра икән бу! Кыз чыккан да, курыктыңмы, мин шаярттым, дигән!..

Әйе, 80 нче елларда, армиядә, хәрби частьта гына солдат формасын бирәләр иде. Без дә, мунча кергәннән соң, өр-яңа форма алдык. Прапорщик миңа, нигәдер, бар киемнең дә ике размерга зуррагын бирде. Алыштырыгыз әле, дигәч, дембельдән соң яраклысын әниең алыр, диде. Күрше караватта миннән шактый гына гәүдәлерәк егет бар иде. Мин аңа үземнең ХБны бирдем, киеп карагач, искиткеч килеште аңа, әйтерсең, махсус парадка әзерләгәннәр үзен... Мин аңа: «Сиңа килешә, салма», – дидем. Ә үзем аныкын киеп куйдым! Күрсәгез иде сез мине, әтисе киемен кигән кечкенә малайга охшап калдым!

Китапханәгә юл тоткан булып, комбат янына таба атладым!

– Это что за пугало огородная? – ди комбат.

– Шушындый форма бирделәр, матурын өеңә кайткач киярсең, диделәр.

Ул, старшинаны чакыртып, бер сәгать эчендә солдатка охшаган булсын, дип әмер бирде. Шулай итеп, мин үземә таман форма кидем!

Тел озынлыгы

Кичә, шыгрым тулы автобуста кесә телефоным шалтырады. Энекәш икән. Ике минут чамасы сөйләшкәннән соң, карасам, миңа бер кеше текәлеп карап тора. «Извините, вы на каком языке говорили?» – ди бу. Мин аңа: «Воот! – дип, телемне чыгарып күрсәттем, аннан: – на татарском», – дип өстәп куйдым. Ул бераз югалып калды...

Кем кемнеке?..

Мин биш катлы йортта яшим, кемдер асфальтка «Света, я тебя люблю», дип язып куйган. Күршем – татар, ә аның хатыны, татар кызы булуга карамастан, Светлана исемле. Кем язганын белмисеңме, дип сорый бу. Мин каян белим инде... Беркөнне, җылы кич белән, безнең подъездга бизәкләнгән машина килеп туктады, җитмәсә капотына «Света, выходи!» дип язылган. Машина берөзлексез кычкырта. Әлбәттә, Света түзмәде, чыкты! Баксаң, бу унҗиде яшьлек кызчык икән! Ә күпме ир борчылып, гаиләләр тиргәшеп бетте! Романтик егеткә фамилиясен язарга булмый идемени?!

Шәфкать ГАНИЕВ.
Ижау шәһәре

ЗАРИФИЗМНАР

• Явызлык – әҗәт кебек: иртәме-соңмы, түләргә туры киләчәк.

• Йөз киңәшкә караганда, бер үрнәк яхшырак.

• Кош очканда – каурый, бала читкә очканда, күз яше коела.

• Кайвакыт башкаларга гына түгел, үз-үзеңә дә ярап булмый.

• Кешене тикшерсәң, нәселеңне тикшererләр, хатыныңны тикшерсәң, дәрәҗәңне төшererләр.

• Җәяүлегә – янчык, терәүле йортка түбә дә авыр.

• Игелек – савапсыз, яманлык җавапсыз калмас.

• Сандугач булу өчен, сайрый белү генә җитми, кунар урын да кирәк.

• Мәхәббәт формуласы: эзләдем, таптым, югалттым...

• Бай – акча, явыз – дошман юклыктан зарлана.

• Кеше күңеленә дөнья да сыя, нәфес кенә сыеша алмый.

• Чебешләрне – көзен, казларны өйләнгәндә саныйлар.

• Бака үрчесә – күл, түрә үрчесә, ил казнасы саега.

• Сакал акыл өстәсә, кәҗәдән дә акыллырак хайван булмас иде.

• Байның – хатыннары, ярлының салымнары күп була.

• Кешеләр маймылдан яралган булса, урманда бер агач та калмас иде.

• Илдә чыпчык үлми, саны гына кими.

• Марста тереклек бар, диләр. Кеше аяк басуга, ул юкка чыгачак.

• Сагышлыдан – елмаю, табышлыдан мал сорама.

• Агымга иярсәң – юлыңнан, нәфескә иярсәң, илеңнән язарсың.

• Орчыкка да үз җыры тансык.

Фирдәвес ЗАРИФ

БӘЛӘКӘЙ ЛИЛИЯ

Борчылма, дәү әни!

Пчеловод (Кукмара районы) урманында укучылары арасында Галия Минская (сулда), дәү әни – Гафикамал Гаффарова (уңда), алдагы рәттә – кечкенә Ләлә белән Лилия.

Әнием ягыннан дәү әти белән дәү әни Кукмара районының Пчеловод авылында яшиләр иде. Җәй саен аларга кунакка кайтам. Ул чакта миңа биш яшьләр тирәсе булгандыр. Пчеловодта бала-чага чиратлап каз көтүе көтә. «Көтүчеләргә» кызыгып карыйм. Көннәрдән бер көнне чират безгә дә җитте.

– Дәү әни, быел каз көтүен үзем генә көтим әле, – дип ялынам.

– Кызым, син кечкенә бит әле, зуррак кызларны җибәрик, – ди дәү әни.

Соңыннан ризалашты тагын үзе. Бер көтү бала-чага иртән иртүк торып, эшем кешеләре кебек җыенып, каз көтәргә киттек. Төшке аш вакыты җиткәч, Дәү әни әбәд әзерләп, берочтан безгә күз-колак булыйм дип килеп җитсә, бөтен казлар – арыш басуында, ә без күлдә рәхәтләнеп, чупырдый-чупырдый су коеныпятабыз.

Дәү әни:

– Кызым, казларыгыз басуга кергән бит, – дип кычкыра-кычкыра, тау башына чаба.

Мин:

– Дәү әни, борчылма, ашап туйгач су эчәргә үзләре төшә алар, – дип, берни булмагандай, күлдән чыгып киләм икән.

Ә читек?!

Икенче җәйне әни миннән ике яшькә зуррак апам Ләлә белән безне янә дәү әнигә кунакка алып барды. Барышлый, Арчадагы бер кибеткә кереп, дәү әнигә бүләккә дип, ул заманда бик дәрәҗәле саналган чиккән читек сатып алдык. Безне Пчеловодта калдырып, әни кайтып китте.

Дәү әниләрнең каршында гына авыл кибете урнашкан иде. Без апа белән көн дә шул кибетне «штурмлыйбыз». Дәү әнидән ирис-конфетка акча сорыйбыз. Дәү әни бер бирә, ике бирә акчаны.

Өченче көнне әйтеп куя:

– Кызлар, әниегез акча калдырып китмәде бит, ә мин инде пенсиядә, кайдан җиткерим соң?..

Шунда без дәү әнигә беравык карап уйланып торганбыз да беравыздан ярып салганбыз:

– Ә чите-е-ек?!!

Люция укый!..

Беренче класста минем тырыша-тырыша укырга өйрәнгән чагым. Сәгатьләр буена урыннан кузгалмыйча, «а-у», «а-у», дип утырам... Шунда әни, мине кызганып: «Кызым, бик күп укыдың бит инде, бар, бераз уйнап кайт», дип, урамга чыгарып җибәрә. Биш минут та узмый, мин тыныма кабып, йөгереп кайтам.

– Әни-и-и, Люция укый!!! (Бүгенге көндә «Казан утлары» журналының бухгалтеры.) дим, шартлардай булып. Тиз-тиз генә чишенеп, янә укуга ябышам.

Еллар узды. Минем эшем дә гел укый торган булып чыкты. Утыз елдан артык «Казан утлары» журналы редакциясендә мөхәррир-корректор вазифасында. Эштә дә укыйм, өйдә дә укыйм. Алны-ялны белгән юк.

Хәзер йә әти, йә Ләлә апам шылтыраталар да: «Нишлисең әле?» – дип сорыйлар. Мин безнең гаилә әгъзалары гына аңлый торган ике генә сүз әйтәм:

– Люция укый!!!

Язмыш-такыям алдамады...

Минем балачагым, мәктәп елларым Арча районы Утар-Аты авылында узды. Без бер урамда биш кыз уйнап үстек. Дүртебез бер класстан: Люция, Алсу, Нажия һәм мин. Наилә бездән ике класска түбәнрәк. Нинди генә уеннар уйлап тапмый идек... Берсендә су буенда чәчәкләр җыеп, такыялар үрдек. Шунда кемдер әйтеп куйды:

– Әйдәгез, такыяларны суга агызып җибәрәбез, кемнеке алга чыга – шул кияүгә дә беренче чыгачак!

Иң беренче Люциянеке йөзеп китте. Аннары Нажиянеке, Наиләнеке, Алсуныкы. Ә минем такыям бер борылышта нәрсәгәдер эләгеп туктап калды...

...Еллар узды... Дус кызларым нәкъ шул тәртиптә кияүгә чыкты. Ә минем язмыш-такыям һаман теге борылышта торадыр кебек...

Пенсиямне көткәндә...

Һәркемнең туган көне бер генә була. Ә минеке икәү. Дөресрәге, мин Яңа ел алдыннан, 1963 елның 28 декабрендә туганмын. Әни мине «Кызым бер-ике көн аркасында картаеп йөрмәсен әле», дип, 1964 елның 1 гыйнварына яздырып куйган. Ул елны авылның шәфкать туташы үзе дә хастаханәдә булып, әнинең шуклыгы сизелми дә калган. Шулай да еллар узган саен әни еш кына: «И кызым, яздыруын яздырдым да, син пенсияләргә җиткәндә генә законнар үзгәреп куймаса ярый инде», – дип әйткәли иде.

Менә 2019 ел да килеп җитте. Быел тоттылар да, 55 ел буена үзгәрмәгән законны үзгәрттеләр дә куйдылар... Һәм мин пенсиягә кадәр тагын ярты ел артыгын эшләргә мәҗбүрмен! Әнием исән булса, и борчылыр иде... Ә минем аны юатасым килә:

– Әнием, син мине бер елга, ә хөкүмәтебез тагын ярты елга яшәртте бит!

Лилия ГАТАУЛЛИНА,
ТРның атказанган матбугат һәм гамәви коммуникацияләр хезмәткәре

Редакциядән:

Бу айда хезмәттәшебез, 35 ел гомерен журналыбызга багышлаган Лилия Илгизәр кызы Гатауллина юбилеен билгеләп үтә. Аңа сәламәтлек, киләчәк тормышының да балачак хатирәләрендәге кебек якты, бәхетле булуын телибез!

УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

Туфан МИҢНУЛЛИН

Минһаҗ маҗаралары

Кердек әкәдим наукка. Җыелышлары башланган. Бик күп кеше җыелган. Яртысы пеләш, яртысы ак чәчле.

– Болар барысы да әкәдимнәрме? – дип сорыйм безнең янда утырган Разыйл Вәлиевтән.

– Болары әле чепуха. Ун меңләп әкәдим әле килмәгән, – ди. Әкәдимне хәзер хәреф таныган бөтен кешегә өләшәләр, – ди.

– Алайса мине дә әкәдим ясагыз әле, – дим.

– Гаяз Исхакый әйбәт язучы булган, дип әйт, ясарлар, – ди Разыйл Вәлиев.

– Туктагыз инде, татар халкының язмышы хәл ителгәндә, сөйләшеп утырмагыз,– дип, Туфан Миңнуллин безне туктатты.

Әкәдимнәрнең ни сөйләгәнен тыңларга керештем. Әй, егетләр! Андагы галәмәтне ишетсәң... Лилин булып Лилиннең ни сөйләгәнен аңлый идем, боларны булмый гына бит аңлап. Берсе трибунга менә дә әйтә: «А» хәрефенең өстендәге ике нокта арасы ярты миллимитыр булырга тиеш, һәм алар «а» хәрефенең өске өлешеннән бер миллимитыр биеклектә торырга тиеш», – ди. Икенчесе аңа каршы чыга: «Дөрес түгел, татар арфагырафиясенең уйгур-рун язмасында ноктала вапшы юк», – ди. Өченчесе әйтә: «Җ» хәрефенең койрыгы кәҗә койрыгы кебек өскәрәк кәкрәеп торырга тиеш, – ди. – Кәҗә дигән сүздә «ж» хәрефенең булуы очраклы хәл түгел, – ди.– Кәҗә койрыгы белән «ж» койрыгы фанатик яктан бәйләнешкән», – ди. Шуннан тотынды болар талашырга. Икегә бүленделәр – берсе яңалиф булды, икенчеләре төрек булды. Китте галәмәт, берсе өстенә берсе очып-очып куналар. Бара-тора нәрсәгә җыелганнарын да оныттылар.

Разыйл Вәлиевтән сорыйм:

– Нишлиләр алар? – дим.

– Белмим, – ди Вәлиев, – сихер эше бу, – ди. – Нәбирә Гыйматдинованың да катнашы юк микән?

Шуннан үземне тиргәргә тотындым: «Их син, дурак, дим. Мәскәү хәтле Мәскәүгә барып, Жиринәуски белән сугышып йөргән буласың... Аның өстәлендә бер-берсе өстеннән татарлар язган бер кочак жалу, монда сүгешү. Нишләп йөрисең монда, бар, кайт Кайпердеңә, дим. Ноктасы да юк Җома-бикәннең, койрыгы да юк, кочакла да ят», – дим. Тордым да чыгып киттем җыелышларыннан.

Туфан Миңнуллин ияреп чыккан.

– Кая барасың, Минһаж абзый? – ди.

– Кит, – мин әйтәм, – бүтән яныма киләсе булма. Райунга да кайтып йөрмә. Бер нокта өчен талашасыз. Дөрес эшли Мәскәү, сезнең барыгызны өтернең койрыгына элеп куеп суктырырлык, – дидем дә кайтып киттем.

(Дәвамы бар)

НАЛАСАЛЫ

«Салучылар»

Гариф Ахунов исемендәге премия тапшыру тантанасына Арчага Казаннан да язучылар кайта. Бөтенесе дә канәгать, бары Вакыйф Нуриевның гына, классиклар әйтмешли, күңеле төшенке. Өстәвенә, әле бер-ике көн элек үз юбилеен шаулатып

уздырган язучы «Казан утлары» журналының баш мөхәррире белән бер машинада кайта. Кан басымы да уйнаган шикелле, йөрәк тә ныграк кага бугай. Кыскасы, елмаерлык бер сәбәп тә күренми...

Җиңүчеләрне сәхнәдән котлап, затлы табында чәй эчкәч, кунаклар да кузгалыша. Арчадан сигез чакрымда гына урнашкан баш мөхәррир авылына – Наласага да кереп чыгалар.

Госман агай Вакыйф Нуриевның елмаймау сәбәбен бер караштан аңлап ала. Бераздан өстәл янында язучының шат тавышы ишетелә башлый, йорт, каралты-кура турында сүз чыга. Вакыйф Нуриев үз гомерендә өч йорт төзүен әйтә.

– Минем әти дә өч йорт җиткезгән, – дип сүзгә кушыла Рөстәм Галиуллин. – Институттан Олы Мәңгәргә укытучы итеп җибәргәч, шунда салган. Арча педучилищесында укытканда, Арчада салган. Наласага мәктәп директоры итеп кайтаргач, монда да салган...

Шулвакыт күрше бүлмәдән Госман агайның хатыны Нурсөя ханымның тавышы ишетелә:

– Ник арттырып сөйлисең инде, улым?! Алай тәртипсезләнеп салып йөрмәде ич инде ул...

Табын көйләү мәшәкатьләре белән мавыгып, ул сүзнең ни хакында барганын аңлап бетермәгән икән. Ниһаять, Вакыйф Нуриевның кәефе чын-чынлап күтәрелә.

Морад ДУСАЙ

Хикмәти кәлүш

Магниттау (Магнитогорски) каласында йөргәндә, Казан кунакларын күренекле шагыйрь Равил Фәйзуллинның сыйныфташы Шамил Әхмәтшин эзләп тапты. Үзенә дә шигырь «җене» кагылган җор телле Шамил ага бала чакларын, атаклы сыйныфташының мәктәп елларындагы шуклыкларын сагынып искә төшерде:

– Равил бәләкәй чагында бик шук иде ул. Хәзер ничектер, ул заманнарда мәктәпкә аяк киемен салып керешле иде. Аяк киеме дигәнем шул – кәлүш инде, кызыл эчле. Берзаманны шулай, укытучы абыебыз болдырдагы кәлүшенә аягын тыкса... Кузгалмый гына бит кәлүше! Идәнгә кадаклап куелган, менә сиңа вәйт! Соңыннан белдек – Равил эше!

Без көлешеп туйгач, шагыйрь Газинур Морат, сакалын сыпырып, болай дип куйды:

– Кадаклау ягына чос инде ул минем бажай...

Марсель ГАЛИ

Табышлар

- Тотка – ишекнең ишәге....
- Чишмә – диңгез имиен эзләп чапкан сабый су...
- Ажаган – күкрәвеннән тол калган кысыр яшен.
- Китап – үзең ачып керәсе, үзең ябып чыгасы серле мәгарә.
- Вакыт – Ходай тәсбихы. Төймәләре күпме тезелгән – берәү дә белми.
- Мәңгелек – яшәү уенының юаныч куены.
- Идея – татлы имезлек. Сабыйлык акылы кертеп, халык авызына каптырып куялар да... Шуны тәмләп суыра-суыра, дистә еллар буена иләсләнеп яши торгач, имезлекнең тәме бетә, халык, айный башлап, төкереп ташлый да, яңача алданырга имезлек көтеп, авызын ача.
- Нокта – җөмләне куркытып туктаткан ядрә эзе.

Сәхифәне **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИННЕҢ МЕМОРИАЛЬ МУЗЕЕ

Күренекле тарихчы, мәгърифәтче, педагог, «Шура» журналының мөхәррире, 1922-1936 елларда Рәсәй күләмендә мөфти вазифаларын башкарган дин әһеле Р.Фәхреддиннең (1859-1936) Татарстан Республикасының Әлмәт районы Кичүчат авылында «Татнефть» АҖ ярдәме белән төзекләндерелгән мемориаль музее 1995 елның 25 маенда Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев катнашында ачылды.

Биш залга бүлеп урнаштырылган экспозиция тулысынча Р.Фәхреддин яшәгән чорны, аның тормыш юлын, бай иҗади мирасын яктырта. Беренче залның төп экспонаты – рәссам М.Шәйдуллинның ТР Президенты М.Ш.Шәймиев үтенече буенча ясаган Ризаэддин Фәхреддин портреты. «Кичүчат – минем туган җирем» дигән бүлектә XIX гасыр – XX йөз башындагы татар крестьяннары, укымышлы имамы файдаланган эш кораллары, кием-салым, көнкүреш әйберләре, сабый Ризаэддиннең нинди шартларда үскәнен күрсәтә торган татар йорты күренеше белән дә танышырга мөмкин. Экспозицияләрнең өченче залы Р.Фәхреддиннең Оренбург каласындагы эшчәнлеген яктырта. Биредә исә үзәк экспонатлар – «Шура» журналының нөсхәләре һәм эш өстәле – галимне бөтен төрки дөньяга мәшһүр мөхәррир буларак ача. Дүртенче зал Уфа чоры турында сөйли. Биредәге экспонатлар музейга килүчеләрне Уфадагы мәртәбәле галим, дин эшлеклесе, мәшһүр биобиблиографик хезмәт – «Асар» авторы Р.Фәхреддин белән таныштыра. Бишенче экспозициянең үзәгенә галимнең нәсел-нәсәбен чагылдырган шәҗәрә урнашкан. Анда 800гә якын исем теркәлгән! Музейга килүче кунаклар Р.Фәхреддиннең әтисе яки әнисе, җәмәгате Нуржамал абыстай ягыннан ясалган шәҗәрәләрне күреп, үзләренең нәсел җепләрен барларга керешәләр.

Галимнең балалары, якын туганнары музей фондларын даими рәвештә тулыландыру эшендә бәһаләп бетергесез игелекле эшләр башкарды. Р.Фәхреддиннең 50 яшьлек юбилеена олы кызы Зәйнәп ханым чигеп бүләк иткән намазлык кына да ни тора! Музейның түрендә саклана торган юл сандыгын Ризаэддин хәзрәт китаплар салып йөрер өчен сатып ала. Аның каләм кебек язу-сызу җиһазларын салыр өчен махсус тартмачыгы да бар.

Дин әһеле үзе һәм гаиләсе белән бик күп мәртәбә фотога төшкән. Фотоларның арткы ягында «тәзкирә», «сагынмаклык», «гомерлек ядкәрем», «ядкәр гажизанәм», «туганкаем», «яраткан сеңлем», «сөекле туганым», «хөрмәтле әткәем вә әнкәемә», «сөекле балакайларым», «газиз балаларым», «бәхет вә тәүфыйк, сәгадәт теләүче әткәләре» дип, татар теленең, туганлык мөнәсәбәтләре лексикасының байлыгын, сыгылмалыгын белдерә торган күркәм сүзләр язылган. Музей фондындагы фотолар арасында Уфа, Казан, Оренбург, Ленинград шәһәрләрендә төшерелгәннәре, хәтта Мәккәдән кайткаллары да бар.

Музейда тупланган фотосурәтләр, китаплар, җиһазлар, әсбаплар, кульязмалар Р.Фәхреддин мирасы белән генә чикләнми. Биредә татарның затлы-зыялы уллары Кәримиләр, Шәрәфләр, Рәмиевләр, Хөсәеновлар нәселенә кагылышлы бай материал белән дә танышырга мөмкин. Экспозицияләрдә шул чорның мәгърифәтчеләре Гыйльман Кәрими, Шиһабетдин Мәрҗани, Исмәгыйль Гаспралы кебек шәхесләргә кагылышлы китаплар, кульязмалар да урын алган.

Ел саен диярлек «Татнефть»АҖ карамагындагы «Рухият» фонды, музей белгечләренең ярдәмен һәм киңәшен истә тотып, Р.Фәхреддиннең китапларын бастырып чыгара, туган җирендә фәнни-гамәли конференцияләр оештыра.

Р.Фәхреддин музеен булдыруга Самдун Җамалетдин улы Фәрхетдинов, аның ярдәмчесе Рифкать Ширияздан улы Шаһиев зур өлеш кертә. 1994-2001 елларда директор булып Гөлүсә Вәлиҗан кызы Хөснуллина эшли, ә инде 2001 елдан музейны әдипнең бай мирасын өйрәнүгә һәм пропагандалауга саллы өлеш керткән яшь галимә Диләрә Габделкави кызы Гыймранова җитәкли.

Сәхифәне **Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН** *алып бара.*

«ХӘЗИНӘ» КОНКУРСЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ

«Казан утлары» журналы, әдәби барышны халыкка җиткерүче төп басма булу белән берәттән, сүз сәнгатен үстерү бурычын үзалдына максат итеп куя. Шуңа да журнал һәрдаим конкурслар оештыра. 2018 ел Татарстанда нефть чыга башлауга 75 ел тулу вакыйгасы белән дә истәлекле. Бу уңайдан «ТАТМЕДИА» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте филиалы «Казан утлары» журналы редакциясе, «ТАТНЕФТЬ» акционерлык җәмгыяте белән берлектә әдәби конкурс игълан итте, һәм менә ел азагында нәтиҗәләр билгеле булып, җиңүчеләр бүләкләнде. Әлеге әдәби конкурс нефть сәнәгате тарихы һәм хезмәтчәннәре турында иң яхшы повесть, хикәя һәм шигырьне билгеләде. «Хәзинә» конкурсына Төркия, Чувашстан, Башкортстан, Пермьнән һәм башка төбәкләрдән 11 повесть, 30дан артык хикәя, мәктәп укучыларыннан 40тан артык хикәя һәм шигырь килде.

25 декабрь көнне Казанда җиңүчеләр бүләкләнде. Аларны Татарстан Республикасының «ТАТМЕДИА» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов, Татарстанның халык шагыйре, ТР Дәүләт Советының мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, «ТАТНЕФТЬ» акционерлык җәмгыятенең «Рухият» программасы мөхәррире Рамил Миңнуллин, ТР Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры киңәшчесе, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, шагыйрь, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Газинур Морат, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәсьәләләр идарәсе җитәкчесе Лилия Әхмәтҗанова һ.б.лар котлады. Чарада күренекле әдипләребез, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев, галимнәр Мөдәррис Вәлиев, Искәндәр Гыйләҗев, Дания Заһидуллина, Ким Миңнуллин, шагыйрь, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире Ленар Шәех һ.б. кунаклар катнашты.

«Хикәя»:

I урын – Зәбир Гыймаев (Түбән Кама).

II урын – Рәмзия Габделхакова (Әлмәт).

III урын – Альберт Хәсәнов (Әлмәт).

Кызыксындыру бүләге – Ирек Бәдретдинов (Азнакай), Гәрәй Рәхим (Казан), Рәфкать Шаһиев (Әлмәт), Гөлфия Солтанова (Лаеш).

«Повесть»:

II урын – Айзирәк Гәрәева-Акчура (Төркия).

III урын – Тәлгат Галиуллин (Казан).

III урын – Рәмис Латыйпов (Казан).

Кызыксындыру бүләге – Фәнзәлия Бәдертдинова (Башкортстан), Марат Кәбиров (Казан), Әхтәм Зарипов (Казан).

МӘКТӘП УКУЧЫЛАРЫ АРАСЫНДА

«Поэзия»:

I урын – Ландыш Габдрахманова (Әтнә районы Күңгәр авылы).

II урын – Гөлгенә Шәкүрова (Чувашстан, Комсомол районы Тукай авылы).

III урын – Камилә Мостафина (Арча).

Кызыксындыру бүләге – Марат Ихсанов (Бөгелмә), Исламия Сафина (Питрәч районы Шәле авылы), Назлыгөл Сабирова (Нурлат), Рияз Шәфигуллин (Апас районы Бакырчы авылы).

«Хикәя»:

I урын – Алинә Хәбибуллина (Актаныш).

II урын – Әмир Гыйбадуллин (Яшел Үзән).

III урын – Әмир Фәрхуллин (Мамадыш районы Кече Кирмән авылы).

Кызыксындыру бүләге – Әдилә Маннапова (Бөгелмә), Айзилә Мингалиева (Чувашстан, Комсомол районы Тукай авылы).

ТЕАТР ЕЛЫ

2019 ел Россиядә Театр елы дип игълан ителде. Театр елын уздыру турындагы Указны Россия Президенты Владимир Путин имзалады. Бу хакта Кремльнең рәсми порталында басылган документ текстында әйтелә.

«Театр сәнгатен алга таба үстерү максатыннан, Россия Федерациясендә 2019 елны Театр елы итеп уздырырга», – диелгән Указда.

Республикабызда Театр елын ачу тантанасында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР мәдәният министры Ирада Әюпова катнашты. Чара 2018 елның 13 декабрендә Әтнә театрында узды.

«Театрларны төзекләндерү – безнең эш, аларның эчтәлеген булдыру – сезнең эш», – диде ТР Президенты Р.Миңнеханов. Әлеге чара барышында ул В.И.Качалов исемендәге Казан дәүләт академия рус Зур драма театрының сәнгать җитәкчесе Александр Славутскийга – Почёт ордены, Буа дәүләт драма театры сәнгать җитәкчесе-директоры Раил Садриевка «Татарстанның халык артисты» исемен бирү турында таныклык тапшырды.

Тантананың икенче өлеше Әтнә театры тарихына багышланды.

ПРЕЗИДЕНТ ХОЗУРЫНДА

2018 елның 27 декабрендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов республика һәм федераль массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән очрашты. Чара Хөкүмәт йортында узды.

«Сез Татарстанда гамәлгә ашырыла торган проектлар турында мәгълүмат бирәсез, гражданнарга төбәкне киләчәктә үстерү планнарын җиткерәсез. Теге яисә бу мәсьәлә матбугатта җитәрлек дәрәҗәдә чагылдырылмаса, җәмгыятьтә аларга карата төрле мөнәсәбәт туар иде. Шуңа күрә дә сезнең эшегез бик мөһим», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Әңгәмә барышында ул сорауларга җавап бирде. Журналистларны РФ Президенты указлары кысаларында проектларны гамәлгә ашыру, татар эстрадасын үстерү, татар телен популярлаштыру һ.б. темалар кызыксындырды.

ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Казанда Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш булды. Анда катнашучылар Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Чаллы, Әлмәт язучылар оешмалары җитәкчеләре Факил Сафин, Рәфкать Шаһиев докладларын тыңладылар. Аннары жанрлар буенча Лилия Гыйбадуллина (шигърият), Гөлфия Гайнуллина (проза), Әлфия Галимуллина (рус әдәбияты), Айсылу Галиева (балалар әдәбияты), Әлфәт Закиржанов (драматургия), Рамил Ханнанов (әдәби тәнкыйть) чыгыш ясадылар. Докладлар буенча фикер алышулар, чыгышлар булды. Җыелышта резолюция кабул ителде. ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлегенең әдәби премияләре лауреатлары бүләкләнде: шагыйрь Рәниф Шәрипов – Гаяз Исхакый; язучы, шагыйрә Фирүзә Җамалетдинова – Фатих Хөсни; шагыйрь Рифат Җамал – Һади Такташ; язучы, шагыйрә, галимә Рифә Рахман Җамал Вәлиди исемендәге премиягә лаек булды.

ГАМИЛ АФЗАЛ ПРЕМИЯСЕ ТАПШЫРЫЛДЫ

Актаныш районы үзенең якташы, күренекле шагыйрь Гамил Афзал исемендәге әдәби премия булдырган иде. Аңа ел саен юмор һәм сатира өлкәсендә иң үткен дип табылган әсәр авторы лаек була. Аның беренче иясе Туфан Миңнуллин иде. Төрле елларда бүләккә Фәнзаман Баттал, Марат Әмирханов, Әмиржан Моталлапов, Камил Кәримов, Ләбиб Лерон, Данил Салиховлар ия булды. Быел әлеге премия язучы һәм журналист Дамир Гыйсметдиновка тапшырылды.

ГАКЫЙЛЬ СӘГЫЙРЕВ УКУЛАРЫ

Ульяновск шәһәренең Губернатор сараенда шагыйрь, рәссам, легендар шәхес, Халыкара «Филантроп» оешмасы бүләге иясе Гакыйль Сәгыйрев укулары узды. Анда ТР Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов чыгыш ясады.

УТЫРЫШ

Матур традиция буларак, ел азагында, «Казан утлары» журналының идарә утырышы узды. Чарада ТР Дәүләт Советының мәдәният,

фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, ТР Фәннәр академиясенең вице-президенты, академик Дания Заһидуллина, ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин, ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры Искәндәр Гыйләҗев, ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, әдипләребез Равил Фәйзуллин, Тәлгат Галиуллин, Рәдиф Гаташ, Зиннур Мансуров, Рәфикъ Юныс, Газинур Морат, Мөдәррис Вәлиев һәм Алмаз Хәмзин чыгыш ясады. Утырышны баш мөхәррир Рөстәм Галиуллин алып барды.

ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Пекин университетында «Дөнья мәдәни контекстында Ч.Айтматов» дигән темага Халыкара конференция булып узды. Анда Кытайның һәм чит илләрнең күп кенә галимнәре, мәгариф һәм мәдәният әһелләре катнашты. Чараның пленар утырышында, Россия Федерациясенең бердәнбер вәкиле сыйфатында, профессор Хатыйп Миңнегулов чыгыш ясады.

***

Әдипнең юбилее уңаеннан, Татарстан Фәннәр академиясендә халыкара фәнни-гамәли конференция уздырылды.

Бәйрәмнең йомгаклау өлеше буларак, Кукмарада язучының әнисе Нәгыймә һәм аның улы Чыңгызга һәйкәл ачылды. Чарада галимнәребез Фоат Галимуллин, Зөфәр Рәмиев, Марсель Ибраһимов, Анна Софобаева һәм Роберт Мансуровлар катнашты.

ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Уфа Башкорт Дәүләт опера һәм балет театрында «Йөрәк сүзе» шигъри проектының финалы узды. Әлеге проектта шагыйрьләр, актёрлар, музыкантлар һәм журналистлар, поэзия яратучылар шигъри осталыкта көч сынашты.

Башкорт кардәшләрнең шигырь бәйрәмендә Татарстаннан язучылар һәм шагыйрьләр Фәйрүзә Мөслимова, Эльмира Шәрифуллина, Факил Сафин, Рәмис Аймәт, Йолдыз Шәрапова, Айгөл Әхмәтгалиева, Әлфия Ситдыйкова, Гөлнур Корбанова, Рифат Җамал, Роберт Сәлахиев катнашты.

ОЧРАШУ

Түбән Каманың Габдулла Тукай исемендәге үзәк китапханәсендә Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин белән очрашу узды. «Күңеле тулы моң булгач...» дип аталган кичәгә ТР Язучылар берлеге рәисе, драматург Данил Салихов һәм Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим, район җитәкчеләре, укытучылар, китапханәчеләр, журналистлар, укучылар килгән иде.

БӨТЕНРОССИЯ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Мәскәүдәге Россия Фәннәр академиясенең Космик тикшеренүләр институтында «Югары энергияләр астрофизикасы бүген һәм иртәгә – 2018» дигән Бөтенроссия конференциясе узды. Анда академик Рәшит Сүнәев җитәкчелегендә Россия-Алмания «Спектр-Рентген-Гамма» орбиталь рентгенобсерваториясен 2019 елның апрелендә космоска җибәрергә әзерлек турында сүз барды. Казаннан килгән Татарстан Фәннәр академиясе һәм КФУ галимнәре Татарстанның Төркиядәге РТТ-150 телескобы ярдәмендә «Спектр-Рентген-Гамма» табачак яңа рентген чыганакларын (нейтрон йолдызларны, кара материяне, галактикалар тупланмаларын, квазарларны) өйрәнү хакында сөйләделәр.

ТӨРКИЯ ЖУРНАЛЫНДА – ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

Төркиянең «Мотив» фәнни журналының декабрь санында татар халык авыз иҗатына кагылышлы хезмәтләр һәм шул юнәлештә эшләгән галимнәр турында фәнни мәкалә дөнья күрде. Аның авторы – төрек-татар дөньясында танылган галим, Эгей университеты төрек теле һәм әдәбияты бүлеге профессоры, татар кияве Мостафа Өнәр. Ул халык авыз иҗатын беренче булып Каюм Насыйри өйрәнә башлавын әйткән. «Кырык бакча», «Ләһҗә-и татари» кебек хезмәтләрен анализлап, Каюм Насыйрины татар халкының бөек мәгърифәтчесе дип бәяләгән. К.Насыйриның халык авыз иҗатын, фольклорны системалы өйрәнергә кирәклеген искәрткән беренче татар галиме булуын ассызыклаган, Габдулла Тукайның да халык җырларын, әкиятләрен җыеп баруын, «Халык әдәбияты» дигән темага чыгыш ясавын һәм китап бастыруын бәян иткән, шагыйрьнең иҗатыннан үрнәкләр китереп, кайбер шигырь һәм әкиятләрен халык авыз иҗатыннан илһамланып язганлыгын җиткергән.

2018 елның 2 декабрендә 62 нче яшендә озакка сузылган каты авырудан соң шагыйрь, Г.Тукай исемендәге Дәүләт, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты **Зәкуанов Рөстәм Газизҗан улы** (Рөстәм Зәкуан) вафат булды.

В ЭТОМ НОМЕРЕ:

Слово главного редактора Р.ГАЛИУЛЛИНА.
«Проза и поэзия»: роман Р.КУРБАНОВА «Родина», повесть Ч.АЙТМАТОВА «Белое облако Чингизхана», рассказ А.ХАЛИМА «В темноте тёмной ночи»; поэма А.ГАФФАРА «Мы – Белый барс», стихи Ф.САФИНА, Б.ИБРАГИМОВА, Ф.КАРИМА.
«Новые имена»: стихи Г.АХМАДУЛЛИНОЙ-АРХИПОВОЙ.
Литературный конкурс «Достояние»: документальный рассказ Г.ЮЛЫШЕВОЙ «Счастье», рассказ З.ГИМАЕВА «После землетрясения».
«Литературное наследие»: Р.ШИГАБУТДИНОВ. «Вместо предисловия». Х.ТАКТАШ. «Плачет скрипка». Д.ЗАГИДУЛЛИНА. Взгляд на произведение.
«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.
«Татарстан. История. Личности»: очерк Н.ХАСАНОВА «Малайка».
«Юбилеи»: Р.СВЕРИГИН. «Освобождение от оков» (70 лет А.ГАФФАРУ). Л.МУХАМЕТЗЯНОВА. «Ощущая дыхание времени…» (60 лет К.МИННУЛЛИНУ).
«Поздравляем»: 70 лет Д.ГИСМУТДИНУ.
«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.РАХМАН.
«Наш календарь»: 130 лет со дня рождения Г.КАМАЛА.
«Сенной базар»: юморески Ш.ГАНИЕВА. Ф.ЗАРИФ. «Зарифизмы».
«Белый парус»: Л.ГАТАУЛЛИНА. «Маленькая Лилия».
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
«Наши музеи»: Л.ГУБАЙДУЛЛИН. Мемориальный музей Ризаэддина Фахреддина.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: здание мемориального музея Ризаэддина Фахреддина. Фото Д.Гимрановой; поэт Булат Ибрагим.

IN THIS ISSUE:

Word of the chief editor R.GALIULLIN.
«Prose and poetry»: novel by R.KURBANOV «Homeland», novel by CH.AYTMATOV «White cloud of Genghis Khan», story by A.HALIM «In the dark dark night», poem by A.GAFFAR «We are White bars», poems by F.SAFIN, B.IBRAGIMOV, F.KARIM.
«New names»: poems by G.AKHMADULLINA-ARKHIPOVA.
Literary contest «Treasure»: documentary story by G.YULYSHEVA «Happiness», story by Z.GIMAEVA «After the earthquake».
«Literary heritage»: R.SHIGABUTDINOV. «Instead of preface». H.TAKTASH. «Crying violin». D.ZAGIDULLINA. Perspective on the work.
«Actual criticism»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.
«Tatarstan. History. Person»: essay by N.KHASANOVA «Malayka».
«Anniversaries»: R.SVERIGIN. «Freeing from the shackles» (70 years old to A.Gaffar). L.MUKHAMETZYANOV «Feeling the breath of time…» (60 years old to K.MINNULLIN).
«Congratulations»: 70 years old to D.GISMUTDIN.
«Tukay and Tatar literature»: section is conducted by R.RAHMAN.
«Our calendar»: 130th anniversary of G.KAMAL.
«Hay market»: humoresques by Sh.GANIEV. F.ZARIF. «Zarifisms».
«White sail»: L.GATAULLINA. «Little Lily».
«Pages of humor»: secrion is conducted by M.GALIEV.
«Our museums»: L.GUBAIDULLIN. Memorial museum of Rizaeddin Fakhreddin.
From the photo archive of the magazine.
Diary of social and cultural life.
On our covers: building of the memorial Museum of Rizaeddin Fakhreddin. Photo by D.Gimranova; poet Bulat Ibrahim.

Тышлыктагы сурәтләр

Тышлыкның беренче битендә: Ризаэддин Фәхреддин музее бинасы.
Диләрә Гыймранова фотосы.

Тышлыкның дүртенче битендә: шагыйрь Булат Ибраһим.